# ИСТӘ КАЛГАННАР

## Сәяхәтнамә

Издательский дом Маковского,
Казань, 2016

УДК 070.431.5:94(5=512.145)
070.431.5:821.512.145
ББК 76.005.2:83.3(2=632.3)-8Тукай
76.005.2:63.3(5=632.3)
И83

Тукай эзләре буйлап сәяхәтне оештыруда һәм, ниһаять, биш елдан соң әлеге китапны чыгаруда ярдәм иткән фикердәшләремә олы рәхмәтемне белдерәм.

**«Тукай фонды» президенты Риман Гыйлемханов**

И83 **Истә калганнар.** Сәяхәтнамә. – Казань: Издательский дом Маковского, 2016. – 368 с., ил.

ISBN 978-5-904612-41-2

2010 елда Татарстаннан 4 журналист Урта Азия һәм Кытайга сәфәр кылдылар: төрки халыклар күңеленнән Тукайны эзләделәр. Бу китап шул сәфәрдә алган тәэсирләрдән чыгып язылды.

УДК 070.431.5:94(5=512.145)
070.431.5:821.512.145
ББК 76.005.2:83.3(2=632.3)-8Тукай
76.005.2:63.3(5=632.3)

© Мөхәррир: Рөстәм Зәкуан, «Таттелеком» милли элемтә компаниясенең матбугат идарәсе җитәкчесе

© Авторлар: Риман Гыйлемханов, Гөлназ Галимҗанова, Рәмилә Газизуллина, Альбина Газизуллина

© Издательский дом Маковского, 2016, оформление

2010 нчы елның августында «Тукай фонды» озын-озак сәфәргә чыкты. 46 көн эчендә дүрт журналист – Риман Гыйлемханов, Гөлназ Галимҗанова, Рәмилә Газизуллина һәм Альбина Газизуллина җиңел машинада 20 мең чакрым ара узды. Казакъстан һәм Кытайда яшәүче татарлар һәм башка төрки халыклар хәтереннән Тукайны эзләде…

*Дөнья буйлап аваз салып барам –*
*мин Тукайны эзлим телләрдән;*
*яшәлмичә калган гомерләрдән,*
*тау-тау китап янган көлләрдән…*

*Ут актарам – зобаныйлар оча!..*
*Бүгенгегә күчә хәтерләр.*
*Эзләмәсәк бүген Тукайны без,*
*Туар чорлар нәрсә әйтерләр?*

*Роберт Әхмәтҗан*



**«И күк! Җанымны ал, ләкин, зинһар, шөһрәтемне алма;**
**Минемчә, онытылган, ташланган булу – үлүдән яманрак».**

**Г. Тукай (1886-1913)**

*«Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең! (язың)*
*Качан китәр кичең, килер нәһарең? (көндезең)*
*Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,*
*Кыямәт көнендә мин үлеп терелгәч?»*
*Г. Тукай, «Качан соң…», 1907 ел*

# Сүз башы һәм юл башы

2009 нчы елда оешкан «Тукай фонды» олы юлга чыкты. Заманында Хәсән Туфан: «Тукай – диңгез кебек тирән, киң һәм катлаулы шагыйрь ул. Безнең аны тулысынча белеп җиткергәнебез юк әле», – дигән иде. Фондның «Олы юлы»н әнә шул бөегебезнең иҗади мирасын саклау һәм үстерү, тормышын-язмышын кат-кат өйрәнү өчен мәңгелек сәфәргә чыгу белән чагыштырасым килә. Дөрес, бернәрсә дә мәңгелек түгел диләр, әмма хәтер, халык хәтере беркайчан да юкка чыга алмый. Хәтта җир йөзеннән юкка чыккан халыклар, милләтләр дә кешелек хәтереннән юылмый. Тик менә хәтерне саклый да белергә кирәк әле.

Тукай чоры бездән һаман да ераклаша бара. Мәшһүр шагыйребезгә битарафлык күрсәтә башласак, хәтер дигәннәребез таралып китмәсме, Тукаебыз белән бергә үзебезнең дә нинди өммәттән икәнлегебезне онытмабызмы? Фондны оештырырга шуның ише уйлар этәрде һәм без яңадан хәтерне барлый башладык. Тукай һәм татарныңербөтен икәненә, алай гына да түгел, Тукайның бөтен төрки дөньяны берләштерүенә тагын бер кат инандык.

Укучым, сиңа «Истә калганнар» исемле китап тәкъдим итәбез. Аны язу ансат булмады. 2010 нчы елның августында олы эшнең олы сәфәренә – «Тукай-тур» фәнни-иҗади экспедициясенә чыктык. Шагыйрьнең 12 елга сузылган Җаек чорын өйрәнеп, «Тукай фәне»нә күпмедер яңалык өсти алдык шикелле. Аннан соң Казакъстанны иңгә-буйга йөреп, Кытайдагы кардәшләребез янында 10 көн яшәп, Азия киңлекләрендә Тукай идеясенең ничек, ни хәлдә булуын өйрәндек. Үзебезне борчыган күп кенә сорауларга җавап таптык кебек.

Китап сәяхәтнамә рәвешендә язылды. Укучы без булган төбәкләрдәге җирле халыкның да, шул җөмләдән, милләттәшләребезнең дә ничек яшәве, йола-тәртипләре, көнкүреше хакында да шактый кызыклы, гыйбрәтле мәгълүмат алыр. (Кем белгән, бәлки, киләчәктә без йөргән юллардан йөрергә теләүче яңа фидакарьләр табылыр. Ә юл йөргән кешегә нәрсәнең нәрсә икәнен белеп тору ярый ул).

Укучы бу китаптан зур-зур фәнни ачышлар өмет итмәсен. Аның «Истә калганнар» дип аталуы да юкка гына түгел. Беренчедән, әлеге исем Тукайның автобиографик әсәре исеме белән аваздаш булса, икенчедән, без сәфәр вакытында иң истә калган, күңелне кузгаткан вакыйгаларны, кардәшләребез белән кызыклы – гыйбрәтле очрашуларны тасвирларга тырыштык. Өченчедән, бүгенге буынның Тукайны ни рәвешле истә тотуын, ягъни халкыбызның ни дәрәҗәдә хәтерле булуын нечкәләдек.

Казанга кайткач бер академик: «Әллә кайларда вакыт уздырып йөрисең. Татарстанның үзендә милли проблемалар беткәнмени?» – диде.

– Нинди проблемалар? – дип башны бераз җүләргә салдым.

– Татар мәктәпләре ябыла. Милли мәгариф бетә…

– Кем гаепле соң?

– Үзебез, – диде бу.

– Соңгы сүзегез дөрес, – дидем дә, академик кешегә акыл өйрәтүне кирәк тапмадым. Бәлки, бу китапны укыгач, зыялыбызның «Тукай фонды»на, сәфәребезгә карата фикере үзгәрер. Тукай кебек бөек шагыйрьләр халыкларны, халыкларны гына түгел, континентларны берләштерәләр. Без чит мәмләкәтләргә үзебезне Тукайның илчеләре итеп тоеп бардык, һәм, иң куанычлысы, безне шулай кабул иттеләр дә.

Мәктәпләр ачу – Тукай фонды эше түгел. Һәркем үз урынында үз бурычын җиренә җиткереп үтәсә, «бетәбез!». дип кара тавыш чыгарып бәргәләнмәс идек. «Үз урынында үз бурычы» дигәндә, мин хакимияттә эшләүчеләрне, милли мәдәнияткә, сәнгатькә, мәгарифкә хезмәт итүчеләрне, гади татарымны, татар гаиләләрен күз алдында тотам. «Бетәбез» дип ыңгырашып кына эш бармый. Тукай сүзләре белән әйтсәк:

Җиһанда үлмәс һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.
Көрәш угърында (юлында – *Р.Г.*) ар, тал, тирлә, имгән:
Омид итмә булышлыкка ләимнән (саран, түбән җанлы кеше – *Р.Г.*)

Кызганыч, әмма хак: Татарстаннан читтә яшәүче кардәшләребез безгә горуррак кебек, «татар өчен җан атарга» әзер чын татар кебек тоелды.

Хәер, китапны укыгач, үзегез нәтиҗә ясарсыз. Ә хәзер, әйдәгез, сәфәргә!

**Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ**

**Сәяхәт – хыялдан башлана…**

*Хыял – яшәү өчен ләззәт.*
*Сәяхәт – ул татлы төш: йөргән юллар,*
*яңа танышлар сагындырып төшләргә керә.*
*Һәр сәяхәт – ул бүген. Башка беркайчан да кабатланмас бүген!..*

# Юл хәстәрләре

…Кичтән сумка-чемодан тутырганда: «Безне алданиләр көтә?» – дигән уй баштан чыкмады. Кайвакыт, бер көнлек командировкага барыр алдыннан төн буе йокламый чыгасың. Ә монда? Бөек стенасы белән кешелекне шаккаттырган Кытай илен дә күрәсе бар. Юк, анысы, гомумән, төш кебек кенә. Бубилар килеп татар мәктәбе ачкан Кытайстан! Карале, Бубилар Кытайга баруны хәл иткәч, ничек әзерләнделәр икән?..

Сәфәр алды төне хыял, күңел күтәренкелеге белән үтте. Үткән баруыбызда күргән карлы таулар, шарлавыклар һаман үзенә тартты. Иртәнге сәгать алтыда шеф, ягъни Риман Гыйлемханов яшәгән йорт янына җыелырга сүз куешкан идек. Уяну белән сумкаларны барлап чыктык: телефон, фотоаппарат, блокнот, ручка… Журналистка тагын ни кирәк?! Туктале, болары нәрсә?.. Нигә безгә йонлач кофталар, эссе якка барабыз бит! Сумкалардан җылы киемнәрне берәм-берәм алып, кире шкафларга чөйдек. Әмма йөк җиңеләймәде. Китап-диск, плакат, милли курчаклар, Балык Бистәсе чабаталары, Кукмара итекләре, кап-кап чәк-чәк – монысы инде вак-төяк күчтәнәч. Әле Риман абый гаражында 9 тартма китап-фәлән ише бүләгебез бар. Өч кызга йөк мени бу?! Без бит татарлар янына барабыз, күчтәнәчсез ничек юлга чыгасың?!

Килешкән йорт янына килеп тә бастык. Берзаман ак «Фиат» микроавтобусы пәйда булды. «Кырлай мемориаль комплексы» директоры Тәлгать Гомәров шоферы Илдар Хәбибуллин белән Арчадан ук килеп җиткән. Тукайның Җаек чорын тәфсилләбрәк өйрәнү өчен үзебез белән барырга күндергән ике галим белән Риман абый да шушында. Төяндек тә, «Бисмилла»ны укып, юлга кузгалдык. Риман әфәнде генә калды. Чөнки экспедиция өчен акча җитми иде. «Аллаһ бирсә, артыгыздан куып җитәрмен. Аңарчы җай чыгар әле. Аллаһ бар ул», – дип калды ул артыбыздан. Болай китү – моңсу. Нишлисең, башка юл юк: йә бүген китәбез, йә калабыз. Казанны чыгу белән әле ике-өч көн элек кенә «кайнаган» вакыйгалар кылт итеп искә төште…

## Сәяхәт... акчадан да башлана

«Тукай фонды» экспедициягә әзерләнә дигәч: «Кәеф-сафа корырга, фонд акчасына дөнья күрергә чыгалар икән», яки «Ул Тукайны әле өйрәнеп туймаганнармы? Әллә башка эшләре беткәнме?», – кебек мәгънәсез сүзләр дә ишетелә башлаган иде. Әмма хәер-фатыйхасын биреп, хәерле юл теләүчеләр күбрәк булды. Экспедицияне хуплаган, оештыруда ярдәм күрсәткән һәркемгә чиксез рәхмәтле без! Юк, күңел ачарга да, кызык эзләп тә чыкмадык ерак юлга. Ял итү өчен кеше үзалдына милли миссия куеп, Казакъстан белән Кытайга экспедициягә түгел, ә, диңгез, табигать кочагына барадыр, бәлки.

«Тукай-тур» экспедиция проекты кәгазьгә төшкәч, аны ул вакыттагы Татарстан мәдәният министры Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева кулына тоттырдык. Әмма ул вәгъдә иткән сумма сәфәргә җитми иде. Хөкүмәттә дә бит акча санаулы. Инде калганын үзебез табарбыз дидек.

Шулай итеп, озын сәфәр алдыннан өчәү: Риман, Гөлназ, Рәмилә – акча юнәтергә Татарстан районнарына чыгып киттек. Хәтерлисезме 2010 нчы елның июль-август көннәрен? Соңгы елларның иң эссе җәе иде ул. Баш миләрен кайнатып кояш кыздыра, корылык, басуда иген үсми. Район Башлыклары аптырашта: малга кышын ни ашатасы да, басудан нинди ашлык җыясы? Ләкин, чүп өстенә чүмәлә дип, безне кире бормадылар. Алай гына да түгел, «глава»лар: «Бу эсседә нинди йомыш ул, ничек курыкмадыгыз кояштан? Тукай? Сәбәбегез җитди икән...» (Кама Тамагы). «...Экспедициягә күпме җитми? Ник әйтергә оялып утырасыз? Тукайны читтә калдырган юк, бик кызыклы экспедициягә охшаган. Фәлән сум бирсәк, шул җитәр микән?». (Кукмара). «Кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез. Үзебезнең Галия Кайбицкая яшәгән җирләргә җыенасыз...» (Кайбыч) диделәр. Атналар буе кояш астында әлсерәп акча сорап йөрүләр бу.

Ул арада бүләк хәстәрләдек. Балык Бистәсеннән чабатачы Нәгыймулла абыйдан чабаталар, Казан кызы Диләрә Вәлиуллинадан милли курчаклар сатып алдык. Кукмара киез-итек фабрикасы директоры Шамил Әхмәтшин Татарстан гербы, милли бизәкләр, «Кукмара», «Казан» дигән язулар төшкән махсус ак итекләр бүләк итте. Җырчылар Зөфәр Билалов белән Зәйнәп Фәрхетдинова дискларын бирде. Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Дәүләт советы депутаты, шагыйрь Разил Вәлиев, КФУ китапханәсе директоры Җәүдәт Миңнуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, «Аксу» студиясе, «Ялкын», «Сөембикә» «Ватаным Татарстан», «Мәдәни Җомга», «Татарстан яшьләре» күркәм гадәт буенча газета-журналлар, китап-диск белән ярдәм

итте. Фондыбыз дизайнеры – Рушан Гыймалетдинов татарларга бүләккә 2011 нче ел өчен «Тукай фонды» календаре эшләде.

Сәфәргә 11 нче августта кузгалырга тиеш идек, әмма фондка акчалар кереп җитмәү сәбәпле юлны тагын бер атнага кичектердек. Инде нишләргә? Милләттәшләрне бүтән көттереп булмас дип, ниһаять, 17 нче августта сәфәр чыктык. Риман Гыйлемханов кына Казанда калды…

## Китмибез!

Тукай эзләренә илтүче сукмаклардан барабыз. Автобус элдертә генә! Татарстанда юллар шома, үзебезнең табигать. Сәяхәт алды хисе дә кушылыпмы, кояш җылысы йөрәкләргә кадәр үтә. Казаннан Җаекка юл Самара аша. Казан белән Җаек арасы – 750 чакрым.

Ерак юл һәрвакыт күңелле. Телләр сүтелеп, юл уңаеннан таныша киттек. Безнең белән сәфәргә чыккан галимнәребез – Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, сәнгать институты хезмәткәрләре Рәшит Кадыйров белән Зөфәр Мөхәммәтшин. Алар – «Тукай энциклопедиясе» иҗат коллективы әгъзалары, фән кандидатлары, «тукайчы»лар.

Юлга чыкканда дустың үзеңнән яхшы булсын диләр, бит. Зөфәр әфәнде шаяртырга яратуы белән аерылып тора икән. Мәзәкләр сөйли, эч катканчы көлдерә. Рәшит Кадыйров исә, сине ахырга хәтле тыңлап бетерә дә, аннан соң үз фикерен чәпәп куя. Аның белән рәхәтләнеп теләсә кайсы темага сөйләшеп була. Гомумән, галимнәребез гаҗәеп зирәк, юл кыенлыкларыннан курыкмаучы кешеләр булып чыкты. Аларның сәяхәт соңында нинди маҗараларга тап булуларын белгәч шаккатырсыз әле…

Самара юлы өстендәге бер кафеда тамак ялгадык. Тагын бераз барсак, чик таможнясы. Җаектагы Тукай музее директоры Марат Баһаутдиновка телефоннан хәбәр салдык. Ул: «Сез чикне чыккач, очрашырбыз», – дигән иде. «Сезне ничек таныйрбыз, кая туктыйк?», – кебек сорауларга: «Мин сезне үзем танырмын, борчылмагыз. Ә мин татар түбәтәеннән булырмын», – диде.

Хуш, менә чиккә дә килеп җиттек! Аркылы тимер шлагбаум куйган капка. Янында бер яшь егет. Без, автобустан төшеп, йомышыбызны аңлаттык. Ул исә автобуста гына утырырга боерды. Ике машинаны үткәргәч, ниһаять, яныбызга килде. Транспорт документын, паспортларны карады. Көлә-көлә шлагбаумны күтәрде дә: «Вас не пропустят. Но попытайтесь уж», – дип куйды. Ничек «не пропустят»? Шофер Илдар абыйны кызыл кирпеч бинага чакырттылар. Бу транспорт документларын энәсеннән җебенә кадәр тикшерү урыны икән. Ул ара-

да таможня ишегалды «КАМАЗ», автобус, йөк машиналары белән шыплап тулды. Шлагбаумда зур чират. Кемнедер Казакъстанга кертмиләр. Әнә бер «КАМАЗ» хуҗасы аты-юлы белән сүгенеп, шлагбаумнан чыкмаска киреләнә. Әмма чиктә сатулашып торып булмый. Кертмиләр дигәч, кертмиләр инде!

Безнең Илдар абыйның йөзенә дә канәгатьсезлек галәмәтләре чыккан иде. Ул зур-зур атлап яныбызга килеп басты да: «Кертмиләр. Документлар җитми, Татарстан транспорт инспекциясеннән рөхсәт кирәк булган», – диде. Монысы – икенче сәбәп. Беренчесе – тагын да шаккатмалы! 17 кешелек микроавтобуста без 7 генә кеше икән. Калган урыннар террорчылар өчен икән, янәсе. Хәтта инспекция кәгазен хәл итсәк тә, буш 10 урын өчен безне кертмәячәкләр иде.

Казакъстанга Самара аша барганда, ике таможня үтәсе: Русия һәм Казакъстан. Чикнең һәрберендә өч урында тикшереп, өч мөһер сугалар. Мөһер сугу өчен «Миграция картасы» тоттыралар. Башта аны тутырасы: исем, фамилия, җенес, чит илгә керү һәм чыгу көннәре, сәфәр максаты язасы. Миграция картасы казакъ телендә. Казакъ телен чамалыйбыз – бланк тутыру авыр булмады.

Тамашаны күзәтеп торган Тәлгать Гомәров «погран»нар янына барып, изге эш белән йөрүне аңлатып маташты. Әмма, файдасыз! Безне барыбер кертмиләр… Аптырагач, Риман абыйга шалтыраттык. Ул да ни әйтергә белмәде. Инде әзерләнеп чыкканбыз икән, кире борылу юк, Тукайчалап «китмибез», диештек!..

Ике ел элек Казакъстанга поездда барган идек. Чик чыкканда, Аллаһка шөкер, бер җафа да күрмәдек. Туганнарыбыз: «Казакъстан чигендә яланаяк калдырганчы чишендерәләр», – дип куркытканнар иде. Дөрес, «Петухово» чигендә күп пассажирны тентеделәр. Ләкин безнең бер сумканы да ачып карамаганнар иде ул чакта. Туганнар сөйләгән «чишендерү» чиге, күрәсең, шушы «Черниговка» булган.

«Китмибез», – диешеп, таможня ишегалдында инде ярты сәгатьләп басып торабыз шулай. Чик хезмәткәрләренең түземлеге бетте, ахрысы, берсе килеп: «Освободите двор!», – дип кычкырды. Шлагбаумны чыкканда документ тикшерүче теге егет тагын килеп: «Я же вам сказал, что не впустят…», – дип авыз ерды. Бу вакытта төш турысы узып, сәгать икеләр иде.

Юл чатына чыгып, Марат Баһаутдиновка шалтыратабыз:

– Безне кертмиләр. Документ җитми… Террорчы сез диләр…

– Ай Аллам, ай Аллам! Нишләргә?.. Сез хәзер кайда?

– Юл буенда. Аптырап торабыз. Үзебез генә чыгар идек, автобусыбызны нишләтергә?

– Шунда торыгыз. Хәзер улым Рәшидне җибәрәм. Ә автобусны таможня стоянкасында калдырып була. Чикне җәяү чыгарсыз.

Сәгатькә якын вакыт үткәч, Рәшид Баһаутдинов килеп җитте. «Сыйганнар миңа утыра. Калганнар юлдаш машинада чыга. Мондый хәлләрнең булганы бар. Таможнядан үткәрмәгән машиналарны чик стоянкасында калдыралар», – дип сөйләнә-сөйләнә, Рәшид автобустагы сумкаларны тиз-тиз генә үз машинасына күчерә башлады. Без – кызлар, Рәшид машинасына кереп утырдык. Ике галимебез – Рәшит белән Зөфәр әфәнде, җәһәт кенә бер юлдаш машинага сеңде. Килешү буенча, ике таможняны чыккач, алар төшеп калды. «Бисмиллаһ»ны укый-укый, шлагбаумга җиттек. Безнең бәхетсезлеккә сөенгән теге егет: «Все равно вас не впустят!», – дип, үзенчә көлә бирде. Ә безнең башка юл юк. Китмибез икән, димәк, китмибез!

Беренче пичәт сугу пунктына туктадык. Бөтенебезгә дә машинадан коеласы икән. «Погран»нар багажникны ачтылар. Күзләре шар булды:

– Что везем, куда едем? – ди берсе.

– В Уральск, в Музей Тукая. В Красную мечеть (Кайбычтан муниципаль район башлыгы урынбасары Рәмис Хәялиев: «Кызыл мәчет – пароль кебек: аны әйтсәң чиктән җиңел үткәрәләр», – дигән иде). Везем подарки нашим соотечественникам. Книги, сувениры…

– В Красную мечеть??? Значит, мусульмане! А это экстремистская литература! Не пропустим.

Паспортларны тикшерүчеләрнең берсе, безне танып: «Да это же те, которые на белом «Фиате» приехали, у них 10 свободных мест было из 17. Где ваши 4 человека?»

Без, югалып калмыйча, икесенең Казанга кайтып китүен, ике галимнең үз юллары белән чикне чыгуын аңлаттык.

Ләкин таможня хезмәткәрләре аңларга теләмәде. Шулкадәр сумка белән өч кызны калдырып китү шикле, диләр. Аннан паспортлар белән мине кызыл кирпеч бинага алып киттеләр.

– Докажите, милая девушка, что это не экстримлитература? – дип сүз башлады арадан берсе.

– Мы простые студенты-аспиранты. Едем с научной целью. У нас есть документы, что эти книги, диски и прочие вещи – подарки!

(Белеп торыгыз: Казакъстан чигенә артык энә дә алмаска кирәк! Аннан, бөтен бүләк туганнарга диясе. Югыйсә, каян һәм кемгә дип, баш миен тик кайнатачаклар. Таможняда күргәннәребезне тәфсилләп сөйләп тормыйм. Ярый әле бүләк бирүчеләрдән «накладной», «сопроводительное письмо», «акт» ише документлар алдык. Юкса, бөтен бүләкләрне шушында «кысып» калачаклар иде).

Документларны бик җентекләп өйрәнделәр. Багажникны яртылаш бушатып, чәчелмәсен өчен ябыштырылган тартмаларны ачтылар. Татар язуын берсе таныган булып, әле укып та маташты. Шунда бер мәрхәмәтлесе телгә килде:

– Да пропустите уж, не видно что-ли, нормальные девчонки. Книг не видели, да?

Бу кешегә эчтән генә рәхмәт укып, икенче пичәт сугучыга килдек. Ул да читтән күзәтеп торган. Бәйләнеп маташмады. Уңышлар теләп, өченче мөһергә җибәрде. Ә монда аерым пост эшли. Ларек кадәр генә бинаның тәрәзәсенә башны тыгып сөйләшәсе. «Фейс-контроль» бу. Паспорттагы фото белән йөзне чагыштыралар…

Ур-ра! Үткәрделәр, Русия чиген үттек! «Алда әле Казакъ чиге, аннары сөенербез», – диде Рәшид.

Машинада 3-4 чакрым баргач, Казакъстан флагы һәм гербы күренде. Фирүзә төсенә төшерелгән кояш белән бөркет. Исәнме, Казакъстан!

Тагын өч пичәт пункты үтсәк, Җаекта булабыз. Казакълар да машинаны бушатты. Шул ук сораулар: нинди китап, кая барасыз, күпмегә? Без бөтен барачак шәһәрләрне саный киттек… Бер казакъ «погран»ы итекләрне тартып чыгарды. Казакъ теле татарныкы белән охшаш булгач, сүзләр җиңел аңлашылды:

– Нәрсә бу? – диде сакчы.

– Итек, туганнарга бүләк.

– Ник күп алдыгыз?

– Аларның 6 баласы бар. Бу – бер гаилә. Икенче гаиләдә 4 бала, өченчесендә 5 бала…

– Туганнар шулкадәр күпме?

– Күп, без төрле шәһәргә бит.

– Татарлар күпме безнең Казакъстанда?

– Күп, 250 мең!

– У-у, бу бүләк кенә җитми дә икән әле. Ярый, хәерле юл сезгә, – дип, мөһерен сукты.

Икенче пичәт. Өченчесе. Казакъ шлагбаумы ачылды. Машина әкрен генә урыныннан кузгалды. Сәгать кичке 10. Экспедициянең беренче сынавын уздык. Кояш кебек елмаеп, каршыбызга Марат әфәнде килеп чыкты. Гомердә күрмәгән, ишетеп кенә белгән Җаек музее җитәкчесе дөньяда иң якын кешеләрнең берсе булып китте шул минутларда. Ул безнең чик үткәнне 9 сәгать көтеп торган! «Кызлар, әссәламегаләйкем, исәнмесез! Хуш килдегез! Тәртипме? Борчылмагыз, сез булдырдыгыз! Чикне чыкканны – калганы булыр», – дип, җылы сүзләрен яудырды ул.

Бертөрле рәхәтлек хисе кичердек ул чакта! Үзебезне зәңгәр күктәге казакъ бөркете кебек ирекле, кояшлы итеп хис иттек. Әйтерсең, төрмәдән иреккә чыкканбыз. Тик күңелдә бер шөбһә: Риман абый ничек килер? Чиктән уздырмый азапласалар, нишләргә?

* * *

Җаекка җиткәндә ай тәмам тулды. Сәгать телләре төнге уникегә якынлашты. Ә милләттәшләр шул гомер йокламыйча безне хәләл кафеда көткәннәр. Бер гаилә булып табын артына утырыштык. Сөйләшү-танышулар китте. Кардәшләребез иртәге көнгә кая, кайчан барасын минутлап язып, безгә «эш планы» да төзеп куйганнар икән. Димәк, кем әйтмешли, «иртәгә бәйрәм түгел», ял итәргә кирәк. Кафеда хушлангач, кунакханәгә киттек.

Кунак өе нәкъ шәһәр уртасында, исеме дә безгә туры килә – «Сәяхәт»! Җаектагы беренче төн – сәяхәтнең беренче көне тәмам иде. Йокларга яттык. Артта – маҗаралы көн, «погран»нар, фейс-контроль. Күңелдә – бәләкәй Апуш. Без аның икенче ватанында!

## Җаек

**«Мин – Кушлавыч кешесе. Бу бала авылымызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр идек; менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр кулында йөргүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел Җаекта аның кушуы буенча бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм».**

**Мөсафирның бу сүзләренә әтинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте: «Ярар менә, без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны 3-4 ел ашатып торыйк та, хәзер, эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән?», – кеби сүзләр илә бик нык тартыштылар.**

**Мөсафир Бәдретдин абзый: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга, мин хәзер үрәдниккә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне падсуд җибәрермен», – дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар».**

**Габдулла Тукай, «Исемдә калганнар», 1909 ел**

**Гөлназ Галимҗанова.**



# КАЗАКЪСТАН



# ИСӘНМЕ, ҖАЕК!

*«Йокысыннан Кояш ничек уяндисә,*
*Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә;*
*Исә-исә бөтен дөнья буе китә:*
*– Торыгыз! – ди, – уянырга вакыт җитә!»*
*Г. Тукай, «Ай һәм Кояш», 1909 ел*

Кичәге газаплардан соң Тукай шигырьләрен искә ала-ала йокыдан тордык.

Беренче көннән үк безне Марат Баһаутдинов үз канаты астына алды. Казакъстан буйлап сәфәр кылганнан соң, Кытайга барасыбызны ишеткәч, бөтенләй хафага төште: «Юлга ничекләр генә чыдарсыз? Казакъстан юлларын белмисезме әллә? – диде. «Чыдамаган ди, безгә ияреп 61 яшьлек Риман абый да чыга бит әле. Ул түзгәнне…» – дигән булабыз.

Шефның юклыгыннан «файдаланып», без шәһәр, татарлар белән таныша тордык. Риман абый үзе дә: «Мин килгәнче Тукай музеен өйрәнеп куйсагыз була», – дигән иде.

Европа белән Азияне кисештергән Җаек безне тарихи, мәдәниятле кала булуы белән гашыйк итте. Монда яшәүче халык үзен азияле дип тә, шул ук вакытта европалы дип тә саный. Биредәге һава торышы чагыштырмача Русиядәге белән бер тирә. Монда да: «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява», – диделәр безгә.

216,5 мең кешелек шәһәрдә 86 төрле милләт яши. Географик яктан, Казакъстанның Русиягә иң якын шәһәре ул Җаек. Төрле яклап Әстерхан, Волгоград, Саратов, Самара, Оренбург өлкәләре, Башкортстан республикасы белән чикләшә.

## Әз-мәз тарих…

Җаекка инде биш гасыр исәпләнсә дә, аның тагын да тирән тарихлы һәм үз чорында Бөтенрусия күләмендә мәдәни яктан дан тоткан кала булуы шиксез. Шәһәрне «Яицкий казаклары», ягъни Яик (Җаек) елгасы буенда яшәүче казаклар нигезләсәләр дә, аның төзелешендә нугай татарларының, башкорт һәм калмыкларның да кулы-көче күп кергән, диләр. Шуңа күрә, фәнни, яисә популяр әдәбиятны, матбугат, архив материалларын карасак та, Җаек төрле милләт вәкилләре, аеруча татарлар өчен көн күрү, рухи яктан тормыш итү өчен уңайлы


ГАБДУЛЛА
ТУКАЙ
1886-1913

җирлек булган. Биредә татарларның икътисад, сәясәт, мәдәният, мәгърифәт өлкәләрендә зур казанышларга ирешүе дә шуны раслый. Татар байларының йортлары, сәүдә рәтләре, аерым бистәләре, хәтта милләттәшләребезнең аерым матбугаты булу үзе үк Җаекның никадәр дәрәҗәдә татар шәһәре булып китүе турында сөйли. Җаек өлкәсендәге күп кенә бистәләрне Татарстаннан күчеп килгән татарлар торгызуы мәгълүм. Әмма без, сәфәрдән кайткач, аның Казанга кул сузымында гына утыручы шәһәр булуына карамастан, өйрәнелми, тикшерелми торуына аптырадык. Җаекны әле безгә дә өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Чөнки бу шәһәрдә безнең Тукаебыз, милләтебез тарихыннан күп кенә сәхифәләр ачыкланмый күмелеп ята.

Шулай итеп, милләттәшләребезне сыендырган шәһәрнең үткәне нинди булган соң? Җисеменә кадәр исеменә килсәк, Җаекның иң борынгы исеме – Кайран (Песчаный). Кайраннан – Тәкә, аңардан – Җаек килеп чыккан, диләр. Элек авылдан шәһәргә килүчеләр: «Тәкәгә барабыз», – дип сөйләгән. Җаек тирәсендәге авылларда яшәүчеләр хәзер дә ике төрле: «Тәкәгә барабыз һәм Җаекка киләбез», – дип әйтә ди. Казакълар да: «Тәкәгә барабыз», – диюне кулайрак саный икән.

Географик яктан Җаек – яшәү өчен бик уңайлы җирдә урнашкан. Һавадан төшергән фоторәсемдә аның Җаек елгасына коя торган Чаган суы култыгында утыруы аермачык күренеп тора.

Борынгы шәһәрдә Емельян Пугачев восстаниесе юл башы ала. Аның гаскәрендә мөселманнар, шул исәптән татарлар да була. Восстание бастырылгач, әби-патша Екатерина II Җаек шәһәренең исемен Уральскига алыштыра.

XIX гасырда 40 мең халыклы Җаек Русия империясенең иң эре шәһәрләре исемлегенә кертелә. XIX-XX гасырларда монда 5 эре мәдәният үзәге эшләгән, 29 уку йортында 2400 укучы белем алган. Театр, мәчет, чиркәү, бай китапханә, музейлар, архив, типографияләр булган. Җаек театры дигәннән, ул Казакъстанның иң борынгы театры да әле.

## Гугниха – Гайшә?!

Җаекның тарихы, халкы турында сүз чыккач Марат абый бер риваять сөйләде. Бик тә гыйбрәтле булып буыннан-буынга күчеп, хәзер безгә ияреп, Казанга да кайткан риваятьнең асылы мондый.

Казаклар арасында шундый гадәт яшәгән: өченче тостны Гугниха-әби хөрмәтенә күтәрә торган булганнар. Гугня – утрак тормыш башлаган казак атаманнарының берсе. Ул заманда казаклар кызларны




Элекке Уральск



әсир итеп, төрлечә җәберли торган булганнар. Менә бервакыт болар бер сылу татар кызын әсирлеккә төшерә һәм аны үзара бүлешә башлый. Сөяк атып җирәбә салсалар, сөяк татар егетенә чыга. Егетне атаманның дуслары үтерә һәм Гугня-атаман татар кызын үзенә ала. Ул кызга шулкадәр гашыйк була ки, хәтта походка китәр алдыннан аңа землянка казып, җитәрлек ризык-су калдыра торган була. Менә берзаман ризыгы беткәч, кыз толымнарын кисеп, ятмә үрә һәм елгадан балык тота башлый. Казаклар кире әйләнеп кайтканчы шулай көн күрә бу. Казаклар балык тотарга татар кызыннан өйрәнәләр дә инде. Шуңа күрә Гугниха-әбигә гомер буе рәхмәт укып, тост күтәрәләр икән. Ә Гугниха әбинең чын исеме – Гайшә була…

Әлеге риваять уйдырмага тартым булса да, андагы вакыйга нигезсез түгел дип уйлыйбыз. Бу бит татарның казакъ илендә элек-электән эзле, абруйлы булуына бер ишарә.

## Нугай бистәсе

Татарлар белән казаклар арасында тыгыз элемтә һәрвакыт булган. Беренчедән, 1897 нче елда Бөтенрусия халык санын алу нәтиҗәләре буенча, Җаекта яшәүче 18 мең татарның 6 меңе – казаклар булып исәпләнгән. Икенчедән, тарихи чыганакларда: «Татарлар, күпләре казаклар булып саналсалар да, Җаекта элек-электән аерым бистә булып яшәгәннәр. Үзләренең милли йолаларын, мәдәниятләрен, диннәрен саклауга зур әһәмият биргәннәр», – дигән сүзләр дә очрый.

Татар бистәсен җаеклылар «Татар олусы» дип тә йөрткәннәр. Ә андый «олуслар» шәһәрдә берничә тапкыр төзелгән. Иң беренчесе – шәһәрнең хәзерге лесхоз тирәсе, Куренида оешкан була. Аның турында 1769 нчы елда галим Петер-Симон Паллас та әйтеп уза. Чөнки Курени – ул шәһәрнең иң иске өлеше. Биредә өч иман йорты эшләгән: ике агач һәм таштан корылган «Войсковая» мәчете. Куренины «Большая Михайловская» урамы ике өлешкә бүлгән: көнбатышы – Татар Бистәсе, көнчыгышы – «Уральная» дип аталган. Бер ягында – чиркәүләр, икенчесендә – мәчетләр төзелгән булган.

Түбәнлектә утырганга, бистәне еш кына елга суы баса торган була. Әмма көчле янгыннан бистәнең зур өлеше юкка чыккач, XIX гасырның икенче яртысында татарлар базар буендагы калкулыкларга күченә башлый. (Бу урын хәзер Некрасов урамыннан Чаган елгасы, Казан чиркәвенә кадәр булган тирәлек.) Биредә татарлар кирпечтән мәчет төзиләр (ул Кызыл мәчет булып китә). Тукай шушы бистәгә килә дә инде. Ул елларда Җаек Казакъстанның иң эре шәһәрләреннән санала.




**Акимат монда иске йортларны җимертми. Хәтта иң тузып, какшап беткән бина да Казакъстанның архитектура һәйкәле санала**

Алматыда 9 мең кеше яшәсә, Җаекта халык саны – 6 меңгә җитә. Шуларның 4 меңе – татарлар була.

Җаек өлкә статусын алгач, Уральск һәм Әстерхан губерналары чигендә урнашкан Джангыл дигән җирлеккә Татарстаннан күпләп татарлар күченә башлый. Яңа Казанка дигән авыл, мәсәлән, шулай барлыкка килә. Татарстан татарлары нугайлар яшәгән казак станицалары һәм авылларына да килеп төпләнәләр.



Казак-татарлар балык промыселы, төрле һөнәрләр белән көн күрсә, «яңа» татарлар сәүдә итә һәм тиз арада байый. Ике мең милләттәшебезнең шәхси сәүдә эше булуы да мәгълүм. Сәүдәгәрләр үзләренең зәкәт акчаларына Җаекта өч мәдрәсә, шәһәрнең күп кенә биналарын төзи.

Татар мохитенә килеп эләккән Габдулла казакълар белән дә аралашып яшәгән. Истәлекләрдә аның казакъ далаларына чыгып йөрүе әйтелә. Әле мәдрәсәдә укыган чакта ук Җаектан сиксән чакрымдагы Дәвана дигән җиргә кымыз эчеп дәва-

ланырга барган ул. Анда 15 көн торып, күлләрдә балык тоткан, тотканын – казакъ балаларына калдырган. Тукай тормышның ачысын кечкенәдән татыганлыктан, казакъларга кулыннан килгән кадәр ярдәм дә күрсәткән. Билгеле булганча, ул вакытта казакъ балалары 6-7 яшькәчә ялангач йөргән. Дәваланырга баргач, Габдулла бер казакъ хатынына сөлгесе белән тастымалын бүләк иткән. «Зурына – күлмәк, кечкенәсенә – ыштан тегеп киерт», – дип әйткән булган…

Бүген Җаекта Тукай заманыннан ниләр саклана соң? Иң элек шәһәр үзе, дияр идек. Борынгы диварлары, бизәкле капка-йортлары, иске урамнары белән Татар Бистәсе. Икенче төрле Нугай Бистәсе ул. Җаекта шунысы гаҗәп: акимат монда иске йортларны җимертми. Хәтта иң тузып, какшап беткән бина да – Казакъстанның архитектура һәйкәле санала.

## Татар үзәге

– Монысы – Төхфәтуллиннар йорты, – диде Марат абый алсу төстәге ике катлы йортка күрсәтеп. (Мотыйгулла Төхфәтуллин, аның Тукай язмышындагы роле хакында алдарак сөйләрбез әле) – Кызыл кирпечтән эшләнгәне – Татар үзәге бинасы. Икесе дә бер ишегалдында.

Эх, боларны ник студент чакта, яисә мәктәптә укыганда килеп күрмәдек икән! Тукай, син нинди бәхетле! Үзең үлгәч тә, халык монда эзләреңне саклый. Син булган йорт дип, горурланып яши!..

Бина тышындагы баннер-тактага Тукайның рәсемен төшереп, казакъча, татарча һәм русча: «Бар уем кичен-көндезен синең хакта, милләтем» дигән шигъри юлларын язганнар.

– Әйдәгез, башта өебезгә керик, – диде Марат абый.

Гадәттә, читтәге Татар үзәкләре бер проблема белән интегә: аларның җыелу өчен үз йортлары булмый. Шуңа күрә милләттәшләр үз өйләрендә Үзәк ача. Яки үз акчаларына арендага берәр бүлмә ала. Ялынып, хөкүмәткә хатлар яза. Ә менә байлар торгызган махсус йортлар – гаҗәеп күренеш инде. Шундый гайре сирәк хәлгә без 5643 татарлы Җаек каласында юлыктык. Җирле меценат Ришат Увәли улы Хәйруллин – мондагы татарларга ике катлы Үзәк тә төзеткән, Тукай музееен да эшләшкән. Бирeдәге хезмәткәрләргә хезмәт хакын да үзе түли икән.

Мәдәни үзәк бинасын Марат абый юкка гына «өебез» димәгәндер. Бик заманча ул. Карыйм дисәң – телевизор, эшләсәң – компьютер, ашыйм дисәң – чәй эчү бүлмәсе, җырлаган-биегән кешегә – зур һәм киң зал. Беренче каттагы кагу уен кораллары торган бүлмәдә төрле репетицияләр



уза икән. Шушында ук грим салу, костюмнар бүлмәсе. Икенче катка менсәң – китапханә… Беркем бер сүз әйтми – телисең икән, көне буе татар китаплары укып ят.

Үзәктә даими чаралар уздырыла. «Без монда йөрүчеләр белән дуслашып, бер гаилә булып беттек, аларның шатлыгы – безнең шатлык һәм кайгысы – безнең кайгы кебек», – ди үзәк рәисе урынбасары Әлфия Лежнина.

Ул Үзәктә 2006 нчы елдан бирле эшли. Әнисе – Наилә Сәлимова тумышы белән Актаныштан. Әтисе Николай – рус. «Әтием исән чакта өйдә татар телендә беркем дә сөйләшми иде. Әти вафат булгач, татарча сөйләшергә өйрәндек», – дип сөйләп китте Әлфия Лежнина. Белгечлеге буенча педагог-психолог, башлангыч сыйныфлар укытучысы. Татар үзәгенә йөрүче яшьләр, өлкәннәр белән уртак тел табуда педагог-психолог булуының да файдасы бардыр, әлбәттә.

Әлфия ханым әйтүенчә, 2002 нче елдан Җаек Татар үзәге иҗтимагый берлеккә әйләнә. Шәһәрнең ике мәктәбендә татар теле дәресләре укытыла. Утызлап яшүсмер атнага бер мәртәбә татар мөгаллимәсе Наҗия Мәхмүт кызы Төхфәтуллина дәресләренә йөри. Үзәктә «Күбәләкләр», «Ләйсән» җыр-бию төркемнәре, «Империя» рок төркеме оеша.

Әдәби кичәләр, шигърият бәйрәмнәре үтә. Тукай көннәрендә балалар казакъ, татар, рус телләрендә Тукай шигырьләрен укый. Балалар белән һәр елны Кырлайга сәяхәт кылалар. Июнь аеның


Әлфия Лежнина

беренче якшәмбесендә Җаекта сабантуй гөрләп уза. Бәйрәмгә төрле милләт кешеләре күңел ачарга килә.

Татар үзәгенә килеп керү белән стендларда иганәчеләр исемлеген дә күргән идек. Бу фидакарьләр арасында Ришат Увәли улы Хәйруллин, Ранил Тамендар улы Хәлилов, Шәйхулла Шәрифулла улы Нотфуллин, Ренат Садыйк улы Монахов, Галина Вавил кызы Хәйруллина, Юрик Гавас улы Җамалетдинов бар. Сабантуй, Нәүрүз, Ураза, Корбан гаетләрен уздырырга да алар булыша.

**Гөлназ Галимҗанова**

# «Безне Тукай күтәрә»

Сокландык Җаек татарларына! «Без Тукайның «Туган тел»ен укып күтәрелдек», – диләр бит. Шәһәр уртасында «Карурман», «Җидегән чишмә», «Туган тел» җырлары яңгырый… Чит мәмләкәттә милли моңнарны ишетү күңелгә аеруча рәхәт икән ул. Кемнәр шулай моңлана дисәк, «Ялкын» вокаль ансамбленә йөрүчеләр булып чыкты. Без килгәндә татар үзәгендә репетиция бара иде.

Милли моңнарга сихерләнеп, яннарына узганыбызны сизми дә калганбыз. Безне күрсәләр дә, сер бирми җырчылар, күрмәмешкә салышалар. Гармун тынгач кына аралаша алдык.

– Җаекта татарның күбесе туган телендә сөйләшә белми. Наҗия Мәхмүт кызы иң элек безне татарча сөйләшергә өйрәтә, җырның мәгънәсен ачып сала. Аннан соң, баянчыбыз Равил Зәйнулла улы көйне өйрәтә. Инде утызлап җырыбыз бар. Тагын яңадан-яңа татар халык җырлары өйрәнәсе килә, – ди алар.

«Ялкын» ансамбле 1989 нчы елда оеша. Репертуарда хәзер ни генә юк: заманча җырлар, Тукайның «Бала белән күбәләк», «Туган авыл», «Пар ат» җырлары…

– Безнең яшьләргә әби-бабаларыбызның җырларын өйрәтеп калдырасыбыз килә, – ди «ялкынлылар».

Бу фидакарьләрнең кайберләре белән сезне якыннанрак таныштырабыз.

* * *

**Әхмирова Рәйсә Хәкимулла кызы:**

«Әтием – Хәкимулла Гариф улы Казакъстанда туган. Әнием Гөлҗиһан – Татарстанның Әтнә ягыннан. Үзем Казакъстанның Чыңгырлау районы Ачисай совхозында туып, шунда укыдым. «Ялкын» ансамбле турында очраклы гына белдем. Эльмира исемле танышым тамада булып эшли иде. Бер туй вакытында ул минем яныма килде дә: «Рәйсә апа, син нигә ансамбльгә йөрмисең? Бергә күңеллерәк булыр иде», – диде. Шуннан бирле «Ялкын»нан аерылганым юк. Киленем рус булса да, 6 яшьлек оныгым Карина миңа ияреп йөри, кушылып татарча җырлый…».



* * *

**Галиуллин Рафаил Әбүбәкер улы:**

«Тумышым белән Казакъстанның Җимбите авылыннан.

Бабам Бөгелмә районы Габдрахман авылында туып үскән. Үзе сәүдәгәр булып, яшь чагында Җимбитегә сәүдә итәргә килеп йөргән. Шунда әбием белән танышып, гаилә корып җибәргәннәр.



Тормыш иптәшем Асия Әсхәт кызы да шул авылдан. Ул зоотехникум бетереп, мәктәптә лаборант булып эшләде. Үзем гомер буе мәктәпләр инспекторы идем.

Мандолинада уйнарга ничек өйрәндем дисезме? Миңа нәселдән килгән сәләт бу. Әтием музыкага һәвәс иде. Ул мандолина, скрипкада уйнарга яратса, миңа мандолина хушрак килде. Аннан әтием клуб мөдире булып эшләгәндә татарларны җыйнап, спектакльләр куя иде… Хәзер үзем «Җомга», «Баламишкин», «Сарман», «Галиябану»ларны ноталарга карап уйныйм. Ә хәләл җефетем Асиянең әнисе – баянчы. Шуңа күрә гомер буена җыр-моңнан аерылмадык.

Әлфия, Лилия һәм Гөлфия исемле өч кызыбыз, кияүләребез һәм дүрт оныгыбыз бар. Ике оныгым институт тәмамларга өлгерде инде. Аларны үзем татар классына йөртеп укыттым. Оныгым Надия Үзәктәге «Ләйсән» бию ансамбленә йөри, җырлый белә. Аллаһка шөкер!»

* * *

**Габитов Равил Зәйнулла улы:**

Равил абый Татар үзәгенең атаклы гармунчысы һәм, әлбәттә, бер генә кичә дә ансыз узмый.



Ул җиде яшькә хәтле татарча сөйләшкән, ләкин рус мәктәбенә укырга кергәч, туган телен онытып җибәргән.

Җаек музыка училищесының халык уен кораллары бүлеген тәмамлагач, мәдәният сараенда укыткан. Педколледжда баян классы буенча унтугыз ел дәресләр алып барган. Хәзер ул Татар үзәгенең алыштыргысыз гармунчысы. Алай гына да түгел, Равил абыйның музыка дәресләренә йөргән Рамил Рәхимбердин Казанда «Татар моңы – 2010» бәйгесендә катнашкан. «Миңа татар мохитендә кайнау ошый. Үземә яңа дөнья ачтым. Безнең барысы да алда әле!», – дип, канатланып әйтеп куйды ул әңгәмәбез соңында.

# Татар яшьләре

*«Сөям мин сезне, сез чын яшь егетләр, өмет бар сездә, сез интеллигентлар».*

*Г. Тукай, «Әдәбият кичәсе ясаучы яшьләребезгә», 1906 ел*

Җаек яшьләренең татарчасы такы-токырак булса да, бик милли җанлылар икән. Безнең белән очрашуга Дамир Гыйматдинов, Рифат Джумагулов, Люция һәм Илдар Мозаффаровлар, Элеонора Әхмәтшина, Мария Хәсәнова, Роберт Вәлиев, Рамил Карабалин, Рәшид Әбдельманов, Камил Галиев килгәннәр иде. Шуңа игътибар иттек: күбесе «Я – татарин», «Татар малае», «Татарстан» дигән язулы футболкалар киеп йөри. «Яшьләр арасында хәзер шундый мода китте:

өс-киемебезгә әлеге сүзләрне үзебез ябыштырабыз. Татар булуыбыз белән горурланабыз!», – диде егетләр.

Ул көнне бергәләп чын бәйрәм уздырдык! Өстәл артында «түгәрәкләнгәч», «Туган тел» темасына брейн-ринг үткәреп алдык. Яшьләр сынатмады: сорау гына биреп җитеш! Җырлашып, күмәк уеннар уйнап алгач, чәй эчү бүлмәсендә табын әзреләдек. Төп ризыгыбыз, әлбәттә, чәй һәм Казакъстан карбызы иде. Уен-көлке өстәл артында да дәвам итте: кем шигырь сөйли, кем безнеңбеләнтаныша. Гармун чыкты, милли моңнар – «Туган тел», «Ай, былбылым» агылды…



## «Империя» татарча җырлый!

Җаек яшьләре арасында шактый популяр булган «Империя» рок төркеменең татар халык җырларын башкаруы турында ишеткәч, егетләр белән дә очрашып сөйләштек.

2004 нче елда барлыкка килгән «Империя» дүрт егеттән тора: Максим – вокалист, Илдар – барабанчы, Артур һәм Виктор – гитарачылар. Егетләр җырчы булабыз, зур эстрадага чыгабыз дип хыялланмаган. Бервакыт табигатьтә ял итеп ятканда, боларның Роман исемле дуслары берәр музыкаль төркем оештырасы килү идеясен әйтә. Озак та үтми, икенче дуслары Андрей «ВАЗ 2106» машинасына багышлап «Зеленая шаха» дигән җыр яза. Бәлкем егетләр «идеяләр» белән тукталып та калган булырлар иде, әмма «Созвездие-Йолдызлык» фестивалендә катнашып, өченче урынны алу аларның күңелләрен җилкендереп җибәрә. Финалда алар хәзерге вакытта яшьләр арасында популяр булган «Слот», «Ангелы» төркемнәре белән көч сынаша һәм өчлеккә эләгә. Хәзер егетләр яңадан-яңа планнар белән янып яши. Репетицияләр, концертлар, яңа җырлар…

– Тик менә репетицияләр ясарга урын юк иде. Кечкенәдән үк энем белән Җаекның Татар үзәгенә йөргәч: «Безгә берәр бүлмә бирә алмассыз микән?», – дип сорадык. Ярдәм иттеләр. Бүлмәбезне үзебезчә бизәп тә куйдык, – диде Артур.

Урыс җырларыннан тыш, егетләр, әйткәнебезчә, татар халык җырларын да башкара. Мәсәлән, 2010 нчы елда узган сабантуенда алар «Ай, былбылым»ны җырлаган. Хәзер исә Александр Пушкинның «Ангелы» шигырен татар теле укытучылары Наҗия ханым Төхфәтуллинадан тәрҗемә иттереп, татарча башкармакчылар. Тукайның Пушкинга мөкиббән киткәнен беләбез. Шуңа күрә Җаек егетләренең нәкъ Пушкин шигырен сайлаулары гаҗәп түгел.

– Ә син төркемнең татар телендә җырлавына ничек карыйсың? – дибез рус егете Викторга.

– Минемчә, һәр кеше үз милләтен яратырга, аны дөньяга танытырга тиеш! – диде ул.

**Альбина Газизуллина**

# Президент килә!

Көн дә яңа урыннар, яңа танышулар – Риман абый гына юк. Беркөнне Үзәктә кайнап йөргән мәлдә Марат абый эндәште:

– Риман Солтаныч Самараны узып киткән, – диде.

– Чыннанмы? – дидем ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

– Әйе, каршы алырга сине алсам инде. Бер-беребезне танымый торсак тагын…

Марат абый белән икәү машинага сикердек. «Ур-ра! Риман абый безне куып җиткән! Ур-ра! Инде юллык акча тапты микән? Әллә борыннарны салып, кире Казанга кайтырбызмы? Юк, Риман абый акчасын табар. Яхшы кешегә акча бирердәй яхшы кешеләр дә табылмый калмас…

Сәяхәттә безнең һәр минут санаулы, һәр минут кадерле булды. Төнлә дә вакытны заяга уздырмадык, көндез дә йоклап ятмадык. Риман абыйны каршы алырга чыккач та Марат абыйны сораулар белән күмдем:

– Марат абый, килгәнебезгә инде өч көн. Ә сезнең турында җүнләп белмибез дә.

– Үзем дә, әллә боларга Тукай гына кызыклымы икән дип уйлаган идем! – дип шаяртып алды да, сүзен дәвам итте Марат абый. – Музейга

чаклы «Мир копий» канцелярия тауарлары кибетендә директор булып эшләдем. Ә аңарчы мәктәптә һәм педучилищеда физика-математика укыттым. Музейга уйламаган-нитмәгән җирдән эләктем. Язмыш инде. Моннан 8 ел элек бердәнбер улым Рәшид көн дә Татар үзәгенә репетициягә йөри башлады. Алар Тукай тормышыннан өзекләр сәхнәләштермәкчеләр икән. Тукай ролендә – улым Рәшид. Кичләрен үзе генә йөрмәсен дип, аңа мин дә иярдем. Моңа хәтле канцелярия кирәк-яраклары белән Үзәккә ярдәм күрсәткәли идем үзе… Спектакль сәхнәгә куелды. Тамашага бик күп татар җыелды. Шул вакытта профессор, милләтпәрвар Разак Әбүзәрев белән танышып киттек. Театр – аның идеясе иде. Соңыннан Разак абый Тукайның 120 еллыгы уңаеннан оештырылган Халыкара конференциягә чакырды. Тукай минем тормышка әнә шулай килеп керде.

Машина туктады. Шәһәр читенә җиткәнбез икән. Борын төбендә тимер шлагбаум. Аның артында – полиция посты.

– Риман әфәндене шушында көтәбез. Ә мин сиңа сөйли торам. Кыскасы, һаман шул «Мир копий»да эшләгән вакыт. Беркөнне Равил Ваһапов дигән танышым яныма фоторәсем тотып кергән. Сурәттә «Татары в Уральске» дигән язуы да бар. Бу фото эзеннән мин Казанга юл алдым…



**Казан галимнәре Рәшит Кадыйров, Зөфәр Мөхәмmәтшин Тукай музее директоры Марат Баһаутдинов белән**

Офыкта ялгыз машина күренде. Юк, бу Солтаныч түгел, машинадан юан гына гәүдәле бер адәм төшеп, полиция постына китте. Марат абый:

– Килеп җитәр әле, дала белән хозурланып барадыр. Казакъстанга беренче килүеме? – дип сорап куйды.

– Беренче шул. Юкса, шулкадәр борчылмас та идек. Бик ачык күңелле ул Риман абый. Самими менә, чын сабый кебек. Нәрсә әйтсәләр – шуңа ышана. Ерак сәфәргә дә беренче чыгуы. Ә хыялы инде студент чагыннан булган.

– Нинди хыялы?

– Тукай эзләреннән сәяхәткә чыгу. Иң кызыгы – безнең дә хыял иде ул. Берләштек тә, тәвәкәлләдек.

– Әйтәм бит, һәр нәрсә – язмыш инде. Разак Әбүзәрев белән танышуым да очраклы булмады. 2005 нче елда ул әле Тукайның Җаектагы Евразия үзәген җитәкли иде. Бервакыт, мине үзенә булышчысы итеп чакырды. Ризалаштым. Тагын бер елдан – Тукай



музее директоры итеп куйдылар. Хәзер музейның җитәкчесе дә, экскурсоводы да, каравылчысы да – мин! Соңгы вакытта бер уй белән яшим. Тукай 1907 нче елда Казанга поезд белән киткән бит. 1899 нчы елда салынган ул вокзалны инде 1980 нче елларда сүтеп, читтәрәк яңаны торгыздылар. Димәк, Тукайның эзләре вокзалда да бар дигән сүз. Шушы вакыйгалар истәлеге итеп, улым Рәшид белән «Тукайны озату» дигән иске вокзал макеты ясадык…

– Гөлназ, көмеш төсле тагын бер машина килә. Бу Риман әфәнде түгелме?

– Шул! Нәкъ үзе!

Әнә, дала киңлекләрен тутырып, Риман әфәнде җилдерә! Әгәр акчабыз җитсә, Аллаһ бирсә, бу машина белән безнең әле бөтен Казакъстанны урыйсы бар! Насыйп булса, Кытайга да җитәрбез! Йортыбыз да, атыбыз да, дустыбыз да буласы бар әле бу машинаның! «Йөрәге» генә чыдасын! Ә без түзәрбез…

**Гөлназ Галимҗанова**



*«…Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вострок бар бит:*
*Куярлар астырып дарга, ятып тор, бер дә кузгалмый.*
*Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмый;*
*Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмый».*

*Г. Тукай, «Сорыкортларга», 1906 ел*

# Тукай ни өчен ләгънәт укып киткән?

Сәфәр вакытында истә калырлык вакыйгалар, гыйбрәтле очрашу-күрешүләр шул хәтле күп булды ки, инде менә яза башлагач еш кына: «Кайсыннан тотыныйм икән?», – дип югалып та каласың. Әлбәттә инде, Җаек турында язганда иң әүвәл Апуш беренче булып туктаган йорт – Галиәсгар Госманов йортын телгә алырга кирәк. Галиәсгар абзый безгә җизни тиешле. Аның хатыны Газизә апа белән минем әнинең әбисе Бибифаизә – бертуганнар. Бу хакта әнием Дания миңа балачактан ук әйтә килде. Ул Габдулланы чит кеше түгел, нәкъ менә безнең җизни тиешле Галиәсгар абзыйның үзенә сыендыруы белән эчтән генә горурлана да иде. Чөнки, матбугаттамы, кеше телендәме: «Күпме туганнары булып, шул ятим Габдулланы сыендырыр кеше табылмаган…» кебек сүзләр әледән-әле чыга, ишетелә тора иде.

Бәләкәй Габдулла бу шәһәргә чана юлы белән 18 тәүлек барган. «Тукай турында хатирәләр» (Казан, Таткитнәшр, 1976 ел) дигән китапта Габдулланың яшьтәше, Кырлай мәктәбендә бергә укыган иптәше Хәлилрахман Гобәйдуллин: «Габдулла Кырлайдан 1895 нче елда түгел, 1897 нче елда китте», – дип яза. Әмма Балтач һәм Арчаның Загс бүлекләрендәге мәгълүматларга караганда, Габдулла Кырлайдан 1894 нче елның көзендә киткән. Безнең фаразыбызча, Габдулланы Җаекка 1895 нче елны алып килгәннәр. Чөнки Тукайның апасы Газизә Зәбирова истәлекләренә карасаң, Бәдри абзый Җаекка беренче чана юлы төшкәч, ягъни 1894 нче ел ахырында килгән һәм Галиәсгар Госманов аңа: «Икенче килгәндә Габдулланы да алып кил, үзебез тәрбияләп укытырбыз», – дигән. Бәдри абзый, 18 тәүлеклек юлга бер ай эчендә ике мәртәбә чыга алмаган, әлбәттә. Шуңа күрә Габдулланың 1895 нче ел башында Җаекка килүе – дөреслеккә иң якыны дип уйлыйм.





**Г. Госманов йорты 2010 елда һәм ТР президенты Р. Миннеханов ярдәме белән төзекләндерелгәннән соң**

* * *

Җаекта яшәүче кардәшебез Разак Әбүзәрев белән тарихи бинаны күзәтәбез. Ике катлы Госмановлар йортыннан 9-10 яшьлек Тукай йөгереп чыгар төсле…

«Мин биредә инде 20 ел яшим. Элек монда Тимерьюлчылар йорты булган. Өй эчендә Тукай заманыннан берни дә үзгәртелмәгән дип беләм, агач баскычлар да шул ук. Бу йортка күчкәч, капканы гына алыштырдык. Монда 8 гаилә яшибез. Госмановлар йортында тарихи музей ясасалар, башка урынга бик теләп күченер идек», – диде бүгенге көндә Госмановлар йортында яшәүче Галимҗан Тайбәков. Разак әфәнденең дә Госмановлар йортында Тукайның музееn оештырасы килә. «Чөнки Тукай яшәгән йорт-җирләр әкренләп җимерелә бара. Вакытында саклап калсак иде аларны!», – диде ул.

Разак абыйны үзе артында гына яратып «локомотив» дип йөртәләр. Тукай музее мәсьәләсен дә ул күтәргән, якшәмбе мәктәпләрен ачуны, Тукайга һәйкәл куюны да… Кыскасы, Җаекта милләт язмышын, Тукай рухын саклау белән бәйле мәсьәләләрне Казакъстан акиматы (хакимияте – *Р.Г.*) каршында иң элек нәкъ менә ул күтәрә икән. Шуңа күрә аны «татар эшалонын» тартып баручы локомотивка тиңлиләр дә.

Инде үземне борчыган бер сорауга күпмедер дәрәҗәдә җавап табарга омтылып карыйм.

1909 нчы елның 13 нче мартында Тукай Җаекта яшәүче Гайнетдин Туприев дигән кешегә хат юллый һәм анда мондый юллар бар: «Уральскиның үзенә һәм аның җаһил (надан – *Р.Г.*) татарларына һәммәсенә киткән вакытымда ләгънәт укып киткән идем.

Шуңа күрә Рәкыйбе булсын, аның бозавы вә ишәк Хәсәнҗаны булсын – һичбере тугърысында хәзер сиңа язасым вә шуларны исемә төшерәсем килми. Муеннары астына килсен шунда ул сыерларның…»

Тукай Җаектан ни өчен шундый рәнҗүле хисләр белән киткән соң? Ә бит без Җаекны «Тукайны шәхес һәм шагыйрь иткән кала»

дип бәялибез. Шулай бәяләү, бер уйлаганда дөрес тә, чөнки нәкъ менә Тукай яшәгән чорда җәмгыятьтәге каршылыклар Апушны олы шагыйрь, көрәшче иткән. Гәрчә ул үзе Кырлайны «дөньяга күзем ачылган урын» дип язса да, Кырлай аның «балачак дөньясына» күзе ачылган урындыр. Ә Җаек – булачак шагыйрьнең чынбарлыкка күзе ачылган урыны. Ул монда чын тормышның үзе белән очраша һәм хаклык эзләгән шагыйрь күңеле бихисап каршылык-киртәләргә очрый. Бу юлларны язар алдыннан Тукайның Җаек чоры иҗаты белән инде ничәнче мәртәбә яңадан танышып чыктым: шигырьләрен аласыңмы, чәчмә әсәрләренме – һәркайсында диярлек шул чорны, яшәешне камчылау, усал итеп көлү.

Беренчедән, язмыш гомер буе Тукайның үзен камчылаган, әмма ул «тормыш камчысы» астында бөгелеп төшмәгән, киресенчә, усаллана гына барган.

*Ачы булгач күңлем, шигъeither ачы чыга,*
*Бәгъзан пешкән дип уйласам да – чи чыга.*
*Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,*
*Әлләничек! – Мыр-мыр итеп мәче чыга.*

*Г. Тукай, «Бер татар*
*шагыйренең сүзләре», 1907 ел*

Туприевка язган хатында шагыйрьнең: «Рәкыйбе булсын, аның бозавы вә Ишәк Хәсәнҗаны булсын…» – диюе һич кенә дә Уральскины, аның халкын сүгү түгел, ә заман итәгенә ябышып артка өстерәүче консерватив татар руханиларына һәм сәүдәгәрләренә нәфрәт белдерүе. 1905 нче елгы буржуаз революциядән соң Уральскида Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый нәширлегендә демократик рухлы газета-журналлар чыга башлый. Заманыннан «узып туган» Тукайга матбугатта юл ачыла. 1905 нче елның ноябрь ахыры, декабрь аенда язган шигырьләре генә дә 224 юл һәм алар «Фикер», «Нур» газеталарында дөнья күрә. 1906 нчы елның беренче 6 аенда Тукай «Әлгасрел-җәдит»нең һәр санында икешәр-өчәр шигырь, ә «Фикер» газетасында җиде шигырь бастыра. Боларга хикәяләр, рус классиклары әсәрләренең тәрҗемәләрен дә өстәсәң, шагыйрьнең ничек канатланып иҗатка чумуы аңлашыла.

Тик Тукай үз иҗатының башында ук надан, иске карашлы, фанатик муллаларның, бай-бәтчәләрнең каршылыгына очрый. Тукай үз хатында телгә алган шул ук Рәкыйп хәзрәт хөр фикерле татар матбугатын бетерү өчен шагыйрь әйтмешли «итәк астыннан керосинга ут төртеп пожар чыгарырга» йөри. «Габдерәкыйп хәзрәтнең вәгазе» дигән мәкаләсендә («Фикер»,






**Тукай хәреф җыючы булып эшләгән «Уралец» газетасы басмаханәсе**

1906 ел, 11 сентябрь) ул (имзасыз булса да, әлеге мәкаләнең авторы Тукай икәнебәхәссез–*Р.Г.*)Габделрәкыйпхәзрәтнеңтөрлемәҗлесләрдә«Фикер» газетасын кабәхәт сүзләр белән сүгеп йөрүен яза. «һәм бәгъзе мәҗлесләрдә ушбу сүзләрне сөйләде: «Әүвәл – Аллаһ, икенче мин риза түгел, «Фикер» гәҗитәсен укымагыз»,– ди. Бу сүз ничек була, бу сүз бит мин Аллаһтан бер генә дәрәҗә ким дигән сүз була түгелме?», – ди дә, мәкалә ахырында: «...әүвәл – мин, икенче – шәригым Аллаһ дисә дә барыбер булыр иде...» – дип төрттерә Тукай.

Әлбәттә, матбугат битләрендә барган көрәш тормышка күчә, «Фикер» типографиясенә ачыктан-ачык янаулар башлана. Әлеге типографиядә «Әлгасрел-җәдит» гәҗите һәм «Уклар» сатирик журналы да чыга һәм типография Тукайның төп эш урыны була. Габделрәкыйп хәзрәт яңалыкка каршы көрәштә берьялгызы булмый, әлбәттә. Хәйрулла Гаделшин исемле купец белән Гайнетдин Кари «Фикер» матбагасын һәм редакциясен тар-мар итү, Мотыйгый һәм аның гаиләләрен кыйнау өчен, хәтта, махсус отряд та оештыра башлаган булалар. Казанда чыккан «Бәянелхак» газетасының «Фикер»гә һөҗүм итеп, башкаларны өстерәп торуы да бушка китми. Нәтиҗәдә, 1906 нчы елны «Уклар» журналы, 1907 нче елның май аенда «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдит» газеталары ябыла.

Олуг шагыйребезнең Габдерәкыйп хәзрәт бакчасына әледәнәле таш ыргытуы, аны яман итеп телгә алуы тагын бер вакыйга белән бәйледер дип уйлыйм. Мотыйгулла хәзрәтнең Җаекта шактый еллар өлкән имам булып торуы кайберәүләргә, аерым алганда, әлеге дә

баягы Габдерәкыйп хәзрәткә дә ошап бетми һәм «кәнәфи» өчен астыртын көрәш башлана. Мотыйгулла хәзрәтне имамлыктан алу өчен тырышучылар арасында Габдерәкыйп хәзрәтнең кияве Мортаза бай да була. Нәкъ менә аның тырышлыгы белән Мотыйгулла хәзрәт имам вазыйфасыннан азат ителә һәм аның урынын Габдерәкыйп ала. Тукай үзенең остазына карата эшләнгән «этлеккә» карата сүз әйтми каламы соң? Юк, әлбәттә. Шуңа күрә ул Габделрәкыйп тарафына «муеннары астына килсен», – дигән сүзләр ыргыта да.

Әлеге язганнарыбыз Тукайның «Уральскига һәм аның надан татарларына ләгънәт укып» китү сәбәпләренең бик аз өлеше генә. Тукай, бер уйлаганда, гомер буе тормыштан, яшәештән канәгать булмаган кебек. Дөньясына, әле дә баягы томаналыкка протест аның үз-үзен тотышында да чагыла башлый. Европача киенү, чәч җиткереп яланбаш йөрү аның өчен гадәти хәлгә әйләнә. Тәмәкесен дә качып тартмый, алай гына да түгел, каршысына үзе сөймәгән кеше килгәнен күрсә, тәмәкене махсус кабыза. Толстой иҗаты белән җенләнгән вакытларында, аның кебек озын күлмәк киеп, билбау буып йөри башлый. Аның бу гадәтләрен яшьлек җүләрлегенә, яшьлек бунтарьлыгына гына сылтау дөрес булмас иде. Чөнки Тукайның Җаектан соңгы тормышы да көрәш белән уза. Һәм гомер кояшы батарга озак та калмый, ул күңел ачысы белән болай дип язар:

*Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,*
*Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.*
*Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,*
*Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.*
*Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:*
*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*

*Г. Тукай, «Кыйтга», 1913 ел*

Тукайның «лжеишанство»дан котылып Русиянең ирекле гражданины булырга чакырулары кайбер истәлекләрдә һәм Ибраһим Нуруллинның «Тукай Уральскида» дигән китабында шактый тәфсилләп язылган. Университеттагы остазым, Тукай буенча иң зур белгечләрнең берсе, инде мәрхүм Ибраһим ага шагыйрьнең Җаек чоры тормышы турында «Тукай турында хатирәләр» (Казан, Таткитнәшр, 1976 ел) китабында да шактый мәгълүмат биреп калган. Әмма «биреп калган» гына шул. Китап ахырында «олуг шагыйребез турында хатирәләр туплауны дәвам итәсе иде, монысы – киләчәк буын кулында», дигән өмет тә белдереп куйган. Без менә шушы өметне күпмедер дәрәҗәдә аклау өчен Җаекка сәфәр чыккан идек

тә инде. Әмма, ни кызганыч, вакыт узган булып чыкты. Кайчандыр Тукайны белгән, аның белән аралашкан кешеләрнең туганнары да бакыйлыкка күчкән. Хәер, без Тукайны күргән-белгән кешенең ике туганы белән очраштык.


Нәҗия апа Төхфәтуллина

Берсе – Мусаев Нәгыйм Зөлкарнай улы. Аның әтисе – Зөлкарнай Мирхәйдәр улының баҗасы – Хәлилов Мөхәммәтҗан мулла була һәм Тукай аның өенә килгәләп йөри. Самавыр куючы була. Монысы инде, әлбәттә, тамак кайгысы белән бәйледер. Шуның өстенә, Тукай мулла өенә җыелган яшьләргә төрле кызыклар, гыйбрәтләр сөйли, шигырьләрен укый… Нәгыйм абый безгә артык мәгълүмат бирә алмады: «Тукай турында истәлекләр кирәк булыр дип кем уйлаган…» – дип аптырап кулларын гына җәеп куйды.

Әңгәмәдәшебезнең икенчесе Нәҗия апа Төхфәтуллина (Урманчеева) иде. Аның ире Әсгать абзыйның әтисе – Кәлимулла Тукай белән мәдрәсәдә укыган, булачак шагыйрь белән шактый аралашкан. «Тукай бик акыллы, бик җитди иде. Чаган елгасы аша Хан урманына чыгарга бик ярата иде. Кеше күзенә күренмәскә тырышты. Хыялланырга бик ярата иде»,– дип сөйли торган булган Кәлимулла абзый. Һәм безгә янәдән «ни кызганыч» дип әйтергә туры килә, чөнки Тукай турында мәгълүматлар шушының белән чикләнә.

Соңга калабыз шул, һәрчак соңга калабыз һәм үткәнне кире кайтарып булмасы башыбызга барып җиткәч, акланып маташабыз.

Әлбәттә, без Җаекка Тукай турында истәлекләр җыярга дип кенә бармадык. Әлеге калада бер атна яшәп кенә «Америка ачып» булмасын да белә идек. Безнең белән барган галимнәр – Зөфәр Мөхәммәтшин белән Рәшит Кадыйров Җаекның татар зиратында булып, Тукай белән бәйле тарихи урыннарны карап, күпмедер фикер туплый алдылар кебек. Архивта утырып Тукай чорындагы Җаек тормышын өйрәнергә дә исәпләре бар иде, әмма архив материаллары төрле җиргә, аерым алганда Алматыга һәм Оренбургка җибәрелгән диделәр. Алматыда үзебез, ягъни дүрт журналист ике көн архивта казынып утырып карадык, әмма кызыксындырырлык мәгълүмат күзгә чалынмады. Инде Оренбург архивына өмет калды. Вакыт һәм акча табылган очракта, галимнәребез Оренбургка сәфәр чыгарга риза.

# «Интеллигент татар» һәм «Шияпка»

Тукайның революцион идеяләр белән янып яшәве дөреслеккә ни дәрәҗәдә туры килүен дәлилләү хәзер шактый кыен. Шулай да аның асылында, күңелендә бунтарьлык ятканын әйтсәк, илдә-җирдә барган үзгәрешләргә Тукай битараф калмаячак иде. Аның Җаек тормышы турында яшьтәшләре дә кызыклы гына истәлекләр сөйләп калдырганнар. Мәсәлән, типографиядә Тукай белән бергә эшләгән Александр Гладышев «Апуш белән кәгазьләр, прокламацияләр, революцион җырлар таратып йөрдем», – ди. Тукайның «Карт вахмистр», «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» кебек җырларның һәммәсен белүе, алай гына да түгел, ул җырларны башкаларга да өйрәтүе турында да яза.

Кечкенәдән үк апасы Газизәгә: «Апай, минем белмәгән җырым юк», – дип мактанырга яраткан Тукайның җырга да хәтере искиткеч булуын әйтсәк, халык арасында «җыр коткысы» таратып йөрүе табигый. Кайбер истәлекләргә караганда, Җаекта яшәү чорында Тукай типография эшчеләре белән даими элемтәдә торган һәм бөтен «чуалышларга» үзеннән өлеш керткән. Типография эшчеләре аны «интеллигент татар» дип йөрткәннәр. Кушамат тагуга бик хирыс булган Тукай да Александр Гладышевка «Шияпка» дип эндәшә торган булган. Тегесе: «Нинди кушамат ул?», – дип аптырагач: «Кушамат түгел, Александр – Сашаның татарчасы «Шияпка» була», – дип әйткән, имеш.

Менә шул «интеллигент татар» белән «Шияпка» эшчеләрнең 1 нче Май демонстрацияләрендә гел катнаша торган булганнар. «Демонстрациядә Тукай аеруча рухланган һәм һаман революция турында миңа нидер сөйли, ләкин, дөресен әйткәндә, мин ул


Г. Тукай (сулда) Г. Кариев белән



**Тукай Уральскидагы иптәшләре белән. Сулдан уңга: Нәҗип Нигъмәтуллин, Курушкин, Рәхмәтулла Хәйруллин, Габдулла Тукай, Сираҗетдин Белюков. 1907 ел**

вакытта барысын да аңлап бетерми идем әле…» – дип язып калдырган Александр–Шияпка. Ә Тукай аңлаган, гомумән, белер-белмәс теләсә ни сөйләп йөрергә яратмаган ул. Әле 20 яше дә тулып җитмәгән егет Җаекта шагыйрь генә түгел, гаделсезлеккә каршы көрәшүче буларак та җитлеккән.

Җаек урамнары буйлап йөргәндә һәм эшчеләрнең 1 нче Май демонстрациясе уза торган Хан урманы, митинглар үткәрелә торган шәһәр мәйданнары тирәсен ураганда арабыздан кемдер: «Тукай тагын бераз яшәсә, аннан революционер чыккан булыр идеме?», – дип сорап куйды. Шундук җавап бирергә аптырап, бераз уйланып калдым. Аннан соң: «Булыр иде, әмма барыбер озак яшәмәс иде. Чөнки, беренче сафта баручыларга һәрчак каты эләгә», – дип куйдым.

**Риман Гыйлемханов**

# Тукай рухы тагын кайларда саклана?

*«Йөрәкләрдә – синең ялкын!*
*Син Җаекта канат кактың.*
*Җырларыңнан биек күктә*
*Син мәңгелек йолдыз яктың».*
*Җакан Сыздыков, казакъ шагыйре*

## Хан урманы

Марат абый көннәрнең берендә безне Җаек елгасына алып төште. Аннан кулларын суга тыкты: «Монда борынгы хәзинәләр күп», – дип сөйләнә-сөйләнә, борынгы савыт-саба, чүлмәк ватыкларын тартып чыгарды. «Элек, XVIII гасырларда биредә казакълар яшәгән. Су әкрен – әкрен ярны ашап, аларның торакларын җимергән», – диде ул.

Шаулап аккан Җаек ел саен кибә икән. Өстәвенә соңгы арада агым юлына ләм утыра башлаган һәм чүлмәк ватыклары агып китә алмыйча, ярларда кала икән.

– Уң якта – Хан урманы, – дип экскурсияне дәвам итте Марат абый. – Җаек белән Чаган елгасы кисешкән урын ул. Габдулла Тукай бу агачлыкта эшчеләр маевкасында катнашкан. Биредә хәзер шәһәр паркы. 1891 нче елда ул – Цесаревич, Совет чорында – Горький исемнәрен йөртте. Маевка истәлегенә анда хәзер монумент та бар».

– Ә ни өчен Хан урманы дип атала?



**Тукай еш булган Җаек яры**

– Җаекка казакълар аяк басканчы, бу урында татарларның зур шәһәре булган, диләр. Урманда Нугай Урдасы ханнары җәйге резиденция тоткан. Биредә таҗ кию, хан тәхетенә утырту йолалары башкарылган. Казакъ ханы Җиһангир биредә үзе таҗ кигәндә, көне буена бәйрәм уздырган, диләр. Хан урманы, ягъни «Ханская роща» – бүген татарларның яраткан ял итү урыны.

Әйе, Тукай да еш килгән монда. Дусты Габдулла Кариев үз истәлекләрендә болай дип яза: «Тукаевның иң хозур үткәргән вакыты җәй көне була иде. Җәй көннәрендә мәдрәсә күршесендәге сәгатьче Камали абзыйның көймәсе берлә Чаган суыннан Рощага хозурга чыгып, шунда чәйләр эчеп, балык тотып күп көннәрен үткәрде».



Габдулла бу мәчеткә бишвакыт намаз укырга йөргән

## Кызыл мәчет

Елга яры буйлап шәһәргә таба киттек. Тар сукмак, яшел аллеялар буйлап Татар бистәсенә килеп чыкканбыз. Бу – шәһәрнең иң борынгы урыны. Тукай исеме белән бәйле бөтен йортлар да шушында саклана икән. Без башта Кызыл мәчеткә кердек.

• Кызыл мәчеткә 1871 нче елда нигез салына. Мәчетнең имамы итеп Тукайның булачак укытучысы Мотыйгулла Төхфәтуллин билгеләнә. Габдулла бу мәчеткә бишвакыт намаз укырга йөргән.

• Әлеге иман йорты 1920 нче елларга кадәр эшләп, 1930 нчы елларда аның манарасын кисәләр.

• 1990 нчы елларга кадәр Кызыл мәчет сөргенгә сөрелгәннәр өчен яшәү урыны, төзелеш участогы, инвалидлар йорты (1936-1962), һөнәрчеләр училищесы, СПТУ тулай торагы булып тора.

• 1990 нчы елда татар меценаты Ришат Увәли улы Хәйруллин хәрабәләргә әйләнгән иман йортын төзекләндерүгә керешә. Аллаһның рәхмәте белән, аның ихлас нияте Җаекның мәрхәмәтле халкын «уята». Төрле катлау, милләт вәкилләре, дин әһелләре мәчет төзелешенә кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтә. Акчалата гына түгел, төзелеш материаллары, башка кирәк-яраклар белән дә булышалар.

• 2006 нчы елның 13 нче апрелендә Кызыл мәчетнең манарасы торгызыла. Вакыт һәм «ят куллар» мәчет диварларын таушалдырып, ярымҗимерек хәлгә китергән була.

• 2006 нчы елның 30 нчы июнендә Кызыл мәчеттә беренче азан яңгырый. Бу – җомга көн була. Мәчетнең гүзәллеге белән сокланырга бар халык килә.

• Кызыл мәчет – Җаектагы 3 иман йортының иң борынгысы.

Разак Әбүзәрев әйтүенчә, Кызыл мәчет янындагы мәдрәсә «Мотыйгыя» түгел. Күп кенә чыганакларда бу турыда ялгыш мәгълүмат бирелгән. Кызыл мәчет янындагы мәдрәсә – «Рәкыйбия», – ди ул.

## «Мотыйгыя» мәдрәсәсе

*«Габдулла әфәнде мәдрәсәдә иң галим, иң үткен, зирәк шәкертләрдән хисаплана иде».*

*Габдулла Кариев*

1870 нче елларда төзелгән «Мотыйгыя» мәдрәсәсе сакланып калмаган. Ул – биредә Тукай белән бәйле юкка чыккан биналарның берсе. Кайбер фаразлар буенча, ул 1918 нче елда, Гражданнар сугышы вакытында снаряд төшеп җимерелгән. Бүген мәдрәсә урынында – зәңгәрсу түбәле таш йорт.





**Тукай Камил Мотыйгый белән**

Тукай вакытында Җаекта 3 мәдрәсә эшләп килгән. Мулла Рәкыйп Тулбаев карамагындагы «Рәкыйбия», Гайнетдин Кариныкы – «Гайния», Мотыйгулла Төхфәтуллиннныкы – «Мотыйгыя». Болар өчесе дә кадим уку йортлары булып торсалар да, Төхфәтуллиннарныкы заманчарак яшәгән.

Гомумән, «Мотыйгыя» шәкертләре – алдынгы карашлы татар яшьләре саналган. Камил Төхфәтуллин биредә әдәби кичәләр уздырган. Беренче шигырьләрен дә Тукай биредә укып, мәдрәсәнең беренче шагыйренә әйләнгән. Дуслары аны алкышлар белән каршылый торган булган…

Мотыйгулла Төхвәтуллин шәкертләргә Әбүгалисина, Әл-Фәраби хезмәтләрен аңлата, Фирдәүси, Гомәр Хәйам, Сәгъди, Нәвои поэзиясе белән таныштыра. Тукайга гарәп шигырь төзелешен төшендерүче, телескоп аша күк җисемнәре белән таныштыручы да Мотыйгулла хәзрәт була. Ул вакытта «Мотыйгыя»га төрек һәм гарәп телләрендә «Шәркый рус», «Тәрҗеман», «Тәраблис» кебек газеталар килеп тора. Дәмелла Мотыйгулла алар белән файдаланырга шәкертләргә дә рөхсәт итә.

## Тукай көшеси

*«Татарлармы, белмим, кая киткән?*
*Зурсы, киңме, тап-тар гынамы?*
*Анда түгел хикмәт, килгән яшәп*
*Җаекта бер татар урамы.*
*Тора-бара барыбер бетәр иде.*
*Башка исем белән аталды:*
*Хәзер Тукай, гомер буе шулай*
*Саклап калган Тукай татарны».*

*Сибгат Хәким, 1977 ел*

Җаектагы Тукай урамы шәһәрдә иң матур урамнардан дип ишеткәнебез бар иде, ә үзебез күргәч тагын да шаккаттык! Әйе, киң, шома асфальт юллы, яшеллеккә төренгән урамнарның берсе икән ул. Алай гынамы?! Урам башында ук сине Тукай портреты төшерелгән баннер каршы ала. Анда шагыйрьнең кыскача тормыш юлы шәрехләнә. Валлаһи, шул баннерга кызыгып, борылмас җиреңнән Тукай урамына борылып та куясың. Их, безнең Казанда берәр шагыйрьгә шундый урам булсамы?! Бу бит искитмәле: Тукай урамын шәһәр буйлап эзләп тә йөрисе юк! Әнә, Достык проспектыннан барганда ул әллә каян үзенә җәлеп итеп тора!






Йорт почмакларында аратирә «Тукай көшеси» дигән сүзләр дә очрый. Казакъчадан тәрҗемә итсәк – «Тукай урамы» була инде ул.

Татар бистәсенең рухи үзәге – Кызыл мәчет булса, мәдәни үзәге – Төхфәтуллиннар йорты. Габдулла Тукай 12 ел дәвамында үзенең остазы Мотыйгулла хәзрәткә килеп йөргән.



* * *

Мотыйгулла хәзрәт вафат булгач, аны үзе хезмәт иткән Кызыл мәчет янында җирлиләр. Тора-бара бу каберлек тапталып, аяк астында кала. Мотыйгулла хәзрәтнең кызы Галия Кайбицкая, Җаекка бер кайткач, әтисенең каберен Татар зиратына күчерергә уйлый. Рөхсәт алу өчен кәгазь җафалары чигә чигүен, әмма морадына ирешә. Инде 24 ел Мотыйгулла хәзрәт җан тынычлыгын Татар зиратында таба.

## Тукай музее

Тәмам «экскурсоводка әйләнгән» Марат абый безне Тукай музеена алып керде. Музей исә Төхфәтуллиннарның шәхси йортларында урнашкан.

– Бу музейның концепциясен Разак Әбүзәрев эшләде. Кызганыч, Тукайның монда куярлык шәхси әйберләре сакланмаган. Мотыйгулла хәзрәттән өстәл, урындык, өстәл япмасы, лампа калган. Җаекта яшәүче татарлар 1920 нче еллардан бирле музей өчен бина сорап йөрде. Әмма селкенүче булмады. Тукай эзләре акрынлап юкка чыкты. Ярый әле 1986 нчы елда, Тукайның 100 еллыгы уңаеннан, Казаннан экспедицияләр килеп, Тукайга бәйле экспонатларны алып киттеләр. Юкса, бөтенләй юкка чыккан булырлар иде, – дип сөйләде ул.

1905-1906 нчы елларда Тукай бу бинадагы типографиядә һәм «Фикер» газетасы, «Уклар», «Әлгасрел-җәдит» журналлары редакцияләрендә эшләгән. 5 меңгә якын тираж белән чыккан «Фикер» газетасы Төхфәтуллиннар йортыннан Русиянең төрле почмакларына таратылган.

Уйлап карасаң, кызык килеп чыга бит әле: татар дөньясында беренче газета «Нур» (Санкт-Петербург) – 1905 нче елның 16 нчы сентябрендә, икенчесе – «Казан мөхбире» (Казан) шул ук елның 29 нчы октябрендә, Җаекта «Фикер» – 26 нчы ноябрьдә дөнья күрә башлаган. Һәрбер басманың нәшер ителү арасы – бер ай булган. Димәк, Җаек – ул Казан, Санкт-Петербург белән бер рәттә торучы, татар дөньясының «өченче рухи башкаласы» булган түгелме?!

«Фикер» – әдәби һәм цензурасыз газетага әйләнеп, аның 73 саны дөнья күргән. Шунысы сөенечле: «Фикер»нең кайбер саннары әле исән-имин икән. Алар Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Россия Фәннәр академиясенең Казан филиалы китапханәсе, Үзбәкстанның Бируни исемендәге Шәрекъне өйрәнү институты китапханәсе, Башкортстан Республикасы милли китапханәсендә саклана. Әле, бәлкем, без белмәгән кулларда да күз карасыдай сакланадыр



**Музей Төхфәтуллиннарның шәхси йортларында урнашкан**

ул «Фикер»ләр. Нибары ике ел гына нәшер ителгән газетаның соңгы саны – 1907 нче елның 13 нче маенда дөнья күргән.

Тукай «Фикер»дә дә, Камил Мотыйгый тарафыннан чыгарылган тагын бер басма – «Әлгасрел-җәдид»тә дә басыла.

1906 нчы елның 15 нче гыйнварында татар дөньясы кулына беренче (!) татар журналы ала. Ул – «Әлгасрел-җәдид» була. «Фикер» кебек үк «Әлгасрел-җәдид»тә 1907 нче елга кадәр генә чыгарыла. Аның 17 санының дөнья күрүе мәгълүм. Әдәби һәм сәяси журналның нөсхәләрен Казан дәүләт университетының Лобачевский исемендәге китапханәсе, Татарстан Милли китапханәсе, КФРАН, Башкортстан милли китапханәсе, Россия Фәннәр Академиясенең Шәрекъне өйрәнү институты китапханәсендә (Санкт-Петрбург) күреп була.

Камил Мотыйгый 1906 нчы елның 25 июнь – 15 ноябрь аралыгында «Айлык рәсемле сатирический журнал» – «Уклар»ны нәшер итә. Шушы ук елны «Уральский дневник» газетасының баш мөхәррире булып китә. «Яңа тормыш» газетасын оештыручыларның да берсе була.

– Тукай наборщик булып эшләгән вакыттагы станоклар 1990 нчы елларга кадәр подвалда торды. Подвал хуҗасы Өлкә музеена килеп: «Алып китмәсәгез тимергә тапшырам», – дигән. Хуҗа сүзендә тора: «Фикер», «Уклар» җыелган станоклар юкка чыга, – дип тә сөйләде Марат абый.

Ә бит шушы станоклар – Җаекны татар матбугатының икенче ватаны иткән җиһазлар булган! Әлеге тимер кисәкләренең һәм бу вакыйгаларның әһәмиятен, ни кызганыч, кешелек вакыт узгач кына аңлый.

Подвалга төштек. «Уральский дневник» газетасының бер санын пыяла тартмага беркеткәннәр. Тукайның наборщик вакытта төшкән фотосын зурайтып куйганнар. Бер почмакта гарәп язулы каберташ ватыклары ята. Аларны Татар зиратында табып-җыеп, аяк астында ятмасынга бирегә куйганнар икән. «Зиратыбыз – борынгы, ә каберташлар гарәп язулы булгач, аларны укый белмибез. Ә укырга, өйрәнергә кирәк. Мотыйгулла Төхфәтуллин, Мортаза Гобәйдуллин да шул зиратта җирләнгән», – диде Марат абый.

Мотыйгулла хәзрәт подвалының «серләре» каберташлар белән генә чикләнми. Монда төшкәч, без тән һәм җан белән Тукай заманы рухын сиздек. Бәлки, безнең халәт яңача ремонт күрмәгән стеналар, сүрән яктылык белән дә бәйле булгандыр. Шулай да, күңелнең кузгалып-сыкрап куюы, асылда, мондагы гаҗәеп экспонатлар белән бәйле иде. Алар турында Марат абый аерым басым ясап сөйләде:



– Хөрмәтле кунаклар, ә хәзер бөтен игътибар менә бу баскычларга! – диде ул. Без ике басмалы бер баскыч кисәгенә төбәлдек.

– Бу – Мотыйгулла хәзрәт яшәгән йорт баскычы. Ремонт ясаганда, ике адымлы өлешен булса да саклап калырга тырыштык, – дип, өстәп куйды Марат абый.

– Төхфәтуллиннар йорты истәлеге инде бу алайса, – диештек.

– Алай гына түгел, беләсегез килсә, бу баскычлардан Тукай йөргәндер дип уйлыйбыз. Юк, дөресе шул – басманың һәрберсендә – Тукай эзләре…

Марат абый сүзләреннән бөтен тән чымырдап китте: ә без нәрсә саклый алдык? Күңел белән Кырлайга, Кушлавычка кайтып килдек. Казакъстанның Җаегында: «Моннан Тукай атлаган», – дип, күз карасыдай баскыч саклап торалар бит ә?!

– Менә бу плитәләр дә Төхфәтуллиннарныкы. Аларны мич сүткәндә алып калдык. Аларга салкын кичләрне аркасын терәп, бәлки, Галия Кайбицкая да җылынгандыр. Урамнан туңып кергән кулларын



**Тукай музей подвалында урнашкан басмаханәдә дә эшләгән**

Тукай да куеп торгандыр. Безнеңчә, Тукайның кул җылысы аларда бүген дә саклана. Плитә белән баскыч басмаларын сак кына тотып карый аласыз, – диде Марат абый.

Мотыйгуллага бу йортны Тау Гайни дигән бай салып бирә. Кайбер фаразлар буенча, бу сәүдәгәр чыгышы белән Кайбыч районы Борындык авылыннан. Борындык – элек сәүдәгәрләр авылы саналган. Аның янында биек тау булган. «Тау Гайни» дигән исеме дә шуңа бәйле түгел микән дигән уй бар. Бу йортка күчкәнче, Мотыйгулла хәзрәт үзенең гаиләсе белән Кызыл мәчет янындагы өйдә яшәгән.

Әлеге кирпеч йортның беренче каты элек таштан, икенче каты агачтан була. Бервакыт Мотыйгулла хәзрәтнең йортына ут кабып, икенче кат янып бетә. Ташландык хәлдә яткан бай йорты 2006 нчы елда яңадан төзекләндерелә.

1995 нче елда, иң әүвәл Җаекта Тукай үзәге төзелә. Аннан, Казанның Меңъеллыгы көннәрендә, Татарстан һәм Казакъстан президентлары Җаекта Тукайга музей ачу турында сөйләшәләр. Өлкә башлыгы Төхфәтуллиннар йортында яшәүчеләргә 6 фатир бүлеп бирә. Реставрацияләү эшен, Минтимер Шәймиев үтенече буенча, «Татнефтегеофизика» финанслый. Шулай итеп, 2006 нчы елның 12 нче декабрендә Тукай музее ачыла. Аны без Габдулла Тукай һәм Төхфәтуллиннар гаиләсенең берләштерелгән музее дияр идек.

Дулкынландыра Төхфәтуллиннар йортында. Аның беренче каты – чын татар мохите: көнкүреш җиһазлары, кием-салым, шул заман фотолары. Гарәп язулы касә – бу залның иң кыйммәтле экспонатларыннан берседер, мөгаен. Зәңгәрсу төстәге су касәсе 1891 нче елда коела. Уральск казакъларының Романовлар йортына хезмәт итүләренә 300 ел тулу уңаеннан Җаекта оештырылган бәйрәмгә килгәч, Николай IIгә бүләк ителә. Ул касә – Кызыл мәчетнең икенче имамы – Рәкыйп Тулбаев хатынының шәхси әйбере булган.

Музейның беренче каты белән танышып чыккач, Марат абый кызыктырып куйды: «Икенче каты күбрәк Тукай белән бәйләнгән. Анда Мотыйгулла хәзрәт кабинеты, Камил Мотыйгый, Галия Кайбицкая тормышын чагылдырган экспонатлар да күп. Ләкин анысы турында Разак абый сөйләячәк. Үзе килмичә икенче катка аяк басмаска кушты», – диде.

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», – дип язган Тукай 1913 нче елның 14 нче мартында «Уянгач беренче эшем» мәкаләсендә. Шушы сүзләргә 97 ел үткәч, менә без дә Тукаебыз эзләреннән аның «үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр» тикшерергә Җаекка кадәр килеп җиттек. Аллаһка шөкер, Тукай Җаекта онытылмаган.








…Ишегалдындагы шау-шу Разак абый килүен белгертте. Тизрәк урамга ашыктык. Әйе, бу без Җаекка барганчы ук ишетеп кенә белгән кеше Разак Әбүзәрев иде. «Әдәпле, артыгын сөйләми, гыйлемле кеше», – дип, алдан ук әйтеп куйганнар иде безгә. Разак Абдрахман улы – педагогика фәннәре докторы, профессор. Җаекта күпләрнең остазы икән. Фәнни хезмәтләре казакъ мәктәбендә рус телен укыту методикасына карый. Әбезнең белән Разак әфәнде саф татарча сөйләште.

Музейның икенче катына күтәрелдек. Монда бар да борынгы, шул ук вакытта зәвыклы һәм пөхтә. Фотоальбомнар, стендлар, китаплар Тукай, Төхфәтуллиннар язмышы белән бәйле булудан тыш, Җаектагы татар дөньясы тарихының битләрен ача.

Бер зур гына бүлмәне Галия Кайбицкаяныкы иткәннәр.

Биредә күзгә иң ташланганы – Мотыйгулланың оныкчыгы, рәссам Ильяс Айдаров ясаган портрет булды. Татар опера сәнгате йолдызы Галия Кайбицкая сурәтләнгән бу рәсемне Ильяс әфәнде 2008 нче елда Җаекка килгәч бүләк иткән.

Музейның һәр тарафын Тукай әсәрләре бизи. Чыкканда шигъри юллар озатып кала:

*Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,*
*Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.*
*Хуш гомер иткән шәһәр инде еракта калдыгыз,*
*Аһ таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.*

## Рус мәктәбе

Рус мәктәбе урнашкан ак таш бина – хәзер торак йорт. Габдулла Җаекка килгән заманнарда татар мәдрәсәләре каршында рус класслары эшләп килгән. Тукайның сабакташы Ярулла Морадиның 1913 нче елда басылган «Тукаев Уральскида» дигән китапта Габдулланың школга 1896 нчы елда укырга керүе әйтелә.

Җаекта мондый мәктәпнең ачылуы көтелмәгән һәм күренекле вакыйга була. Җирле матбугат бу яңалыкны шундук эләктереп ала. «Уралец» газетасының 1897 нче ел, 21 нче сентябрь санында басылган мәкалә шуны искәртә: рус байлары Мортаза Гобәйдуллиннан үрнәк алып, мәктәпләр салырга тиеш:

Газета «Уралец», 1897 г., №24, 21 сентября

«Строитель Новой мечети, почтенный блюститель русского класса при Уральских медресе г. Муртаза Губайдуллин, купил дом на Петропавловской улице и, приспособив его под помещение класса, пожертвовал в его собственность. Здание – двухэтажное. В верхнем этаже обширный класс человек на 40 и учительская комната, а в нижнем – квартира учителя, состоящая из 2-х комнат и кухни. Ход в верхний этаж – прекрасная лестница из плетняка. Со двора здание удовлетворяет своему назначению. На дворе построены новые службы для класса и квартиры учителя, а находящиеся на дворе старые службы и деревянный флигель г. Губайдуллин обязался снести и на месте их предположил развести сад. Таким образом, для отдыха учеников при



**Тукай укыган Рус мәктәбе**

училище будет вполне пригодное для этого место. Приобретение этого здания в собственность школы избавит от ежегодных переселений из одного помещения в другое, и в следствии постоянного вздорожания в квартир в г. Уральске, все в худшее и худшее. В настоящее время в классе 40 учеников? разделенных на 3 отделения. Все ученики по возрасту от 8-14 лет. Курс 3-годичный. Программа начальных училищ.

Не мешало бы и русским последовать примеру г. Муртазы Губайдуллина, так как начальные русские школы исключая Кирилло-Мефодиевской церковно-приходской школы, не имеют собственного вполне приспособленного помещения и принуждены платить за помещения втридорога».

Рус мәктәбендә Тукай 3 ел белем ала. Кыш көне генә килүенә карамастан, көздән үк укый башлаган шәкертләрне дә узып китә һәм урыс әлифбасын берничә ай эчендә су кебек «эчә» башлый. Укытучысы – Әхмәтша Сираҗетдинов, зиһенлеге, тырышлыгы өчен Тукайны аеруча яраткан. «Габдулла әфәнде Тукаев газеталарда яза башлагач, карт учитель аш мәҗлесләрендә Габдулла әфәнденең школада вакытындагы зирәклеге хакында, хосусан чит телләрне белүгә бик истигъдатлы (сәләтле – *Г.Г.*) дип сөйли иде. Габдулла әфәндегә учительлек иткәнлеге берлә ифтихар (горурлану – *Г.Г.*) кылган сымак сөйләп куя иде», – дип яза Габдулла Кариев үзенең истәлекләрендә.



**Әхмәтша учитель**

Әхмәтша учительнең бай китапханәсе була һәм ул Габдуллага рус язучыларының әсәрләрен биреп укыткан. Кызганычка каршы Әхмәтша учительнең гомере фаҗигале рәвештә вакытсыз өзелә. Советка каршы пропаганда алып барган өчен аны 1919 нчы елда атып үтергәннәр.

Бу хакта безгә Җаекта яшүче фотохәбәрче Юрий Асманов сөйләде. Яңа танышыбыз, хәтта, «советка каршы пропаганда»ның асылын да әйтеп бирде. Әхмәтша учитель гарәпчәдән «гаделсезлек иң көчле дәүләтне дә җимерә» дигән юлларны урысчага тәрҗемә иткән булган һәм бу «фикер» советларга ошамаган.

Юрий Асманов «Тукай фонды»на үзенең «Записки старого газетчика» (Уральск, «Оптима», 2005 ел) исемле китабын да бүләк итте. Габдулланың Җаек чоры тормышы турында моңа хәтле билгеле булмаган мәгълүматлар тапмабызмы дип, әлеге китапны караштырып утырдык. Анда булачак шагыйрьнең Галиәсгар абзый гаиләсендәге

тормышы, 1905 нче елгы революцияне ничек каршы алуы, революцион-демократ яшьләр белән прокламацияләр ябыштырып йөрүе хакында икеләнүле уйлар, төрле фаразлар бар иде. Тик аларны дәлилләү инде мөмкин түгел.

Әмма, фәйләсуф Декартның «хакыйкатькә юл – икеләнүләр аша» дигән фикерен искә төшерик тә, һәртөрле фараз, истәлек игътибарга лаек дип күңелгә беркетеп куйыйк. Шуның өстенә, яңа танышыбыз үзенең әтисе, Җаек кешесе Әдһәм Бикмөхәммәтовтан да кызыклы гына истәлекләр сөйләтеп калган. Ә. Бикмөхәммәтов Тукайның чордашы булып, Габдулланың бала чакларын яхшы хәтерләгән. «Әтидә татар китаплары, хәтта, Тукайның фоторәсеме дә бар иде. Мин аның нөсхәсен эшләдем», – дип сөйләгән иде безгә Ю. Асманов.


**Софья ханым Аухариева**

Габдулла Галиәсгар абзый гаиләсендә, кайберәүләр язганча, ачлы-туклы яшәмәгән. Ю. Асманов, Тукайны мескен итеп язучыларга, гомумән, каршы. Аның китабында Җаекта Тукай белән бәйле урыннарның фоторәсемнәре, алар турында мәгълүматлар да бар. Әмма, без барысын да үзебез күрәсе иттек.

Ә беркөнне без Җаекта урнашкан кунакханәгә Софья ханым Аухариева килеп керде.

Мөләем генә бу татар апасы безгә бер мәгълүмат җиткерергә килгән. Беренчедән, аның әтисе Минһаҗ – Тукай белән таныш булган. Икенчедән, 1947-1948 нче елларда Әхмәт Фәйзи Җаекка Тукай турында роман язарга килгәч, Минһаҗ абзыйлар гаиләсендә яшәгән. Аларның өйләре исә ике катлы Пугачев йортында булган. Ул вакытта Софья ханым Казанда укый. Шулай да, Җаекка әти-әнисе янына еш кайткалап йөри. Еллар үткәч, әтисенең Тукай турында сөйләүләрен Софья ханым бүгенгедәй хәтерли: «Тукай укыган өч класслы урыс мәктәбендә әтием дә укыды. Ул Тукайны күреп белгән. Тукай бик кызыксынучан, күп белүчән шәкерт булган. Әтием 1898 нче елгы. Тукайдан яшь буенча бәләкәйрәк булсалар да, алар аны танып, читтән «Бу – Тукай», – дип, күзәтеп йөргәннәр. Койма ярыгыннан аның кузна уйнаганын карап торганнар. Әтием бик сагынып миңа шуларны сөйли иде», – дип, хәтирәләрен яңартты ул. Минһаҗ әфәнде исә гомере буе Җаек педагогика институтында хисапчы булып эшләгән.

## «Иске Уральски»

Җаекта борынгы йортларны, әйткәнебезчә, сүтмиләр дә, җимермиләр дә. Күпчелеген музей итеп тоталар. Ә музейлар монда йөзләп. Шуларның икесеннән ел әйләнәсе кеше өзелми. Берсе – Тукайныкы булса, икенчесе – «Иске Уральски» музее. «Иске Уральски»га барып, без бер көлке хәлгә дә калдык.

Җаек турында иң борынгы экспонатлар саклана биредә. Бүлмә эчендә бүлмә, музей зур һәм бай. Сирәк җиһазлар, иске-москы көндәлек кирәк-яраклары – ни генә юк! Арлы-бирле йөреп, музей белән танышкач, биредә бер генә әйбер тапмадык. Ул да булса – чабата! Икенче көнне юл уңаеннан музей директоры Геннадий Леонидович Мухинга бер пар чабата кертеп чыктык. Ә абзыкай исә борынын гына чөерде. Имеш, ник әле мыскыл итәсез? Казаклар бит чабата кимәгән! Чабата – ул урта хәлле крестьяннарның аяк киеме! Уңайсызланып, кызарып калган идек шул чакта. Ярый әле директор әфәнде хәлебезгә керде. «Соң, калсын бездә. Без аны Тукай почмагына куярбыз!», – диде. Чабата татарның милли аяк киеме дип уйлады микән ул? Безнең татарларның сафьян читекләрдән йөргәнен йә белми, йә оныткан, күрәсең. Ярар инде, хуҗа кешегә каршы әйтү килешми, ояты үзенә булсын.




Тукай почмагы дигәне, ни гаҗәп, почмак түгел, ә килеп керү юлындагы бер экспозиция булып чыкты. Бер рәссам ясаган Тукай портретыннан, татар өе күренеше, талдан үрелгән тәгәрмәчле бала арбасыннан, баян, чигүле сөлге, сандыктан һәм… без бүләк иткән бер пар чабатадан гыйбарәт ул. Аны икенче төрле «Татар почмагы» дип тә атыйлар икән. Чигүле татар калфакларын күргәч, без – кызлар, бөтенләй эредек. Арада сирәк очрый торган чулпы, бизәнү әйберләре дә ялтырады.



**Тукай почмагы дигәне, килеп керү юлындагы бер экспозиция булып чыкты**

– Бу көзгеле трильяж, кием-салымны каян алдыгыз? – дибез директор-экскурсоводка.

– Музей ачылганын ишетеп татарлар үзләре китерде. Бик җитез, уңган халык бит сез.

«Татар почмагы»нда иң уникаль экспонат – чикләвек вату җайланмасы! Ул Былтыр бармагын кыстырган Шүрәле рәвешендә эшләнгән. Шүрәле авызына чикләвек саласың да, «шалт» урталай ярасың. Кызганыч, музейчылар экспонат китерүчеләрнең исемлеген алып бармаган. Әмма бу Шүрәле – гаҗәеп табылдык дип уйлыйбыз. Чөнки ул Җаектагы татар яисә башка милләт гаиләсендә Тукай рухы күптән яшәгәнен, һичьюгы, монда «Шүрәле»нең кем икәнен белеп торганнарын дәлилләүче ядкарь.

Җаекта зыялы татарлар яшәгән. Бу хакта XIX гасыр фотолары сөйли. Аларны безгә яшерен тартмачыктан өстәлгә җәеп директор әфәнде күрсәтте. Фотодагы геройларын исемләп белмәсәк тә, калфак-камзуллардан укымышлы гаиләләр икәнен чамаладык.

Ә бу рәсемнәрдә сез XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында Җаекта яшәгән татарларны күрәсез. Алар барысы да Җаек урамнары буйлап йөргәннәр, ниндидер һөнәр, шөгыль иясе булганнар.









Йөзләренә игътибар белән карасагыз, үзләренең дәрәҗәсен белү, үз-үзләрен хөрмәт итү чалымнарын күрерсез. Моннан бер гасыр элек Җаек халкының горур, бәйсез, шул ук вакытта киләчәккә карап рухи омтылыш белән яшәгәнлеген аңларсыз. Әлеге кешеләрне күрергә һәм үткән тарихка борылып карарга безгә кем ярдәм итте соң? Әлбәттә, иске Уральскиның фото осталары. Алар үз эшләрен шул хәтле нечкәләп һәм сыйфат белән башкарганнар ки, әлеге рәсемнәр гасыр гына түгел, артыграк вакыт үтсә дә, шулай ачык һәм сыйфатлы булып сакланырлар иде. Моннан бер гасыр элек Җаекта В.П. Ануфриев, Е.Н. Аршаулов, бертуган Вершковлар, Д.И. Донков, В. Конохов, П.Л. Поляков, А.В. Сиво, В.А. Юдин, С.А. Ярмарков кебек гаҗәп талантлы фоторәссамнар яшәгән. Аларның иҗаты безгә әйтерсең лә вакыт машинасына утырып үткән гасырга кире кайтырга ярдәм итә. Әлеге рәсемнәргә карап без моннан бер гасыр элек яшәгән җаеклыларның ничек киенгәннәрен, чәчләрен ничек йөрткәннәрен белә һәм, гомумән, ул чактагы тормыш-көнкүрешнең үзенчәлекләрен чамалый алабыз.

## Тукай иле

*«Һәр халыкның үз Тукае бар, ләкин Тукай барлык халыклар өчен дә уртак».*

*Сабит Мухамов, казакъ язучысы.*

Без Җаекны Тукай шәһәрчеге буларак кабул иттек. Шәһәрнең Аурразия проспектындагы билбордларда рус язучысы Лев Толстой, казакъ композиторы Кормангази белән беррәттән татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны күргәч, бигрәк тә гаҗәпләндек… Адым саен Тукай, әйтерсең Җаек – Тукай иле!

Аурразия проспекты безне кабат Татар бистәсенә китерде. Биредә Тукай белән бәйле урыннар шактый: Госмановлар йорты, «Казан» кунакханәсе, Ванюшиннар йорты, Тукай укыган рус мәктәбе, Тукай скверы… Шул скверга 2001 нче елның 30 нчы октябрендә куелган Тукай һәйкәле – Җаек татарларына Минтимер Шәймиев бүләге. Скульпторы – М.М. Гасимов, архитекторлары С.С. Айдаров, А.М. Галеев, Р.А. Вафиев. 2002 нче елдан башлап шагыйрьнең туган көнендә монда ел саен шигырь бәйрәме үткәрәләр.

Тукай бюсты шәһәрнең гүзәл паркында урнашкан. Күптән түгел бирегә җиз эскәмияләр, ут лампалары куйганнар. «Хәл җыеп, күккә карап» без дә бу паркта ял итеп алдык. Шунысы куанычлы, монда кеше өзелми. Бигрәк тә китап сөючеләр җыела. Кайберәүләр Тукай янына басып фотога төшә, аңа чәчәкләр куя.

**Гөлназ Галимҗанова**




**Риман Гыйлемханов һәм Разак Әбүзәрев**

# «Казан» кунакханәсе

*«Тәшагырь итмә, зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син,*
*Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син».*
*Г. Тукай, «Мөтәшагыйрьгә»*
*(«Шагыйрь булып калучыга»), 1907 ел*

Габдулла Тукай Казанга киткәнче, ун айлар чамасы (1906-1907) Җаекның «Казан» кунакханәсендә яши. Биредә ул «Шүрәле» поэмасын, «Пар ат» шигырен иҗат итә. Хәзер кунакханә бинасында Җаек шәһәренең Мәгариф идарәсе урнашкан. 1932 нче елда монда Александр Пушкин исемендәге педагогика институты булганы билгеле.

Ә 1905 нче елга хәтле «Казан» кунакханәсе комплексы тулысынча Коммерция клубы була. Анда китапханә, ресторан, актлар залы урнашканлыгы билгеле. Комплекс 1880 нче елларда төзелгән дигән фараз бар. 1905 нче елда купец Карев йортында ремонт эшләре төгәлләнгәч, Коммерция клубы шунда күчә. Шул вакытта бушаган бинаны Камил Төхфәтуллин арендага алып, анда татарлар өчен мәгърифәт клубы, татар матбугаты өчен типография, уку һәм концерт заллары, ресторан-чәйханә эшләмәкче була. Күрәсең, бу ният барып чыкмый һәм «Казан» кунакханәсе бинасын Мортаза Гобәйдуллин арендага алып, татар рестораны, уку залы, кунакханә номерлары эшләтә.

Элеккеге «Казан» кунакханәсенең икенче каттагы залына узабыз. Разак әфәнде Тукай яшәгән бүлмәне яхшы хәтерли. Анда хәзер сәхнәле зал.

– Тәрәзәдән карагыз әле! Тукай моннан тирә-якны күзәтергә яраткан. Затлы, мәһабәт бинаны күрәсезме? Ул – сәүдәгәр Ванюшиннар йорты. Тукай анда әдәби кичәләргә йөргән, – диде Разак абый.

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап… Бу юллар фәкать Җаекта, «Казан»да гына туа ала шул. Тукай Казанны шулкадәр сагынып яшәгән ки, хәтта Җаекта «үз» Казанын табып, шедеврлар иҗат иткән…

Тукайның дусты Габдулла Кариев, бу кунакханәдә үткән тормышларын искә алып, болай дип яза: «Казан» номерында торганда (Г. Тукай – *Г.Г.*) бүлмәбездә чәй янында идән буена йөри-йөри шигырь яза, соңра миңа укыйдыр иде. Мин дә бик ихлас берлә тыңлый һәм күңелемә бик ошаганнарын бикләп тә аладыр идем. Бервакыт кыш көне «Казан» миһманханәсендә русларның ниндидер бер вечерлары булды. Шул вечерда Тукаев бер Хәкимҗан исемле иптәшебезне хәерче



**Тукай яшәгән «Казан» кунакханәсе**

киемнәре киендереп, үзе шуңар хитабән (мөрәҗәгать итеп) «Теләнче» нам шигырен укыды, халык бик яратты. Ләкин теге иптәшебезне берәр айга кадәр хәерче дип мыскыллап йөрделәр…»

Татар базары мәйданына еш чыга торган була Тукай. Бер елның язында кунакханә каршында урнашкан Ванюшиннар йортының өй кыегына карлыгачлар оялаган була. Тукай чыр-чу килгән кошларга күзен алмый озак карап торгач: «Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын оя итте минем сөйгән карлыгачым», – дип шигъри юллар әйтеп куя. 1909 нчы елда дөнья күргән «Карлыгач» әнә шулай туган шигырь.

Ванюшиннар йорты 1917 нче елга кадәр беренче өлкә идарәсе буларак хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы елларында монда эвакуацияләнгән Одесса пехота училищесы урнаша. Соңрак авыл хуҗалыгы техникумы, пионерлар сарае, казакъ урта мәктәбе була.

## Җаек басмаханәләре

*«И, каләм, безгә һәр сулуда ярдәм һәм мәрхәмәт ит:*
*Хәсрәт, ярлылык, хурлык, мескенлекләр – барысы да бетсен».*

*Г. Тукай, «И, каләм», 1906 ел*

Шулай бер сөйләшеп утырганда Марат Баһаутдинов Тукай белән кызыксынучы һәм бу як тарихын шактый еллар буе өйрәнүче бер кешенең исемен телгә алды. Рөстәм Вафиев дигән әлеге егет үзе сәнгать белгече, архитектор икән. Тукай бюстын эшләүдә катнашкан. Җаекта туып-үсеп, хәзер Петербургта баш архитектор ди. Аның туганнары заманында Тукай белән бик аралашканнар. Әлбәттә, безгә

Рөстәм әфәндене күрергә насыйп булмады, әмма Марат аркылы аның белән элемтә урнаштырдык. Рөстәм әфәнде һаман да Петербург архивларында казынуын дәвам итә һәм Җаекта Тукай яшәгән чорга кагылышлы мәгълүматлар җибәрә тора.

Кызганыч, хәзергә «Тукай фонды»ның Петербургка «кулы җитми» әле, насыйп итсә үзебез дә барып чыгарбыз. Тукай буенча белгечләр дә хәзергә төрле архивларда эзләнергә вакыт таба алмый кебек. Ә «вакыт галиҗәнапләре» артык сузганны яратмый ул. Шуңа күрә без күргән-белгән, ишеткәннәрне укучыларыбызга тизрәк җиткерә торырга булдык.

Киләсе елга Казакъстанның Җаек каласындагы беренче басмаханәгә 150 ел тула. Бу уңайдан Рөстәм Вафиев Тукай музее директоры Марат әфәндегә хат юллаган, ә ул аны безгә җибәрде.

Беренче басмаханәгә А.Д. Столыпин нигез салган икән һәм ул «Гаскәри басмаханә» («Войсковая типография») дип аталган.

Камил Мотыйгый үз газеталарын чыгарган вакытта, ягъни 1905 нче елда Җаекта 5 басмаханә булган. Беренчесен атадым инде. Икенчесе – Өлкә басмаханәсе. Анда «Уральские областные ведомости», төрле хисап документлары, брошюралар бастырылган. Басмаханә өлкә идарәсендә урнашкан булган һәм бу китапта без әлеге бинаны «Ванюшиннар йорты» («Казан» кунакханәсе каршында) дип телгә алдык инде. Сүз уңаеннан: заманының алдынгы карашлы зыялыларыннан исәпләнгән Ванюшин Камил Мотыйгый белән дустанә мөнәсәбәттә була.

Өченчесе – Жаворонкова фамилияле ханымның шәхси басмаханәсе. Анда баштарак «Уральский листок объявлений», соңрак «Уральский листок» басыла. Ә инде 1907 нче ел ахыры, 1908 нче ел башында Камил Төхфәтуллин «Мусин» фамилиясе астында «Яңа тормыш» дигән газета чыгара башлый. Бу вакытта инде Казанда булу сәбәпле, Г. Тукай әлеге газетага үз өлешен кертә алмаган. Камил белән арасын өзеп киткәнгә күрә, бәлки, ул чыгарган газета белән әлләни язышмагандыр һәм «Яңа тормыш»ка шигырьләрен дә җибәрмәгәндер. Һәрхәлдә, безнең бу хакта төгәл мәгълүматка юлыкканыбыз юк. Хәер, «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» дигән китапта (Казан, Таткитнәшр, 2003 ел) саран гына бер мәгълүматка тап булдык. «Яңа тормыш»ның 5 нче санында Тукайның «Әл-ислах»та басылган «Бер манигы тәрәккыйгә» дигән шигыренә югары бәя бирелгән. Рецензиянең авторы куелмаган. Галим Ф. Яхин фикеренчә, аны К. Мотыйгый язган. Бик мөмкин, бик мөмкин. Никадәр һавалы булмасын, Камил инде татар шигърияте күгендә иң якты йолдыз булып кабынган Тукай белән үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу юлын эзләми калмагандыр.

Инде басмаханәләрне санап бетерик. Дүртенчесе – купец Симаковныкы. Покров чиркәвен төзетүче буларак, Симаков, нигездә, дини, иске карашлы әдәбият бастыру белән шөгыльләнгән. Ә менә бишенчесе – «Уралец» басмаханәсендә Төхфәтуллин нәшер иткән бөтен татар газеталары басылган. Әлеге басмаханәнең беренче адресы билгеле түгел.

Г. Тукайга килсәк, ул Чапаев урамындагы басмаханәдә эшләгән. Аннан соң басмаханә Симаков йортына күчкән (Коммунистическая-Крестовая урамы), Р. Вафиев әйткәнчә, шул вакытта Камил Төхфәтуллин аны арендага алган да инде.

Рөстәм әфәнде хатында тагын бер кызыклы мәгълүмат бар. «Шул ук 1905 нче елның августында, – ди ул, – К. Төхфәтуллин Рус сәүдә-промышленность банкының Җаек бүлекчәсе башлыгы Краузе белән килешү төзеп, басмаханәне әлеге банк бинасының ярымподвалына күчерә. Керү ишек алдыннан була. Төхфәтуллинның «Уралец», «Уральский дневник»лары шунда басыла да инде».

Басмаханәгә Камил «Тәраккый» дип исем куша. Ярый, хуш, әлеге басмаханәдә урыс газеталары чыксын да ди, ә татарчалары кайда басыла соң? Рөстәм Вафиев фаразлавынча, шул ук «Тәраккый» басмаханәсендә. Аның дәлилләре дә ышандырырлык. Банк бинасы үзәктән пар белән җылытыла, аның үз электр станциясе, редакциядә аерым телефон һәм куәтле станоклар була. Шуңа күрә Камил Төхфәтуллин нигә әле татар газеталары өчен өстәмә акча түгеп башка бина алсын ди?! Аннан соң «Фикер» газетасының тиражы, мәсәлән, «Уральский дневник»ныкыннан шактый зур була һәм бөтен илгә тарала торган «Фикер»не кечкенә подвалда урнашкан басмаханәдә чыгарып булмый.

Ә инде Төхфәтуллиннар өенең подвалына килсәк, Р. Вафиев анда, кайберәүләр язуынча, янгын да, погром да булмаган дигән фикердә. «Юкса бу хакта бөтен шәһәр шаулаган булыр иде, рус газеталары да язмый калмас иде», – ди Р. Вафиев. Күрәсең, Р. Вафиев ул вакытларда нәшер ителгән өч урысча газетаның берсендә дә бернинди мәгълүмат та тапмаган. Ә урыс матбугаты белә торып күз йомса? Моңа ышануы кыен. Чөнки Тукай чорында татарлар шәһәр тормышында зур роль уйнаганнар һәм татар дөньясында «шылт иткән» һәр нәрсә матбугатта яктыртылып барган. Мортаза Гобәйдуллинның урысча школа ачуын гына искә төшерегез. М. Гобәйдуллин дигәннән, бөтен татар газеталары аның кулына күчкәч, кайда бастырылалар соң? Әлбәттә, Төхфәтуллиннар подвалында түгелдер. Менә дигән бинада «Тәрәккый» басмаханәсе булганда, идән астына «качуның» хаҗәте бармы соң?

Димәк, Тукай язышкан татар газеталары Рус сәүдә-промышленность банкы бинасында һәм Симаков йортында нәшер ителгән. Бу инде Тукай белән бәйле тарихи урыннар исемлегенә тагын ике йорт өстәлде дигән сүз. Һәм иң куанычлысы – алар бүген дә исән. Банк йортында бүген шәһәр акимәте урнашкан.

**Риман Гыйлемханов**

# Нәҗип Җиһанов



**Нәҗип Җиһанов**

Татар казакъларга Латыйф Хәмидине бирсә, Җаек безгә Нәҗип Җиһановны бирде. Сәфәр вакытында әлеге шәхес белән бәйле урыннар белән дә таныштык.

Яшьләй ятим калган Нәҗип Җиһановны сыендырган балалар йорты бинасы да исән икән әле.

• Нәҗип Гаяз улы Җиһанов – композитор, халык артисты, педагог. Дәүләт премияләре иясе. Казан консерваториясенең беренче ректоры. 1911 нче елның 15 нче гыйнваренда Җаекта туа. 77 яшендә Уфада (Башкортстан) вафат була. Казанның Арча кыры зиратында күмелә.

• Н. Җиһанов 1928 нче елда Казанга килә. Үзлегеннән фортепианода уйнарга өйрәнә. Казан музыка училищесын, Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка техникумын тәмамлый. 1945 нче елда Казанда консерваториягә нигез сала.

• 1939-1977 нче елларда Татар АССРның композиторлар Союзын җитәкли. Казанда Татар опера һәм балет театрының ачылуы, Дәүләт симфоник оркестрының оешуы, консерватория каршындагы лицей ачылу аның исеме белән бәйле.

• Нәҗип Җиһанов 8 опера, 3 балет, бихисап симфония һәм камера әсәрләре авторы. Казанда композиторның мемориаль музей-фатиры бар.

• Казан, Прага (Чехия), Баньска Быстрица (Словакия) сәхнәләрендә куелган «Җәлил» операсы өчен, 1959 нчы елда Нәҗип Җиһанов Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

**Гөлназ Галимҗанова**

## «Мин Тукайны беләм!»

Җаекта кем генә булмаган: Александр II, Николай II, Ф.И. Шаляпин, В.Г. Короленко, А.С. Пушкин, В.И. Даль, В.А. Жуковский, Л.Н. Толстой… Соңгы дүрт шәхес Атаманнар йортында туктый. Әйтик, Пушкин, 1833 нче елда Җаекка килгәч, нибары 2 генә көн тора. Тукайга музей ачылган елда, Җаекта Пушкин истәлегенә дә музей ачалар. Хәтта паркта һәйкәл дә бар! Җаек – ул бит әле Пушкин күңелендә дә тирән эз калдырган шәһәр була. Монда җыйган материалларыннан чыгып, ул «Пугачев тарихы» дигән гыйльми хезмәт һәм «Капитан кызы» дигән повесть яза.




Разак Әбүзәрев фаразынча, Пушкинга һәйкәл кую тантанасында бөтен шәһәр халкы катнашкан һәм яшь Тукай да читтә калмаган.

Бу турыда Ибраһим Нуруллин «Моңлы саз чыңнары» (Казан, Таткитнәшр, 2000 ел) китабында: «Габдулла школада өченче кышын укыган вакытта Уральски җәмәгатьчелеге Пушкинның йөзъеллыгын киң итеп, зур итеп үтәрергә карар кылган. «Башлангыч белем бирүгә ярдәм җәмгыяте», зур программа төзеп, 1899 нчы елның мартында «Уралец» газетасында бастырып чыгара. Программада «Пушкин халык йорты» исемендәге махсус клуб ачу, анда түләүсез китапханә һәм уку залы булдыру, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрү, Пушкинның бюстын кую һәм башка чаралар каралган. 21 нче апрельдә «Урман дуслары җәмгыяте»нең башлап йөрүе һәм җитәкчелек итүе белән бакча утыртыла һәм аңа А.С. Пушкин исеме бирелә. Бу вакыйгада мең ярымнан артык кеше катнашкан. 26 нчы майда, ягъни Пушкинның



**Ә экскурсияне музей директоры Сара Искаир кызы Танабаева үзе алып барды**

тууына нәкъ йөз ел тулган көнне, 11 сәгать 30 минутта тантаналы рәвештә «Пушкин йорты» ачыла. Тантанага әзерлек эшләре тегеләйме-болаймы Габдулланың колагына ирешкәндер дип уйларга кирәк. Бакча утырту вакыйгасын, «Пушкин йорты»н ачу тантанасын да аның үз күзе белән күргән булуы бик ихтимал. Бәлки әле, Әхмәтша учитель классны ул тантанага үзе алып баргандыр», – дип яза.

Тукай гомере буе Пушкиннан үрнәк алып иҗат итә, аның күп кенә әсәрләрен тәрҗемә кыла һәм бөтен төрки дөньяга таныта. Тукайның ике классик рус шагыйрен өлге итеп кулланoccу турында дусты Г. Кариев болай дип яза: «…рус әдәбиятыннан Лермонтов һәм Пушкинның әсәрләрен бик яратып укый иде. Мин алар мәдрәсәсенә барган вакытта рус китапларыннан ике калын книга күрә идем: ул Лермонтовның һәм Пушкинның мәҗмугаи асаре икән. Мин моны соңыннан гына белдем».

Пушкин һәйкәлен карагач, музеена да сугылдык. Аның ачу тантанасында ике президент – В. Путин һәм Н. Назарбаев катнашкан. Музей бинасы элек Уральски казаклары атаманы йорты булган. Италия архитекторы Дельмедино аны 1825 нче елда төзеткән.

Безне бирегә бушлай керттеләр. Ә экскурсияне музей директоры Сара Искаир кызы Танабаева үзе алып барды. Ни дисәң дә, безне,

беренчедән, Тукай илчеләре итеп кабул итсәләр, икенчедән, Казан кунаклары идек бит. Сара ханым:

– Ә мин Тукайны беләм, – дип сүз башлады. – Казаннан галим Р. Нәфыйгов килгәч, аңа Тукай турында мәгълүмат җыештым. Тукайның бөтен тормыш юлы, иҗаты белән танышмын.

Без казакъ кардәшебез Сара ханымның татар шагыйренә булган ихласлыгына сокландык.

**Альбина Газизуллина**

# Меценатлар

*«Милләт образованный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мөнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә тота торган милләт арысланнарынна мохтаҗ...»*

*(Г. Тукай, «Хиссияте миллия», 1906 ел)*

## Шәйхулла Шәрифулла улы Нотфуллин

Татар Үзәгенә ярдәм кулы сузарга теләүчеләр Җаек эшмәкәрләре арасында табылып кына тора. Шуларның берсе – подполковник, шәһәр мәслихәте депутаты Шәйхулла Шәрифулла улы Нотфуллин.

Ул Чиләбедә туган, 1987 нче елда Җаек шәһәренә күченгән. «Барлык туганнарым да Татарстанда яши. Минем күңел дә шул якларга тартыла. 2000 нче елда Татар үзәгеннән матди ярдәм сорап мөрәҗәгать иттеләр. Хәлемнән килгәнчә булыштым, кризис дип тормадым. Кризис ул – Африкада да кризис. Без үз милләтебезнең үсешенә ярдәм итәргә тиешбез», – ди ул.



Шәйхулла әфәнде – шәһәр мәслихәтендә татарлардан беренче депутат. «Кечкенәдән Тукай турында ишетеп үстем. Балаларны ел да Кырлайга алып барабыз. Бөтендөнья Татар Конгрессы

ярдәме белән Үзәккә татар китаплары алып кайтабыз. Үзәкнең бай китапханәсе бар, – диде дә, ахырда, – эшләгән кешедә проблема була инде ул, ялкауларда гына бер борчу-мәшәкать тә юк…» – дип өстәп куйды.

## Ришат Увәли улы Хәйруллин

«Тукай» музее, Кызыл мәчет һәм Татар үзәгенең алыштыргысыз меценаты Ришат әфәнде Хәйруллин белән без сәфәрнең соңгы көнендә генә күрештек. Очрашуга ул кырык эшен кырык якка ташлап килгән иде.

«Мин кешеләргә ярдәм итүдән рәхәтлек кичерәм», – ди ул. Ришат Хәйруллин Уральски өлкәсе һәм Казакъстанның мәдәни-сәяси тормышында актив катнаша. 2005 нче елдан Җаек Татар үзәген җитәкли, Казакъстан Халыклары Ассамблеясе әгъзасы. Берничә ел дәвамында Җаекның Үзәк мәчетенә, Коткаручы Христос храмына, балалар хоккее һәм футболы үсешенә матди ярдәм күрсәтә.

«Бу тормышта яхшы исем алу җиңел түгел, аны югалту гына җиңел», – ди ул. Хезмәтенә күрә – хөрмәте. Ришат Хәйруллин Казакъстан президенты Н. Назарбаев карары белән – «Шәфәгать», «Казанның меңъеллыгы», Мәскәү һәм Бөтенрусия Патриархы медальләре белән бүләкләнгән.

Гадәттә, җитәкчеләр белән уртак тел табу ансат түгел. Аларны нәрсәгәдер ышандырырга, сөйләгән сүзеңнең дөреслеген дәлилләргә кирәк. Ришат әфәнде исә ул яктан безгә үрнәк күрсәтте. Уртага салып, гади генә сөйләшү күңелдә якты бер сәхифә булып калды.

– Тукай – ул безнең үткән дә, киләчәк тә. Заманында, язучылар, галимнәр Җаекка килеп йөргән. Аларны Җаек мәгърифәт һәм мәдәният мәркәзе буларак кызыксындырган. Эзләнүләр бүген дә бара. Менә сезнең дә Тукайның шигъри ватанына юлыгыз төшкән. Теләк шул – Тукайны киләчәк буын да нәкъ шулай өйрәнсен иде. Аның тормышы һәм иҗаты һәр чорда, һәр яшьтә кызыклы, гыйбрәтле, – дигән иде ул. Мондый сүзләрне Тукай рухы белән, милләт өчен җан атып яшәүче кеше генә әйтә ала.

**Гөлназ Галимҗанова**




Сулдан өченче – Җаекның атаклы меценаты Ришат Увәли улы Хәйруллин

## Без җаекка рәхмәтле

*«Милләт хыялы, һичшиксез, барлык хыялдан татлырак,*
*Мин юләрләнсәм дә, шул хыялдан гына юләрләнермен».*
*Г. Тукай, «Милләткә», 1906 ел*

Үзе исән вакытта ук «халык шагыйре» исеме алган Бөек Тукай берничә гасыр дәвамында Русия империясендә милли һәм дини изүне шактый татыган татар халкы өчен кем иде соң?

80 ел буе Тукай иҗаты шактый өйрәнелде. Соңгы 25 ел эчендә шагыйрьнең гомуми танылу алган әсәрләрен, яки балалар өчен язылган шигырьләрен туплап юбилей уңае белән җыентыклар нәшер ителде, аерым фәнни мәкаләләр басылды, фәнни-гамәли конференцияләр уздырылды. Тик шагыйрь иҗатын тагын бер баскычка күтәрү өчен болар гына аз иде.

Шуны да әйтим: фәнни язмаларда һәм конференцияләрдә, күп очракларда шагыйрьгә аның «IV томлык» һәм «V томлык»ларында дөнья күргән шигырь һәм публицистик мәкаләләренә таянып берьяклырак, заман идеологиясе кушканча бәя бирелде.

Ниһаять, XXI гасырның беренче унъеллыгы узып барганда бу ялгышларны төзәтү, Тукай иҗатын булдыра алган кадәр тулыландыру мөмкинлеге туды. 2006 нчы елда Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына директор булып, фольклор галиме, профессор Ким Мөгаллим улы Миңнуллин килгәч, беренче көннәрдән үк Г. Тукайның VI томлык әсәрләре тупланмасын төзеп бастыру мәсьәләсен куйды. Әмма институтның текстология бүлеге фәнни хезмәткәрләре тагын бер мәшһүребез Г. Исхакыйның XV томлык әсәрләрен төзү белән шөгыльләнү сәбәпле, бу эш бераз кичектерелде. Ниһаять, 2011 нче елдан Г. Тукай томнарын нәшер итү текстология бүлегенең төп эш планына кертелде. Әлеге гамәлне тормышка ашыруга күпмедер дәрәҗәдә өлеш кертү өчен Риман әфәнде Гыйлемханов җитәкчелегендәге «Тукай фонды» әгъзалары белән бергә, без Җаек шәһәренә сәфәр чыктык.

Фәнни экспедициянең бу каладан башлануы очраклы түгел иде. Шигърияттә тәүге чирканчыкларын алу, 1905-1907 нче елгы инкыйлаб дулкынында барлыкка килгән вакытлы матбугат аша милләтнең күренекле шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелү белән бергә, Тукайның шагыйрьлек сиземләве (фәндә пәйгамбәрлек дип атау да бар) аркылы милләтнең төзәтеп булмаслык милли фаҗигасына әйләнгән кимчелекләрен ачып бирә алу дәрәҗәсенә ирешкән шәһәре дә ул Җаек. «Тукай фонды» әгъзалары белән берлектә озын юлга чыгуның төп максаты, әлбәттә, иң беренче чиратта, Уральски өлкә архивында





**Шәһәрнең Татар каберлеге бездә аеруча кызыксыну уятты**

Тукай чорына кагылышлы архив чыганакларын барлау, икенчедән, XIX гасыр ахыры XX гасыр башы татар мохитын хәтерендә саклаган Татар каберлеген өйрәнү иде. Шул максатларны Җаекның Тукай музее директоры Марат Баһаутдиновка аңлаттык. Аның ярдәме белән Уральски өлкә архивында һәм татар каберлегендә булдык. 1920 нче елга кадәрге Уральски тарихын чагылдырган язма чыганакларның Оренбург губерна архивында саклануы ачыкланды. 1917 нче елгы инкыйлабка кадәр Уральски шәһәренең Тургай өлкәсенә керүе һәм аның үзәге Оренбургта икәнен белсәк тә, күңелне тынычландыру, үзебезне ышандыру өчен архивны үз күзләребез белән күрү кирәк иде. Камил Мотыйгый нәширлегендә дөнья күргән «Фикер», «Уралец», «Уральский дневник» газеталарының тулы саннары Санкт-Петербург китапханәләрендә саклану ихтималы барлыгы да ачыкланды.

Халык һәм дәүләтләрнең тарихи хәтерен архив, яисә төрле язма чыганаклар гына сакламый, ә бәлки, каберлек һәм кабер өстенә куелган ташлар да дәлилле чыганак булып тора.

Ләкин архив чыганакларыннан аермалы буларак, аларның юкка чыгу куркынычы күпкә зуррак. Җаектагы Татар зиратына да шундый куркыныч яный, тирә-юнендә завод-фабрика корылмалары, шуңа өстәп казакъ төрбәләре шактый очрый.

Шәһәрнең Татар каберлеге бездә, әлбәттә, аеруча кызыксыну уятты. Кызганыч ки, бу зиратка татар галимнәренең аяк басканы булмаган.

Сакланып калган өлеше әлләни зур түгел. Каберлектә XIX гасырның 80 нче елларыннан алып XX гасырның 20 нче еллар урталарына кадәр чорда Җаекта яшәгән татар сәүдәгәрләре, зыялыларының һәм гади халыкның тарихи хәтере күмелгән. Анда бүген дә сынлы сәнгать әсәрләренең гүзәл үрнәкләре саналырлык 150 ләп кабер ташы да җентекле өйрәнүне көтә. Соңаруыбыз да ихтимал, чөнки әйткәнемчә, Татар зиратында казакъ төрбәләре көннән-көн арта бара. Шуны да искәртү кирәк: кабер ташлары сәнгатьчә эшләнеше белән Башкортстанның кайбер төбәкләре, Оренбург Татар зираты һәм Татар Каргалысы каберлекләрен хәтерләтәләр. Аларда да шул стильдә башкарылган ташлар саклана. Бу төбәкләрдәге кабер ташларының игътибар итәрлек икенче ягы – алар күпчелек татарның элекке Казан губернасыннан күчеп килүен раславы. Мөһаҗирлек чоры, нигездә, XVIII гасырдан башлана. Ташларда мәрхүмнәрнең, мәсәлән, Казан, Зөя өязенә, яисә башка өязгә кергән авыллардан килгәнлеге дә язылган. Чыганаклар шул яклары белән әһәмиятле: Җаекның Татар зиратындагы кабер ташларын җентекле өйрәнү Тукайның чордашлары турында өстәмә мәгълүмат бирер иде. Тукай иҗатында билгеле бер дәрәҗәдә искә алынган шәхесләрне «фәнни әйләнешкә» кертү мөмкинлеге дә туар иде.

Мәгълүм ки, Җаек – казакълар шәһәре. Һәвәскәр тарихчы Н.Г. Чесноковның «Город малиновых зорь» китабында язылганча, татарлар бирегә XIX гасырның 40 нчы елларында күпләп килеп урнаша. Чынлыкта исә, Җаек базарларында татарларның XIX гасыр башларында ук сату белән шөгыльләнүләре билгеле. Бүген биредә чыгышы белән Татарстанның Кайбыч төбәгеннән булган мәгърифәтче, мөгаллим Мотыйгулла Төхфәтуллинның шәхси йортына урнашкан Г. Тукай музеенда Җаекта гомер кичергән татарлар тарихын чагылдырган экспонатларга аерым урын бирелгән. Ягъни бинаның беренче катында Җаек татарлары тарихы, икенче катта Тукай шәхесен һәм иҗатын яктырткан экспонатлар һәм күргәзмә әсбаплар исә, Җаек татарларын Тукай образы аша тарих мәйданына чыгара сыман. Һәрхәлдә, беренче карашка бездә шундый тәэсир калды. Шунысы ачык: шагыйрьнең Җаек чоры иҗатын шәһәр тарихыннан аерып карау мөмкин түгел, алар бер-берсен тулыландырган бербөтен организмны тәшкил итә. Музей директоры Марат әфәнде Баһаутдиновның сүзләренә караганда, музейны материаллар белән баетуда беренче чиратта Уральски өлкә музее, җәмәгатьчелек шартларында яшәгән «Иске Уральски» музее ярдәм иткән, шулай ук шәхси кулларда сакланган чыганаклар да музейда тиешле урынны алган.






**Мотыйгулла Төхфәтуллин кабере. Аңа хәзрәтнең кызы Галия Кайбицкая яңа таш куйдырган булган; Әле безнең кабер ташларына язылган тарихыбыз да бар**

Форсаттан файдаланып, Тукай музеена кагылышлы кайбер фикерләр белән уртаклашу да урынлыдыр дип саныйм. Иң элек монда яшәүче кардәшләребезгә рәхмәт. Тукай музее исеме астында Җаек татарлары тарихын да берләштергән музей ачулары үзе үк зур батырлык. Татарстанның үзендә Тукайга җитәрлек игътибар булмаган бер заманда, чит дәүләт – Казакъстанда шагыйрьне олылау үзе мактауга лаек.

Бер елны Казандагы Тукай музеенда «түгәрәк өстәл» уздырылган иде. Сөйләшүнең төп максаты – музейны яңа экспонатлар белән баету, күргәзмә залларын үзгәртеп кору, янкормалар төзү һәм башка мәсьәләләрне хөкүмәт дәрәҗәсендә күтәрү иде. Җәмәгатьчелек музей хезмәткәрләре тәкъдимнәрен хуплап каршы алса да, җитәкчелек, аерым депутатлар, һәрвакыттагыча, акча юклыкка басым ясадылар. Түгәрәк өстәлдә шушы юлларның авторы да катнашып, Тукай музее эшчәнлеген яхшырту, халыкны музейга күбрәк җәлеп итү өчен аны фәкать Яңа Бистәнең XX гасыр башы архитектурасы үрнәгендә генә яңарту мөмкин булачагын әйткән иде. Музейга нинди генә финанс ярдәме күрсәтелмәсен, Тукай рухы һәм XX гасыр башы стиле сакланмаса, халыкны да, туристларны да музейга тарту җиңел булмас, мөгаен. Бу очракта Җаек шәһәре бәхетле.

Музей эшчәнлеген камилләштерү максатыннан, уйланырлык нәрсәләр дә бар. Беренчедән, музейны экспонатлар белән баету, яңарту мәсьәләсе. Җаек шартларында бу гамәл тормышка ашмаслык бер эш дип уйлаучылар да табылыр. Әмма Казан һәм Кырлайның Тукай исемендәге музейлары, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән элемтәләр урнаштырып, күп кенә кульязма һәм басма чыганакларны, шул исәптән, шагыйрьнең шәхси әйберләренең күчермәсен монда биреп булыр иде. Музей белән танышып йөргәндә Камил Мотыйгый һәм Тукай мөнәсәбәтенә караган материаллар җитәрлек булмавы да күңелне тырнап алды. Тукайның Тукай дәрәҗәсенә ирешүендә Мотыйгулла хәзрәт беренче урында булса, икенче урында исә, нинди генә каршылыклы һәм нинди генә эшчәнлек алып бармасын, Камил Мотыйгый тора. Бәлкем, киләчәктә музейда бу мәсьәләгә игътибар итәрләр. Инде килеп, музей эшчәнлеген камилләштерү йөзеннән, Тукай шәхесе һәм иҗатын белү белән шагыйрь яшәгән мохитны да өйрәнгән, һәм гомумән, Җаек татарлары тарихыннан киң мәгълүматлы, тирән гуманитар белемле, экскурсия белән җитәкчелек итәрлек кеше дә кирәк. Дөрес, бүген профессор Разак әфәнде Әбүзәрев үзенең белемен килгән кунаклар һәм туристлар белән теләп уртаклаша. Ләкин аңа ярдәмгә көч-куәте ташып торган, һәм, әлбәттә, музейның эш принципларын яхшы белгән яшь кешенең дә алынуы ямь өстенә ямь булыр иде. Аннан соң, юл күрсәткече булдырып, шуның нигезендә планлы рәвештә экскурсияләр оештырганда, музей эшчәнлеге уңай якка гына үзгәрер иде.

Гомумән, безне шул куандырды: Тукайны Җаекта онытмыйлар. Бүген шагыйрь шәхесе шәһәр тарихының аерылгысыз бер өлеше итеп карала. Әлегә музей эшчәнлеге шәһәрнең энтузиастлары кулында булып, татар эшмәкәрләре тарафыннан финанслана. Киләчәктә, бәлкем, Җаек хөкүмәте Тукай шәхесенә күбрәк игътибарны юнәлтү һәм Җаек тарихында татарларның тоткан ролен күрсәтү йөзеннән, җаваплылыкның бер өлешен үз өстенә алыр. Татар зираты да шундый кайгыртуны сорый. Без татар халкының символик образы – Тукай һәм аның иҗат мирасын, рухын саклаган өчен Җаек татарларына рәхмәт әйтәбез, матур гамәлләрен мактап искә алабыз, аларга үтә дә катлаулы һәм милләте каршында җаваплы эшләрендә уңышлар телибез.

**Зөфәр Мөхәмммәтшин**

# Тукай һәм аның остазы

*«Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә латыйф (нечкә һәм гүзәл) булып, анчак гүзәл вә мокатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр. Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре иманланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез караучан булалар».*

*Г. Тукай, «Мокатдимә», 1910 ел*

Габдулла Тукайның кыска гына гомерен өч чорга бүләргә мөмкин. Бу – шагыйрь туып-үскән Казан арты еллары, үсеп-җитлегеп, шәкерттән шагыйрь булган һәм танылу алган Җаек чоры һәм, ниһаять, гомернең соңгы еллары – Казан чоры. Кайда гына яшәсә дә, аның тормышында аерым шәхесләр зур роль уйнаган. Бүген шуларның икесен олылап телгә аласы килә.

Беренчесе – Александр Пушкин. Бөек рус шагыйренең булачак татар шагыйренә йогынтысы ни дәрәҗәдә булуы хакында күп языла, күп сөйләнелә. Тик сүзебез бу хакта түгел. Иң элек башка чыганакларда күзгә чалынмаган бер сорауга җавап табасы килә. Ни өчен Габдулла үзен «Апуш» диеп атарга рөхсәт иткән? Кайдан килгән аңа бу кушамат?

Җаекта яшәгән Төхфәтуллиннар гаиләсендә буыннан-буынга шундый риваять сакланган: Габдулла кечкенәдән әкиятләргә, соңрак шигырьләргә тартыла. Әле рус телен аңлар-аңламас хәлдә үк, Пушкинның кайбер әсәрләрен белә һәм ярата башлый. Пушкинның үзен дә бик хөрмәт итә, әлбәттә. Иптәшләренә кушаматлар эзләгәндә, Габдулла бу эшкә иҗади яктан килә һәм үзенә дә русның бөек шагыйре исем-фамилиясеннән «Апуш» (Александр Пушкин) дигән кушамат ала. Бу башкаларга да ошый һәм кушамат шулай телгә кереп тә китә. «Апуш» атамасының чыгышы бик гади булса да, бу Г. Тукайның тормышында да, иҗатында да гомерлек бәйләнеш хасил итә.

Габдулла Тукай язмышына хәлиткеч йогынты ясаган тагын бер шәхес – Мотыйгулла Төхфәтуллин. «Мотыйгулла кем булган?», – дип сорасаң, татарның күбесе кыенрак хәлдә калыр иде. Андый язучы булмаган, әсәрләре юк. Без бит Мөхәммәдъярдан алып Каюм Насыйрига кадәр һәм аннан соңрак яшәгән шәхесләрне, нигездә, язма мираслары, истәлекләр аша беләбез. Тукай белән бәйләнешле

булган икән, димәк, Мотыйгулла турында да нинди дә булса мәгълүмат шагыйрьнең үз язмаларыннан да килеп чыгарга тиеш иде кебек. Әмма анысы да юк дәрәҗәсендә.

Г. Тукайның тормышын, иҗатын фәнни өйрәнүгә Совет елларында нигез салына һәм бу эшчәнлек дистәләгән еллар буе дәвам итә. XX гасыр башында төп тәгълимат Русиядәге революция һәм революциянең татар тормышына да зур йогынты ясавы белән бәйле була. Габдулла да Җаек эшчеләренең 1 нче Май чыгышларында катнашкан, яисә, һичьюгы, карап-күзәтеп барган. Совет еллары күзлегеннән караганда, Пушкин да патшаның дошманы. Герценнан алып башка язучылар да, гомумән, 100 ел буена революция әзерләгәннәр. Татарның Тукае читтә кала аламы соң бу хәрәкәттән?! Әлбәттә, юк! Тукай, чын революционер булмаса да, һичьюгы революцион-демократ булган. Рас шулай икән, «революцион Тукай темасы»нда ниндидер мулла-хәзрәтләргә урын каламы соң инде? Тукайның Мотыйгулла хәзрәтне еш телгә алмавы күпмедер дәрәҗәдә әнә шушының белән дә бәйле дип уйлыйм. Булачак революционер – яшьләр укыган мәдрәсә-семинарияләр исә бары тик «догматик, схоластик» мәгърифәтне каплап торучы пәрдә генә булган. Бу пәрдәне аеруча батыр рухлы, революциягә, яңалыкка омтылучы, муллалар белән көрәшеп (ә кем белән көрәшсен соң инде?) чыныкканнар гына ерта-җимерә ала.

Чынлыкта, бу – безнең Тукайны шулай итеп кабул иткән образ. Бу «әкияттә» рольләр бүленгән. Муллаларга, алар нинди талантлы мөгаллим булсалар да, уңай бәя бирелми. Шул ук вакытта, укытучыларны бөтенләй төшереп калдырып та булмый, мәсәлән, мулла булып тормаган Әхмәтша – учитель кебекләрне.

Чыннан да, мәдрәсәләр дә, мөгаллимнәр дә төрле һәм араларында бик алга киткәннәре дә булган. Юкса, Тукай кебек талантлар кайдан гына чыккан да, ничек кенә үскән соң? Шушындый чишмәләр башын өйрәнүгә Тукайга 125 ел тулу да җитмәгән кебек әле.

Кызганычка каршы, Тукайның Җаек чоры да начар өйрәнелгән. Бу шәһәр хәзер чит илдә калса да, анда Тукайның, ниһаять, музее оешты. Тик ни гаҗәп, Тукай музее дип кереп карап чыккач, башка бүтән фикер дә килә. Бу бит чынбарлыкта, Мотыйгулла хәзрәт музее. Музей урнашкан бина анык. «Мотыйгыя» мәдрәсәсе бинасы элек бөтен бер комплекс булган. Беренчеләрдән булып чыккан татарча газета һәм журнал шушы өйнең подвалында җыелган һәм басылган. Габдулла монда укыган һәм, хәтта яшәгән. Беренче шигырьләрен язган, язганын үзе җыйган, бастырган. Тарихи яктан да бу музей – үзе бер дөнья, татар дөньясы.



**Мотыйгулла хәзрәт һәм Тукай. Бу рәсемне музейга хәзрәтнең оныкчыгы рәссам Ильяс Айдаров бүләк иткән**

Мотыйгулла Төхфәтулла улы 1840 нчы елда, Кече Кайбыч авылында дөньяга килә. Муллалар нәселенең дәвамчысы Төхфәтулла хәзрәт хаҗ кылып кайтканда серле үлем белән дөньядан китә. Мотыйгулла кечкенәдән ятим кала. Әллә ятимлектән, әллә нәселдән, сәеррәк бала булып үсә. «Сәерлеге» исә моңлы булуында, укуга, китапларга кирәгеннән артык тартылуда. Бу баланың чынлап та белеп укыймы, әллә белмичә генә укыймы икәнен «ачыклаган» авыл картлары, бергә җыелып, мондый фикергә киләләр: бу безнең арада сирәк очрый торган зирәк бала. Димәк, аны укытырга кирәк. Ә якын-тирәдә аңа гыйлем бирердәй мәдрәсә юк. XIX гасыр уртасы. Юллар авыр булса да, Мотыйгулланы Казан аркылы, Кышкар мәдрәсәсенә озаталар. Мотыйгулла уңышлы укыган. Туган ягын сагынса да, еш кайта алмаган. Мөстәкыйльлеккә бик яшьли күнеккән.

Укыганда үзе шикелле шәкерт – Кушлавыч авылыннан килгән Мөхәммәтгариф белән дуслаша ул. Бер-берсенә «ахирәт» дип дәшәләр. Мотыйгулла үз ягына кайта алмаса, ахирәтләр кунакка – каникулга Кышкардан ерак булмаган Кушлавычка юл тоталар. Мотыйгулла соңрак: «Мәмдүдә түтинең кыстыбыйларын күп ашарга туры килде, хәзер дә авызда тәмнәре тора әле», – дип әйтә торган була.

Ул вакыттагы уку шартлары шундый: шәкертләр мәдрәсәдән япь-яшь килеш авыру эләктереп чыгалар. Ахирәтләр моны белә һәм үзара сүз куешалар: әгәр гаиләдә бәхетсезлек килеп берәрсенең балалары ятим калса, алар турында исән калганы кайгыртырга тиеш.

Шулай килеп чыга да. Мөхәммәтгариф үз авылында мулла булу бәхетенә ирешә, тормыш кора, вә ләкин дөньядан иртә китеп бара. Бала ятим кала. Ә ахирәт кайда?

Ә Мотыйгулла, Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап үз авылына кайта. Бердән, Кече Кайбыч авылы беркайчан да муллясыз тормый. Икенчедән, Төхфәтулла хаҗиның баласында галимлек чалымнары сизелә һәм авыл картлары янәдән җыелып, тагын да укытырга кирәк бу егетне, дигән карарга киләләр. Әмма Бохара белән генә чикләнмичә, дөньяда иң абруйлы саналган беренче мөселман университеты-мәдрәсәсенә җибәрергә карар итәләр. Бу Каһирә шәһәрендәге Әл-Әзһәр була инде. Юлына да, баргач торырлыгына да акча җыеп чыгарып җибәрәләр. Татарлардан Әл-Әзһәргә беренче булып килеп эләккән шәкерт Мотыйгулла була.

Әмма ләкин, аның Мөхәммәтгариф ахирәткә дигән амәнәте үтәлми тора бит әле. Ара бик ерак. Бернинди чара юк. Бу вакытта, булачак шагыйрь Габдуллаҗанга, дөньяның ачысын-төчесен дә, михнәтләрен дә, әз-мәз шатлыгын да татырга кушылгандыр Аллаһы Тәгалә тарафыннан.

Мотыйгулла Каһирәдә 10 елга якын укып белем алып, галим дәрәҗәсендәге шәхес булып, туган якларга кайтырга чыга. Кайтышлый, юл өстендәге Уральски каласында, туган тиешле апаларына туктала. Тау Гайни мәхәлләсендәге мәчеткә намазга керә. Мәчет картлары мөхтәрәм кыяфәтле галимнән берәр дога укып күрсәтүен сорыйлар. Бик моңлы тавыш белән укып җибәрә бу, халык таң кала. Бераз һушларына килгәч, дигәндәй: «Монда кал әле, безгә хезмәт ит әле», – диләр. «Юк, кала алмыйм, авылым халкы каршында бурычлы мин», – ди Мотыйгулла. Бер фараз буенча аның Җаекка кире кайтуын сорап, Кайбыч халкына үзе киткәч, үтенеч хаты язып салалар, икенче фараз буенча исә, хатны үзенә биреп җибәрәләр. Әйткәнемчә, авылда болай да мулласыз тормаганнар. Аннары, мондый галимнең гади авылда калуында бик мәгънә дә күрмәгәннәрдер. Шулай итеп Кече Кайбыч халкы Мотыйгуллага Җаек шәһәренә китеп урнашырга фатыйха бирә.

Бу урында Тау Гайни исемле шәхесне телгә алырга кирәк әле. Ул үз мәхәлләсендә мәчетне тотып торучы, шул ук мәхәлләдә мәдрәсә ачарга уйлап йөргән, картая башлаган бай сәүдәгәр булган. Кайбер фаразлар буенча, чыгышы белән Кайбыч районы Борындык авылыннан. Борындык элек сәүдәгәрләр авылы саналган. Аның янында биек тау булган: «Тау Гайни» дип йөртелүе дә шул тау белән бәйле түгел микән дигән уй бар. Килүгә үк Тау Гайни Мотыйгуллага үзенең йортларының берсен бирә, асрау булса да, бик күркәм һәм булдыклы Гыйззинәс дигән кызга өйләндерә. Гаиләдә 17 бала туып, яртысыннан артыгы бала чакта ук үлә. Үсеп җиткәннәре: Камил Мотыйгый, Галия Кайбицкая, Әдһәм Кайбицкий, Тукайны соңгы юлга да озаткан Гариф һәм татар дөньясында шактый тирән эз калдырган башка балалар.

Соңрак Тау Гайни бу ишле гаиләгә атап 2 катлы таш йорт салып бирә. Менә шул йортта инде бүгенге көндә Тукай музее урнашкан. Ә ул вакытта монда мәдрәсә була. Исеме – «Мотыйгыя».

Бу мәдрәсәдә иң алдынгы уку алымнары кулланылган, дөньяви фәннәр өйрәнелгән. Үзе күрше мәдрәсәдә укып «Карый» дәрәҗәсенә ирешкән Габдулла Кариев та шушы мәдрәсәдә укырга кызыккан. Укымаса да килеп йөргән, шигъри кичәләрдә катнашып артистлыгын чарлаган. Артистлыкка да, шигъриятьтә каләм тибрәтүчеләргә дә юл ачык була мәдрәсәдә. Беренче кульязма газета-журналлар, шигырьне сәнгатьле укулар, беренче театр-концерт тамашалары XX гасыр башында мәдрәсәне бик популярлаштыра. Шәһәрнең татар карагруһчылары исә Мотыйгулланы, аның мәдрәсәсен беренче дошман итеп күрә. Сүздә генә калмыйлар, берничә тапкыр һөҗүм итәләр, хәтта ут төртеп яндыралар. Шундый янгыннарның берсендә

Мотыйгулланы үлемнән бер урыс абзые гына коткарып кала. Болар һәм башка авырлыклар Мотыйгулланың сәламәтлеген тәмам какшата, сукыраюга китерә.

Мотыйгулла хәзрәт үзенең дусты – Кушлавычның Мөхәммәтгариф язмышы белән Каһирәдән кайтуга ук кызыксынганмы, монысы тәгаен генә билгеле түгел. Әмма ләкин кечкенә Габдулла, тиктомалдан гына Җаекка җыенып китмәгәндер. Әлбәттә, бу фикер бәхәсле. Миңа калса, Мотыйгулла хәзрәт, Гариф мулланың малае ятим калганын белеп, аны үз янына алдырырга теләгән. Ләкин, Габдулланың үз җизнәсе була торып, ул «чиратны боза» алмаган. Бары тик итәгатьле рәвештә, малайны шәһәргә чакырырга кирәк дип ишарә генә ясый алгандыр. Тагын бер истәлек буенча шагыйрьнең әнисе Бибимәмдүдә үләр алдыннан:» Габдуллаҗанны бары тик Мотыйгулла хәзрәт кулына гына бирергә кирәк», – дигән.

Инде килеп, Габдуллаҗанның Җаектагы 3 мәдрәсәнең теләсә кайсына түгел, нәкъ менә «Мотыйгия»га укырга керүе дә очраклы түгелдер дип уйлыйм.

Укуга килгәндә, Мотыйгулла хәзрәт яңа шәкертнең аның үзе кебек үк зирәк, һәрнәрсәне тиз эләктереп алганын күрә. Холкын да аңлый һәм ятимлектә каткан бәгъренә тимичә, холкын сындырмыйча гына укыта. Артык үсендермәсә дә, ким-хур да итми. Хәзрәтнең хәләл җефете Гыйззинәс абыстай да Габдуллага ана назы бирә. Бары тик олы малай – Камилдән генә баштарак тәкәбберлек хисе бөркелә. Бик дәрәҗәле егет бит!

Шунысы кызык, Камил Мотыйгый үз мәдрәсәсендә күрәсен күреп, аласын алгач, әти-әнисе аны кая да булса белемен күтәрергә җибәрергә уйлыйлар. Мотыйгулла хәзрәт өзми дә куймый: «Кышкарга барасың!», – ди. Бу яшьлек хатирәсе ни дәрәҗәдә көчле икәнен күрсәтә бит! Әмма, бу очракта Гыйззинәс абыстайның практик акылы җиңә. «Ничек инде малайны шәһәрдән нindидер ерак авылга җибәрергә, ди. Бары тик шәһәргә! Казан кебек мәркәзгә!» – дип үз фикерен өскә чыгара ала ул. Хәер, Камил анда бер генә барып кайта, аннан соң әтисе юлыннан Каһирәгә китеп бара. Кайткач тагын да тәкәберрәккә әйләнә Камил. Чөнки ул инде мөгаллим, яңа ысуллар кертеп укытучы.

Дөрес, Мотыйгулла хәзрәт үзе дә иҗади эшләрдән ерак тормый. Ул Габдуллага шигырь төзелеше дәресләре бирә. Гомумән, иҗат итү өчен бөтен шартлар тудыру, каләм тибрәтүчеләрне мактап, үсендереп тору Мотыйгулла хәзрәтнең тормыш принципларыннан берсе була.

Югыйсә, татар дөньясында иң көчле елгаларга әйләнгән ничә чишмәнең башы Мотыйгуллага килеп тоташмас иде. Беренче газета-

журналлар басмасын булдыру, шул басмаларда Тукай иҗатының язгы чәчәкләр кебек шаулап чәчәк атуы, төрле сәбәпләр белән матбугат басмалары ябылгач, Камил Мотыйгыйның профессиональ дәрәҗәдә беренче татар музыкаль артистлык карьерасын башлап җибәрүе, Камил артыннан, инде Совет чорында, бер-берсе артыннан балалары зур артистлар булып китү, «Мотыйгыя»да чуалып йөргән Кариевнең Габдулла исеме алуы, татар театрын оештыруындагы зур урыны – барысы да Мотыйгулла хәзрәт белән бәйле.


**Камил Мотыйгый**

Шушы кыска гына вакыт эчендә, үзәктән ерак торган бер шәһәрдә, бер мәдрәсә-мәхәлләдә чыннан да татар ренессансы нигезен тәшкил иткән күпме чыганак бит!

Бер Тукайның остазы булуы гына да Мотыйгулланы «бөек» дип танырга җитә. Аның үз подвалында, патшага да, карагруһчыларга да каршы килеп, күпмедер мөлкәтен тотып типография эшләтүе дә батырлык түгелмени? Мулла буларак, үз өендә музыкаль салон оештыруы да соклану хисләре уятырлык.

Бөеклекнең нигезендә һәрвакыт гадилек ята. Мотыйгулла Төхфәтуллин изге гамәлләрен гадәти эш дип санаган. Әмма, мәсәлән, Тукай бөек икән, димәк аны укыткан, тәрбияләгән остаз да татар тарихына алтын хәрефләр белән язып куелырга тиеш.

**Рәмис Хәялиев,**
**Кайбыч муниципаль районы башлыгы урынбасары**

# Остазның туган ягында

Рәмис Хәялиевнең Мотыйгула хәзрәт турында язганнарын укыгач, уйга калдым: Тукайның иҗаты һәм тормышы белән кызыксынучы галим-голәмә, әдипләр, соң чиктә, татар зыялылары Мотыйгулла хәзрәтнең туган ягы – Кайбычта еш булалармы? Шагыйрь язмышында «беренче скрипкә» үк булмаса да, иң әһәмиятле урыннарның берсен тоткан Мотыйгулла Төхфәтуллин турында Кайбыч халкы нинди истәлекләр саклый? Гомумән, әлеге шәхескә татарыбызның мәхәббәте кай тирәдә? Шулар хакында кызыксынучылар бармы?

Белүемчә, Кайбыч юллары такыр булса да, бу төбәккә «күңел сукмагы» салынып җитмәгән әле. Ә бит, шартлы рәвештә булса да, Тукай Кайбыч ягында да «әсәрле һәм эзле» булып чыга.



**Галия Кайбицкая**

Ярый әле Кайбычта Мотыйгулла хәзрәтнең кызы, ТАССРның халык артисткасы, М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисткасы Галия Кайбицкая (1903-1993) музее бар. Шунысы да әһәмиятле, бу музейны ачу турында фикер теләсә кайсы елда-көндә түгел, ә нәкъ менә Тукайның тууына 90 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә туа. Һәм музейны ике елдан соң рәсми рәвештә ачалар да. Кайбыч халкына, район җитәкчелегенә ничек рәхмәт әйтмисең ди инде.

Музейда Галия Кайбицкая бүлмәсе, этнография залы, музыка салоны бар. Анда мәшһүр җырчының иҗатташ дуслары фоторәсемнәре, пианино куелган. Төрле очрашулар, «Музей дәресләре» шунда уза.

Г. Кайбицкаяның 1962-1991 нче елларда язылган «Истәлек дәфтәрләре» һәм гаилә фоторәсемнәре, Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камилгә багышланган стенд иң кыйммәтле тарихи ядкарьләрдән саналалар. Ниөчен? Килегез, күрегез, укыгыз, өйрәнегез – нәтиҗәне үзегез ясагыз. Тукай остазының туган якларына сукмак өзелмәсә, бу шәхесләребезне, тарихыбызны тагын бер кат барлау, татар хәтерен озайту булыр иде.



**Мотыйгулла хәзрәтнең чалмасы һәм дисбесе**

## «Таблетка»

Җаекта эшне төгәлләгәч, сәфәрне галимнәрдән башка гына дүрт журналист дәвам итәргә тиеш идек. Рәшит Кадыйров һәм Зөфәр Мөхәммәтшин белән, кем әйтмешли, «еламыйча гына» саубуллашсак та, без киткәч галимнәребез «хет көл, хет ела» хәленә калганнар. Без моны Казанга кайткач кына ишеттек. Хезмәттәшләре әлеге ике галимгә «таблетка» дип кушамат та такканнар, имеш.

Ә хәл менә болай булган. Таможняда тентү вакытында Рәшит әфәндедәнниндидертаблеткалартапканнарһәмаларны«психотропное вещество» рәтенә кертеп, галимебезне тоткарлаганнар. Алай гына да түгел, әлеге таблеткаларның наркотикка керәме-юкмы икәнен ачыклаганчы, Рәшитне кире Җаекка кайтарганнар һәм кунакханәдә «домашний арест» салганнар. Икенче галимебез Зөфәр таможня хезмәткәрләренә әлеге таблеткаларның баш авыртудан эчә торган дару гына икәнен дәлилләргә тырышып караган үзе, әмма тегеләрнең үз дәлилләре булган. Янәсе, таблетка саны 12 дән артмаска тиеш, ә Рәшит әфәндедә нигә 30 данә? Шулай итеп, аптекаларда сатыла торган әлеге таблеткалар аркасында, йоклар алдыннан таблетка йотарга күнеккән галим таблеткасыз да тагын бер көн Җаек кунакханәсендә кунарга мәҗбүр булган.

Казакъстан таможнясы хезмәткәрләрен гаепләп тә, җавапка да тартып булмый. Ни дисәң дә, Казакъстан – чит дәүләт бит, законнары да башкадыр, бәлки. Шунысы гына гаҗәп, таблетка 12 данә булганда – дару, ә аннан артса, наркотикка әйләнә микәнни?

Менә шулай, җәмәгать, читкә чыкканда һәрнәрсәне уйлап чыгарга, аласыңны – чамасын белеп кенә алырга кирәк. Юкса, күңелгә килмәгән, төшкә кермәгән хәлләргә таруың бар.

## Әгәр Тукай булмаса…

*«Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, –*
*Шул минем макасатым, теләгем һәм бәхетем»*
*Г. Тукай, «Милләткә», 1906 ел*

Уйлап-уйлап утырам да, тагын бер уйлап куям әле: әгәр Тукай булмаса, без Җаекка сәфәр чыгар идекме? Алай гына да түгел, бу шәһәрнең барлыгына да күз йомар идек без. Чыннан да, татарга ни хаҗәтемә ул Казакъстанның бер шәһәре – Җаек? Хәер, тарихны, аерым алганда, татар тарихын өйрәнүчеләр анда-санда әлеге калага барып чыккан булырлар иде, бәлки. Анда-санда гына шул, чөнки тарихи мирасны барлау буенча төрле экспедицияләр оештыру элегрәк тә бик дәрәҗәле эш түгел иде, хәзер дә бик хупланмый. Беренчедән, алар шактый кыйммәткә төшә, аннан соң татар тарихы буенча озын-озак сәфәргә чыгарга атлыгып торучы фидакарьләр дә күп түгел хәзер. Мин төрле бәйрәмнәргә «лента кисәргә», читтәге кардәшләр алдында ялкынлы чыгыш ясап «бәлеш ашарга» баручыларны фидакарьләргә чутламыйм. Аларның «фидакарьлеге» кире кайтканда машина селкенгәндә дә төшеп кала торган. Ә менә сәфәр вакытында, Тукайның тормыш юлына, иҗатына кагылышлы ядкарьләрне бөртекләп җыеп, саклап буыннан-буынга тапшыручы чын фидакарьләрне күп күрдек без. Тукай рухы тирәсенә тупланып яшәүче һәм Тукайны яшәтүче шундый кардәшләребез булмаса, без, мөгаен, Костанайга да, Карагандага да, Алматыга да, Кентау, Атакентка да, Кытайның Өремче, Чүгүчәк, Голҗа калалаларына да бармаган булыр идек. Әйе, безне Тукай юлга чакырды, кардәшләребез белән Тукай очраштырды.

«Истә калганнар» китабында фоторәсемнәрне мулдан файдаланып, тарихи ватаннарыннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең исемнәрен күпләп атап та дөрес эшләдек, дип уйлыйм. Киләчәк буын 2010 нчы елда Җаек ни рәвешле булганын, анда Тукай белән бәйле урыннарның, йортларның ничек сакланганын, бүгенге көндә Җаекта һәм без булган башка шәһәрләрдә «мин – татар!» дип горурланып яшәүчеләр кемнәр икәнен белеп торсын, дидек.

**Риман Гыйлемханов**

Казакъстан

## КОСТАНАЙ •

*«Белмим, ни өчендер күңелем «милләт» дигән сүзне сөя;*
*Милләтем, син мине милли ит, шатлык бүләк ит!»*
*Г. Тукай, « Милләткә», 1906 ел*



# Туганнарны эзләп

*«Казакълар арасында элек-электән билгеле булган Тукай, казакъ теленә тәрҗемә ителгәннән соң, казакъ халкының төп акынына, халык акынына әйләнеп, киң сахраларда яңгырый башлады…»*

*Җакан Сыздыков, казакъ шагыйре*

Сәфәр чыкканчы ук, Җаектагы Тукай музее директоры Марат Баһаутдиновтан Тукайның Казакъстандагы туганнарын табарга булышуын үтенгән идек. «Костанайда Суфия апа яши, адресын белешеп куярмын», – дигән иде ул. Белешеп кенә түгел, Костанайдагы милләттәшләребез аша безнең киләсен Суфия апага җиткереп тә куйган булып чыкты.

Суфия апа белән очрашуны көтеп алдым мин. Нindиерәк кеше икән ул? Костанайга ничек килеп эләккән? Тукайның туганы булуы белән горурланамы? Костанай татарларының аңа хөрмәте ни дәрәҗәдә?.. Шундый уйлар белән юлга чыктык. Җаек белән Костанай арасы мең чакрымнан артык булганга, көнендә барып җитмәсебезне белә, шуңа күрә кайда булса да төн кунарга туры киләчәген сизә идек. Таныш түгел юл һәрчак озын-озак тоела инде ул. Җитмәсә, әллә каян кычкырып торган күрсәткеч такталар да юк. Ярый әле кызлар, машинага бензин салырга туктагач, заправкалар төшерелгән юл картасы алганнар. Гөлназ шул картаны тотып янәшәгә утырды, мин аңа, шаяртып «навигатор», «штурман» дип эндәшә башладым. Инде моңа хәтле дә Казакъстанда булганга, кызлар шәһәрләргә ничек барасын бераз чамалыйлар иде. Ә Гөлназ фәлән чакрымнан соң заправкамы, шәһәрчекме, кафемы буласын әйткәләп барды. Араны карта масштабыннан чыгып линейка-мазарсыз да шактый төгәл чамалый иде. Җаектан чыгып, кеше әсәре күренмәгән дала юлы буйлап йөзәрләгән чакрымнар үткәч, караңгы да төшә башлады. Казанда чакта серле романтикасы белән кызыктырган, палаткалар куеп төн кунулар турында хыялланган без – фәкыйрьләрне, төнге дала шактый ук шикләндерә иде. Иксез-чиксез киңлек өстенә төннең кара пәрдәсе төшә башлагач, машинаның сулъяк көпчәге сәер генә шыгырдый башлады. Көпчәкнең «җибәрәсен» көткән идем инде, чөнки Совет чорында чирәм җирләрне үзләштергәндә салынган асфальт юллар урыны-урыны белән бүлтәеп, чокырланып беткән. «Ашыккан җитми, боерган җитә» дигән асыл хакыйкатьне онытып, Костанайга тизрәк барып җитәр өчен куа-куа, шактый чокырлар «санагач» көпчәкнең



**Казанда чакта серле романтикасы белән кызыктырган, палаткалар куеп төн кунулар турында хыялланган без – фәкыйрьләрне, төнге дала шактый ук шикләндерә иде**

дискасы кәкрәеп һава чыгып бетте. Кызлар ярдәме белән көпчәкне алыштырып ары киттек, әмма күрәчәк алда икән әле. Көпчәк тагын «җибәрде». Алай гына да түгел, сулъяк ике тәгәрмәчнең дә тыннары чыгып беткән иде. Далада төн кунарга хыялланган идем, менә, кун, рәхәтлән! Салкын төшә башлады. Дала салкынына курку хисләре дә өстәлде. Чөнки, безне төнлә юлга чыгу куркыныч дип кисәткәннәр иде. Монда талау, үтерү очраклары да булгалый икән, «каравыл» кычкырсаң да сине ишетүче булмаячак. Әлләнигә бер йөк машиналары үткәли, әмма туктаучы юк.

Ниһаять, бер «Фольксваген» фургоны туктады. Яшь кенә ир кеше яныбызга килеп: «Что случилось?», – диде. Юл кырыена тезгән сумкаларны, машина тирәсендә ыгы-зыгы килгән шәүләләрне күргән дә, безне юл фаҗигасенә юлыкканнар дип уйлаган. Исеме Руслан икән, нәселендә татар каны да булуын әйткәч шатлануыбызны белсәгез! Иң якын туганны очраттык мени! Шуның өстенә Тукай турында да күпмедер дәрәҗәдә мәгълүматлы булып чыкты Руслан. Менә бит, дала уртасында очраган гади бер кеше Татарстанны, татарны һәм бу халыкның бөек улы Тукай барлыгын белә!

Кәкрәйгән дискларны каккалап-суккалап төзәтеп карадык, әмма файдасы тимәде. «Ярый, азапланмыйк, – диде Руслан, – минем авыл моннан 27 чакрым чамасы, юлдан читтә. Анда бер картның «шиномонтажы» бар. Уятып карыйм. Төнлә иренсә, иртән иртүк эшләттерермен, бирегез көпчәкләрегезне!»

Шулай итеп бер ягын домкрат белән күтәрткән, ике көпчәктә генә торган машина янында кагаеп калдык. Китәр алдыннан Руслан: «Будьте осторожны, тут рядом есть небольшая деревушка, там злые люди живут», – дип күңелне «тынычландырды». Күп тә үтмәде, аның сүзенә куәт дигәндәй, ак төстәге бер «Жигули» безнең машинаны урап әйләнде дә килгән юлына кире китеп барды.

«Хәзер үз ишләрен җыеп килә бу, – дим кызларга, – әйдә, сумкаларны машинага төйик!»

Әйберләрне төядек тә, машина домкраттан төшеп китмәсен дип, сулыш алырга да куркып утырабыз. Гөлназ тынычландырырга тырыша: «Безнең күп икәнлекне күрде бит алар, кире килмәсләр», – ди. Рәмилә белән Альбина дәшмиләр. Кызларны жәллим, юлбасарлар килеп чыкса, нишләргә икән дип планнар корам. Ә кызлар миннән кыюрак булып чыктылар: зарланмыйлар, сыктамыйлар, әле берәр машина уты күренгән саен: «Әнә, теге дуслар килә», – дип шаярткан булалар. Бераздан: «Ярый, Риман абый, без бераз черем итеп алабыз, карт кешенең йокысы сак була, безне сәхәргә уятырга онытма», – дип

төрттерделәр дә тынып калдылар. Алар уразада иде. Мин каршы яктан машина уты күренгән саен: «Руслан булса ярар иде», – дип теләкләр тели-тели, машинаны кабызгалап җылыта-җылыта уйларга батып утырам. Ни гаҗәп, мондый озын юлга чыгуыма да, машина белән маҗараларга таруыма да тамчы да үкенми идем. Чөнки, максатыбыз ачык һәм изге иде: күңелләрендә Тукайга хөрмәт саклаган кардәшләребезне барларга чыктык бит.

Кызларны сәхәргә уяттым. Белгәннәрен укып, капкалап алдылар да тагын изрәп киттеләр. Аларның күңел тынычлыгы миңа да күчте…

Ниһаять, төн караңгылыгы сыеклана башлады. Әкрен генә, пышылдап кына Тукайның шигырен көйлим:

*Галибәнә яктырып, әкрен генә ал таң ата;*
*Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата…*
*Кызларымның күтәренке тавышы мине сискәндереп җибәрә:*
*«Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң*
*Шул вакытта уйла, Риман, килер Руслан, уйласаң».*

–Йокламыйсыз мени сез? Ах, шутникларым минем!

Шактый талчыккан, йончыган булсалар да, сер бирми кызларым, һаман шаярткан булалар. Аларның яшьлек дәрте, яшьлек романтикасы минем уйларымны да әллә кайларга бөтереп алып китә.

Җаекта яшәгәндә Тукай да казакъ далаларына кымыз эчәргә чыккалаган, дөресрәге аны Бәдри абзыйның (Тукайны Кырлайдан алып килүче, өлкән Газизәнең ерак туганы Бәдри абзый турында сүз бара – *Р.Г.*) улы Камалетдин үзе белән алгалаган. Камалетдин исә казакълар арасына чыгып вак-төяк сатып һәм балта эше белән көн күргән. «Тукай турында хатирәләр» дигән китапта аларның казакъ даласына 15 көнлек сәфәре турында шактый тәфсилләп язылган. Юлда барганда Тукай Камалетдинга ике китап язуы, аларны Казанга бастырырга җибәрүе турында сөйли. Ул чакта Тукай минем кызлардан 2–3 яшьләргә кече булган, ә мин икеъярым Тукай гомерен яшәдем. Яшәвен яшәдем дә, ни кырдым соң?

Рәмилә Газизуллинаның сәфәр башында ук әйткән сүзләре искә төшеп китте. «Бу бит – журналистлар экспедициясе! Кемнең шулай җыйнаулашып Тукай эзләреннән озын сәфәргә чыкканы бар? Татар журналистикасы тарихы мондый нәрсәне белми…» – дигән иде ул. Аның фикерен башка сүзләр белән Алматыдагы татар эшмәкәре Торсынтай Габитов кабатлар. Аның үзе турында әле алдарак, әмма сүзләрен хәзер искә төшерми булдыра алмыйм.

– Сездән интервью аласы иде, – дигәч: «Минем хакта түгел, үзегез турында язарга кирәк. Сезнең Тукайны олылап шундый юлга чыгуыгыз – үзе бер батырлык», – дигән иде Торсынтай.

Батырлык беркайчан да батырлык эшлим дип эшләнми ул. Бәндә баласы үз алдына куелган бурычын тулысынча үти, максатына ирешә икән – шул батырлык буладыр, минемчә…

Уйларымны кызлар тавышы бүлә. «Ур-ра! Руслан килә!». Төнге 12 дән иртәнге 9 га хәтле далада утыруыбыз бушка китмәде: әнә ул, коткаручыбыз. «Извините, немного задержался. Как вы тут?», – дип сөйләнә-сөйләнә машинасыннан безнең көпчәкләрне алды. Алды гына түгел, куеп та бирде. «Үземнең дә шундый хәлләрдә калган бар, гел юлда бит мин. Бәладә калган кешене калдырып китү – «не в моих правилах», – ди. Аллаһның рәхмәтләре яусын сиңа, Руслан, олы эшебездә синең дә өлешең бар.

## Суфия апа

Костанайдагы кардәшләребез безнең өчен кунакханә урынына ике бүлмәле фатир әзерләп куйганнар иде. Татар мәдәни үзәге рәисе урынбасары Тәнзилә Хәкимова белән юл буе телефон аша элемтәдә торганга, ул безнең хәл-әхвәлләрдән, маҗаралардан хәбәрдар иде. «Фатирга урнашкач та әллә кая барып йөрмәгез, үзебез киләбез, Үзәк активистларын шунда җыям», – диде. Татарчасы әйбәт кенә. Акиматта эшли икән. «Анда эшләүнең татар өчен файдасы да бар, милли проблемаларны хәл иткәндә җитәкчелек булыша», – ди.

Шулай итеп, «штаб-квартира»да Костанай татарларының «каймагы» җыелды. Үзләре белән милли ризыклар да алып килгәннәр, тиз генә өстәл әзерләделәр…

Ишек кыңгыравы чылтырады. «Ренат Биктимеров бу, Суфия апаны алып килгәндер», – ди Тәнзилә.

Менә ул, Тукай кардәшләреннән берсе – Суфия апа. Йөз-кыяфәте нәкъ казакъларныкы инде: түгәрәк кенә бит, кысынкы күзләр. Кызы Гөлнара да суйган да каплаган казакъ. «Ирем Җомабәк белән милләтне бүлмәдек, татар булып тууым белән бәхетле мин. Кая гына барсам да, кем белән генә аралашсам да, милләтем белән горурланам», – дип өздереп әйтеп куйды Суфия апа. Аның тагын бер горурлыгы, әлбәттә, бөек Тукайның туганы булуы. Нәсел чылбыры буенча Суфия апа белән мин – бертирә буын. Әбием Бибифаизә Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф белән бертуган булса, Суфия апаның әтисе Гали абый – Тукайның үги әнисеннән туган Газизә апаның улы. Шагыйрьнең Җаек тормышын



**Суфия апа да, кызы Гөлнара да Тукай нәселеннән булулары белән горурланалар**

күпмедер дәрәҗәдә белгән кешеләр хәтерлидер, Тукай Газизә апасын бик яраткан. Беренчедән, алар икесе дә ятимлек язмышына дучар ителгәннәр. «Сак белән Сок кебек яшәгәннәр инде әбием белән Тукай», – ди Суфия апа. Ярый әле, «асрамага алынган» балалык язмышы аларны Җаекта Галиәсгар Госманов гаиләсендә очраштыра. Әлеге гаиләгә Газизә Габдулладан 3 елга иртәрәк, 1892 нче елда килеп керә, кияүгә чыгып, Гали белән Вәли исемле ике ул таба һәм Тукай аларны бик ярата. «Апай, бу балаларны мин үзем укытырмын, яме!», – дип әйтә торган була. Әлбәттә, Тукайга аларны укыту насыйп булмаган.

Суфия апа әнә шул балаларның берсе – Гали абзыйның кызы инде. Бәхеткә каршы, Костанайда Гали абзыйның тагын ике баласы яши булып чыкты һәм икенче көнне без алар – Рафаэль абый һәм Рәисә апа белән очраштык.

Алар үзләренең затлы нәселдән, ягъни Тукай нәселеннән булулары белән горурланып гомер кичерәләр. Безнең якта эшлексез, төссез, кулыннан берни килмәсә дә, күкрәк сугып, черки кебек күзгә керергә торганнарны «затсыз» дип сүгәләр. Балачактарак мин бу сүзне «оятсыз»ның синонимы, һичъюгы «оятсыз»ны бозып әйтү дип аңлый идем. Юк, «затсыз» – син беркем түгел, буш кеше дигәнгә якынрак килә ахрысы. Ә Костанайдагы Тукай туганнары үзләренең дәрәҗәсен, затлы нәселдән икәннәрен белеп илгә-җиргә хезмәт итеп яшиләр.

Суфия апаның әтисе Гали абзый – Чапаев дивизиясендә сугышкан. Аннан соң репрессиягә эләгеп хәбәрсез юкка чыккан. Суфия апа әйтүенчә, аны 1932 нче елда кулга алганнар. Гали абзыйның бертуган сеңлесе, Ленинград «Эрмитаж»ында фәнни хезмәткәр булып эшләгән Фаизә Зәбирова-Кондратьева совет властенең каһәреннән курыкмыйча, абыйсын эзләүдән туктамый, әмма эзенә төшә алмый.

«Гали абзыйның бертуган абыйсы Вәли дә революционер булган. 30 нчы елларда Ленинградта, Ташкентта укыган. Студент чагында Мохтар Әүэзов белән коммуналкада бергә яшәгәннәр. СССР Фәннәр академиясенең тарих фәннәре ассоциациясе гыйльми секретары булган Вәли абзый да репрессиягә эләгә.

Суфия апа сөйләвенчә, аны сугыш алдыннан кулга алганнар. «Шул ук елны атып үтергәннәрдер дип уйлыйм», – диде ул. (**З. Рәсүлованың «Тукай эзләреннән»** дигән китабында Вәли Зәбиров 1941 нче елда үлгән дип язылган – *Р.Г.*).

Безнең әле Газизә апа тармагы буенча да Тукай нәселен барлап бетерәсе бар. Гомумән алганда, язмыш Тукай нәселен ил-җир буйлап Балтыйк диңгезеннән алып Тын океан ярларынача чәчкән. Аларны җыеп, туплап китап итеп чыгарасы иде. Миннән еш кына: «Тукай фонды» ни белән шөгыльләнә соң ул?», – дип сорыйлар. «Тукай туганнары» китабын чыгару өчен генә дә әле күпме архивларда казынасы, илләр гизәсе, Тукай шәҗәрәсен тулыландырасы бар. Бу эшкә без тотынмасак, кем тотыныр? Ходай биргән гомерне яшәп, Тукай, ягъни татар тарихында якты бер эз калдырасы килә. Шушы җөмләдән үк фондның максаты аңлашылса кирәк.

Суфия апа Зәбирова белән гәпләшеп утыру шактый озакка сузылды, тик сүзләрнең очы-кырые күренми иде. Суфия апа үзе дә: «Казан ягыннан татарлар килә дип кенә ишеткән идем, Тукай каны да аккан кеше дә килә дип белмәдем», – дип миңа туганнарча җылы караш ташлады.

Кызы Гөлнара: «Миндә Тукайга булган туганлык хисләре әнидәге кебек үк көчле түгелдер. Ул бит Газизә әбине исән чакта да күргән. Әмма, 2006 нчы елда күңелемне кузгаткан бер вакыйга булды: безне Казанга, Тукайның тууына 120 ел тулуга багышланган тантанага чакырдылар. Тукай өчен, татар өчен горурлык хисләре белән кайттык», – диде.

Казанга чакырылу очраклы булмаган икән, Суфия апа үзе турында берничә кәлимә сүз язып, ул чактагы президентыбыз М. Шәймиевкә хат юллаган, «юл чыгымнарын үзем күтәрәм, акча сорамыйм» дип тә өстәгән. Безнең белән очрашуга Суфия апа Тукай юбилее тантаналары вакытында Татарстан җитәкчелеге, аерым алганда М. Шәймиев һәм



**Суфия апа һәм Костанай татарлары белән гәпләшеп туя алмадык**

Сәкинә ханым белән төшкән фоторәсемнәрен дә алып килгән иде. Горурланып, шатланып утырды. Менә бит, бәндә баласына күп тә кирәк түгел, кешечә мөнәсәбәт, җылы караш та җитә.

Суфия апа да: «Без үзебезне Тукай туганнары дип, бер кешедән дә, берни дә сорамыйбыз, таләп итмибез, киресенчә җаваплылык тоеп яшибез», – диде. Авызыңа бал да, май, туганым Суфия апа, без шулай тәрбияләнгән инде.

Шулай сөйләшеп утырганда күңелем тулып-тулып киткәне йөземә дә чыккан ахрысы, кызларым кеше күрмәгәндә генә «И-и, сабый», – дип башымнан сыйпап, җилкәмнән кагып алдылар. Әйе, дулкынландым шул, гомер уйламаган җирдән дигәндәй, Казакъстан калаларының берсендә кан-кардәшем белән очраштым, исән чакта хәбәрләшеп торырбыз дип кул бирештек.

Кире кайтканда яңадан Костанайга тукталу ниятебез дә бар иде. Мондагы кардәшләребез шәһәрнең татар яшьләрен җыеп безнең белән очрашу үткәрергә сүз бирделәр. Татар үзәге әгъзасы Рәисә ханым Сиит: «Мин коттеджда торам, мунчалар ягып, бешбармаклар әзерләп торырмын», – дип тә өстәде. Кире кайтырга дигән якты уйлар белән Костанайдан чыгып киттек үзе, әмма әлеге каланы, кардәшләрне якын арада күрү насыйп итмәгән икән. Сәфәр чыккан һәр кешене юл хәвефе сагалый бит ул… Алга таба анысы турында да язарбыз әле.

**Риман Гыйлемханов**



**Сәүдәгәр Яушевлар төзеткән Зәңгәр мәчет**

# Шәһәр белән танышу

Икенче көнне иртә белән шәһәр буйлап сәяхәткә чыктык. Костанай шәһәре Тубыл елгасының сулъяк ярында утыра. Шәһәргә 1879 нчы елда урыс һәм украин кешеләре нигез салган. Безне Костанайның борынгы өлеше җәлеп итте. Биредә заманындагы атаклы сәүдәгәрләрнең затлы йортлары урын алган: бертуган Яушевлар пассажы, Лоренц, Воронов, Сенокосов йортлары… Шәһәрнең бу өлеше – чын мәдәният үзәге! Тарихи музейлар, театрлар, китапханәләр дә монда урнашкан.

Костанай шәһәренең борынгы мәчете 1893 нче елда Татар бистәсендә яшәүче бай сәүдәгәрләр хисабына төзелгән. Төп иганәче «Бертуган Яушевлар» исемле Троицки сәүдә йортының хуҗасы Габделвәли Яушев булган. Элек мәчет бинасында төрле елларда клуб, ленинградчыларны эвакуацияләү пункты, кинотеатр, концерт залы оешкан. Хәзер исә биредә иман йорты. Яушевлар мәчете Костанай каласының тарихи һәйкәле булып тора.

Бертуган Зәбировлар белән тарихи бинада – 1902 нче елда төзелгән сәүдәгәр Яушевлар пассажында күрештек. Хәзерге вакытта ул Костанай шәһәренең Халыклар дуслыгы йорты буларак билгеле.

## Безнең дә күңел кузгалды

Әйе, Риман абыйның Тукай туганнары белән очрашуы безнең дә күңелне кузгатты һәм әлеге очрашуны без «тарихи вакыйга» дип бәяләдек.

«Тукайны яраткан кешеләр – барысы да безгә туган», – дип каршы алды безне Суфия Гали кызы Зәбирова. Ә Риман Гыйлемханов белән очрашуга ул бик шат иде. Әледән-әле җилкәсеннән сөеп: «Нишләп син мине иртәрәк эзләп тапмадың, туганым-җаным?!», – дип кабатлый иде. Без исә ханбикәләргә хас холыклы, нурлы йөзле ханымның әбисе Газизә Зәбирова, әти-әнисе, үз тормышы турында сөйләгәнен тын да алмыйча тыңлап утырдык.

Рафаэль Гали улы белеме буенча техник-механик булса да, Тукай кебек иҗат кешесе икән.

– «Свобода слова» газетасына мәкаләләр язам. Күбрәк сәяси темаларга. Берничә мәкаләм бигрәк эмоциональ килеп чыкты әле, – диде әңгәмәдәшебез.

Шигырь дә язып караган, ләкин барып чыкмаган. «Поэзия миңа бик авыр бирелә», – дип аңлатты ул. Шулай дисә дә, Рафаэль абыйның иҗади



**Суфия, Рафаэль, Рәисә Зәбировлар**

кичәләрдә абруе зур. Бик күп шагыйрь дуслары иң беренчеләрдән булып шигырьләрен аңа укыта икән.

Рафаэль абыйның хатыны Фәридә даруханәдә фармацевт булып эшли. Кызлары Лилия белән Наилә Алматы, Санкт-Петербург шәһәрләрендә үз тормышлары белән яши.

«Хәзерге тормыш тәгәрмәчтә әйләнүче тиенне хәтерләтә. Гаилә коруыма да 30 ел булган. Соңгы тапкыр Казанга баруыма да биш дистә вакыт узган бит», – дип моңсуланып алды ул.

Рафаэль абый беренче карашка аз сүзле, җитди кеше булып тоелса да, ахырда моның ялгыш фикер икәнен аңлап аласың. Ул Тукай кебек үк яңа карашлы, бай күңелле иҗат кешесе.

Суфия апаның сеңлесе Рәисә Зәбирова белгечлеге буенча – инженер-химик. Улы Илдар – филолог, Костанай педагогика институтының инглиз-төрек телләре факультетын тәмамлаган. Кыскасы, зыялы нәсел дәвам итә һәм, әлбәттә, Тукай да онытылмый. Шулай сөйләшеп утырганда Рәисә апа әнисе Мәгъмүрәне искә алып куйды. Мәгъмүрә әле үсмер чагында ук әтисеннән: «Тукайны күргәнең бармы?», – дип гел сораштыра торган булган. Ә әтисе Тукайның Казакъстанда кымыз эчеп дәвалануы, кайчан очрашулары турында истәлекләрен кызганмаган. Ә Мәгъмүрә апа Тукай турында әтисе сөйләгәннәрне баласына сөйли торган булган. Менә, кан ничек тарта бит.

## Уртак йортта




Костанайдагы татар-башкорт үзәгенең «Дуслык» дип аталуы да, Казакъстан халыклары мәдәни оешмаларының «Халыклар дуслыгы йортын»да урнашулары да күңелле генә уйларга этәрде. Мондагы бар милләт халыклары бер түбә астында, ягъни уртак йортта яшәгән тату бер гаилә кебек. «Эчендәге тышында» дигәндәй, дуслык йорты үзенең архитектурасы белән Костанайның матур бер бизәге кебек тә әле.

Бусаганы атлап кергәч, тагын бер шатландык: иң күренә торган



**Сәүдәгәр Яушевлар пассажында урнашкан «Халыклар дуслыгы йорты»**

җирдә Татарстан әләме тора иде. Без моны казакълар тарафыннан тугандаш татар халкына олы хөрмәт билгесе дип бәяләдек. Әлбәттә, башка милләтләргә дә өстән генә, кимсетеп карау юк. Бинада үз халкың турында кайгырту өчен бөтен шартлар тудырылган.

Безне Үзәкнең «тоткалары» Тәнзилә Хәкимова, Сәрия Сиит, Ренат Биктимеров, Фәния Сафина, Светлана Мәрданова чәй кайнатып көтеп утыралар иде. Телләр чишелеп, күңелләр нечкәреп китте. Нечкәрмәслекмени, шушы берничә бөртек дигәндәй кардәшләребез Костанайда татар язмышын үз җилкәләренә алганнар бит. Алар әлеге калада татарга хөрмәт зур булуы турында горурланып сөйлиләр. Әмма, хөрмәтне, абруйны югалтмаска да кирәк бит әле. Милләттәшләребез үзара килешеп эш бүлешкәннәр. Мәсәлән, Сәрия апа татар теле дәресләре алып бара, Фәния апа аулак өйләр уздыру өчен җаваплы. «Әти-әниләрдән калган бу матур гореф-гадәтне өч-дүрт ел элек яңадан башлап җибәрдек. Татар егетләре татар кызлары белән танышып-кавышып гаилә корып җибәрсеннәр өчен тырышабыз», – ди Фәния Сафина. Милләт язмышы турында кайгыртканда эшнең зурысы, кечкенәсе юк инде ул. Каян башларына килгән диген, 28 нче февраль көнне Костанай татарлары «Аш-су бәйрәме»

уздыра икән. Ни өчен 28 нче февральдә, чөнки бу – милли ашлар остасы Юныс Әхмәтҗановның туган көне. «Иң татлы» бәйрәмгә йөзләгән кеше җыела. Бер яктан хуҗабикәләр милли аш-суга осталыкларын күрсәтсә, икенче яктан Костанай халкы татарның шушы өлкәдә нәрсәгә сәләтле икәнен бәяли, тел йотарлык тәм-томнар әзерли белгән татарга рәхмәт әйтә.

«Сабантуйларын әйтәсе дә юк. Элек бу бәйрәмне күрергә Казанга бара идек, ә хәзер үзебез гөрләтеп уздырабыз», – ди Тәнзилә Хәкимова һәм: «Тукай көннәре», Каз өмәсе, Корбан гаете, Мәүлет бәйрәме, әдәби кичәләр… берсен дә читләтеп узган юк», – дип өстәп куя. Ә бит әле бәйрәмнәргә милли киемнәр дә кирәк! Кардәшләребез бу мәсьәләне дә хәл итеп куйганнар: милли күлмәкләрне Сәрия Сиит ялт иттереп тегә дә куя икән. Без Костанай татарларын эчтән рәхмәтләр укый-укый тыңладык, шул ук вакытта кайбер кардәшләрнең күбрәк урысча сүзләр кыстыруы борчулы уйларга да этәрә. Нишләмәк кирәк, СССРдан «бүләк» булып калган урыс теле басымына казакълаштыру сәясәте дә өстәлү телебезне шактый кыен хәлгә куя шул.

**Рәмилә Газизуллина,**
**Альбина Газизуллина**

# «Татар телең нәрсәгә?» – дисәләр

*«Күрмәгез берьяклы дип сез бу вафасыз дөньяны;*
*Ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы».*
*Г. Тукай, «Нәсыйхәт», 1910 ел*

Костанайның «Дуслык» татар-башорт үзәгенә йөрүче Ренат Биктимеров безне якын туганыдай каршы алды. Татарчасы бик үк шома булмаганга бераз кыенсынса да, гел үзебезчә сөйләшергә тырышты. Шәһәр буйлап озатып та йөрде, кирәк җиргә алып та барды. Баштарак читтән килгән кунакка шундый мөнәсәбәт тиештер дип уйлап, Ренатның безгә үтә игътибарлы булуына әллә ни исем китмәгән иде.

Инде менә ул, бу китап язылганда Казанга килгәч, иркенләп сөйләшеп утырдык. Казанга юл төшүенең сәбәбе шул: ике кызы Эльмира



**Уңда – Ринат Биктимеров**

һәм Алинәне инде менә өченче ел лагерьга – «Идел» яшьләр үзәгенә алып килә икән. Бераз татарчаларын да чарласыннар, мили мохитне дә тойсыннар, ди. Быел абыйсының кызы Ренатаны да иярткән.

Кызларга татарча сүз катам, гади җөмләләрне аңлыйлар, тик татарча җавап кайтарырга кыенсыналар. Монда бер кешене дә гаепләп булмый. Казакъстанда яшәүче татарларга ана теле, гомумән, кирәкме соң? Кая Казакъстан?! Әле Татарстаныбызда да: «Татар теле белән кая барасың?», – диючеләр шактый. Ана телебезгә ихтыяҗ тудыра алмыйбыз. Алай дисәң, нигә ерак Кытайда милләттәшләребез тел һәм гореф-гадәтләрне гасырлар буе саклап киләләр? Алар татар теле белән кая бара ала? Күрәсең, тел, милләт сагында булу татарыбызның ни дәрәҗәдә рухи бай, горур булуы белән бәйледер. Ренатка да шушы хис-сыйфатлар хас, тик ул кайчак, япа-ялгыз сугышчыны хәтерләтә. «Үз арабызда, гаиләдә булса да татарча сөйләшик», – дип туганнарның да теңкәсенә тиеп бетәм. «Дуслык» үзәгенә йөрүчеләргә дә тынгы бирмим», – ди.

– Ә алар нәрсә ди?

– Дәшмиләр, ык-мык киләләр.

– «Дуслык» татар-башкорт үзәгенә йөрүчеләр кайсы телдә сөйләшә?

– Күбрәк урысча шул. Бер мәртәбә ачуымнан шигырь язып ташладым да, Үзәк җыелышында укыдым әле. Тукайның «Туган тел»енә ияреп язган идем. Укысам, күләрсең инде, мин шагыйрь түгел бит. Кая, Риман абый, истәлеккә блокнотыңа язып куйыйм әле, сагынганда укырсың…

Әйе, камил шигырь түгел иде ул, әмма аның һәр юлында ихласлык, татар өчен гарьлек иде. Менә, укып карагыз әле.

*И, туган тел, и матур тел,*
*Әбкәм-бабамның теле.*
*Дөньяда бик күпне белер идем,*
*Әгәр белсәм туган телемне.*
*Инде хәзер бу тел белән*
*Әбиләр әкият сөйләмиләр.*
*Әниләр төннәр буе*
*Бишек җырын көйләмиләр.*
*И, туган тел! Синдә булган*
*Иң элек кылган догам.*
*Ярлыкагыл халкыбызны*
*Һәм үземне, и Ходам!*

Сез дә бу юлларны минем шикелле ритм-рифмага бик игътибар итмичә генә укыгыз. Иң кыйммәтлесе, бу юллар – Ренатның гына түгел, милләт язмышы турында кайгырткан һәр татарның күңел авазы.

«Балаларым көннәрдән беркөнне: «Әти, менә син тырыша-тырмаша татарчага өйрәттең. Ә бит сөйләшергә кеше юк», – дисәләр нишләрсең, ә», – дип куя Ренат.

Әйе, кыен хәл. Читтәге татарлар ике күзләрен дүрт итеп дигәндәй, зур өметләр баглап Казанга карый. Ренат та шундый ук өметләр белән кызларын үз машинасына утыртып, меңәр чакрым ара узып, ел саен Казанга килә. «Беркөнне Кремльдәге кафега кердем. Татарча белүем белән мактаныйм дип, аш бүлүче кыз белән сөйләшә башладым. Ә ул: «Я ваш татарский не понимаю», – диде. Күкрәгемә пычак кадап өстән аска кадәр ярып төшерделәрмени!.. Казан уртасы – Кремльдә бит бу!»

Ренат шулай сөйләнә-сөйләнә миңа җаваплы караш ташлый. Татарның дәүләтчелеге символы булган Кремльдә телебезне санга сукмау аңа кыргыйлык тоела.

Ренат, бер уйлаганда, милли сәясәттән ерак кеше. Караганда шәһәрендә политехника институты, аннан соң Костанайда юридик институт тәмамлаган. Шәһәрдә Татар үзәге оешуын ишетеп, аны үзе



**Р. Биктимеров Казанга ел саен кызларын да алып килә**

эзләп тапкан. Һәм инде менә 10 ел милләт шатлыгын һәм кайгысын үзенеке санап шушы Үзәккә йөри. Бер гыйбрәт әйтеп куйды әле. Аның хәләл җефете – Лилиянең бабасы Бөгелмә районы Карабаш бистәсеннән икән. Менә шуның туганы Фазыл үзенең өендә Һади Атласи музее оештырган. Һәм туганнары, танышлары аның бу гамәлен ничек бәяләгән дисез? Бу егет «ычкынган» дигәннәр. Бәлки, Ренат турында да, йөзенә бәреп әйтмәсәләр дә, шулай уйлаучылар бардыр. Булса, андыйлар «ычкынмаган», киресенчә, күңелләренә «мескенлек богавы» салынган коллар дип уйлыйм. Акыллы, тырыш халык икәнлегебезне белеп, горурланып яшик, җәмәгать!

Ә Ренатка килгәндә, ул Казаннан күпмедер дәрәҗәдә күңел тынычлыгы алып китте бугай. Бу аның күзләрендә чагыла иде. Машинасы янында басып шактый вакыт аерылыша алмый тордык. Ешрак күрешеп, хәл-әхвәл белешеп яшик, кардәшләр!

**Риман Гыйлемханов**



# Астана юлында – Африка кызы?!

Безне алда бик катлаулы маршрут көтә иде: Астана-Балхаш-Алматы-Шымкент-Атакент-Кентау-Төркестан-Алматы-Хоргос-Өремче-Чүгүчәк-Голҗа-Хоргос-Алматы-Караганда…

Уйлы юллар… Тукай да бит 1912 нче елның язында казакъ «сахра»сында «ак күмәч берлән ашарлык саф һава» сулап яткан. Шагыйрь «Мәкаләи махсуса»да болай дип яза: «…Бу – сахра. Бу – казакъ җире. Әүвәл «бисмиллаһи» дип бер чишенеп ташладым. Коры степь һавасы. Сөт, каймак, теләсәң коен, әле генә сауган саф кымыз, бөтен нәрсә алдаусыз». Тукайның күңелендәге хисләре «Валлаһи» шигырендә дә чагылыш тапкан.

*Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;*
*Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!*
*Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,*
*Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!*

Хәер, Тукай язганча оҗмахка тиң, кунакчыл «сахралар» безгә тәтемәде.

Казакъстан башкаласына якынлашуыбыз сизелә: сикәлтәле юлларны майлап куйганнармыни – машина «оча» гына.

Менә Караганда шәһәрен узып киттек. «Кайда? Кайда? Карагандада!» дип шаярталар бит әле. Кайтканда әлеге шәһәр татарларын күреп чыкмыйча булмас, мөгаен.


Гөлназга карасак, танырлык түгел

Чиксез далада әз-мәз яшеллек күренә башлады. Еракта биек тауның карлы бүрекләре калыкты. Без күрергә хыялланган Тянь-Шань тавы микән бу? Шуңа игътибар иттек: казакълар калкулыкларда таштан кошкорт, төрле җанвар сыннары ясап куйганнар. Бигрәк тә ике метр биеклектәге бөркет, дөя сыннарына гаҗәпләндек.

Машинада барганда бик күп казакъ авыллары очрады. Безнең татар авыллары яшәсен! Биредә йортларның күбесе балчык белән сыланган, койма-капкалар төссез, буялмаган. Халык ишәк җигеп көн күрә. Казакъстанның төньягында дөя көтүләрен күрә алмадык.

Ур-ра! Машинада казакъ радиосы да тота башлады. Рәхәтләнеп шуны тыңлап бардык. Ни дисәң дә, цивилизация инде.

Көн кичкә авышты. Инде 15-16 сәгать юлда барабыз, арытып җибәрде. Чираттагы казакъ авылына кердек. Тигез генә юлдан барабыз шикелле… Дых!!! Машинабыз борыны белән чокырга чумды. Чокыры да әллә нинди – болай гына күренә торган түгел. Без – кызлар машинадан сикереп төштек тә, «Шевроле-Лачетти»ны этмәкче булабыз. Бер, ике, өч! Өстебезгә фонтан булып мазутлы су сиптермәсенме! Яныбыздагы Гөлназга карасак, танырлык түгел. Африка кызларына охшап калган. Мазутлы битендә энҗе тешләре генә җемелди… Аны тиз генә фотога төшереп алдык. «Африка кызын» күреп, машинабызны коткарырга теләүчеләр артты. Котылдык!

**Рәмилә Газизуллина**

## • АСТАНА

*«Тормак ярый: бертуктаусыз ялганласаң,*
*Тугры сүзле кешеләргә ялганласаң,*
*Вөҗданыңнан шәйтан төсле чыр-чыр качып,*
*Үзең алдап, башкалардан алданмасаң».*

*Г. Тукай, «Дөньяда торыйммы?», –*
*дип киңәшләшкән дустыма», 1907 ел*



# Еракка китеп кара син, еракка китеп кара…

Казакъстанның элекке башкаласы булган Алматыга юл бик ерак иде. Бер көндә барып җитмәсебезне белгәнгә, хәзерге башкала – Астанада кунып чыгарга ниятләдек.

Мин кызларны «ана куеныннан чыгып җитмәгән»гә чутлап бик ялгышканмын икән. 23 яшьлек Гөлназ белән Рәмиләнең моннан алда Казакъстанда булып, «йөрисен йөргән, олтаны тузган» кызлар икәнен истән чыгарганмын. Аларның һәр шәһәрдә танышлары бар иде. Һичьюгы татар оешмалары җитәкчеләренең, Татарстанның Казакъстандагы вәкиллекләренең телефоннарын беләләр иде. Юлда барганда Астанада вәкиллектә эшләүче Мәдинә ханыма шалтыраткалап тордык, фәлән сәгатькә килеп җитәрбез, кунарга урын белешегез әле, дидек. Тик безне «алты колак, дүрт күз белән» каршы алмадылар. Алай гына да түгел, Мәдинә ханым телефоннан: «Вокзалда квартбюро бар, шунда барыгыз!», – дип кыйммәтле киңәш бирүдән уза алмады.

Кызлар: «Борчылма, Риман абый, урамда кунмассыз», – дип тынычландырдылар. Алар белән апак-чапак килеп сөйләшә-сөйләшә шактый юл узылса да, Астанага шактый ерак иде әле. Башкалага төн уртасы җиткәндә генә барып кердек. Вокзалны, «квартбюро» дигәннәрен эзләп таптык. Әмма, кечкенә генә сәүдә лавкасын хәтерләткән әлеге «квартбюро» ябылган булып чыкты. Аз сүзле, әмма әйтсә, каты агачка каршы чөй сугарга гына торган Рәмиләгә, әле сабыйлыгыннан яңа чыккан Альбинага, чокырга төшкән машинаны эткәндә мазутлы пычрак чәчрәп негр кызына әйләнгән Гөлназга сораулы караш ташладым. Сер бирмиләр: «Машинада утырып төн чыгарбыз, бер төн йокламаганнан гына кеше үлми», – дигән булалар.

Аллаһ бар бит ул, шулвакыт машина янына бер хатын килде дә: «Кунарга фатир кирәк мәллә?», – ди. Дүрт тавышка: «Әйе шул», – диештек. Ике бүлмәле фатир кунакханә номерыннан да арзан булып чыкты. Ашау турында кайгырасы юк, кызлар уразада булганга, сәхәр ашарга дигән тәм-томнары һәрчак бар иде. Эре генә итеп: «Безнең белән ураза тоткан булсагыз, сәхәргә уятып сезне дә ашатыр идек», – дигән була болар миңа.

Шөкер, йокыга ятканчы ук ашаттылар тагын, рәхмәт төшкерләре.

Икенче көнне әче таңнан юлга кузгалдык. Картада гына Астана белән Алматы арасы «таяк ташлам» кебек күренә ул, якты көздә тәки барып җитеп булмады. Ни дисәң дә, меңьярым чакрым ара бит! Ярый әле кызларда күңел төшенкелеге дигәннәренең духы да юк иде.

– Балхаш күлен күргәнегез бармы? – диләр болар миңа.

– Бар.

– Кайчан күрдегез?

– Юлга чыгар алдыннан, картада.

– Менә хәзер үзен күрерсез.

Бераздан тере «навигатор» – Гөлназ: «Озакламый Балхашка җитәбез», – дип куйды.

– Ни өчен «Балхаш» дип атала ул? Кызлар бар белемнәрен эшкә җигеп, миңа Балхаш турында тулы бер лекция укыдылар.

Балхаш күле Казакъстанның Көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы – 16,4 мең квадрат чакрым. Ул зурлыгы буенча кипми торган күлләр арасында, Каспий диңгезеннән генә калышып, икенче урында тора. Дөньядагы иң эре күлләрнең берсе булган Балхашны Сарыесик ярымутравы ике өлешкә бүлә: күлнең Көнбатышында су – төче, Көнчыгыш өлешендә – тозлы.

Балхаш ярымай рәвешендә якынча 600 чакрымга сузылган. Киңлеге 9 чакрымнан 74 чакрымга кадәр җитә. Тирәнлеге – 26 метр.

Көнчыгышта Балхаш Сасыккүл, Алакүл, Әби-Нур күлләре белән тоташа. Шулай ук, аңарга Элә, Каратал, Аксу, Аягүз елгалары агып төшә. Балхаш күленең килеп чыгышы турында бер кызыклы риваять бар. Балхаш атлы бер байның Элә исемле гаҗәеп чибәр кызы була. Кызы буйга җиткәч, Балхаш аны бай, чибәр һәм батыр егеткә кияүгә бирәм дип, тирә-якка чаң суга. Эләнең кулын сорап дөньяның төрле почмагыннан кияүләр җыела. Чибәр Элә исә ярлы көтүче Карагалны ошата. Балхаш кызының мәхәббәтенә каршы килә. Эләнең Каратал белән качуын белгәч, ачулы ата боларны каргый һәм гашыйклар елгаларга әверелә. Алар беркайчан да кушылмасыннар өчен Балхаш күл булып алар арасына егыла…

Балхаш топонимы татар, казакъ, алтай телләренең «balkas» сүзеннән барлыкка килгән. Түмгәкләр белән капланган сазлыклы урын дигәнне аңлата. Балхаш күлен казакълар «Диңгез», төрек һәм монголлар башта «Ак-Диңгез», аннары «Күк-Диңгез» дип атый. Ә кытайларда ул – «Си-Хай», ягъни «Көнбатыш диңгезе»…

Шулай лекция тыңлап бара торгач, ай яктысында «күл көзгесе» күренде. Соклануын йөгәнли алмаган, нечкә күңелле Гөлназ кычкырып




ук җибәрде: «Риман абый, Балхаш бит бу, аңлыйсызмы, Балхаш бу!». О-о… Балхаш!!! Чыннан да соклангыч иде бу күл. Ярлары буйлап 60-70 чакрым барганбыздыр, әмма соклანудан туктамадык.

– Әйдәгез, су коенабыз! – мәйтәм. Кызлар белдекле генә итеп: «Күлнең бу ягында яр буйлары пычрак, саз. Теге ягына чыгарга кирәк, тик аның өчен тагын 3-4 сәгать барасы», – дип каршы төштеләр.

Төнге караңгылыкта Караганда яныннан да уздык. Кызлар: «Шәһәргә керәбезме?», – дисәләр дә, әллә, төнлә күргәнгә, әллә шәһәр исемендә «кара» сүзе дә булганга, күңел тартмады. Тик язмыштан узмыш юк дигәндәй, безгә Карагандага керергә, алай гына да түгел, ничарадан бичара 10 көнгә якын яшәргә дә туры килде. Болары турында соңрак.

Күзгә йокы элерә башлады. Гөлназ моны сизде ахрысы, магнитолага татар дискасы тыкты да, болар өчәүләшеп, каравыл кычкырып, җырлый башладылар. Аларга мин дә кушылдым. Кызык инде, бер генә адәм әсәре дә булмаган, ялгыш кына, бер генә машина да узмаган дала юлында рәхәтләнеп татарча җырлап барабыз. Үземне Татарстанда кебек хис итеп алгалыйм. Тик туган-торган җир ераклаша гына бара. Әле сәфәребезнең уртасына да җитмәгән идек. Хет, тизрәк таң атсын иде… Юл урыны-урыны белән, көзге кебек үк булмаса да, тип-тигез. Тик артык кызулап китсәң, берәр чокыр-чакырга барып керәсеңне көт тә тор. Шулай булды да: алгы уңъяк көпчәк шыгыр-шыгыр килә

башлады. «Анысы да монысы, бер йомырка ватылды» дигәндәй көпчәкнең тыны тәмам чыгып бетеп, туктап калдык. Багажник төбендә яткан «запаска»ны алыр өчен Алматыдагы, Кытайдагы кардәшләргә дип төягән бөтен бүләкләрне юл читенә бушатып, көпчәк алыштырдык. «Шевроле»дә запас көпчәк бигрәк мәзәк инде ул: калынлыгы мотоцикл көпчәгенеке кадәр генә. Аны иң якын «шиномонтаж»га барып җитәр өчен генә куялар. «Дүрт кешене, машина тулы сумкаларны чыдатырмы икән?», – дим. Кызлар шунда да шаяртып маташалар: «Ураза тоткач, җиңеләйдек инде без», – диләр.

Ярый, Ходай язмаган эш түгелдер, әкрен генә кузгалып киттек. Артык кумадык, кызлар һәр чокырны алдан күреп, мине кисәтеп барды.



Шулай итеп «әче таң»да Алматыга килеп кердек. «Таң зәрәсе белән безне кем каршы алыр икән?», – дигән идем, кызлар: «Барысы да сөйләшенгән-килешенгән», – дип авызны капладылар.

Юлда барганнарны шулай тәфсилләп язуым үзеннән-үзе килеп чыкты. Чөнки, һәр чакрымы истә калырлык булды. Икенчедән, укучыбызга изге ниятләр белән чыкканда «юл газабы – гүр газабы» түгел икәнен дә сиздереп куюны кирәк таптым. Казакъстанның элеккеге башкаласы – Алматыда татарларның ишле икәнен дә, аларның «аты да юк, заты да юк» милләт булып яшәмәвен дә белә идек. Еракка китеп карагач, үзеңнең кем икәнеңне якыннанрак күрәсең бит ул. Үзебезгә әнә шулай еллар-юллар артыннан тагын бер багарга булдык.

**Риман Гыйлемханов**



## Затлы татарыбыз

*«Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр – бәхет эстәү;*
*Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак – мәгърифәт эстәү».*
*Г. Тукай, «Ике юл», 1909 ел*

Татарстаннан читкә киткән саен, татарның абруен һәм зыялылыгын күбрәк тоя башлыйсың икән. Бер яктан бу үзе үк парадокс:ерактарак яшәгән саен, татар аягында нык басып, җәмгыятьтә югары урын тоткан кешегә әйләнә. Монда тамырларның да роле зурдыр. Бүгенге татар элитасының шәҗәрәсенә карап фикер йөртсәң, шул аңлашыла: татарга зыялылык нәселдән килә…



**Тәүфикъ Әкрәм улы Кәримов**

«Казакъстан республикасының татар һәм башкорт милли-мәдәни үзәкләре Ассоциациясе» юридик затлар Берләшмәсе президенты Тәүфикъ Әкрәм улы Кәримов белән без моннан алда Астанага баргач танышкан идек. Күп мәртәбә Алматыда, Казанда, Бөтендөнья татар конгрессы утырышларында да күрешкәләдек. Шулай бер очрашкач, ул безгә үзенең «Төсләр балкышы» (Казан, Таткитнәшр, 2009 ел, Флера Тарханова тәрҗемәсендә) китабын бүләк иткән иде. Тарих укытучысы, сәясәт, тау инженеры-геолог белгечлекләре буенча өч югары белем алган кешенең уникаль китабын уку бер нәрсә, әле бит Тәүфикъ әфәнде типография тоткан бертуган Кәримовлар нәселеннән дә. Казакъстанга бу юлы баргач: «Әле укып карадыгызмы «Төсләр балкышы»н? Ул минем китап язуда беренче тәҗрибәм һәм татарчага тәрҗемә ителеп басылган беренче эшем. Аңардан соң Казакъстанда һәм Татарстанда рус, казакъ һәм инглиз телләрендә тагын берничә китабым чыкты. Сезне Тукай буенча эзләнүләр алып бара дип ишеткәч, яшьлегегезгә карап сөендем. Кәримовлардан тыш, нәселем Тукайга да барып тоташа бит», – дип, әйтеп куйган иде ул. «Төсләр балкышы»н автор үзе тарихи чыганакларга нигезләнеп, җитди әсәрләр һәм лирик истәлекләрдән торган китапка тиңли. Без аны милләт тарихын сөйләүче бер җыентыкка охшаттык һәм китаптан бер өзек китерәбез.

«1862 нче елда туган бабабыз сәүдәгәр була. Үзенең шәхси эшен зурайту, үстерү ниятеннән XX йөз башларында Казаннан үзенең яшь хатыны – безнең әбиебез белән бу якларга (Казакъстанга – *Г.Г.*) килеп чыга һәм Каспий яры буендагы Жилая Коса бистәсендә диңгез балыгы промыселын оештырып җибәрә. Шуңа өстәп эре терлекчелек хуҗалыгын булдыра һәм сәүдә лавкалары, кибетләр ача.

Мөхәммәтҗан белән Шәрифҗан Кәримовлар, Уфадагы һәм Казандагы мануфактура, сәүдә лавкаларыннан тыш, үз исемендәге типография дә ачалар. Анда мөселманнарның изге китабы Коръән, ул еллардагы мәгърифәтчеләрнең хезмәтләре басыла.

Бертуган Кәримовлар типографиясендә, мәсәлән, бөек казакъ шагыйре һәм акыл иясе Абайның поэмаларыннан берсе, С. Сәйфуллинның «Узган көннәр» дигән беренче шигырьләр җыентыгы, дини-дидактик, фәнни-популяр, матур әдәбият, публицистик һәм тарихи әдәбият, дәреслекләр, сүзлекләр, газеталар татар, гарәп һәм рус телләрендә басыла. 1901-1917 нче елларда алар 20 миллион (!) данә китап бастырып чыгаралар.

Алар милли татар интеллигенциясенең типик вәкилләре була: Татарлар Мәҗлесе утырышларында чыгышлар ясыйлар, Стокгольм һәм Истамбул белән швед, француз, төрек телләрендә язышалар; мөгаен, Казан губернаторы һәм губерна жандарм идарәсе, Казан полицмейстеры күзәтүенә нәкъ менә шуның өчен алыналардыр. Ике туган берничә мәртәбә тентүгә дучар ителә. 1991 нче елда мин соратып алган Татарстанның Үзәк дәүләт архивы мәгълүматлары моны шулай ук раслый.

Аларның карашы һәм гамәлләре хакимиятләргә элекке, патша режимында да ярашмаган. Шуңа күрә әбием хатирәләреннән чыгып шуны әйтә алам: октябрь вакыйгаларыннан соң алар Русиядән Франциягә күчеп китәләр. Сенная (хәзерге Г. Тукай) урамындагы типографияләрендә яңа хакимиятләр инде Казанның РСДРП(б) органы – «Рабочий» газетасы басыла башлый…

Әбиебез исә, Кәримова Маһибәдәр, кыз фамилиясе Дәүләтгәрәева, 1890 нче елда Казаннан 60 чакрым ераклыктагы Кушлавыч авылында, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга кардәш булган Гәрәй һәм Ганиянең күп балалы крестьян гаиләсендә туа.

Җиде баланың барысы да – соңлап туган балалар. Әбиебез кияүгә чыгып киткәннән соң, алар да аның артыннан башта Гурьевка, аннары Жилая Косага күченеп киләләр һәм шунда үз гаиләләрен коралар.

Ә менә әбиемнең әнисе күпмедер вакыт Әстерханда үзенең икенче кызы Мөхетдинова Майшәкәрдә яшәп ала.

Шагыйрь Габдулла Тукай белән кардәшлекне әбием һәм башка туганнарның истәлекләре раслый. Мәсәлән, аларның берсе Бөек Ватан сугышында катнашкан пенсионер Вәкил Мөхетдинов болай дип язган иде: «…без Габдулла Тукайның ерак туганнары, ул безнең авылдан… Г. Тукайны тәрбияләгән икетуган апа аннан соң Гурьевта без дәү әти дип йөрткән Гыйззәт абыйларда яшәде. Ул минем әтиемне дә (Абдулланы) Казаннан алып килде.»

Үз чиратында, Г. Тукай да, 1956 нчы елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган татар телендәге әсәрләренең IV томлыгына кертелгән хатларының берсендә (якынча 1902 нче елда язылган), Гурьевта бай кардәшләренең булуы, аларның 15 сум акча бирүләре һәм шул акча ярдәмендә мәдрәсәгә кереп, инде укып йөрүе хакында яза…

Язмыш кушуы буенча, безнең әни ягыннан булган икенче бабабыз – 1878 нче елда Бәшир дигән татар авылында дөньяга килгән Мөхәммәтгариф Габдрәхип улы Тулбаев та хәзерге Казакъстан территориясенә килеп чыга.

Үзенең әтисе (безнең бабабызның әтисе булып чыга инде) эзеннән китеп, рухани була. Ул чактагы Русия империясенең башкаласы Санкт-Петербургта югары дини белем алып, Төркиядә – Истамбулда тәҗрибә туплаганнан соң ул Уральск шәһәренең өч мәчетләренең берсенә – татар тыкрыгындагысына, соңыннан билгеле булганча, указлы соңгы мулла (имам) итеп җибәрелә.

Калган ике мәчетнең берсе Куренидә, икенчесе Югары Базарда була. Ә ул мулла булган кызыл кирпечтән төзелгән мәчет үзләре яшәгән өйнең янәшәсендә генә була. Яннарында гына Чаган елгасы аккан һәм Хан урманы шаулап торган…

Шунда ук, мәчетнең үзендә мәдрәсә дә була. Анда дини фәннәр генә түгел, грамота һәм башка гомуми белем бирүче фәннәр дә укытыла. Дәресләр, дин кушканча, аерым алып барыла: малайлар – беренче катта, кызлар – икенче катта укый.

Бу мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында Урал татар интеллигенциясенең үз мөгаллименә олы хөрмәт белән караган байтак вәкиле чыга. Соңыннан, сугыш башлангач, алар үзләренең өлкән сыйныф укучылары белән фронтка китә һәм кайберләре «халык дошманы» рәтләрен тулыландыра… Биредә Исмәгыйль Акчурин укый, Яруш Мохтаров, Бари Билюков, З. Хабидуллина, С. Мөхәммәтшина һәм башкалар белем ала.

Дәресләр үткәрергә ул чакта аңа безнең әбиебез, әниемнең әнисе Тулбаева (Исхакова) Гөлсем Хәби кызы булыша. 1893 нче елда гади татар гаиләсендә туган әбиебез Уральскига килгәнче, үзе әйткәнчә,

Кенәз бистәсендә (Көнбатыш Казакъстанның Калмыково бистәсе) яши», – дип яза ул «Төсләр балкышы» китабында.

Тәүфикъ Кәримов үзе дә Казакъстанның Гурьев шәһәрендә, 1958 нче елның 1 нче февралендә туган. Милләте буенча үзен Казан татары дип саный. Бер кыз, ике ир бала тәрбияләп үстерә. Бүгенге көндә Астанада яши.

Әби-бабалары кебек үк, Тәүфикъ Әкрәм улы да бөтен дөньясында шактый танылган шәхес. Аны Казакъстан президенты администрациясенең баш инспекторы, АКШның Аризона штаты почетлы гражданины, Досмухамедов исемендәге Атырау университетының почетлы профессоры да, ярдәмчел, милли җанлы шәхес буларак та беләләр.

Ә хезмәт юлын ул әле Совет чорында, училище укытучысы, комсомолның өлкә комитетында инструктор булып башлый. Аннан бүлек мөдире, нефть-газ эзләү экспедициясендә инженер, партиянең өлкә комитетында җаваплы оештыручы, Совет-Германия уртак предприятиесендә төп белгеч, «Тенгизмунайгаз» акционерлык җәмгыятендә баш инженер булып эшләп китә. 1994-2005 нче елларда Тәүфикъ Кәримов Казакъстан республикасының Атырау өлкәсе акимы аппараты җитәкчесе булып тора. 1993 нче елда Германиянең Мюнхен шәһәрендәге «Linde AG» концернында 9 ай дәвамында стажировка үтә. 1996 нчы елда Русиядә Президент сайлауларында аны халыкара күзәтче итеп куялар. 1997 нче елда АКШның Вашингтон һәм Туссон шәһәрләрендә Казакъстанның югары дәүләт хезмәткәрләре өчен оештырылган бер айлык укуларда да белемен арттырып кайта ул.

«Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, Казакъстан һәм Татарстан республикаларының Язучылар Берлеге әгъзасы булып торуым белән дә горуланам. Әмма минем өчен иң бөек дәрәҗә – ул дөньяга татар булып килүемдәдер. Нәселем белән мактанырга яратмыйм. Ә бары үземне әби-бабайларым көч куйган эшләрне башкарып, алар юлын дәвам итәргә тиеш дип саныймын. Безнең милләт – зур һәм акыллы халык. Әгәр һәрберебезнең тамырларын казып карасак – без хәтта туганнар булып чыгабыз. Алай гына түгел, затлы нәселләргә тоташабыз. Бөек Тукай белән мине дә милләттәшлек кенә түгел, нәсел җепләре дә бәйли. Тик Тукай, Кәримовлар буенча эзләнүләр алып барасым шактый әле. Үзебезнең кем икәнлекне белеп яшәргә тиешбез», – диде ул.

**Гөлназ Галимҗанова**

## • АЛМАТЫ

*«Тукай миңа бик иртә кергән. Ана сөте белән. Халык моңнарын тоя башлагач та. Татар халкы булган җирдә Тукай булган. «Кайчан?». дигән сорауга, «Халык сулышы белән», – дип кенә җавап бирә алам».*

*Сибгат Хәким.*
*Татарстанның халык шагыйре,*
*Г. Тукай ис. Дәүләт бүләге лауреаты.*



# Без, без, без инде – җепкә тезелгән инде

*«Тукай үзенең замандашлары, яшьтәшләре өчен генә түгел, үзеннән бик күп яшькә яшь кешеләргә дә, киләчәктә туачак балаларга да замандаш булган шагыйрь. Тукай һәр буынга яшьтәш, Тукай һәр буын белән яңара. Чөнки, Тукай – гасырлар шагыйре».*

*Сәгыйть Агиш, башкорт язучысы*

Бу дәүләттә татарны «диаспора» дигән ят сүз белән атасалар да, кардәшләребез Казакъстан президенты Нурсолтан Назарбаевның Мәскәүдә, Дәүләт Советы утырышында: «Татары в Казакъстане – не диаспора, они – мой народ», – дигән сүзләрен күңелләрендә ныгытып куйганнар да, хәзер шактый ук горурланып, үзләренең бәясен белеп яшиләр.

## Әюповлар

Алматыда «Татар этномәдәни берләшмәсе» шактый куәтлеләрдән санала. Кызларның «барысы да сөйләшенгән-килешенгән» булуы, шушы Үзәкнең яшьләр канатын җитәкләгән Ренат Әюпов белән бәйле икән. Әле «сандугачлар да уянмаган» булуына карамастан, Ренат кесә телефонына шундук җавап бирде: «Сезне фәлән җирдә, фәлән машина белән Ренат исемле егет көтә», – диде. Иске Алматыдан яңасына барып җиткәнче шактый вакыт узды, урамнарда машиналар да ишәйгән иде. Шулай да таптык без Ренатны. Зифа буйлы яшь кенә егет. Татарчасы аксаса да, безгә хөрмәт йөзеннән рәхәтләнеп «җырмачлый».

– Кая алып барасың? – дим.

– Ренатларга, – ди бу. – Безнең Алматыда татарларның яртысы Ренат исемле», – ди.

Кызлар җанланып китеп, пышылдашып алдылар. Мин сораулы караш ташлагач: «Узган килүебездә да шуларда туктаган идек», – диештеләр.

Хуҗабикә Айнура ханым Әюпова кызлар белән исемнәрен әйтеп, җылы итеп күреште. Әйтерсең лә якын туганнар озак вакыт бер-берсен күрми торган! Тыйнак, сабыр гына сөйләшә торган бу татар хатынында күзгә күренмәгән нindидер көч-куәт бар шикелле. «Мине бит малай



**Бу йорт еш кына яшьләрнең җыелу урынына әйләнә**

**Яшьләр янына гадәттә өлкәннәрне дә дәшәләр**

туа дип көткәннәр, «Айнур» дигән исем дә әзерләп куйганнар, кыз булгач «Айнура» дип кушканнар», – ди. Илдар, Шәүкәт, Ренат исемле өч улы, Камилә исемле кызы бар. Ренат, шул, алданрак әйткәнемчә, татар яшьләренең җитәкчесе була инде. Һәм бу йорт еш кына, яшьләрнең җыелу урынына да әйләнә икән.

Әюповларның күңелләре киң булса да, аларның бу сыйфатыннан «явызларча» файдаланырга теләмәдек һәм Айнурадан берәр кунакханә табуын үтендек. Баштарак ул: «Әллә бездә ошамыймы?», – дип үпкәләп алса да, без бик гозерләнгәч: «Ярый, кунакханә белешермен», – диде. Эшне кызу тотты Айнура. Алматыда мин ишетеп кенә белгән татар эшмәкәре – «Сабантуй» дигән кунакханә тотучы Торсынтай Габитов белән сөйләшеп тә куйды. «Сәгать 11ләргә «Сабантуй» кунакханәсендә көтәләр. Әйдәгез, ашап-эчеп, ял итеп алыгыз да, аннан соң китәрсез», – диде.

Торсынтай турында алдарак язармын әле. «Сабантуй»да яшәсәк тә, без Әюповларга еш килә идек. Айнура көненә әллә ничә шалтыратып йә өйлә ашына, йә авыз ачарга дәшә иде. Без килгән саен табыны мулдан булыр иде аның.

Бервакыт: «Кешедән туймыйсызмы?», – дип сораган идем, аптырап калды Айнура ханым. «Ничек инде, кунактан туялар мени?», – ди. Әйе, читтәге татар, ничектер, аерымрак шул. Алар татарның иң яхшы сыйфатларыннан берсе – кунакчыллыкны да саклап калганнар.

Беркөнне, Ренат пылауны бик әйбәт пешерә икән дигәнрәк сүз ишеттем дә: «Безгә дә осталыгыңны күрсәт әле!», – дидем. Шаяртыбрак әйткән сүземә каршы Ренат: «Әйдәгез, бүген кичкә әзерлим, яшьләрне дә чакырабыз», – диде. Базарга барып «эсбижий» ит алып кайткан бу. (Гомумән, мондагы базарда итне туңдырып сату юк – *Р.Г.*)

 

Ишек алларында зур казан тора. Безне каршы алган Ренатны да чакырып, ике адаш шул казан тирәсендә мәш килделәр. «Ренат пылауы»ның рецептын язып алган идем, кәгазен югалтканмын. Бары тик казанга итне ваклап турамыйча, зур-зур кисәкләр белән салып, майда кыздырганы истә калган.

Ай, тәмле булды ул пылау. Шуның өстенә кичкә татар яшьләре дә җыелды. Өстәл артына утыргач, иң элек мулла абзый догалар укып алды. Айнура ханым аны махсус дәшкән. Ашап-эчеп, гөрләшеп-җырлашып кара төнгә хәтле утырдык. Яшьләрнең күбесенең татарчасы такы-токы булса да, барыбызның күңелендә дә милләтебез белән горурлану хисе иде. Һәр мәҗлесне Тукайның «Туган теле» белән тәмамлау гадәткә кергән монда. «Әйдәгез, шуны җырлыйк!», – диюче юк, «Туган тел» күңелдән үзеннән-үзе чыга. Бу – Тукай рухы җырлый дигән сүз.

Алматы татарларының бергәләп сабантуйлар, төрле милли бәйрәмнәр уздырулары да, галим-голамәләрнең, шагыйрь, журналистларның әледән-әле Тукай иҗатына кайтып китаплар нәшер итүләре, мәкаләләр чыгарулары да шушы рухның гомере озын булуы хакында сөйли. Әлбәттә, әйдәп баручылар булмаса, татар, Тукай рухы «бавы өзелгән көлтә» хәлендә калыр иде. Алматы татарлары – Әюповлар, «Татар этномәдәни берләшмәсе» рәисе Торсынтай Габитов, галим-журналист Мөнир Ерзин, галим-язучы Гриф Хәйруллин, күренекле шәхесебез, академик Миркасыйм Госмановның туганы Назилә апа Усманова һәм башкалар – әнә шул «татар көлтәсен» таратмый тотучылар.

## Торсынтай Габитов

«Сабантуй» кунакханәсенә, гадәттә, иң кадерле кунакларны урнаштыралар икән. Шушы сүзне ишеткәч, бер башка үсеп киткәндәй булдык. Кунакханәгә урнашуга кыстыбый, чәй белән сыйладылар.

Торсынтай әфәнде үзе юк иде, әмма авыз ачарга үз өенә чакырган икән.

«Арыслан күләгәсендә тиен дә туенган» дигән шикелле, кызларның ураза тотулары нәтиҗәсендә, Риман абыегыз да шактый ук балдамайда йөзде бит әле.

Торсынтай Салих улы Габитов үз йорты белән Алматы читендәрәк тыныч кына бер урамда яши. Бу тирәдә хәлле кешеләр торганы күренеп тора: йортлар таза, бар җирдә чисталык. «Хәлле» дигәннән без Алматыда гына түгел, Казакъстаның һәм Кытайның башка шәһәрләрендә дә «ах мәлгә төшкән» мескен татарны күрмәдек. Тырыш шул безнең халык.

Торсынтай – затлы нәселдән. Җеп очы алтын приискасы тоткан Рәмиевләргә барып тоташа. Бабасы Шәрәфетдин һәм әбисе Фәрхиҗамал 1870 нче елда Казаннан Кытайга күчеп килгәннәр. Торсынтайның бабасы да, әтисе – Салих та сәүдәгәр булганнар. Шушы һөнәр нәселдән-нәселгә күчеп Торсынтайга да килеп җиткән. Мин аның бизнесы – «коммерция серләре» белән артык кызыксынмадым, ә менә хезмәт юлын ничек башлавы кызыклы тоелды. 1982 нче елда Торсынтай комсомол чакыруы буенча (алар гаиләсе 1956 нчы елда Кытайдан Алматыга күчеп килә – *Р.Г.*) Төньякка – Уренгойга килә һәм ашханә мөдире булып эшли башлый, аннан соң җәмәгать туклануы системасында җитәкче урыннарны били. Соңрак дуслары белән сәүдә предприятиесен сатып алып беренче ресторан ачалар. Совет чорында шәхси милеккә мөнәсәбәтне беләсез инде, сәүдәгәрлек-эшмәкәрлек канында булмаса, Торсынтай бу эшкә алынмас һәм башкарып чыгара алмас иде. Иң кызыгы, алар ресторанда милли ашлар әзерләтә башлыйлар. Күп тә үтми мәчет тә салып куялар. Мин Торсынтайның ничек эш башлавын махсус яздым. Ни өчен? Чөнки, ул яшьтән үк бербәрсен тулыландыручы ике уй белән яшәгән: бай булу һәм милләткә булышу. Байлык аның өчен «оя казы» кебек акча букчасы өстендә утыру түгел, ә мохтаҗларга ярдәм итү, татарлыкны, телне, динне саклауда матди ярдәм күрсәтү.

«Байлык – кайберәүләр өчен бәхетсезлек. Мохтаҗларга ярдәм итә белмәгән кеше – авыру кеше. Мин кемгәдер булышудан канәгатьләнү алам», – дигән иде Торсынтай. Ул үз акчасына Уйгыр бистәсендә дә мәчет салдырткан, сабантуйлар өчен дә акча кызганмый икән.



**Торсынтай Габитов Сабантуйлар уздырырга да булыша**

Үзебез киткәч, Торсынтайны «Татар этномәдәни берләшмәсе» рәисе итеп сайлап куйганнарын ишеттек. Монысы да тиктомалга түгел, әлбәттә. Нәрсәгә генә тотынсаң да акча кирәк бит. Торсынтай үзен милләтче дип санамый: «Әмма, – дигән иде ул, – «татар» дигән сүзнең үзенә үк битараф кала алмыйм».

Кытайда без Торсынтай акчасына йөрдек. Сорамадык без аннан. Сүз ара сүз китеп, «Тукай фонды»ның бюджеты белән кызыксынды. Мин уңайсызланып калдым: «Милләт җанлы эшмәкәрләр булышкалый», – дип мыгырдандым. Сәфәргә чыкканда кул сузып бурычка акча җыеп йөрдем, дип әйтә алмыйм бит инде. Дәшмәде Торсынтай, өенә кереп өстәл артында ашап-эчкәч, кулга конверт тоттырды. Аны кызларга бирдем. Кунакханәгә кайткач, конвертны ачканнар. Май кояшы кебек балкып минем бүлмәгә керделәр.

– Риман абый, әйт, Торсынтай әфәнде күпме акча биргән дип уйлыйсыз? – диләр.

– Ну… 15, йә 20 мең сумдыр.

– 2 мең доллар, – диләр кызларым елмаешып.

Рәхмәт яусын кардәшебез Торсынтайга. Югыйсә, озын сәфәр вакытында «берне бүлеп, яртыны ярып» ашарга да туры килгән булыр иде.

Торсынтайны затлы нәселдән дигән идем. Ул хатыны Динара белән 8 бала: 5 ул һәм 3 кыз үстерә. Улларына да «морза шәһадәтнамәсе» алган. Андый игелекле бай морзалар күбрәк булсын иде ул. Чөнки, ыштансыз хәерче горур була алмыйдыр, дип беләм.

## Сабантуйда

Торсынтай безне үзенең «Сабантуй» кунакханәсендә дә бушлай яшәтте. Табигатьнең «бер минутта биш туңдырып, биш эретә» торган гүзәл җирендә урнашкан иде ул. Ерак түгел «Күк төбе» дип аталган яман биек тау. Аның түбәсеннән Алматы уч төбендәгедәй күренә. Тауга менгәндә әллә ничә мәйданчык бар. Аларда төрле аттракционнар, кибетләр, кафе-рестораннар эшләп тора. «Күк төбе» ел әйләнәсе диярлек туристлардан бушамый. Алматылылар гаиләләре белән ял итәргә киләләр.

Атаклы «Медео» шугалагы да «Сабантуй»дан ерак түгел иде. Анда да менеп төштек. Табигатьнең оҗмахтай урынында яшәвебез бер нәрсә, әле бит Алматының нәкъ үзәгендәге кунакханә бинасы өстенә әллә каян күренеп тора торган итеп «Сабантуй» дип язылган. Бу инде Алматыда татар яши, монда гореф-гадәтләребез саклана, монда милли ашлар пешә, монда милли көйләр яңгырый дигән сүз. Әнә шулай күп сөйләшмичә генә, үзебезчә тыйнак кына итеп «татарлык»ны саклаучыларның берсе ул, Торсынтай.

**Риман Гыйлемханов**




РЕСТОРАН



# Габитовлар гаиләсе

Торсынтай Габитов өчен дөньядагы иң кадерле нәрсә – гаиләсе. «Әтидә дә сигез бала булган, миндә дә…» – ди ул горурланып.

Ишек бусагасыннан ук кунакларны хөрмәтләп, Торсынтай әфәнде белән Динара ханым һәм берсеннән-берсе кече, сөйкемле сабыйлар каршы алды. Сабыйлар дигәнем, Тимерлан, Солтан, Әмирхан һәм иң татлысы, яңа гына тәпи йөреп киткән төпчеге-бөтерчеге – Алсу иде.

Ишегалдында куе ямь-яшел үләндә тавык-чебеш йөгереп йөри. Торсынтай әфәнденең тавык асравына гаҗәпләнгән идем башта. «Декоратив тавыклар ул. Шуларга карап утырырга яратам – күзне ял иттерәләр. Көнозын хатынга гына карап утырып булмый бит инде», – дип шаяртып, чәк-чәк, куллама, өчпочмак кебек татар милли ризыкларыннан сыгылган мул табынга «авыз ачарга» дәште безне хуҗа. Һәр ел үзе дә Ураза тота икән.

Габитовларның тагын дүрт баласы инде үсеп буйга җиткәннәр, әти-әни канатыннан аерылып, үз тормышлары белән яшиләр икән. «Балаларыма һәрчак үрнәк әти булырга тырыштым. Иртән торгач, иң беренче эшем – әниемнең сурәте янында дога кылу. Миннән күреп, улларым да шулай эшли. Динара аларга кечкенәдән Коръән аятьләрен өйрәтте. Балалар әти-әнинең яхшы гамәлләрен күреп үсәргә тиеш дип уйлыйм», – диде гаилә башлыгы.

– Кайчакта балаларым үземә дә «Әти, син хезмәткәрләргә акчаны әзрәк бирә башлагансың, хезмәт хакын арттырырга вакыт», – дип, киңәшләр бирә хәтта. Бала күңеле сизгер ул. Мин, әлбәттә, аларның сүзләренә колак салам».

Тимерлан футбол белән мавыга, Солтан бик матур итеп рәсем ясый икән. «Әмирханга әле өч кенә яшь. Тиздән аның сөннәт туен үткәрәчәкбез», – ди Динара ханым. Ир балаларны сөннәткә утыртуны Габитовлар бик зурлап – туй итеп уздыралар. «Гадәттә сөннәт туе улларыбызга өч-биш яшь тулгач була. Солтанның бәйрәме ике ел элек булган иде. Иң башта Коръән аятьләре ятлады ул. Табиб чакыртып, улыбызны сөннәткә утырткач, барлык туганнарны, дусларны ресторанга бәйрәмгә чакырабыз. Солтанга алдан ук бик матур киемнәр тектердек, башына чын солтаннарныкы төсле чалма кидерттек. Тимерлан да, Солтан да кунаклар янына ак атларда килеп керде…» – дип, дулкынланып сөйләде хуҗабикә.

Сөннәт туйларын гына түгел, Ураза, Корбан гаетләрен дә уздырырга ярата Габитовлар гаиләсе. «Бездә һәр көн бәйрәм булырга



**Милли ризыклардан сыгылган мул табынга авыз ачарга дәште безне хуҗа**

мөмкин!», – ди Динара ханым. Күптән түгел Торсынтай әфәнденең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үткәннәр. Гомер бәйрәмендә уллары Коръән аятьләре, шигырьләр сөйләгән, Динара ханым исә сөекле иренең тормыш юлына багышлап фильм төшергән. «Миннән нәрсәне дә булса эшли беләсеңме?», – дип сорасалар, мин һәрвакыт: «Барысын да беләм», – дип җавап бирәм. Яхшы хатын оста пешекче дә, яхшы артист та, режиссер да, кирәк икән журналист та булырга тиеш. Иремнең туган көненә фильмны авырлы килеш өч ай төшереп йөрдем. Аны карагач, Торсынтай хәтта шатлыктан елады… Аның белән яшь аермабыз 27 яшь булса да, үземне бик бәхетле хатын-кыз итеп тоям. Ул балаларыбызга үрнәк әти, дусларына тугъры дус. Торсынтай бик яхшы ресторатор, татар милли ризыкларын үзе әзерләргә ярата. Оста аучы, балыкчы да ул. Аның әнисен һәм милләтен өзелеп яратуына, кешеләргә гел ярдәм итеп торуына сокланам», – ди Динара ханым. Торсынтай әфәнденең исә гаиләсе белән горурлануы, чиксез бәхетле булуы йөзенә чыкса да, җавабы бик кыска булды: «Җүләр – үзен мактар, икеләтә җүләр – хатынын мактар…»



**Торсынтай әфәнде белән Динара ханым**

Тапкыр әйтемне дәвам иттереп, акыллы, гыйлемле мөселман газиз әнисен мактар, дияр идем. Торсынтай әфәнде дә әнисе – Мәрзия Шәрип кызын олылый: «Әнием – гаҗәеп кеше иде! Кечкенәдән безнең йорттан кеше өзелмәде. Өебездә бөтен күрше балалары әни пешергән ризыклар белән сыйлана иде… Ни дә булса кылсам, беренче итеп әнине уйлыйм. Әни шулай эшләр иде микән, дим. Ул гомере буе татар кызына өйләнүемне теләде. Аның теләкләре чынга ашкандыр – Үзбәкстаннан татар кызы Динараны алып кайттым менә».

Торсынтай Габитов Татарстан тарихы белән бәйле фотосурәтләрне, газета-журналларны күз карасыдай саклый. Өй стенасында Габитовларның Казандагы йорты, М. Шәймиев белән төшкән фотолары эленеп тора. Күптән түгел кендек каны тамган җиргә – Кытайның Голҗа каласына барып, Татар зиратын төзекләндергән, ата-бабалары, барлык туганнары каберлегенә истәлек тактасы куеп кайткан Торсынтай әфәнде. «Бу дөньяда әти-әниеңә, гаиләңә, туган җиреңә, халкыңа, тарихи ватаныңа булган изге бурычыңны үтәргә кирәк. Шулай яшәгәндә генә тормышның мәгънәсе бар, яшәүләре рәхәт!», – диде игелекле меценат. Аның иң зур хыялы – Казанда сакланып калган Габитовлар йортыннан «Мөһаҗирләр музее» ясап, аны тарихи ватаны – Татарстанга бүләк итү. («Габитовлар йорты» язмышы Казанга кайткач ачыкланды. Бу хакта язма алдарак. – *Р.Г.*)

Габитовлар гаиләсе белән хушлашкач, Алматыда шул нәсел белән бәйле тагын бер тарихи йортны күреп кайттык. Габитовларның туганы сәүдәгәр Исхак Габделвәлиев төзеткән «Тукымалар йорты» иде бу. Иң гаҗәпләндергәне, 1871 нче елда салынган кибет һаман да эшләп килә…

**Рәмилә Газизуллина**

# Таулар моңы

*«Илне аңлау өчен – аның милли телен өйрәнү,*
*җирле халык ашларын татып*
*һәм шул халык кешесенә гашыйк булып карау кирәк».*
*Румын халык мәкале.*

Без Тукайны шагыйрь, журналист, публицист кына түгел, ирекле сәяхәтче буларак та беләбез. 27 еллык гомерендә ул Җаек, Троицк, Әстерхан, Санкт-Петербург, Уфа, Түбән Новгородта булган, Татарстан авылларын да йөреп өлгергән. Авырый башлагач, тагын Кытай, Финляндия, Төркия һәм башка бик күп илләргә чакырганнар аны. Тукай ерак Америка, Австралия, Һиндстан, Африкага барып чыкмаса да, аның иҗатын чит илләр дә таный. Юкка гына кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов: «Тукай 27 түгел, әйтерсең, 270 ел яшәде», – дип әйтмәгәндер. Тукай – ул легенда. Төрки генә түгел, башка дөнья халыклары өчен дә дәрәҗәле, үрнәк шәхес. Иҗади сәфәребез вакытында еш кына: «Әгәр Тукай без йөргән юлларны кичеп, бу як табигатен күргән булса, тагын нинди әсәрләр тудыра алган булыр иде икән?!», – дигән уйга бирелә идек. Бөек шагыйребез нәкъ менә табигатькә, аның могҗизалы якларына еш мөрәҗәгать иткән бит: җир-анабыз, кояш һәм ай, җил һәм җәнлекләр белән сөйләшергә дә уртак тел таба белгән. Безне дә тормыш мәгънәсен табигать төсләре аша күрергә чакыра ул. Сәяхәттә без дә табигатьнең серләренә төшенергә тырыштык. Инде юлда күргән-белгәнне түкми-чәчми сөйләргә алынганбыз икән, казакъ иленең тауларына да тукталып үтик. Шушы таулар моңы аша без кабаттан Тукайга якынайдык төсле. Чөнки Тукай – ул үзе, кеше акылы җитмәслек биек һәм текә тау…

Алтай, Богуты, Еликты, Җаксы-Җалгызтау, Җаксытукты, Җамансопка, Җеке-Батыр, Җыланды, Зерендин, Имәнтау, Күк-Төбе, Күкчәтау, Кызылтас, Күнгәй-Ала-Тау, Мугаджары, Сандыктау, Саур, Айыртау, Амангельда пигы, Баянаул, Синюха, Сырымбет, Таласс-Ала-Тау, Талгар, Чу-Илий, Тянь-Шань… Казакъстандагы дөньяга атаклы таулар, пиклар болар белән генә чикләнми. Сәяхәтебезгә кадәр Риман абый, тауларга әллә ни исе китмичә: «Тау – тау инде ул», – дигән булса, тора-бара аның да күңеле нечкәрде. «Риман абый, әнә, таулар!», – дип сикеренүебезгә, ул да тәэссирләнеп, машинаны туктата ук башлады. Юлда сәхәр ашау, авыз ачу урыннары да шушы тау тирәләре булганга, ул безнең «икенче йорт»ыбызга әйләнде.

Әмма тау – ул гади генә биеклек түгел. Мин аны итәктән, сырттан һәм пиктан торган кеше тормышына охшатам. Уйлап карасаң, без туган көнебездән башлап соңгы сулышыбызга кадәр төрле «таулар» кичәбез. Һәм берзаман гомернең иң биек ноктасы – Тормыш «түбәсе»нә җитәбез. Тормыш биеклегенә юллар төрле, тик һәркемнең үзе менгән тавы биек булсын иде ул! Тукайныкы кебек…

## Тукай пигы

Ә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның үз пигы Тянь-Шань тавында бар. Тянь-Шань – Казакъстан, Кыргызстан, Кытай илләре арасында утыручы искиткеч тау чылбыры ул. 2007 нче елның 2 нче августында Татарстаннан альпинистлар төркеме – Хәҗиәхмәтов Айрат (җитәкче), Чичканов Николай, Ихсанов Ильяс һәм Кузнецов Дмитрий Тянь-Шаньның Сары-Джаз сыртында, 5063 метр биеклектәге исемсез тау түбәсенә күтәреләләр. Бу – катлаулылыгы буенча иң югары категорияле биеклек була. Һәм беренче менүчеләр хокукы буенча, аны «Тукай пигы» дип исемлиләр.

Шулай итеп, Тянь-Шаньның иң биек ноктасы – «Победа» (7439 м), иң легендар пигы – «Хан-Тенгри»(7010 м) янында татар биеклекләре пәйда була. Әле 2006 нчы елда монда «Камал театры», 2005 нче елда «Казанның меңьеллыгы» тау түбәләре барлыкка килә. Тянь-Шань тавы, аның гаҗәеп гүзәллеге һәм безгә билгеле булган серләре хакында без алга таба да сөйләрбез әле.

«Тукай» һәм «Камал театры» биеклекләрен яулап алу буенча оештырылган әлеге экспедицияләрне күренекле альпинист – Рафаил Ишморатов җитәкли. Әле 1976 нчы елда ук, Тукайга тау эзләп, 6 кешелек команда Памирга күтәрелеп карый. Тукайның 90 еллык юбилее илә бу идеяне хуплап алалар. Тик альпинистларның юлы уңмый. «Тукай» пигы шагыйрьнең 120 еллыгына кадәр хыялларда гына яши. Шулай да, Татарстанның ул чактагы президенты Минтимер Шәймиев һәм Татарстан хөкүмәте ярдәме белән «Тукай» пигын ачу тагын бер елдан соң чынга аша. Тукай рухына саллы бүләк ясаулары өчен бу экспедиция командасына фонд исеменнән без дә рәхмәтебезне җиткерәбез. Тарих аларны онытмас.

## «Күк Төбе»

Тукай эзләрен барлый-барлый, сәяхәттә тау үрләрен яулап йөри торгач, безгә Алматының «Күк-Төбе», «Медео»ларын күрергә насыйп итте.







**«Күк-Төбе»нә менгәч, «The Beatles» «егетләре» белән очраштык**

Ә 1100 метр биеклектәге «Күк-Төбе»н яулау өчен, альпинистлар кебек атна буе юл кичмәдек. Махсус автобусларга утырдык та, 15 минуттан шунда идек.

«Күк-Төбе» безгә аерым бер шәһәрчекне хәтерләтте. «Күкләр моннан, чыннан да, якынрак күренә икән шул. Һавасы да икенче инде», – дип куйды Риман абый шәһәр өстендәге тузан катламына ишарәләп. Бу тауны халыкка ял итү, күңел ачу урыны буларак эшләгәннәр.

Шәһәрнең үзендәге кебек, «Күк-Төбен»дә ыгы-зыгылы тормыш тәүлек буе кайный. Монда без төрле ял итү мәйданнары, мини-зоопарк, скалодром, өстәл теннисы мәйданы, концерт залы, мәйрәмханә (ресторан), гашыйклар аллеясына, бәләкәй күлләргә, милли сувенирлар сату лавкаларына да тап булдык.

Ягымлы табигате, заманча шәһәрнең күккә ашкан йортлары белән хозурланучыларга көнозын «Канат юлы» эшли. Әлеге «юл» тау түбәсеннән үзәктәге Абай мәйданына кадәр сузыла. «Канат юлы»н сынап, 6 минутта 2 чакрымлык юлны үтеп карадык. 80 метр түбәнлектәге шәһәр безне төнге утлары белән әсир итте!





«Күк-Төбе»ндәге «Алма» исемле фонтан – кояшлы Алматының символы булып тора



**Медеоның очына менеп җитү – бер нәрсә, кире төшү – мәшәкать икән**

## Медео

Медео – дөньяның иң зур спорт корылмасы, тау башы шугалагы. Бозда 8 ай буе шуу өчен, монда дөньяда тиңе булмаган система булдырганнар. Медео 1972 нче елда төзелеп, аның авторлары СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләнгән.

Союз вакытында Медеода бихисап Олимпия уеннары, туринирлар уздырылып, спортчылар иң югары рекордларын куя. Шуңа күрә халык телендә аны «рекордлар фабрикасы» дип тә йөртәләр.

Без барганда, Медеода реконструкция – «Азиада – 2011»гә әзерлек бара иде. Тик алматылылар һәм туристлар биредән көн әйләнә өзелми. Ник дигәндә, шәһәрдә 40 градуслы эсселек торганда, тау башында температура нибары 25 градус. Югарырак күтәрелеп, кояшка якынайган саен, тагын да салкыная бара. Баксаң, бу тау башындагы боз катламыннан килгән салкын һавага бәйле икән. Тагын әлеге бозлардан Кече Алматинка елгасы башлана. Аның суыннан шәһәр урамнары ел буе туенып тора. Әмма бу галәмәт дәрәҗәдәге матурлыкны үз күзләребез белән күрү өчен, безгә 842 басмадан торган баскычтан күтәрелергә туры килде. Ә Медеоның очына менеп җиту – бер, аннан кире төшү – икенче «мәшәкать» булды.



**«Рекордлар фабрикасы» Медео**

«Медео»ның исеме турында ике төрле фараз яши. Берәүләр аны «М.Д.О.» – ягъни «Местный дом отдыха»дан килеп чыккан, дип саный. Чөнки заманында, бирედә санаторий эшләп килгән. Икенчеләр – аны Медео Пусурман атлы кешегә бәйли. Күчмә тормыш белән яшәүче бу кеше әлеге тау башында төпләнеп, йорт җиткерә. Тау итәкләрендә сарык, эре мөгезле терлек көтүләре тота. Хак булса, тора-бара Алматыдан да кешеләр күченеп, соңрак бер авыл булып яшәгәннәр.

## Казыгурт

Көньяк Казакъстанга барганда «Ташкент – 20 чакрым» дигән язуны күргәч шаккаттык: Үзбәкстан чигенә җиткәнбез икән бит! Риман абый, шаяртыпмы: «Нәрсә безгә, үзбәк кардәшләргә дә кереп чыгыйк!», – дип кыстый башлады. Беренчедән, Үзбәкстанга керү өчен виза кирәк иде. Икенчедән, анда кадәр барып җиткәч, атаклы Хива, Сәмәрканд, Бохара, Фирганә шәһәрләренә ничек керми китәсең ди?! Бер-беребезне куәтләп, бәхәсләшеп барганда, еракта-еракта, биек кенә тау башында бер көймә күренде. Нинди көймә булыр бу?

Тиз генә картадан тауның исемен эзләп таптым – Казыгурт. Бу тау массивын икенче төрле «Изге Курган» һәм «Цивилизацияләр бишеге»

дип йөртәләр икән. Казыгурт – Шымкент белән Ташкентны тоташтыручы «күпер». Икенче төрле Төркестан Арараты дип тә йөртелә.

Казыгурт легендаларга бай урын булып чыкты.

Имеш, бик борынгы заманда Казыгурт галәмдәге иң биек тау булган, ди. Һәм бөтен дөньяны су баса башлагач, Нух Пәйгамбәр, бар тереклекне үз көймәсенә утыртып, шушы Казыгурт түбәсенә килеп туктаган, ди. Бүген Казыгурт тавында Нух көймәсенә куелган заманча һәйкәлнең «тарихы» шундыйрак. Һәйкәл янына «Нух Пәйгамбәр истәлегенә…» дигән истәлек тактасы да куйганнар.

Хак булса, бу тауда Казыгурт-ата, Кошкар-ата дигән кешеләр күмелгән. Тау итәкләрен таштан эшләнгән хайван сыннары бизи. Ә тау куышлыгында мәчет, тагын әллә нинди могҗизалар бар дигәч, безнең тәмам авыз сулары кипкән иде. Тик безне алда юл – Атакент белән Кентауга сәфәр көтә иде. Насыйп булса, Казыгуртка тагын барырбыз, диештек. Тауның минераль суларын татып, кырыс кешеләре белән аралашмадык бит әле!





Нух Пәйгамбәр
көймәсе



## Хромтау

Актүбә өлкәсенең Хромтау шәһәре янындагы трапеция, өчпочмак, квадрат формасындагы таулар – кеше тудырган могҗизалар. Алар җир асты байлыкларын казу вакытында барлыкка килгәннәр. Шәһәр дә әлеге таш-ком өеме арасында утыра.

Хромтау – дөньядагы иң эре хром рудасы табу урыны. Биредә тау казылмасын чыгару комбинаты эшли, тимер юл уза.

Кызыл, кара, саргылт, зәңгәрсу төстәге таш өемнәренең биеклеге чама белән 40-80 метр. Киңлекләре – 6-10 чакрым.



## Нәрсә ул тау?

Сырт, курган, вулкан, биеклек, бөеклек, чиксезлек… Тауны кем ничек күз алдына китерәдер. Географлар өчен – ул бер туфрак өеме, геология фәнендә – җир катламының төзелеш формасы, минем өчен тау – ул могҗизалар иле. Миллиард еллар буе кешелек таулардан җанга сихәт эзләп, гаҗәпләнеп, шул ук вакытта сагаеп та яшәгән. Җир өстендә тауларның барлыкка килүе турында хәзерге фәндә төрле фаразлар бар үзе. Әмма түбәсе күккә ашкан тауларның чал тарихын «казып» чыгару гына мөмкин түгел – сәяхәт иткәндә шуны аңладык. Борын заманнан ук, кешеләр авыл-шәһәрләр төзү өчен иң элек таулы һәм елгалы урынны сайлаган. Димәк, без сәфәр кылган сала-калалар тарихы да аның таулары тарихыннан башлана… Гасырлар узып, цивилизацияләр алмашынса да, таулар гамәли әһәмиятен югалтмый. Кытайда да, Казакъстанда да тауларга моң-зар сөйләү, тау энергиясе белән дәвалану өчен күтәреләләр. Бит таулар – бүген дә адәм баласы өчен ачылмаган серләр һәм риваятьләр урыны.



…Башта мин кыялар арасында идем. Төпләрен яшеллек, бүрекләрен кар баскан тауларны күзәтә-күзәтә берзаман күккә күтәрелдек. Шулкадәр биек күтәрелдек ки, мамык мендәр күк болытлар аста калды. Таулар миңа кул сузымы якынайды. Уч төпләрем белән бозлы түбәсен сыйпарга сузылам… Шулвакыт мәһабәт бер тауның җилкәсендә, ак ефәк күлмәктән бер кызны күрәм. Тау җиле аның күлмәге белән җелфер-җелфер уйный, йомшак чәчләрен назлый. Йөзенә күз салсам, ни күрим: бу кыз – мин икән! Мин һәм таулар… Җил һәм вакыт…

Казакъстанга тәүге тапкыр – 2008 нче елда барыр алдыннан күргән сәфәр төше иде бу. Аның бер өлеше чынга ашып, бер өлеше кабат төшләргә кереп йөдәтте. Вакыт узган саен төшләр кабатланды, аларга яңалары, яңа таулар, яңа кешеләр, яңа табигать могҗизалары өстәлде. Бер генә нәрсә үзгәрмәде ул – төшләрдәге мин һәм таулар.

Тау – ул җир чигәсе. Тауларга карап мин рухланам, илһам җыям, хыялланам, менеп, шатлык-кайгымны тау җилләренә сөйлим. Авылда, шәһәрдә, юл уңаенда калучы бер генә тау яныннан да битараф кына уза алмыйм. Тауларга ныклап карап торыгыз әле, ни күрәсез? Җил агач яфракларын дөнья буйлап сибә, кояш үз нурларын кая тели – шунда җиткерә. Тик тау белән тау гына очрашмый, аның белән кеше генә күрешә. Бу үзе дә могҗиза түгелмени?!

…Юк, казакъ илен аңлау өчен, аның милли телен өйрәнү, ризыгын ашап һәм кешесенә гашыйк булып карау гына җитми. Аның берсеннән – берсе гаҗәеп тауларына сәяхәт кылу да кирәк. Табигатьнең шушы бизәге – Казакъстан таулары аша мин үземне, яшәешне өйрәнәм…

**Гөлназ Галимҗанова**





# Татар эзләре

Алматыдагы Казакъстан Республикасы Үзәк архивына без Мөнир Ерзин һәм Ренат Әюповка ияреп бардык. Бер көтү булып килүебезне монда беркем көтеп тормаса да, мәсьәләне Ренат тиз хәл итте: туп-туры директор ишегенә юнәлде. Тегесе дә бик мәрхәмәтле кеше булып чыкты. Чиратлап, бер көн берегез, икенче көн – икенчегез килерсез дип, безгә расписание төзергә кереште. Аннан йомшарыпмы, Тукайга 125 яшь тулуын да исәпкә алыпмы, безнең һәммәбезгә дә көне буе архивта утырырга рөхсәт бирде.

Ә әлеге архивның тарихы, СССРдагы барлык архивлар кебек үк, 1918 нче елның 1 нче июнендә В.И. Ленин кул куйган декреттан башлана. 1921 нче елның 1 нче сентябрендә Оренбург губерна архивы нигезендә тарихта беренче Казакъстан дәүләт архивы төзелә. Шулай итеп без, алтынга тиң вакытыбызны әлеге «бердәнбер» архивта үткәрә башладык. Монда XIX йөз ахыры – XX йөз башында Казакъстан татарлары тормышына, аерым алганда, Тукайга һәм аның чордашларына кагылышлы мәгълүматлар табылмасмы дип өметләнгән идек. Әмма безгә кирәклеләре инде Оренбург архивына күчерелгән булып чыкты.

Бер яктан, эш тагын да җайлашты кебек: Тукай турындагы мәгълүматлар хәзер Русиядә саклана. Шулай да Алматы архивында утырудан баш тартмадык. Архив хезмәткәрләре безгә бик теләп татарларга бәйле мәгълүматларны табып бирделәр. «Өметсез – шайтан», – дип, 1917 нче ел өчен «Уральская учителькая семинария» эшләрен тикшердек. Кем белгән, бәлки шәкерт Тукай турында соңрак булса да берәр нәрсә теркәп куйганнардыр. Ә материаллар арасында татар исемнәре шактый. Бер педагогик совет утырышы беркетмәсендә, мәсәлән, 6 татар исемен таптык. Алар: Гобәйдулла Мохитов, Хәбибулла Габбасов, Ибәтулла Игенов, Хәмидулла Испаев, Габделгалим Мусагалиев һәм укытучылары Габделхак Хөсәенов. Димәк, татарлар бу җирдә элек-электән «әсәрле, эзле» булган. Һәм тарихчылар өчен монда уйланырлык мәгълүматлар шактый дигән сүз. Җаекка кагылышлы материаллар арасында, «Уральское областное правление МВД», «Дело о новом торговом пути в Закаспийском крае, указанном торговым домом Братьев Ванюшиных с февраля 1879 по октябрь 1893 года» кебек эшләр бар.

XX гасыр башында биредәге татарлар хаҗ юлыннан кайтып кермәгән. Бу турыда чит ил паспорты алу турындагы бихисап документлар сөйли. Берничәсен китереп үтәбез: «О выдаче загранпаспортов татарам. Котноская волость Ходжамберды Абдуллы Изизова, Рознбаки Омурова, Якупа Сулейманова и Абдукадыра Розыева на поездку в Мекку и Медину. 1910 год». Яки: «По отношению Омской казенной палаты об учете расхода бланков заграничных паспортов для мусульман паломников. 16 октября 1911-1916 года».

Тагын бер документ: «Избрание муллы для Татарской мечети в г. Верном крестьянина Рязанской губернии Хусаина Хасановича Девлекамова в звании имама-хатиба. 14 января, 1910 год». Димәк, татар мәчетләренә читтән имамнар китерү очраклары да булган.

Мактауда яшәсәләр дә, татарларга шикаять белдерелгән материаллар да җитәрлек Казакъстан Үзәк архивында. Аларның бер ишесе – «По прошению Наманганского сирта Г. Керимбаева о незаконном избрании обществом пишпекских мусульманов в должности казия имама татарской мечети Гайсинова. 13 января, 1910 год» кебек булса, икенчеләре – «По сообщению Еписопа Туркестанского и Ташкентского о случаях совращения православных в мусульманство. 12 марта, 1910 год» дигән.

Безнең өчен шунысы куанычлы булды: Төркестан Епискобының «жалуына» Семиречински генерал-губернаторы Михаил Альбаум менә мондыйрак эчтәлектә җавап язган: «Әйе, православие диненнән ваз



**Мөнир Ерзин һәм Ринат Әюповка ияреп баруыбызның файдасы зур булды: бертоткарлыксыз архивка кердек**

кичүчеләр бар, әмма аларны Мөхәммәд шәхесе түгел, ә мөселманнарның яшәү рәвеше, ягъни аларның оешканлыгы, бердәмлеге, мохтаҗларга ярдәм итәргә әзер торулары үзенә тарта». Менә шул, диннән ваз кичүчеләргә җәза бирү урынына генерал-губернатор ислам диненә уңай бәя биргән булып чыга.

«Переписка с начальником северного участка Кульджинского района по жалобе жителя г. Кульджи Р. Суфина на удовлетворение его за похищенные деньги» (на татарсоком языке) – архивта Кытай татарлары һәм Кытайдагы сәяси багланышлар турында мәгълүматлар аеруча күп. Алар, нигездә, гарәп язуында. Вакыт аз булу сәбәпле, без аларны тулысынча өйрәнә алмадык.

Әмма үзебезнең Татарстан галимнәренә килеп өйрәнерлек әйберләр җитәрлек монда. Бүгенге көндә бу архив фондларында 1 миллион 500 мең эш саклана. Иң борынгы документлар – 1733 нче елгы, майор Угрюмовның Джунгариягә оештырылган сәфәренә карый, диделәр. Шулай ук, XVIII гасырда рус дәүләтенең Кытай һәм Урта Азия ханлыклары белән сәүдә итү тарихы да саклана. Монголия тарихына кагылышлы документлар да табып була. Шул исәптән, татарлар турында да.

## Латыйф Хәмиди

Архивта күп кенә документларның Латыйф Габделхәй улы Хәмиди турында булуы гаҗәп түгел. 1906-1983 нче елларда яшәгән Латыйф Хәмидине уникаль һәм салмак көйләр авторы буларак биредә «икенче Моцарт» дип йөрткәннәр. Композитор, җәмәгать эшлеклесе, педагог буларак та ул казакъ халкы тарихында зур урын алып торган. «Казакъ гимнын язган татар улы», «Дала һәм домбра белән әсәрләнгән татар» дип бүген дә сөйлиләр аның турында. Әйе, Казан губернасы Свияжск өязе Бували авылында дөньяга килгән Латыйф Хәмиди – Казакъ ССРы гимны авторларының берсе булган.

Без – Тукайлы халык булсак, казакълар – Абай (1845-1904) белән горурлана. Абай (чын исеме Ибраһим) Кунанбаев – шагыйрь, композитор, фәйләсуф һәм җәмәгать эшлеклесе булган. Нәкъ менә Латыйф Хәмиди, казакъ композиторы Әхмәт Жубанов белән берлектә, сәхнәдән төшми торган Абай операсын иҗат иткәннәр. Кунанбаевның 100 еллык юбилеена һәм казакъ халкына Хәмидинең иң зур бүләкләреннән берседер бу. Чөнки, профессиональ казакъ музыкасы Хәмидинең казакъ фольклорын тою сәләтеннән башка формалаша да, үз «моңы»н таба да алмас иде. Бит бихисап казакъ опера, симфония, марш, вальс, патриотик һәм халыкчан җырларны тудыручы да – Латыйф Хәмиди булган.

Латыйф Хәмиди Урта Азиягә ничек барып чыккан соң? Әле 6 яшендә үк ул әти-әнисе белән Үзбәк иленең Сәмәрканд өлкәсе Каттакурган шәһәренә күченеп килә. Мәскәү техникумы студенты чагында үк, аның турында Ташкентта, Русиядә, шул исәптән казакъ илендә дә гел ишетеп торганнар. 1933 нче елда Казакъ дәүләт драма театры чакыруы буенча ул Алматыга килгән һәм биредә төпләнеп тә калган. Сугыш елларында музыка училищесы, дәүләт консерваториясендә хезмәт куйса, 1950 нче елларда аны инде Алматы шәһәр советы депутаты итеп сайлыйлар.

Латыйф Хәмиди Алматыда вафат була һәм Татар зираты – «Киңсай мазары»нда күмелә. Казакъ, татар, башкорт, үзбәк һәм төрекмән халык җырларын һәм инструменталь әсәрләрен халыкка танытуын исәпкә алсак, бүген аны чын мәгънәсендә төрки халыклар композиторы дияргә була.

1961-1962 нче елларда Хәмиди үзенең истәлекләрендә Казан һәм аның интеллигенциясе белән тыгыз элемтәдә торуын да язып калдырган. Ул бигрәк тә Муса Җәлил белән дус булган.

«…Без Муса белән «Дитя Октября» журналы битләрендә балаларга музыка дәресләрен бирергә уйлаштык. Кызыклы килеп чыксын өчен, ике дус малайның үзара язышу циклын уйлап таптык. Мин үз өлешемне язып,

Мусагатапшырдым.Берничәкөннәнултулысыбеләнүзгәртелгәнәңгәмә алып килгән. Минем исем сакланган, ә аныкы юк. «Ник үз исемеңне дә куймадың?», – дип, аңардан төпченергә тотындым. Шулвакыт Муса миңа «Апуш», «МЖ», «М» авторлыгында төрле язмалар күрсәтте һәм: «Синеңчә, боларның авторы кем? – дип сорады. – Минем исемне куймый язышсак яхшырак булыр дип уйлыйм», – диде. Ә «Апуш» тәхәлләүсе Мусага болай тагылды: берсендә без аның үсмер чагындагы фотоларын карап утыра идек. Шулвакыт бер фотода аның «Апушка» – Тукайга охшавын күрдек. Бөек шагыйребезне хөрмәт итеп яшәгәнгә, Муса да икебез арасында аңа «Апуш» дип дәшүемә беркайчан аптырамады. Муса бик тыйнак иде, үзен билгеле шәхес итеп ассызыклауларын теләми иде.

...Опера студиясендә эшкә Җәлил Мәскәүдә яшәүче бик күп татар язучыларын җыя алды. Алар арасында Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Ерикәй, Мәхмүт Максудлар да бар иде. Барыбызны да бер проблема эзәрлекли иде ул чакта – татар милли операсын төзү.

...Ул елларда Муса бик күп укый торган иде: аның өстәленнән Маяковский, Безыменский һәм башка язучы-шагыйрьләрнең китаплары төшмәде. Әгәр ялгышмасам, шул ук вакытта ул Габдулла Тукайның әсәрләре өстендә дә эш алып бара, аларны печатька әзерли иде. Иң истә калганы шул: Муса миңа Тукайның иҗат юлы турында язган үзенең зур мәкаләсен укыштыргалый иде».



**Латыйф Хәмиди**

* * *

Үзбәкле Кыйвам Җәгъфәрнең шундый алтын сүзләре бар: «Заман үз пәйгамбәрен үзе әзерли». Шулай итеп без дә, Тукаебыз һәм ул яшәгән заман вакыйгаларын өйрәнергә теләп, Казакъстан Үзәк архивына да барып чыктык. Тукай турында анык кына мәгълүмат тапмасак та, шагыйрь яшәгән чорны бераз күзалладык, татарлар турында өстәмә мәгълүматлар таптык шикелле. Милләттәшләребез инде ул вакытлардан ук тулы канлы тормыш алып барган. Динен, телен саклап яшәгән. Казакъ, уйгыр, кыргыз, үзбәк, гарәп, кытай, монгол, маньчжур телләрендәге архив материаллары арасында татар телендә дә документлар булуы – шуны раслый.

**Гөлназ Галимҗанова**

# Алматыдагы зыялыларыбыз

Алматыда беренче татар үзәге 1989 нчы елда оешкан. Аңа нигез салучы – Мөхәммәтшәриф Сәмигулла улы Госманов якты дөньяда юк инде. 20 ел дәверендә Алматыда татар мәдәниятен һәм телен үстерүгә гомерләрен багышлаган милли җанлы кешеләр шактый. Алар: күп еллар Үзәкнең рәисе булган Рәүф Гәрәев, галим Мөнир Ерзин, легендар «Сарман» җыр ансамблен оештыручы Равил Гозәиров, Виктория һәм Бәхтияр Табиевлар, Рабин Сәфәргалиев, оста музыкант Галимҗан Тамендаров, Үзәктә туган тел дәресләре алып барган укытучы, радиодиктор Фаягөл Гыйбадуллина, Рафаил Әхмәдиев, татар балалары өчен беренче якшәмбе мәктәбен ачкан Дилбәр һәм Әмин Фәхриевләр, Фирдәвес һәм Гриф Хәйруллиннар…

## Татар абруе

Рәүф Әхмәт улы Гәрәев Алматы татар үзәген ун ел җитәкләгән. Ул – киңкырлы иҗат кешесе: табиб, биология фәннәре докторы, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы.

Рәүф Әхмәт улы 1941 нче елны Алматыда туа. Әтисе хәрби табиб булгач, Гәрәевләр гаиләсенә гел күченеп йөрергә туры килгән. «Ун ел эчендә 11 мәктәп алыштырдым, – ди Рәүф әфәнде. – Әнием Галия Гарифҗан кызы – табибә. Ул Курган өлкәсеннән. Бабай Икенче гильдия сәүдәгәре булган, үз кибетләре бар иде. Курган өлкәсе белән Казакъстан чигендә урнашкан су тегермәне бабайның истәлеге булып әле дә саклана. Әтием – Оренбург өлкәсеннән.

Үзем кечкенәдән тарих белән кызыксындым. Мәктәптә укыганнар аз кебек тоелды да, татар тарихы буенча бик күп эзләнеп, китап иҗат иттем. Ул – «От скифов до татар» (Алматы, «LEM» нәшр., 2001 ел) дип атала…»

Ул китап безнең кулга да керде. Рәүф әфәнде борынгы бабаларыбыз Алтай тирәсендә яшәгән дип фаразлый. Алар үзләрен казаклар дип йөрткәннәр, тышкы кыяфәтләре белән дә без бүген күзаллаган татарга охшамаганнар. Ни генә булмасын, татар тарихында ак таплар күп, үткәнебезне бозып күрсәтүләр дә шактый әле.

Безне шунысы гына һаман да гаҗәпләндерә: белеме буенча тарих фәненнән ерак торган кардәшләребез, бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүчеләр милләт тарихын өйрәнеп китаплар нәшер итәләр, вакытлы матбугатта мәкаләләр бастыралар. Тагын шуны-

сы да гаҗәп, хәер, гаҗәпме, сокландыргычмы бу, Рәүф абый 7 яшькә хәтле татарча белмәгән. Ана телен саф татар мохитендә түгел, ә Читада яшәгәндә өйрәнә башлаган. 7 яшьтән тел өйрәнү белән күңеленә кергән татарлык аны гомер буе озатып килә. Хәтта, Германиядә яшәгәндә дә (6 ел – *Р.Г.*) ул тарихыбызны өйрәнүдән туктамаган һәм нәкъ менә Алман илендә төрле чыганакларда татар тарихының шактый объектив бирелгәнен сизгән. Бу ни дигән сүз? Бу элек СССР, хәзерге Русия империяләрендә милләтләр тарихы сәяси амбицияләр белән бәйле дигән сүз. Ягъни, тарих җәмгыять үсешенең билгеле бер чорында хакимлектә утыручыларның теләк-ихтыяры белән языла.



**Рәүф Гәрәев**

Рәүф әфәнде белән әңгәмәбез кызыклы да, гыйбрәтле дә иде. Ул үз тирәсенә татар зыялыларын күбрәк тупларга омтылуын да яшерми: «һәр дүрт шәкертемнең берсе – татар», – дип горурлана. Аның әйтүенчә, Алматы югары уку йортларында 60лап татар профессоры бар.

Рәүф Гәрәев Кеше һәм хайваннар физиологиясен өйрәнү институтында инде 28 ел лимфоәйләнеш лабораториясен җитәкли, баш фәнни хезмәткәр. Галим медицина юлында – 41 ел! Рәүф Гәрәевнең гаиләсендә барысы да табиблар. Тормыш иптәше – Диләфрүз Исмәгыйль кызы – балалар табибы. Өч кызы да әти-әниләре юлын сайлаган. Гәрәевләрнең дүрт оныгы бар. Алар да табиб һөнәрен үз итә икән.

Һәр милләтнең йөзен аерым шәхесләр билгели. Алар милләтнең «тоткасы», таянычы, абруе. Алматыда Рәүф Гәрәев яшәмәсә, монда татар дөньясының бер чите китек булыр иде кебек. 1966 нчы елдан шушы институтта эшләүче, галәм медицинасы буенча гыйльми эшләр җитәкчесе, космонавтика буенча фәнни-техник совет әгъзасы Рәүф Гәрәев әнә шул «татар абруе»н югары тотучыларның берсе. Казакъ космонавты Тәлгать Мусабаев белән төшкән фотосын күрсәтеп ул:

«Ә бит аның тәнендә дә татар каны ага, әнисе – татар», – дип куйган иде. Рәүф әфәнденең тел төбе аңлашыла: кандаш-кардәш егетне галәмгә менгезүгә үз өлешен кертүе белән горурлана иде Рәүф абый.

Аны тыңлап утырасың да: «Эх, бездә шундый асыл егетләр күбрәк булсын иде!», – дип куясың.

**Рәмилә Газизуллина**

# Кәрим бай оныклары

– Иң зур хыялым – балаларыма, оныкларыма шәҗәрәбезне ясатып калдыру. Без бит сәүдәгәрләр нәселеннән, Кәрим бай оныклары! – дип каршы алды безне Галия апа Хәмитова.

## Кем ул Кәрим бай?

Хәмитовлар 1870 нче елларда Себердә яши башлый. Гаилә башлыгы Әмин Хәмитов бирегә Пенза губернасыннан 4 улы: Хәмзә, Хәнуш, Мөхәммәтҗан, Кәрим белән күченеп кайта. Хәмзә Бохарага барып, мәдрәсә тәмамлый. Кайткач, Томски губернасының мулласы итеп куела. Кәрим дә тиздән абыйсы янына күченә һәм 1904-1905 нче елларда урыс-япон сугышында армиягә атлар сатып әкияти баеп китә. Миллионер һәм Икенче гильдия сәүдәгәр булгач, 1906 нчы елда ул моңарчы беркемдә дә булмаган 12 бүлмәле йорт-сарай төзетә.

Томскида сәүдәгәрләр җыелышының әгъзасы итеп куела. Кунаклар кабул итәргә яраткан Кәрим бай, ишегалдын гөлбакча итә. Анда фонтан эшли, Себердә бик сирәк булган тутый кошлар йөри…

1905 нче елгы революциядән соң халык аң-белемгә тартыла башлый. Татарлар өчен мәктәпләр кирәк була. Кәрим бай иң беренчеләрдән булып татар мәктәбе төзергә дип 10 мең сум акча бирә. Томскида кызлар, ир-атлар гимназияләре, Ак һәм Кызыл мәчет төзетергә байлыгын кызганмый. Су корылмасы ясатып, бөтен халыкны эчә торган су белән тәэмин итә.

Кәрим Әмин улы бик тә чибәр, киң күңелле, белемле кеше буларак та халык күңелендә калган. Ул татар, урыс, гарәп, төрек, фарсы телләрен камил белгән.

Кәрим бай үзен җәлләмичә эшли торгач, 9 баласын һәм 39 яшьлек хатынын калдырып, 56 яшендә якты дөньядан китә. Хатыны Мөтәгарә



**Галия апа улы Рәшит белән**

Латыйп кызы әле тагын 50 ел яшәп, Ташкентта җирләнә. Ә Кәрим Әмин улының кабере – Томскида.

Олы җанлы сәүдәгәр Кәрим Хәмитовны Томски татарлары онытмаган. 1996 нчы елда аның элеккеге йортында (Горький ур., 35 йорт) Татар мәдәни үзәге оеша. Бирегә еш кына Кәрим байның балалары, онык-оныкчыклары җыела.

## Алма агачыннан ерак төшми!

– Әйткәнемчә, оныкларыма нәсел шәҗәрәмне калдырасы килү уе гел күңелдән чыкмый иде. 2008 нче елны туганнарымны эзләп кызым белән Томскига чыгып киттек. Кулыбызда бары тик бер фото гына бар иде. Иң беренче итеп Кәрим бай төзеткән Ак мәчеткә кердек. Нигә шунда,чөнки Ак мәчеткә бары тик зыялы татарлар гына йөри торган булган. Мәчеттә 3 бабай утыра иде, сәдака салгач, әти-әнием турында сораштым. «Беләбез без әтиең Ибраһимны. Бик чибәр, акыллы кеше иде», – диделәр. «Ә Кәрим бай турында нинди дә булса мәгълүмат бармы?», – дигәч, – «Хәзер аның йортында Татар мәдәни үзәге урнашкан», – дип тиз генә Кәримнең оныгы Ифраимга шалтыратырга тотындылар.

Адрес буенча Ифраимның йортын эзләп таптым. Ярлы гына бер фатирда яшәп яталар икән. Ифраимга туган булуыбызны әйткәч, баштарак ышанмыйча торды. «Аферистлар җитәрлек булды!», – диде. «Мин – Кәрим байның туганы!», – дип килүчеләр, чыннан да, күп булган икән. Аннары бөтен тапкан туганнарымны җыеп, Коръән ашы уздырдым», – дип сөйләде Галия апа.

Галия Хәмитова 1936 нчы елда Кемерово төбәгенең Белово шәһәрендә туган.

Бала-чагы авыр сугыш елларына туры килә аның, шуның өстенә 15 яшендә бер-бер артлы әнисе белән әтисен югалта. Ташкентта Элемтә техникумын тәмамлаганнан соң, Томскиның бер заводында эшли башлый. Биредә Сәүдә институтын тәмамлый. Тормыш иптәше Рәхмәтулла белән ике бала тәрбияләп үстерәләр.

1958 нче елда гаиләсе белән Алматыга күчеп кайта. Биредә депутатлыкка да сайлана. Күп еллар кибет директоры булып эшли. 1984-1989 нчы елларда Алматы һәм Семипалатинск төбәкләренең хәрби частьләренә ярдәм күрсәтә.

Галия апага 75 яшь булса да, картаерга ашыкмый – кызлар кебек! Хәзерге вакытта тегү цехы булдырып, төрле оешмаларны махсус киемнәр белән тәэмин итеп тора.

Бер ел элек Хәмитовлар гаиләсенә кайгы килә. Нәсел шәҗәрәсе белән шөгыльләнүче Румия исемле кызы якты дөньядан китеп бара. «Бик акыллы иде кызым. Президент аппаратында, аннан соң бер фирмада юридик мәсьәләләр буенча директор урынбасары булып эшләде. Аның ике малае бар. Хәзер оныкларым белән бергә яшибез», – дип сөйләде әңгәмәдәшебез.

Галия апаның улы Рәшит Татар бизнесменнары клубының җитәкчесе. Запастагы подполковник, бер фирмада генераль директор булып эшли. Жаркент шәһәрендә үзенең крестьян-фермерлык хуҗалыгы бар. 800 кешене эш белән тәэмин итеп тора икән.

Инде сүз башына кайтсак, Галия апа ни өчен нәсел шәҗәрәсе төзү турында хыяллана соң? Татарда «Җиде бабаңны беләсеңме?» дигән сүз бар. Нәселе турында яманаты чыккан булса, кеше җиде бабасын өйрәнеп, нәсел-ыруы белән мактанып-горурланып йөрмәс иде, шәт. Алай гына да түгел, яманатын яшерергә тырышыр иде ул. Ә Галия апа үзенең ата-бабасы, туганнары, балалары, оныклары белән горурланып гомер кичерә. Аның шәҗәрә төзү хыялы – шулай матур итеп тә яшәп була, дип үрнәк күрсәтергә омтылу кебек.

**Альбина Газизуллина**

# «И, Тукай!»ны көйләп…

*«…безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ…»*
*Г. Тукай, «Хиссияте миллия», 1906 ел*

Экспедиция буена «Телебезне Тукай аша сакладык», «Безне Тукай шигырьләре яшәтә», «Тукай аша безгә читтә дә хөрмәт», – кебек сүзләрне ишетеп горурландык. Читтәге татарымның сүз саен Тукайны кыстыруы гаҗәп түгел түгеллеккә. Әмма Тукайдан кала башка каләм әһелләре, сәхнә йолдызлары, сәясәтчеләр барлыгын да онытмаска кирәктер. Аларның популярлыгы өчен бүген күпме акча түгеп, реклама, пиар эшләнә бит. Әнә – газета, телевидение, интернет, радио – кайсын ачсаң да, шулар турында гына сөйлиләр. Ә Тукай исеме – күбрәк бренд, татар милләтенең символы булып кала бирә. Шулай да, реклама-пиарсыз халкыбыз күңелендә гасыр буе Тукай исеме ничек яшәп килгән соң? Бу сорау әле Казанга кайткач та уйландырды…



Ә бренд дигәннән, Тукайны бренд итеп тиешенчә кулланган очракта да, үзебезне саклый һәм танытаалуда тагын күп нәрсәләр эшләп булыр иде. Фондыбыз дәүләт оешмалары белән берлектә моңа өлешчә алынып та карады инде. Әйтик, 2009-2011 нче елларда без Татарстан мәдәният министрлыгы белән берлектә мәктәп балалары өчен «Сөйкемле Шүрәле» бәйгесен уздырдык. Татарстан һәм Русия күләмендә ике ел рәттән оештырылган әлеге декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре конкурсында 7 мең бала катнашты. Укучылар Тукайның барлык персонажларын үз куллары белән тудырып, аларны Казандагы «Хәзинә» милли галереясына тәкъдим итте. Киләчәктә «Сөйкемле Шүрәле»не Халыкара масштабта үткәреп карарга ниятлибез.

Икенче бер кызыклы уебыз – дөнья буйлап Тукай исеме белән бәйле урыннарны барлап, саллы гына китап-альбом чыгару. Әмма бүген һәр нәрсә һаман да акчага терәлеп кала бирә…

## Алматы талантлары

Тукайның чит илдә дә бик абруйлы булуы сәнгать әһелләре белән дә бәйле. Чөнки нәфис сүз осталары, җырчылар һәм биючеләр булмаса, Тукай әсәрләре ерак кыйтгаларда да яңгырый алмас иде. Читкә чыгып киткәч тә, татар, кулына гармун алып моңланган. Тукайның «И, туган тел»е татар гимнына әверелгән икән, димәк, халкыбыз үз телен, туган илен һәм Тукаен сагынып яши.

Алматыда гомер итүче ике дус – Равил Гозәиров белән Галимҗан Тамендаров та гомер буе татар сәнгатенә хезмәт иткәннәр. Равил Гозәиров язган шигырьләргә Галимҗан Тамендаров көйләр чыгарган. «Үзебез кебек җыр-моңга гашыйк кешеләрне җыеп, «Сарман» ансамбле оештырдык. Без – Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстанда яшәүче милләттәшләребезнең көтеп алынган кунагы. Өч кызым – Энҗе, Радмила һәм Регина бу ансамбльдә солисткалар. Яшьләр безгә алмаш инде», – дип сөйләде Равил әфәнде.

Аның Казакъстандагы милләттәшләребез өчен башкарган эшләре санап бетергесез. Ул казакъ профессиональ музыкасына нигез салучы мәшһүр композитор Латыйф Хәмиди каберенә Киңсай мөселман зиратында истәлек ташы куйдыруны башлап йөргән. Милләттәшләренә матди ярдәм күрсәтү нияте белән «Алтын Ай» исемле фирма булдырган. Бу фирма аркылы концерт-очрашу оештыручылар Равил әфәнденең хәләл акчасына афишалар, чакыру билетлары бастыралар икән.

Гозәиров төрле шигъри җыентыклар авторы. Ул күбрәк мәхәббәт, дуслык, туган җирне сагыну турында яза. «Күңелнең иң нечкәргән, гомернең иң авырайган чагында туа ул моң. Менә шул вакытта җырлап җибәрсәң, йөрәктәге сызланулар бетеп китә», – ди Равил Гозәиров. Әсәрләрендә еш кына Тукайны искә ала.

«Идел» татар үзәгебез ел саен зурлап «Тукай кичәләре» уздыра. Монда өлкәннәр дә, яшьләр дә, башка милләтләр дә кушыла. Кичәдә Тукай шигырьләрен укыйлар, ә аларны бездә яттан белмәгән кеше юк. Әле үзебез дә Тукайга ияреп әсәрләр иҗат итәбез. Бервакыт Гриф Хәйруллинның «И, Тукай!» дигән шигыренә көй язгач, җырны бер бәйрәмдә башкарган идек, тамаша – бөтен халык шаккатты. Менә сезгә дә уйнап күрсәтим әле,» – дип, гармунын сузып та җибәрде Галимҗан абый.

Ул инде 59 ел кулыннан гармун, 56 ел баян төшерми икән. Әле 5 яше тулмас борын аңа әтисе Гәрәй җиде телле «Казан» гармуны, 8 яше тулгач, баян алып биргән. Үзенең беренче хезмәт хакына бит әле! Чөнки Гәрәй әфәнде үзе дә татар моңы белән янәшә атлап яшәүче.



**Сулдан уңга: Равил Гозәиров, Галимҗан Тамендаров, Мөнир Ерзин**

Ул Мәскәүдәге «Маяк» радиосыннан 1968 нче елда беренче тапкыр татар халык җырларын башкарып, дөньяга яңгыраткан кеше. Галимҗан Тамендаров та гомерен музыкага багышлаган. Ул бүген 200дән артык җыр һәм музыка авторы. «Былбыл», «Сарман», «Җырлыйбыз һәм биибез», «Иң яраткан көйләрем» кебек казакъ һәм татар телләрендә

10 җыентык, казакъ мәктәпләрендә башлангыч сыйныфлар өчен фонохрестоматия, фильмконцертлар төзүче. 40 ел казакъ мәктәбендә музыка укытып, 20 мең укучы тәрбияләгән ул. Араларында баянчы – Әсхәт Нигъмәтуллин, курайчы – Вәгыйзь Гайнуллин, биюче – Рамил Әмирханов күңелебезгә аеруча кереп калдылар. Казакъстанда бер татар җыены да, Татарстанга бер сәяхәт тә алардан башка узмый икән. Бу егетләр Казакъстан сәнгатендә «татар урынын» тотучылар.

Галимҗан абыйның профессиональ композитор булып китүенә табигый сәләте генә түгел, остазлары да «гаепле». Композиция нигезләрен ул Петропавел музыка училищесында бөек рус композиторы Н.А. Римский-Корсаковның оныгыннан өйрәнгән! «Баян-аккордеон һәм рус халык уен кораллары оркестры дирижеры» белгечлеге буенча укыган егет бүген дә Римский-Корсаков шәкерте булуы белән горурланып яши.

Бөтендөнья фестивальләре һәм конкурслары лауреаты Тамендаровның Казакъстан фольклор музыкасына керткән өлеше зур. Шулай булмаса, ул Казакъстан исеменнән күп тапкырлар Төркия, Германия, Русия, Австрия, Балтыйк буе илләрендә чыгыш ясамас иде. «Җыр язганда сүзләргә хас көй эзләп табарга тырышам», – ди ул. Әйтик, татар халкының Габдулла Тукай сүзләренә җырланган «Туган тел!» мажор пентатоникасында булса, Тамендаров Тимер Заһитның «И, туган тел!» шигыренә көйне минор пентатоникасында эшләгән. Җырның сүзләре исә мондый:

***И, туган тел!***
*(Габдулла Тукайга ияреп)*
*Тимер Заһит сүзләре, Галимҗан Тамендаров көе*

*И, туган тел, и матур тел,*
*Әткәм-әнкәмнең теле.*
*Телемдәй газиз халкым бар,*
*Сөекле туган илем.*

*И, туган тел, мөкатдәс тел,*
*И, моңлы татар теле.*
*Татар теле исән әле,*
*Шуңа халкым да тере.*

*И, туган тел, синең белән*
*Гомерем үтсен шулай.*
*Татар телен мәңгелеккә*
*Бер үзең сакла, Ходай!*

Галимҗан Тамендаровның тагын бер уңышы – аның музыкотерапия методикасын куллануында дияр идем. Әлеге ысул ярдәмендә күп кенә балалар савыгып, бүген Галимҗан абыйга рәхмәт укый. Музыкотерапия нигезеләренә сулыш алу күнегүләре салынган. Инде күп еллар ул «Алатау» республика балалар шифаханәсендә шушы ысул белән балаларны дәвалый икән.

Галимҗан Тамендаров – Казакъстаның атказанган халык мәгарифе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

## «Сарман-Былбыл»

Данлыклы «Сарман-Былбыл» татар халык ансамбленә без барган көннәрдә 25 яшь тулган иде. Әлеге ансамбльне оештыручыларның берсе – милләте буенча казакъ, әмма гомере буе татар музыкасына мөкиббән киткән, профессиясе буенча журналист Серик Кәли улы Кәлиев булган.

«1984 нче елны Серик Кәлиев өйгә шалтыратып, Татар ансамбле төзү турында тәкъдимнәрен әйтте. Мин тизрәк баш тарттым, чөнки ул вакытта СССРның халык артистлары – бертуган Абдуллиннарда, Роза



**Талантлы милләттәшләребез Казакъстанда уза торган һәр бәйрәмдә катнашалар**

Баглановада, «Балдырган» балалар хорында эшләү һәм телевидениенең туры эфирларында чыгышлар ясау белән мәшгуль идем. Ул мине шулай ярты ел үгетли торгач, «Сарман»ны оештырып җибәрдек. 1985 нче елдан инде тулы хокуклы ансамбль булып киттек. Сәнгать җитәкчесе итеп Равил Гозәировны билгеләдек. Ә мин ансамбльнең төп җитәкчесенә әйләндем», – дип сөйләде Г. Тамендаров.

«1986 нчы елның апреле. Бөек Тукаебызның 100 еллык юбилее уңаеннан, «Полиграфист» мәдәният йортында тантаналы кичә үткәрелде. Зал халык белән шыгрым тулы иде. Иң элек әдәбият белгече һәм тарихчы Халит әфәнде Галиәкбәровның халкыбызның олуг шагыйренә багышланган мавыктыргыч чыгышы булды. Татар телендә. Күп еллар үткәч, беренче мәртәбә!.. Лекциядән соң, «Сарман» ансамбле зур концерт күрсәтте. Озак еллар буе ишетелмәгән «Тәфтиләү», «Уел», «Әллүки», «Гөлҗамал» тамашачыларның күңелләрен кузгаттылар. Залдагыларның кулларында кулъяулыклар күренде: күз яшьләрен сөртәләр иде. Дулкынланырлык та шул! Сәхнәдә тантаналы төстә Тукай шигырьләре яңгырый, милли җырлар агыла, дәртле биюләр башкарыла. Моңа ничек сөенмисең?! Халык куанып, рәхәтләнеп кул чапты. Барысы да хәйран калдылар. Үз күзләрең белән күрергә кирәк бу мизгелне! Йөрәк түгел – таш та эрер иде бу минутларда! Әйе, үз илләреннән еракта яшәүче татарларда бар икән әле милли тойгы! Төрле кыенлыкларга карамастан, үзенең әдәбиятына-сәнгатенә, мәдәниятына булган олуг мәхәббәтен саклап калган, югалтмаган икән!..

Бу кичә – «Сарман»лы Тукай кичәсе – халкыбызны рухи йокысыннан уятты сыман. Концерттан соң тамашачылар үзешчән артистларны сәхнәдән тиз генә төшермәделәр – озаклап алкышладылар, чәчәк бәйләмнәренә күмделәр… Менә шул көннән «Сарман»ның уңышлы адымнары башланды…» – дип яза Равил Гозәиров үзенең «Гомер агышы – йөрәк сагышы» (Казан: «Дом печати» нәшр., 2001 ел) китабында.

1995 нче елдан алып бүгенгәчә «Сарман-Былбыл» ансамбле Морат Кәримов җитәкләгән «Идел» Ассоциациясе канаты астында эшли.

**Гөлназ Галимҗанова**

# Без – Кытайдан…

Кытай – заманында бик күп милләттәшләребезне сыендырган, чыныктырган ил. Байтак татар зыялыларының күңел сандыгындагы хатирәләр Кытай белән бәйле. Хәзер алар Татарстанда, Кыргызстанда, Казакъстанда, хәтта Австралиядә яшәсә дә, кендек каннары тамган җирне онытмыйлар. Әйтергә кирәк, Кытайда туып-үскән милләттәшләребезнең күбесе Казакъстанда гомер кичерә. Алар үзләрен: «Без – Кытайдан», – дип таныштырды.

## Кытай – Татарстан күперен ныгытучы

Алматыда Кытайның Голҗа, Өремче шәһәрләреннән күченеп яшәүче татарлар күп. Рабин Сәфәргалиев – Голҗа татары. Ул – Кытай–Татарстан күперен урнаштырып, Кытайдагы милләттәшләр белән берлектә Голҗа һәм Өремчедән 65 татар студентын Казанның югары уку йортларына укырга кертүне оештырган кеше. Үзе 52 нче елын Казакъстанда гомер итсә дә, һаман Кытайны сагынып яши икән.

– Безнең нәселдә исәннәрдән иң олысы – мин. Тамырларым әти ягыннан Урта Азиягә, әни ягыннан – Мамадыш районына барып тоташа.



**Уртада – Рабин Сәфәргалиев**

Әни Голҗада туып үссә, әти анда хәлле крестьяннарны эзәрлекләү башлангач килеп эләккән. Мин мәктәптә укыганда Кыргызстанга күчендек. Югары белемне Мәскәүнең тимер юл транспорты буенча инженерлар институтында алдым. Юллама буенча эшкә Ташкентка җибәрделәр. Кечкенәдән шулай төрле җирдә яшәргә туры килде. Юл кешесе мин, сәфәрдә күп йөрим. Фамилиям дә сәфәр сүзен кушып ясалган – Сәфәргалиев! Җае чыкканда гел Казанга «чаба» идем. Ни өченме? Без әле мәктәптә укыганда, Голҗада яшәсәк тә, Татарстанны туган ил итеп күрдек. Кытай татарлары өчен ул һаман да рухи ватан булып кала бирә. Ул вакытта Голҗада укый-яза белмәгән татар юк иде. Гөрләтеп татар мәктәпләре эшләде… Хыяллана торгач, 2002 нче елда Голҗага барырга насыйп булды миңа. Алматыдан без – 40 кеше ата-бабалар каберенә зиярәт кылырга киттек. Барып төшү белән мәктәпкә йөгердем. Ә анда мәш килеп Сабантуйга әзерлек бара! Хәзер Голҗа татар мәктәбенең бинасы гына калган. Татарларга белемне казакъ, кытай, уйгыр мәктәпләре бирә икән…

Рабин абый искиткеч олы йөрәкле кеше. Моны без аның белән аралашкан саен ныграк аңладык. Кытай татарларының яшь буыны «юкка чыгуына» битараф кала алмаган ул. 2003 нче елда беренче бозны кузгатып, Казан белән элемтәгә кергән. Ике елдан Казанга юллар ачыла: бер төркем бала Казанга белем эстәргә килә.

## Татар җан асрау өчен генә яшәми

*«Тукай теле, аның «Туган тел»е –*
*Әйтерсең бер изге догалык,*
*Шамаилләр итеп элгән халык,*
*Әй, бу халык, бөек бу халык.*
*Ул бер кулы белән һәйкәл салган*
*(Һәйкәлләрен аның сана, ил),*
*Ул икенче кулы белән үзенең*
*Шагыйренә язган шамаил».*

*Сибгат Хәким, 1977 ел.*

Экспедиция вакытында милләттәшләрне сөйләтеп, татарга бәйле урыннарны барлап, кыскасы, Тукай идеясе яшәгән илләрнең рухи асылын өйрәнергә тырыштык. Форсаттан файдаланып, шәхсән Урта Азия һәм Кытайның Шенҗан өлкәсе татарларына рәхмәт җиткерәсем килә. Төрле сәяси шартларда да алар үзләрен милләт итеп саклый алганнар.




**1911 нче елда татар сәүдәгәре Габделвәли Исхаков төзеткән «Кызыл таң» сәүдә йорты бүген тукыма сату кибете буларак хезмәт итә**

Җан асрау өчен генә яшәмәгән алар. Баштан үткән тормыш, уй-хыялларын гыйбрәт итеп, кардәшләренә поэзия һәм проза аша «сөйләргә» ашыкканнар. Хәзер дә, кесәләренә акча чиерттеме – тизрәк китап язып, бастырып, аны бушлай (!) халыкка таратырга тырышалар. Шундый милләттәшләребез Җаекта – Разак Әбүзәров, Костанайда – Суфия Зәбирова, Астанада – Тәуфикъ Кәримов, Алматыда – Мөнир Ерзин, Назилә Госманова-Юсимова, Гриф Хәйруллин (Тимер Заһит), Рәүф Гәрәев һәм Кытайның Өремче шәһәрендә – Абдулла Аббас, Малик Чанышев, Чүгүчәктә – Нәҗметдин Хәсәнов, Голҗада – Ильяр Габитов, Зөлфия Чапаева…

Без җыеп кайткан басмаларның әһәмиятен вакыт үзе бәяләр бәяләвен. Әмма эчтәлекләре ягыннан аларны дәрәҗәле җыентыклар дияр идек. «Китап – белем чишмәсе», «Китап – телсез мөгаллим», – дигән мәкаль-әйтемнәр дә халык телендә, нәкъ шушы Казакъстан һәм Кытай татарлары мисалында барлыкка килгәндер кебек. Авторлар белән аралаша торгач, шул аңлашылды: читтәге татар өчен иң зур байлык хәтер һәм китап икән. Ә бу бик борынгыдан килгән. Ерак кыйтгаларга күченгәч тә, татарлар Казаннан иң элек китап кайтарта башлаган. Мәктәпләр, мәдрәсәләр оештырган. Соңыннан үзләре газета-журналлар, әдәби китаплар, хәтта дәреслекләр бастырган. Кытайның Торфан өлкәсе

Бизеклик шәһәрендә, инде X гасырда ук беренче китап басыла башлавы да Урта Азия һәм Шәркый Төркестан халкына тәэсир итми калмагандыр, мөгаен. Мәгърифәтле халыкны җирле хөкүмәт тә, башка милләтләр дә хуплап каршылаган. Дәүләткә файдалы кешеләр булуы өстенә, татар башкаларны да укырга-язарга өйрәткән бит. Экспедиция вакытында кардәшләребез бүләк иткән басмалар фондбызның «алтын капиталы» булып торачак.

Әлеге китаплар коллекциясенә безнең «Истә калганнар» да өстәлер һәм татар өйләре киштәләрен бизәп торыр дип өметләнәбез. Чөнки без дә, милләттәшләребезнең яшәеш-көнкүрешен бераз яктыртып, исемнәрен тарихка яза алдык шикелле. Экспедициябезнең маршруты да моңа бер дәлил. Казакъстан белән Кытай татарлары бер җепкә «теркәлеп» яшәгәнгә, биредәге милләт тарихы аерылгысыз дип беләбез. Ни өченме? Бу сорага җавап эзләп, Мөнир Ерзинның «Ата-бабалар сукмагыннан» («Тропою предков», Алматы, 2005 ел) исемле китабына мөрәҗәгать иттем.

«1949 нчы елда, Алтайдан Голҗага киткәндә туганым Хәсән Ерзин миңа: «Без бөтенебез Совет гражданы булып язылдык. Сине дә керттек», – диде. Һәм шул вакытта әнием һәм туганнарымны алып, СССРга күченү мәсьәләсен уйлый башладым. Ә 1954 нче ел җиткәч, читтә яшәүче Союз кешеләрен туган якка кире кайтару процессы башланды. Шенҗан округында яшәүче татарлар әкренләп Алматыга юл алды. Һәм бу шәһәр безне гомерлеккә сыендырды», – дип яза Мөнир Ерзин.

Әйе, ул вакытта Советлар Союзы, шул исәптән Казакъстан да, Кытай һәм аның Шенҗанына караганда күпкә алга киткән республика була. Биредә белем алу, «яңача яшәү» өчен бөтен мөмкинлекләр туа. Шенҗанның Элә, Тарбагатай, Алтай округлары һәм Өремче шәһәре татарлары өчен Алматы – икенче туган якка әверелә. Биредә алар йорт-җир җиткереп, уку-эшкә урнашалар. Фән, мәдәният, әдәбият, спорт, медицина, технология, дәүләт эшләрендә уңыш казаналар. Алматыда Татар үзәкләре төзиләр һәм бүгенгәчә аларның активистлары булып торалар.

Араларында күренекле кешеләр дә байтак. Мөслимов Мәхмүд Садыйк улы, мәсәлән, Мәскәүдә төзелеш институтын тәмамлап, соңыннан Казакъстан ССРның авыл хуҗалыгы төзелеше министры булып киткән. Өремчедә туып-үскән Муллашев Камил Вәлиәхмәт улы дөньяга күренекле рәссам һәм Кытайның Гуандун провинциясе Ханьшань пединститутының **почетлы** профессоры булып танылган. Аның әтисе Шенҗанның иң оста каллиграфы саналган. Шенҗанның 1940 нчы елгы банкнотлары һәм кайбер газеталарның титул битендәге гарәп язулары аның кулы белән эшләнгән…



**Алматы уртасында татарча җырладык**

Мөнир Ибраһим улы Ерзин язганча, татарлар Алматыга XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында күченә башлый. Алар шәһәрнең хәзерге үзәге һәм Алматы читендәге урыннарга төпләнәләр. Бу урын бүген дә Татар бистәсе, кыскартып, «Татарка» дип йөртелә. Бүген дә анда Алматы татарларының күпчелек өлеше Кырым, Әстерхан, Ырымбур, Уфа, Казан, Татар урамнарында яши.

Татар бистәсенә милләттәшләребез шулай ук, Казан, Вятка, Тобол губерналарыннан, Семипалатинск, Төмән җирләреннән килеп төпләнгән. 1879 нчы еллар мәгълүматлары буенча, ул вакытка монда 592 кеше яшәгән. Бу – Верный шәһәренең 4 процентын тәшкил иткән. Бистәдә тормышлары алга киткән халыкка хөкүмәт төрле льготалар билгеләгән. Мәсәлән, бакчачылык-хуҗалык, сабын кайнату, йон юу, кирпеч, шәм, күн эшкәртү предприятиеләре өчен җир бүлеп биргән. Чөнки бирегә килеп урнашкан татар интеллигенциясе матди яктан тиз арада аякка баса. 1857 нче елда Татар Бистәсе тирәсендә Алимҗанов (Галимҗанов, бәлки – *Г.Г.*) атлы берәү Алматының беренче су тегермәнен төзи. И. Габделвәлиев, Т. Мөхсинов, З. Таҗетдинов, М. Каипов исә үзләренең сәүдә йортлары белән танылa. Ә И. Габделвәлиев белән Т. Мөхсинов миллионерларга әйләнеп, Беренче гильдия сәүдәгәрләре булып китәләр. Исхак бай Габдевәлиев үз хисабына шәһәр уртасында мәчет төзетә һәм тугызъеллык белем бирүче мәдрәсә ачтыра. Татар бистәсендә XIX гасырның икенче яртысына караган мәчет һәм мәдрәсә дә аның акчасына торгызыла.

1911 нче елда татар сәүдәгәре Габделвәли Исхаков «Кызыл таң» дигән сәүдә йорты төзетә. Аның зурлыгына исең китәрлек – 1450 квадрат метр! А.П. Зенков проекты буенча төзелгән бу мәһабәт бина 1979-1980 нче елларда реставрацияләнеп, илнең архитектура һәйкәле булып танылa. Бүген дә ул Алматыга тукыма сату кибете буларак хезмәт итә. Җирле татарлар, Исхак бай истәлеге итеп, «Кызыл таң»ны татар кибете дип йөртә.



**Дилбәр Фәхриева**

Әлеге татар интеллигенциясе «Шимбәлек» дигән беренче татар оешмасы да төзи. Кешеләргә татар китаплары һәм матбугаты (шул исәптән Тукай иҗаты – *Г.Г.*) белән танышу өчен мөмкинлек туа. 1907 нче елда әлеге оешма көче белән Алматыда беренче мөселман, ягъни төрки халыклар өчен китапханә төзелә. Китап, газета-журналларны Казан, Уфа, Троицкидан кайтаралар.

Шулай ук, Алматыда татар театры да эшләп килгән. Татар балалары И. Гаспралы исемендәге мәктәптә белем алганнар. Габдулла Тукайга багышланган кичәләр, Сабантуй, Нәүрүз бәйрәмнәре инде шул вакыттан бирле үткәрелеп килгән.

Татарларның Алматыга икенче тапкыр күченүе, әйткәнемчә, 1955 нче елда – Элә, Тарбагатай, Алтай округлары һәм Өремче шәһәреннән була. Алар хисабына Алматыда татар рухы ныгый һәм халык саны арта. 1937 нче елда Казакъстанда 92 мең татар исәпләнсә, 1970 нче елга бу сан 288 меңгә җитә, дип искәртә Мөнир Ерзин.

Әллә сан ягыннан күбәйгәнгә, әллә фикер аерымлыклары булганга, Алматыда берничә Татар үзәге, татар-башкорт оешмалары төзелә. Без 2008 нче елда баргач, Алматыда дүрт Татар үзәгенә (бирегә Татар-башкорт үзәге дә керә) тап булган идек. Бу юлы исә Үзәкләр саны – алтыга җиткән! «Безгә шулай уңайлырак. Һәрхәлдә, без – төрле Үзәк татарлары – бер-беребезне хөрмәт итеп яшибез», – диделәр безгә. Алматыда яшьләр дә икегә бүленгән: берләре – Ренат Әюпов, икенчеләре – Зәйнулла Ибраһимовка иярган. Ренат бу турыда: «Булса соң, мин моңа һич каршы түгел. Көндәшлек булганда гына халык

активлаша. 6 үзәк булгач, бәйрәмнәрне дә узыша-узыша үткәрәбез. Яшьләргә дә көндәшлек кирәк. Бу бит әле без таркау дигән сүз түгел», – диде. Ренат үзе эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, Казакъстан халыклары Ассамблеясында яшьләр канаты координаторы. Алматы «Татар этномәдәни берләшмәсе»ндә урынбасар булып тора. Берничә югары белем алган Зәйнулла Ибраһимов исә, Алматыда ике мең дистәдән артык татарны саклап калмакчы. Аның фикеренчә, моның өчен һәр елны 500 бала туарга тиеш. Катнаш никахларның күбәеп китүе моңа, һичшиксез, комачаулый. Узган гасыр башында татарлар арасында катнаш никахлар бер процент булса, хәзер исә 30 тапкыр арткан. Аннан Зәйнулла татар балалары өчен балалар бакчасында татар төркеме булдыру турында хыяллана.

Соңгы елларда татар яшьләре өчен якшәмбе мәктәпләре дә эшләп килгән. Яшьләргә олылар да ияреп, 2008-2009 нчы елларда Татар мәдәни үзәгендә әлифба буенча укырга өйрәнгәннәр. Һәр шимбә саен тарих фәннәре кандидаты Рафаил Гарифулла улы Әхмәдиев милләттәшләренә сабак укыткан. Ә Мамадыш якларыннан Казакъстанга бәхет эзләп килгән Дилбәр һәм Әмин Фәхриевләр 2001-2006 нчы елларда татар мәктәбе тотканнар. «Казакъ, уйгыр, урыс мәктәпләре барында, нишләп татар мәктәбе булмаска тиеш, дип уйлаштык та, шәһәр читендә яшәсәк тә, тәвәкәлләдек. 12 баладан башлаган идек, соңыннан 24кә җиттеләр. Укытырга китап булмагач, ирем Татарстанга кайтып килде. Дәрестә татар халык җырларын көйли идек, Габдулла Тукай, Муса Җәлил шигырьләрен укыдык», – дип сөйләде алар.

Алматыда безне тагын шунысы куандырды: биредә инде 1993 елдан бирле «Фикер-Өмет» газетасы чыга. Башта «Өмет» белән «Фикер» аерым басылганнар. Әмма соңгы вакытта ул «Фикер-Өмет» булып чыга. Тиражы – 500-1000 данә. Баш мөхәррире – Гриф Хәйруллин. Иҗат коллективында – Мөнир Ерзин, Рәүф Гәрәев, Ренат Әюпов, Әсхат Нигъмәтуллин да бар. Биредә Алматы татарлары һәм башка милләт яңалыклары, Татарстан хәбәрләре, танылган каләм ияләренең язмалары урын ала. Газетаның һәр саны берәр иганәче ярдәме белән дөнья күрә. Газетаның соңгы битендә бу мәрхәмәтле иганәченең исем-фамилиясен сан саен биреп баралар. «Фикер-Өмет» бушлай таратыла. Мөнир әфәнде безгә фәнни яктан өйрәнү өчен әлеге газетаның барлык номерларын тапшырган иде. Бер кат анализлап чыккач, шаккаттым: биредә иң күп басылган тема – Тукай һәм аның иҗаты икән. Бу үзе үк, Алматы татарларының Тукай рухы белән яшәүләрен күрсәтә.

**Рәмилә Газизуллина,**
**Гөлназ Галимҗанова**

# «Анда Тукай дәвере, татар әдәби теленең тәэсире көчле иде»

Шагыйрә Назилә Госманова-Юсимованың «Ана теләге» (Алматы, 2005 ел) китабына кереш җөмләне шулай дип язган Мөнир Ерзин. Бу сүзләрне Назилә ханым үзе дә кире какмый: «Тукайдан илһам алып яшәмәсәм, бу кадәр китаплар яза алмас идем», – ди. Ул һәр сорауга үзе язган шигырь юллары белән җавап бирергә ярата:

*Төрле-төрле сәбәп белән*
*Туган илдән киткән бабалар.*
*Шул көннәрдән бирле сагыш көен*
*Җырга кушып җырлый балалар.*
*Милли рухын кушып ак сөтенә*
*Бәбкәенә биргән аналар.*
*Югалтмаска тырышып динен, телен*
*Мәктәпләрне сала бабалар.*
*Илдән еракларда яшәсә дә*
*Казан басмаларын табалар.*
*Тукай теле, Тукай җыры белән*
*Туган телен саклап калалар.*
*(«Безнең бабалар»)*

Ләкин шагыйрә дип кенә дә әйтеп булмый Назилә апаны. Казан дәүләт университетында инде мәрхүм остазыбыз, академик Миркасыйм Госмановның сеңлесе булган бу ханым татар тарихын, Казакъстан белән Кытайда яшәүче күренекле милләттәшләребез не барлаучы да, тәрҗемәче дә. Аның «Онытылмас шәхесләребез», «Остазларга ихтирам», «Татарларның милли йолалары» китапларын энциклопедияләргә тиңләр идем. Билгеле, Кытай һәм Урта Азия илләре татарлары турында бүген басмалар аз түгел түгелгә. Әмма милләттәшләребезнең иҗат җимешләреннән башка бу тарихи чыганаклар тулы була алмаслар иде. Назилә апаның үз акчасына 6 елга 6 китап бастыруы башта гаҗәп тоелды безгә. Ул бит әле тиенләп, пенсиясен җыеп?! Шигырьләре арасында Тукайга атап язылганнары да байтак.

***Тукайга***
*Әдәби байлык – асыл иҗатың*
*Үз милләтеңә бүләк итә алдың.*



**Беренче рәттә уртада Назилә Госманова-Юсимова**

*Халык моңнарын тирән төшенгәч,*
*Йөрәк кылларын тибрәтә алдың.*
*Мактанышы син татар иленең,*
*Асыл ташы син татар җиренең.*
*Якты йолдызы татар күгенең,*
*Чын җәүһәре син татар күзенең.*
*Матур сүзләре татар җырының,*
*Яңгырый сазы татар моңының.*
*Вакытсыз шиңгән татарның гөле,*
*Онытылмас Тукай – ул татар улы.*

Ачык йөзле, тәмле телле, тыйнак холыклы бу ханым йортында сәфәребез вакытында берничә тапкыр кунак булдык. Бүлмәсенә кайчан килеп кермә, ул уйга чумып, өстәл артында нидер язып утырыр иде. «Китапларыгызны ник сатмыйсыз?», – дип кызыксынуыма каршы ул: «Сату өчен язмыйм, балалар. Халкыма кечкенә генә булса да бүләк калдыру теләгем. Язмыш авырлыгына бирешми торган милләт икәнебезне алдагы буын белеп яшәсен», – дип, әйтә иде. «Аның шигырьләрендә татар диаспораларының уй-фикерләре, рухи халәтләре, халкына, иленә, кардәш халыкларга дигән сөю тойгылары аермачык итеп чагылдырыла», – дип яза бу сүзләрне куәтләп каләмдәше Мөнир Ерзин.

*Тукай, Такташ шигырьләрен*
*Халык җырлап ятлаган.*
*Ассалар да, чапсалар да*
*Динен, телен саклаган.*
*(«Татарлар» шигыреннән өзек)*

2008 нче елда Назилә апа казакъ шагыйре Макатаев Мокагалиның 90 шигырен татарчага тәрҗемә итеп, аерым китап итеп бастырган. «Казакъстан хөкүмәте лауреаты» бүләгенә ия булган Мокагали Макатаев – казакъ халкының талант иясе. Аның шигырьләрен укып чыккач, хакыйкатьне яклаучы, динен, милләтен һәм ана телен чын йөрәгеннән дулкынланып сөюче, милли хисләр чолгап алган уйларын халкына җиткерергә омтылганда төрле җәфалар чигеп, киртәләр үтеп, кыска гомере эчендә күпләгән шигырьләр һәм поэмалар язып калдырган бу шәхес мине бик гаҗәпләндерде. Гайрәтенә афәрин!», – ди Назилә Госманова аның турында.

Без бу юлы килгән вакытта Назилә ханым инде икенче китабын тәрҗемә итеп утыра иде. Монысы уйгыр теленнән татарчага һәм русчага икән. «Күз яшенә чыланган ил» – «Край, пропитанный слезами» – Чанышева Сөенгөл Салих кызы авторлыгында, 735 битле, 2006 нчы елда Истамбулда дөнья күргән китап ул. Назилә апа аның көндәлек дәфтәре формасында язылган өлешен тәрҗемә иткән. Өремче шәһәрендә туган Сөенгел Чанышева Шәркый Төркестанның ирекe өчен көрәшүчеләрнең берсе булган. Аның яшерен хәрәкәтләрдә катнашып йөрүен 1962 нче елда Кытай хөкүмәте сизеп алган һәм бер төркем яшьләр белән 18 елга төрмәгә япкан. Бүгенге көндә бу ханым Австралиядә яши.

Назилә апаның «Остазларга ихтирам» җыентыгын укып чыккач, татарның никадәр гыйлемгә омтылып яшәүче халык икәнен тагын бер кат аңлыйсың. Бу китап шулай ук Алматыда, 2006 нчы елда дөнья күргән. Биредә язучы ханым туып-үскән Шәркый Төркестан төбәге, анда хезмәт куйган укытучылар, тәрбиячеләр һәм табиблар турында кыскача мәгълүмат бар. «Китапта күрсәтелгән укытучылар өчен генә түгел, бөтендөнья укытучыларының авыр хезмәтен бәяләп, игътибар итү ягыннан да бик әһәмиятле бу китап. Зур абруй казанган укытучылар Казакъстанга, Советлар Союзына күчеп кайткач та мәктәптә, балалар бакчасында хезмәт иткәннәр. Русиягә, Казанга барып укып, зур дәрәҗәгә җиткәннәр», – дип яза китапка кереш сүздә якташы, мәктәптә 30 ел математика фәне укыткан Наилә Абдулкәримова.

Назилә Госманова үзе Голҗа татар мәктәбен тәмамлаган. Тукай иҗаты белән дә тәүге тапкыр шушы мәктәптә танышкан. «Укытучылар – «Балаларның киләчәге – остазлар кулында», – дип әйтелгән бабалар сүзләренә буйсынучылар. Чын ихлас күңелләре белән милләтенең киләчәк буыннарын кайгыртучылар. Шуңа күрә дә анда караклар, ялкаулар, тәртипсезләр юк дип әйтергә була. Голҗада белем алып чит илләргә таралган татарлар арасында, академиклар, зур галимнәр, атказанган рәссамнар, артислар, университетларда дәрес бирүчеләр дә бар. (Ассызыклап әйтәм, болар бит Кытайдагы татар мәктәбен

тәмамлаучылар! Ә татарның үз җирендә мәктәпләребезнең бүгенге язмышы нинди? 2010-2011 нче уку елында Татарстанда инде 205 мәктәп эшләүдән туктады. Шуның 63ен – вакытлыча, 142сен бөтенләй яптылар. Исәпләүләр буенча, аларның 54 проценты – саф татар мәктәпләре. Уку йортларының ябылу сәбәбен – сыйфатсыз белем бирүдә күрәләр. Ә Голҗа татар мәктәбе нинди сыйфатлы белем дә биргән, күпме татар, уйгыр, казакъны да аңлы-белемле иткән – *Г.Г.*)

Назилә ханым белән элемтәләрне өзмибез. Телефон, интернет аша хәбәрләшеп, Казан белән Алматы арасында йөрүче милләттәшләр аркылы сәламнәр дә җибәрешеп торабыз. Казандагы туганнары – Надия белән Фәрит Мөслимовлар аркылы ул үзенең яңа «иҗат җимешләре» белән Татарстан укучыларын да таныштырып бара.

## Тарихчы Хәйруллин

Гриф Тимерзаһит улы Хәйруллин – педагогия фәннәре докторы. Милли педагогика университеты профессоры, Халыкара информатизация академиясе һәм Халыкара акмеология фәннәре академиясе академигы, Татарстанның атказанган укытучысы, «Казакъстанда фәнне үстерүдәге хезмәтләре өчен» билге иясе, Үзбәкстанның мәгариф отличнигы да. 35тән артык китап авторы. Татар һәм башкорт халыкларының тарихын, мәдәниятен өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхес ул.

«Мине һәрвакыт татарның үткәне, чит җирләргә таралып яшәү сәбәпләре кызыксындырды. Сәяси шартлармы, бәхет эзләүме, әллә утрак тормышка караганда күчеп йөрүне кулай күрүме – татарны читкә нәрсә алып киткән?», – ди Гриф Хәйруллин. Күптән түгел аның «Татары в Казахстане» энциклопедик сүзлеге (Алматы, ИД: « МИР», 2011 ел) дөнья күрде.

«Татарлар үз җирләреннән Урта Азиягә Явыз Иванның 1552 нче елгы яулап алуыннан соң күченә башлый. Казакъ солтаннары һәм бiләре исә качак татарларны патша хөкүмәтенә «сатмаган». Әле тагын шундый фараз бар, бәлки «Татарның монда булганы да юк», – кебек ялганны солтан әйтүе буенча качак татар үзе үк язгандыр да. Чөнки татарлар гыйлемле булып, соңыннан бу җирләрдә аң-белем таратуда өлеш керткәннәр.

Еш кына милләттәшләребез салым түләү яки солдатка барудан качып та казакъ җирләрендә төпләнгән. Хәтта Русиядән авыллары белән күченгән татарларны да хәтерли тарих. Бирегә алар рус, казакъ фамилияләрен алып яңа тормыш корган. Шундый авылларның берсе – Лепсы.

Ә татарлар күченгән вакытта Алматы «Верный» исемен йөрткән. Верныйның тарихы болайрак. 1851 нче елда Русия империясенең хәрби көчләре Җидесу тирәлегенең шактый өлешен үзләренә алып, ныгытмалар төзи башлыйлар. Шундый ныгытмаларның берсе булган «Заилийское» борынгы Алмалы җирлеге, Кече Алматы елгасының сулъяк ярында торгызыла. Ул биш почмаклы крепость формасында эшләнеп, гарнизонында 470 солдат һәм офицер тора. 1854 нче елдан ныгытма «Верный» исемендә йөри башлап, ә 1867 нче елдан Верный шәһәре булып китә. Моннан соң әле бик күп тарихи вакыйгалар булып уза. Бары тик 1921 нче елда гына кала Алма-ата исемен алып, 1929 нчы елдан Казакъстан башкаласы булып китә. Ә 1993 нче елда аны «Алматы» дип яза башлыйлар. 1998 нче елда башкала Астанага күчкәч, Алматыга «Көньяк башкаласы» дигән статус бирәләр», – дип яза үз китабында Гриф Хәйруллин.

Алматы шәһәрен татарлар төзегән дип ишеткән бар иде үзе. Гриф әфәнде Алматы өлкәсенең тирәлеген дә татарлар биләгән дип тә өстәде. Әйтик, Каратал елгасы буендагы Бесбойдак авылына 1860-1865 нче елларда, патша армиясеннән качкан биш буйдак нигез сала. Шуңа күрә халыкта бу җирлек «Бесбойдак» («Биш буйдак») булып китә. Биш буйдакның берсе – «кабилә»нең җитәкчесе Мендигул тарихка «Боранбай Кажи» исеме белән кереп кала. Кабилә 1918 нче елга кадәр яши. Аннан Совет хөкүмәте аларга җир бүлеп биргәч, мондагы халык җир эшкәртеп көн күрә башлый. 1929 нчы елда коллективлаштырудан баш тартулары өчен, бесбойдаклыларны эзәрлекли башлыйлар. Халыкның бер өлеше Кытайга кача. Алар арасында Мендигулның ике улы да булган, диләр. Ә бу урында «Тенлик» («Равенство») исемле колхоз оешып, авыл исеме Тенликка үзгәртелә. Биредә яшәүчеләр бүген дә үзләрен бесбойдак дәвамчылары дип саный икән.

1846 нчы елда, Русия белән Кытай чикләрен саклап калу максатыннан, Алматы өлкәсенең Талдыкорган шәһәре тирәсендә Лепсинск (Лепсы) шәһәре төзелә. Аның беренче кешеләре казаклар була. 1898 нче елда бирегә татарлар да күченә. Мәчет каршында татар мәтәбе ачылып, Казаннан Латыйпов фамилияле укытучы эшкә чакырыла. Лепсы үзенең умарта балы, балавыз, май эшләү, кирпеч заводы, су тегермәннәре һәм башка бик күп яклары белән таныла. Бу авылда ике чиркәү һәм өч мәчет эшләгәнлеге дә мәгълүм. Йортлар агачтан төзелгәндә, мәчетләр кирпечтән һәм таштан корылган була.

Лепсыга барып чыкмасак та, аның җәмигъ мәчете турында И.М. Вафин язмасыннан укыдык. Бу иман йортын указлы мулла Хөсәен



**Уңнан икенче – Гриф Хәйруллин**

хәзрәт Исмәгыйль улы проекты буенча эшләгәннәр. 1944 нче елда, хөкүмәт кушуы буенча аны шартлатырга уйлаганнар. Ләкин мәчет ныклы салынганга күрә, тиз генә бирешмәгән һәм аны алтынчы тапкырында гына шартлата алганнар. Ә бу рәхимсез эштә катнашкан кешеләрнең гомере аянычлы тәмамланган, диләр.

Лепсы тагын күренекле татар шәхесләрен биргән җир дә ул. Биредән юстиция полковниклары, югары дәрәҗәдәге федераль судьялар, фән докторлары, профессорлар, композиторлар һәм сәүдәгәрләр чыккан.

Гриф әфәнде энциклопедик сүзлегендә тагын бер кызыклы мәгълүматка тап булдым. 1919 нчы елда татар актеры Х. Уразиков Верныйга килеп, Г. Тукай исемендәге труппа оештырган. Әлеге труппада кемнәр булган? «Г. Тукай исемендәге театр» кайларда чыгыш ясаган? Ничәнче елда һәм ничек таралган? Ә бәлки, аның дәвамчылары исән-саудыр? Бу турыда эзләнәселәребез алда.

Гриф Хәйруллин шагыйрь дә әле. Аның шигъри җыентыклары Алматы, Казан, Уфа шәһәрләрендә дөнья күргән. Җаек татарларының гимнына әверелгән «И, Тукай» җырының сүзләрен дә ул иҗат иткән.

**И, Тукай!**
*Гриф Хәйруллин сүзләре,*
*Галимҗан Тамендаров көе.*

*Бәхет өчен бу җиһанга*
*Килгән булса да бала,*
*Язмыш аны читкә кагып,*
*Михнәт утына сала.*
*Кушымта:*
*И, Тукай, моңлы Тукай,*
*Кайгылы, зарлы Тукай.*

*Чыдам була, тырыш була,*
*Үсеп җитә бу егет,*
*Идел суы, Урал суы*
*Бергә көч биргән кебек.*
*Кушымта:*
*И, Тукай, нурлы Тукай,*
*Югалмас җырлы Тукай.*
*Якты дөнья читлеге тар*
*Ятим үскән шагыйрьгә.*
*Сазы сынды, үзе сүнде,*
*Сагыш салып бәгырьгә.*
*Кушымта:*
*И, Тукай, нәүмиз Тукай,*
*Халкыңа газиз Тукай.*

*Күктән йолдыз атылгандай,*
*Очты ялтырап Тукай.*
*Ядкарь итеп Тукай моңын*
*Җырлый һавада тургай.*
*Кушымта:*
*И, Тукай, бөек Тукай,*
*Син исән кебек, Тукай!*

**Гөлназ Галимҗанова**

# «Бәхтияр – ул чиксез дала»

Бәхтияр Табиев – дөньякүләм билгеле рәссам, Көнчыгыш мәдәнияте һәм табигате җырчысы. Кытайда туган, Казакъстанда яшәгән, гомере буе тарихи ватаны – Татарстанны сагынган. Шунысы гаҗәп: иң кыйммәтле татар рәссамы Бәхтияр Табиевның иҗаты татарстанлыларга бик үк билгеле түгел.

Морзалар нәселеннән булган Бәхтияр Табиев әле теле ачылганчы ук идәндә күмер белән рәсемнәр ясаган.

Табиевлар – татар дөньясында билгеле шәхесләр. Бу нәселнең тамырлары Рязань өлкәсенең Аҗи (хәзерге Азеево) авылына барып тоташа. Бәхтиярнең бабасы Гани һәм әбисе Аҗар – икесе дә шушы авылда туып үскән.

16 яшьлек чагында, Гани Табиев (тәвәккәллеге өчен аны Мут Гани дип йөрткәннәр), Казакъстанның Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә чыгып киткән. Монда ул мал-туар тотып, йон, тире, терлек сату белән шөгыльләнгән. Әлеге эшкә энеләре Алим белән Садыйк та кушылгач, кәсепчелек тагын да киң колач җәйгән. Бертуган Табиевлар хәтта Германия белән дә эшлекле килешүләр төзегәннәр.

Гани Табиев үз эшен улы Хәсәнгә (Бәхтиярнең әтисе) тапшырырга була. Тик 1917 нче елда Гани байның гомере өзелә. 20 нче елларда хәләл җефете Аҗарны сөргенгә җибәреп, аларның йорт-җирен конфискацияләгәннәр. Хәсән исә йон сортлаучы булып эшләп гаиләсен туйдырырга мәҗбүр булган. 1933 нче елда, Хәсәнне «хөкүмәт эзли» дигән хәбәр таралгач, ул 7 балалы гаиләсе белән Кытайның Голҗа шәһәренә күченеп китә. 1940 нчы елның 14 нче маенда биредә Бәхтияр туа. 1947 нче елда, Хәсән Табиев бакыйлыкка күчкәч, күп балалы гаиләне алып бару хатыны Фатыйма җилкәсенә кала. Фатыйма искиткеч акыллы, сабыр хатын була. Ул барлык балаларына югары белем алу мөмкинлеге тудыра. 1955 нче елда гаилә Кыргызстанга күченгәч, Бәхтияр Фрунзе сәнгать училищесына укырга керә һәм аны кызыл диплом белән тәмамлый. Аннан укуын Суриков исемендәге сәнгать институтында дәвам итә.

Бәхтияр Табиев картиналары «Единый художественный рейтинг» (2002 нче ел, 5 нче сан) белешмәсендә «3А» тамгасы, ягъни «үзенә генә хас сурәтләү алымы булган рәссам-профессионал, сәнгать базары һәм халык тарафыннан сорауга ия» дип бәяләнгән. Аңа тикле Татарстанда яшәп иҗат итүче бер рәссамның да шулай бәяләнгәне булмаган.

Бәхтия Табиевның киңкырлы иҗаты – эстетик яктан күпкә кыйммәтрәк. Ул картиналарында, 69 нчы еллар сәнгатькәрләренә хас булганча, үз телен, тавышын, индивидуаль интонациясен эзли. Аның һәр картинасы – фәлсәфи күзаллаулар дөньясы, дөньяга булган үз карашы. Бу – өрек агачының чәчәктә утыруы, таң атуы һәм кояш баешы, талгын җилдә күлмәк итәге җилфердәве, чиксез дала, ай яки төнне яктыртучы гади бер йолдыз, реаль кешеләр тормышы… Рәссамның картиналары Третьяков галереясында, Урта Азия музейларында, Австралия, Болгария, Германия, АКШ, Төркия, Франция шәхси коллекцияләрендә саклана. Бәхтияр Табиев Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казакъстан республикасы Рәссамнар Берлеге һәм Париждагы Халыкара сәнгать үзәге әгъзасы.

Танылган болгар рәссамы Матей Матеев Бәхтияр Табиев турында: «Бәхтияр – ул чиксез дала», – дип юктан гына әйтмәгән. «Ул һәр өлкәдә сәләтле, гыйлемле, тормышта киң карашлы, искиткеч холыклы Кеше иде», – дип яза аның турында дуслары. Татар халык җырлары, казакъ айтысы, уйгыр һәм үзбәк җыр-биюләре, кыргыз эпосы – Бәхтияр Табиев һәр өлкәдә белгеч була. Халыклар тарихын яхшы белү аңа күп тапкыр Лев Гумилев белән очрашып фикер алышудан килә. Барлык төрки телләрне үзләштерү белән бергә, ул гарәпчә укыган һәм язган, кытай иероглифларын белгән.

Бәхтияр Табиев Казакъстан татар үзәге лидерларының берсе булып торган. Татарстаннан килгән кунакларны Алматыдагы зур йортында кунак итүдән тыш, үзе дә Казанга килергә яраткан. Татарстанда узган беренче референдумда һәм Татарстан Республикасы президенты сайлауларында Казакъстан татарларыннан нәкъ менә ул күзәтүче булып катнашкан. Беренче Бөтендөнья татар конгрессында аның белән кызыклы хәл килеп чыга. Конгресста дөньяның өч җиреннән өч Табиев – Лос-Анджелестан Рифат Таби, Мәскәүдән Фикрәт Табиев һәм Казакъстаннан Бәхтияр Табиев очраша. Баксаң, алар өчесе дә бер нәселдән икән.

Барлык рәссамнар кебек үк, Бәхтияр Табиев та Париж, Лувр турында хыялланган. Бөек рәссамның хыялы 1998 нче елда тормышка аша: аны улы Азат белән Париждагы Халыкара сәнгать үзәгенә чакыралар. Ике ай буена аталы-уллы рәссамнар Парижда яшәп иҗат итәләр, төрле музей-күргәзмәләргә йөриләр. Соңыннан, биредә Бәхтияр Табиевны Халыкара сәнгать үзәгенең әгъзасы итеп билгелиләр.

Бәхтияр Табиевның тагын бер хыялы – тарихи ватаны Казанда иҗади күргәзмә оештыру була. Бу күңелле вакыйгага ул берничә ел әзерләнә. Тик тумыштан килгән йөрәк авыруы 1999 нчы елда аны

дөньядан алып китә... Гаиләсе, дуслары ярдәме белән рәссамның бу хыялы да чынга аша. 2005 нче елда «Казан» милли мәдәни үзәгендә рәссамның күргәзмәсе үтә. Шул елда ук, соңлап булса да, Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы Бәхтияр Табиевны «Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкли.

## «Бәхтияр – минем бәхетле тормышым»

Бәхтияр Табиевның гаиләсе – тормыш юлдашы Виктория ханым, балалары Сәйдә белән Азат бүгенгәчә Казакъстанның Алматы шәһәрендә гомер итә. Алматыга баргач, без дә рәссамнар фатирында кунак булдык. Табиевлар гаиләсе рәссамнар өчен махсус төзелгән комплекста яши.



**Бәхтияр Табиев**

«Бәхтиярга кияүгә чыккач, ул миңа бер генә шарт куйды: «өйгә әйбер җыймаска». Шуңа күрә артык мебель, савыт-саба, чүпрәк-чапрак җыймадым. Акчаны һәрчак күңел өчен тоттык – сәяхәтләрдән кайтып кермәдек... Татарстаннан берәрсе килгәнне ишетсә, бөтен эшен ташлап Алматы буенча экскурсия оештыра, аннары өйгә кунакка чакыра иде. Болын кадәр иркен фатирыбызда татар зыялыларыннан кем генә булмады: Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Хәмдүнә Тимергалиева, Фердинанд Сәлахов, Рабит Батулла, Разил Вәлиев һәм башкалар. Бәхтияр Камал театры артистларының Алматыга килүләрен зарыгып көтеп ала иде, бер спектакльне дә калдырмады! Татарстан театр сәнгатенең күренекле эшлеклеләре белән танышу, аларны өебездә кунак итү – безнең өчен истәлекле, күңелле хатирә.

Бездә 1997 нче елның август аенда Татарстан президенты Минтимер Шәймиев тә кунак булды. Аның килүе исә Алматы татарлары өчен зур һәм сөенечле вакыйга иде», – дип, искә алды Виктория ханым.

Виктория Шәрипова-Табиева тумышы белән Талдыкорган өлкәсенең Сарканд шәһәреннән. Паспорттагы чын исеме – Победа Фазыйл кызы Шәрипова. «Җиңү көнендә – 1945 нче елның 9 нчы маенда туганга, әти-әнием шундый исем кушкан. Миңа барысы да

Виктория, дип дәшә. Бәлки Җиңү көнендә тугангадыр, гомерем буена беренчелеккә, җиңүгә омтылдым. Кирәкме-кирәкмиме барысына да өйрәнергә тырыштым: тегү, чигү, машина йөртү…» – ди ул. Виктория ханым мәктәп елларыннан ук балалар өчен күргәзмәләр, концертлар оештырып йөргән. Оештыру эшен әле дә яратып башкара. Ул татар милли хәрәкәтенең әйдәп баручыларыннан. «Татар үзәгенә бөтен күңелемне бирәм. Монда мин кабат яшьлегемә кайтам. Бәхтиярем белән бергә бәйрәмнәр оештырып йөргән чаклар искә төшә. Беләсезме, без ирем белән шундый матур кичәләрнең берсендә таныштык. Ул вакытта икебез дә студентлар: ул – Мәскәүдә, мин Казакъстанда педагогика институтында укый идем. Озын буйлы, чибәр, тәртипле егеткә бер күрүдә гашыйк булдым. Өстәвенә, ул бик моңлы итеп җырлый иде! «Тормышыңдагы иң бәхетле чагың кайчан булды?», – дип сорасалар: «Иң бәхетле тормышым Бәхтиярга кияүгә чыккач башланды», – дияр идем. Гомеремнең 30 елы аның ышыгында тоташ бәхеттә һәм мәхәббәттә үтте!»

Виктория белән Бәхтияр Табиевларның балалары – дипломлы рәссамнар. Сәйдә һәм Азат Алматыда Тансыкбаев исемендәге сәнгать училищесын, аннары шул юнәлеш буенча югары уку йорты тәмамлыйлар. Хәзер Сәйдәнең үз укучылары бар, ул сәнгать училищесында рәсем сәнгате укыта. Азат исә Дәүләт Сәнгать Академиясендә магистратураны бетерә. 2009 нчы елның җәендә Австриядә белем эстәп кайта. Икесе дә Казакъстанның Рәссамнар Берлеге әгъзалары.

Азат белән Сәйдә Югары Сәнгать дөньясындагы уңышлары өчен әтиләренә чиксез рәхмәтле: «Безнең өчен әти – укытучы да, дус та булды. Үсмер чагыбыз гаилә белән Болгария, Кавказ, Кыргызстан, Үзбәкстан, Кырымга иҗади сәфәрләргә йөреп үтте. Сәяхәттән кайтып керми идек. Кечкенә чакта әти безгә Гарсия Лорка шигырьләрен укый иде. Аны тыңлагач, әтинең картиналары күз алдына килеп баса. Безнең бер генә теләк: әтинең өметләрен акласак иде…»

Сәләт ике буынга күчми, диләр. Әмма, бу Сәйдә һәм Азат Табиевларга кагылмый. Алар – бөтен дөньяга мәгълүм татар рәссамы Бәхтияр Табиев иҗатының дәвамчылары, «Чиксез дала»ның ике газиз баласы…

**P.S.** Бәхтияр Табиев Габдулла Тукай иҗатына да битараф булмаган. Аның күренекле хезмәтләре арасында Г. Тукай, Шүрәле, Су анасы рәсемнәре дә бар.

**Рәмилә Газизуллина,**
**Гөлназ Галимҗанова**

# Ак күпер серләре

Гөлбану һәм Мөнир Ерзиннар... Казакъстанның Алматы шәһәрендә гомер итүче гаҗәеп гаиләне Япония, Кытай университеты галимнәре эзләп килә. Мөнир Ерзин атаклы тарихчы, Урта Азиядәге бердәнбер уйгырчы, тәҗрибәле журналист, синолог. Гөлбану ханым – белгечлеге буенча шәфкать туташы, сөекле иренең терәге, оста пешекче һәм уңган хуҗабикә.

Мөнир аганың өстәлендә япон телендә язылган калын китап ята. Сораулы карашларыбызны күреп, галим безгә аңлатырга ашыкты: «Сездән алда гына Япониядән Наоко Мизутани исемле галимә килеп китте. Япон галимнәре тарафыннан татарлар турында икенче китап басылып чыккан. Үзәк Азиядә яшәгән татар кабиләләре турында... Наоко Мизутани минем белән кытай телендә аралашты. «Татарлар – бик акыллы халык. Япониядәге беренче мәчетне татарлар салган», – диде. Бер айга мине Токио университетына татар һәм уйгыр халыклары хакында лекция сөйләргә чакырып китте».

Гыйлем өлкәсендәге казанышларымда Гөлбану ханымның өлеше зур. Миңа: «Бер нәрсә өчен дә кайгырма – укы!», – дип әйтә иде. Кешелеклелеге, ак күңеллелеге аркасында бәхетле яшәдек», – ди Мөнир әфәнде.

...«Әтием Ибраһим Ерзин Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган Томбов татары. Әнием Фәрзәнә Бикчәнтәева – Казаннан. Мин Шенҗан-Уйгыр автоном районының Алтай өлкәсе Бурчум шәһәрендә 1927 нче елның 27 нче октябрендә туганмын. Казакъ арасында үстем. Башлангыч белемне казакъ мәктәбендә алсам, аннан соң казакъ-монгол мәктәп-интернатында укыдым. Без гаиләдә алты бала: өч угыл һәм өч кыз үстек. Ятимлек ачысы кагылгач, бик укымышлы, зирәк Хәлил бабам миңа: «Син моннан кит, улым. Укысаң – кеше булырсың», – диде. Шулай итеп, мин 13 яшьтә өйдән чыгып киттем», – дип, хатирәләр яңартты галим.

Казакълар арасында үскән егет 1947 нче елда Шенҗан провинциясенең башкаласы – Өремче шәһәрендә педагогика институтын кытай телендә тәмамлый. Ике айда уйгыр телен өйрәнеп, уйгыр газеталарында тәрҗемәче булып эшли. «Шенҗан гәзите», «Инкыйлабый Шәркый Төркестан», газеталарында каләм чарлый, тәрҗемәчедән баш мөхәрриргә кадәр үсеп җитә. Шенҗанда чуалышлар башлангач, сөйгәне Гөлбану белән Советлар Союзына – «чирәм җирләргә» чыгып китәләр. «Казакъстанның Җамбул өлкәсендәге ат заводына эшкә алып килделәр. Паспортларыбызны алып калып, беренче көннән печән чабарга

җибәрделәр. Монда да тел белүем коткарды. Консуллыкта Уйгыр Сайрани дигән кеше эшли иде. Ул мине Язучылар берлегенә алып барды, ярдәм итәрбез, диделәр. Документларны алып, Алматыга күчендек. Мин анда уйгыр телендә чыга торган «Казакъ иле», аннары «Коммунизм байрагы» газеталарында эшләдем», – ди ул.

Мөнир Ерзин Казакъ дәүләт университетының тарих факультетын тәмамлый, уйгыр матбугатын өйрәнеп, диссертация яклый. 1967 нче елга кадәр Казакъстан Фәннәр академиясенең Уйгыр тану бүлегенең тарихчылар төркемендә эшли, әлеге милләтнең мәдәнияте һәм матбугаты тарихына багышланган күләмле хезмәтләр бастыра. «Уйгырлар – бик гыйлемле халык. Матбугат тарихлары 1910 нчы елдан башлана. Уйгырларның «Шура» журналына да мәкаләләр язуы мәгълүм. Шенҗанда алар 8 миллион. Әле дә йөзләгән газета-журнал чыгаралар, телевидениедә берничә уйгыр каналы бар. Казакъстанның Алматы өлкәсендә алтмыш, Алматыда – өч мәктәп, уйгыр театры, радиосы, «Уйгыр авазы» газетасы редакциясе, дәреслекләр чыгара торган уйгыр «Мәктәп» нәшрияте, үз мәчетләре бар. Кызганыч, без алардан бик күпкә калышабыз. Мин һәрчак уйгырларның түрендә булдым. Миңа әле дә хөрмәтләп, Мөнир ака дип эндәшәләр», – диде галим.

Мөнир әфәнде – Алматы шәһәрендә татар телендә нәшер ителүче «Фикер-Өмет» газетасын нигезләүчеләрнең берсе. Ул ТР Журналистлар берлеге әгъзасы, «Бәллүр каләм» бүләге лауреаты.

Мөнир Ерзин Татарстан белән тыгыз элемтәдә тора. 2007 нче елда татар галимнәренең Казанда уздырылган I Бөтендөнья форумында катнашуы хакында аеруча горурланып сөйләде. Аның өчен Казанның меңьеллыгында катнашу көтелмәгән зур шатлык булган. Галим күңелендә саклап йөргән эчкерсез тәэсирләре белән дә уртаклашты: «Казандагы гыйлем учаклары, җәмәгатьчелек фикерен таратучы урыннарда булу күптәнге хыялым иде, бу теләкләремә дә ирештем. Мине Токио, Пекин университетларына студентларга, укытучыларга лекция укырга гел чакырып торалар. Минем, Казан университетына барып, татар балаларына сабак бирәсем килә!», – диде.

Гөлбану һәм Мөнир Ерзиннар – ярты гасырдан артык бергә! Ике кызлары үз гаиләләре белән Алматыда яши. Икесе дә медицина юлын сайлаган – невропатологлар. Безгә мул табын әзерләп йөргән Гөлбану ханым да әңгәмәгә кушылды: «Мин тумышым белән Кыргызстаннан. Табиб буласы кеше идем. Университет тәмамларга саулыгым җитмәде. Мөниргә: «Мин табиб булалмадым, син укы!» – дидем. Күптән түгел Җиңел сәнәгать министрлыгы заказы буенча Җамал Әблә тнең «Кытай медицинасының сайланма рецептлары»



**Гөлбану һәм Мөнир Ерзиннар**

китабын кытай һәм уйгыр телләреннән русчага тәрҗемә иттек. Мөнир – кытай һәм уйгыр телләрен камил белә, мин – русчаны. Үзара килешеп эшләдек. Арадашчыбыз – татар теле булды».

Бу кунакчыл йортта без беренче мәртәбә түгел. Һәр килүебездә безне Ерзиннар кытай, уйгыр, татар ашлары белән сыйлый. Бу юлы Гөлбану ханым әзерләгән кытай сәеннән авыз иттек. Сәй – ит белән яшелчәләрне кыздырып ясалган сый була. Рецепты да бик гади: вак итеп туралган итне кыздыргач, бер-ике кашык кытай соусы (соя мае) салып, баклажан һәм борычны бергә кыздырасың. «Мин кечкенәдән ашарга пешерергә яраттым. Ят ризыкларны күрсәм, өйрәнергә тырышам. Мөнир белән икебез арасында бер уртаклык бар: кешедән күбрәк өйрәнергә тырышабыз. «Яңа гасыр» каналында берәр ризык пешерергә өйрәтсәләр, йөгереп барып, шуны карыйм», – ди хуҗабикә.

Ерзиннар гаиләсе – татар һәм уйгыр халыкларын берләштерүче Ак күпер. Аларның күңеле дә бары аклыктан гына тора… «80 яшьтә дә шундый шат күңелле булып калуыгызның сере нидә?», – дим Ерзиннарга. «Бертуктаусыз гыйлем алу, сәламәт яшәү рәвеше һәм Гөлбану ханым…» – диде Мөнир ага. Гөлбану ханым исә эчкерсез елмайды.

**Рәмилә Газизуллина**

# Тукай идеясе яшәгән илләрдә

## (Журналист истәлекләре)

Тукай дөньясы – иге-чиге юк киң дөнья, олы дәрья. Аның иҗадияте җимешләре күз ачып йомган арада бөтен Идел-Урал буйларына тарала. Әсәрләре кулдан-кулга йөреп укыла, шигырь-поэмалары халыкның моңлы җырларына әверелә. Бу татар илендә генә түгел, бәлки барча тугандаш халыклар арасында да шулай. Казакъ халкының атаклы язучысы, академик Сәбит Муканов «Көнчыгыш шигъриятенең Алыбы» дип атаган Габдулла Тукайның шигырьләре Тәңре Тау, Элә дәрьясының көньягындагы Алатау, Алтай, Тарбагатай калкулыгы итәкләрендә, Ферганә тигезлегендә, Элә, Иртеш, Чу, Тарым елгалары буенда, Каспий, Эссе күл ярларында киң сулыш алып яңгырый.

XX гасырның башларында тугандаш төрки халыклар арасында да атаклы шагыйрьләр дөньяга килә. Ләкин, Сәбит Муканов әйткәндәй, алар арасыннан беркем дә Тукай кебек дан казана алмады.

Габдулла Тукай иҗаты, уйгыр мәдәнияте һәм әдәбияты үсешендә аерым урын алып тора.

Бу очраклы хәл түгел, ә табигый күренеш иде. Аның тарихи тамырлары тирәндә ята. Беренчедән, телебез охшаш, динебез бер, икенчедән, тарихи язмышыбыз да күп яктан бер-берсенә охшаган. XIX-XX гасырларда уйгырлар да яңаруга, уянуга мохтаҗ иде һәм Тукай әсәрләренең теле уйгырларга бигрәк тә аңлаешлы иде. Татар әдәби теленә кергән кайбер гарәп, фарсы элементлары уйгырларның гадәти көнкүреш телендә дә кулланыла. Өченчедән, хосусан XIX-XX гасырларда уйгырлар иленә, шул җөмләдән, алар яшәгән Урта Азия һәм Җидесу тирәсенә татар халкының Габдулла Буби, Хәйдәр Сайрани, Хисам Бавин, Гөләндәм Хәбибуллина, Зариф Бәшири, Гали Ибраһимов кебек мәгърифәтчеләре, алдынгы катарлы (карашлы) укымышлы зыялылары килеп мәктәпләр төзи, уку-агарту эшләрен юлга сала. Алар шулай ук үзләре белән шактый күп татарча китап, газета, журналлар алып килә һәм китапханәләр булдыра. Голҗа, Чүгүчәк, Өремче, Торфан, Алматы, Ташкент шәһәрләрендә төзелгән һәм татар телендә дәресләр укылган мәктәпләр, шул шәһәрләрдә барлыкка килгән китапханәләр татар әдәбиятының үрнәкләрен киң җәелдергән мәдәни учакларга

әверелә. Уйгыр балалары да шул мәктәпләрдә укып белем алалар һәм Габдулла Тукай әсәрләре, татар әдәбияты үрнәкләре белән танышу мөмкинлегенә ирешәләр.

Уйгыр халкы арасыннан чыккан Нәзәргуҗа Абдусемәтов, Зонун Кадири, Лотфулла Моталлиб, Абдухалык Уйгыр, Үмәр Мөхәммәди, Һезим Искәндәров, Теипҗан Әлиев кебек шагыйрьләргә, язучыларга Габдулла Тукайның йогынтысы бигрәк тә зур була. Алар Тукайның иҗадият юнәлешеннән, идеяләреннән һәм художестволык осталыгыннан илһамланалар, үрнәк алалар, аны остаз итеп «Ул безнең дә Тукаебыз», – дип үз итеп горурланалар.

Уйгыр халкының ватанпәрвәр шагыйре Лотфулла Моталлиб бала чагыннан башлап Голҗа шәһәрендәге татар мәктәбендә укый. Ул татар телен үзенең ана теле – уйгыр теле кебек яхшы белә һәм бик җиңел, матур итеп сөйли. Татар әдәбиятын, хосусан, Тукай шигырьләрен яратып, яттан укый. Ул тиз фикерләү, тиз иҗат итү сәләтенә ирешә. 1944 нче елның август башларында Габдулла Тукайга һәвәсләнгән Абдулһәй Рози, Кевир Нияз, Давут Төрәхмәт, Хәлил Һәмраев кебек уйгыр шагыйрьләренең бер утырышында Лотфулла Моталлиб Тукайның «Мәхәббәт» исемле шигырен тирән хисләр белән дәртләнгән хәлдә яттан укый һәм шуның артыннан ук:

*Һай, сөемлек Тукай,*
*Әшгареңне укай.*
*Илһам алдым сәндин.*
*Мән немидин куркай.*
*Кувәт бәрдиң маңа,*
*Дошман күзини чокай, –*

дип тезеп сала. Бу тезмәләрне ишеткән шагыйрьләр аның гаҗәеп талантына афәрин укый.

Габдулла Тукай белән Лотфулла Моталлибнең язмышларында да охшашлыклар бар. Җир йөзендә 27 елдан азрак яшәгән Тукай үз хәятендәге җиде еллык иҗади фәгалиәтендә искиткеч бай мирас калдырган булса, дөньяда бары тик 23 ел гына яшәгән Лотфулла Моталлиб (1922-1945) үзенең кыска гына иҗади фәгалиәтендә күп әсәрләрне, шул исәптән «Елларга җавап», «Деханга» («Игенчегә»), «Һурун дехан» («Ялкау игенче») кебек гаять сокландыргыч шигырьләрне дөньяга китерде (Лотфулла Моталлиб 1945 нче елның 7 нче сентябрьдә Көньяк Шенҗанның Аксу шәһәрендә Гоминьдан партиясе чорындагы Кытай хакимияте тарафыннан төрмәгә ябыла һәм һәлак ителә). Шагыйрьнең иҗатында Тукай рухы, идеясе аңкып тора. Тукай чорының тәэсире белән уйгыр әдәбияты өлкәсендә урын алган

Дәрдмәнднең (Закир Рәмиев) «Кораб» шигырендәге кораб, дулкын, упкын атаулары да аның «Елларга җавап» шигырендә чагылыш таба.

Уйгыр халкының данлы һәм сөекле шагыйре, җәбер-золым елларында дөреслек, гаделлек юлында көрәшүче, берара Казан, Уфа шәһәрләрендә булган Абдухалык Уйгыр да (1901-1933) Тукай мәктәбен үткән шәхес. Ул татарлар тормышы белән якыннан таныша һәм татар телен бик яхшы үзләштерә, татар телендә дә күп кенә шигырьләр яза. Аянычка каршы, аның бу шигырьләре башка әсәрләре белән бергә юк ителә, бары тик бүтән кешеләр кулында сакланып калган «Әлләкем китә» исемле алты куплетлы шигыре генә билгеле.

Габдулла Тукай иҗатының йогынтысы хәзерге заман уйгыр шигъриятен нигезләүчеләрнең берсе булган Абдухалык Уйгыр иҗатында бик ачык күренә. Тема һәм эчтәлек ягыннан да, тел һәм стиль ягыннан да аның шигырьләрендә Тукай йогынтысы турыдан-туры күзгә бәрелеп тора. Аның Тукайдан тәэсирләнгәнлеген, кайбер яктан Тукайга охшап китүен аңлау кыен түгел. Моның өчен Тукайның «Безне урынсыз яманлыйлар» дигән шигыре белән Абдухалык Уйгырның «Бардур» («Бардыр») исемле шигырен карап чыгу кифая.

**Безне урынсыз яманлыйлар**

*Сәдакать бездә юкмыш; булмаса, ялганымыз бардыр;*
*Нифак вставкасында күп медаль алганымыз бардыр.*

*Нәзафәткә ригаять юк имеш бездә, – нә бөһтандыр!*
*Аның чын йорт саен безнең берәр комганымыз бардыр.*

*Тагын бездә гыйлем әһле – зыялылар да юк диләр;*
*Утыз еллап Бохар, Каргалыда торганымыз бардыр.*

*Татарда акча юк, байлык та юк дип, юкны сөйлиләр;*
*Урам тулы, кулын җәеп, бурыч сораганымыз бардыр.*

*Санагать юк, һөнәр юк дип, яманлыйлар урынсызга;*
*Яһүдидән җиңел мал тапкучы ишанымыз бардыр.*

*Закон белән юрист юк бездә дип уйлау хата хәтта,*
*Печән, шалкан базарында закон сатканымыз бардыр.*

*Табиблек фәне юк дип тә яманлыйлар, ди, дошманнар;*
*Мәрыйзларны ясин берлән сугып екканымыз бардыр…*

**Габдулла Тукай**

**Бардур**
*Йәнә йорт пайдисига җәмгый булмаклык бәси мөшкөл,*
*Әгәр бер йәрдә туй булса, берип ятканымыз бардур.*

*Омумның пайдисини йөз елда әсла чүшәнмәймиз,*
*Зыян кылмак өчен булса, әҗәп чакканымыз бардур.*

*Бер бер яхшылык кылса, уның ядын кылмак юк,*
*Ибе килсә, барып әврәтләрен ачканымыз бардур.*

*Хатаән дустыбызда бер гаеп заһир булып калса,*
*Юшурмай, бергә унны тауып катканымыз бардур.*

*Бабалар шөһрәтен, гайрәтен һич сагынмасмыз,*
*Калып гәпләт, җаһаләттә йомып күз, по атканымыз бардур.*

*Хошарт бабида бездән бүләк остасы һәм юктур,*
*Кулугу шомлык белән рәңму-рәң ялганымыз бардур.*

*Кызыл күзлек, күрәлмәслек вә я үзе кылалмаслык,*
*Кылай дип бәл баглаганларга төрле-төмән бөһтанымыз бардур.*

**Абдухалык Уйгыр**

Абдухалык Уйгыр Габдулла Тукай шикелле кыска гына иҗади хәятендә эчтәлек, форма, тел, стиль һәм башка якларыннан уйгыр шигъриятендә яңа бер чор ратты.

Габдулла Тукай:
Кичке азан,
Кичке азан,
Моңнар, уйлар
Килә аннан;
Төшә исәк
Иске заман… –

дип әйткәнендәй, вакыт канча күп үтсә дә узган замандагы искә төшерерлек вакыйгалар бер дә онытылмый.

1947 нче елның сентябрендә мин Элә вилаятенең Голҗа шәһәрендә нәшер ителгән «Инкыйлаби Шәркый Төркестан» газетасының редакциясенә эшкә кабул ителдем. Берәр атна үтәр-үтмәс, бер көнне өйләдән соң редакция бүлмәсенә кешеләр җыйнала башлады. Соңгарак танышып белгәнемчә, алар уйгырларның танылган язучы-драматургы Зонун Кадири, шагыйрьләр Әлкәм Әхтәм, Нурмөхәммәд Бусаков (алар редакциянең әдәби хезмәткәрләре),

Абдулһәй Рузи, Давут Төрәхмәт, Кевир Нияз һәм татар шагыйре, журналист Хәмит Төхфи (ул да редакциянең әдәби хезмәткәре) икән. Аларның күңелләре аеруча күтәренке иде. Сүз 1947 нче ел «Инкыйлаби Шәркый Төркестан» газетасы идарәсенең матбагасында 700 нөсхәдә басылып чыккан. «Г. Тукай сайланма шигырьләре» исемле мәҗмүга хакында барды. Бу басма Г. Тукайның тууына 60 ел тулу уңае белән әзерләнгән булса да, мөмкинлекләр чикле булуы сәбәпле, шагыйрьнең дөньяга килүенә 61 ел тулган бер чакта бастырылды. Үз вакытында Татарстаннан килгән һәм 20-30 нчы елларда Кытайның Харбин, Тәянҗин, Шанхай шәһәрләрендә яшәгән татарлар тарафыннан нәшер ителгән Тукай әсәрләре югалып бетә башлаган бер мизгелдә «Г. Тукай сайланма шигырьләре»нең дөнья күрүе бик әһәмиятле вакыйга иде. Бу мәҗмүганы басмага татар әдәбияты белгече, журналист, шагыйрь Хәмит Төхфи (Төхфәтуллин) әзерли һәм аның кереш сүзен үзе яза. Ул Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйт Рәмиев, Шәехзадә Бабич, Гаяз Исхакый, Максут Садрый, Галимҗан Ибраһимов кебек татар язучы-шагыйрьләренең идеяләрен таратучы буларак уйгыр, казакъ кардәшләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә алган. Шуңа күрә бу утырышта да язучы-шагыйрьләрнең дикъкате аңар юнәлтелгәнлеге шунда ук сизелде.

Сүзне иң элек Зонун Кадири башлады. «Безнең илебездә Габдулла Тукай шигырьләренең дөнья күрүе бик сөенерлек һәм куанычлы эш, күреп, укып шатланып утырабыз. Мөмкинлекләр чикле булган әхвәлдә аны бастырып чыгарганың өчен, Хәмит Төхфи, сиңа һәм Голҗа татарларына мең дә бер рәхмәт. Бу Габдулла Тукайның 60 еллыгына багышланган зур бүләк. Мәзкүр җыентыкта аның «Шагыйрь», «Әхлаксызлык», «Нәсыйхәт», «Алтынга каршы», «Сәрләүхәсез», «Милли моңнар», «Чын вә ялган», «Кыйтга», «Шекспирдан», «Толстой сүзләре», «Өзелгән өмид», «Сагыныр вакытлар», «Ваксынмыйм», «Тәләһһеф», «Теләнче», «Буран», «Туган җиремә», «Төлке һәм йөзем җимеше», «Васыятем», «Тәэсир», «Туган тел», «Пар ат»тан гыйбарәт 22 шигыре урын алган. Алар Тукайның мәңге үлмәс шигырьләре. Аларны татарлар кебек уйгырлар да бик яратып укыйлар. Әгәр матбага яктан уңай шартлар булганда, мәҗмугага шагыйрьнең «Шүрәле» поэмасын да кертеп куйганда, тагын да яхшырак булган булыр иде», – дип үзенең уен йомгаклады. Башка шагыйрьләр белән язучылар да мәҗмугага кагылышлы самими хисләрен белдерделәр.

– Зонун ака! Сез (Зонун Кадири Хәмит Төхфидән 11 яшькә олырак иде, шуңа ул аны ака – ага дип атый) Тукайның «Шүрәле»се хакында әйтеп утырасыз, бу поэма аның иҗатында күренекле урын тота, Хода боерса, алдагы бер нәшерләребездә укучыларга тәкъдим ителер.

1945 нче елда Сезнең «Рудупай» исемле әсәрегез дөнья күрде. Аның «Шүрәле»гә охшаш җирләре бармы? – диде Хәмит абзый.

– Рудупай турындагы риваять уйгырлар арасында күптән таралган. Әкиятләрдә сурәтләнүенчә, ул аяклары чалыш килеш сөйрәлеп йөри торган, күзе мәче башлы ябалакныкы төсле, кеше кыяфәтендәге сарышкак мәхлук. Ул юлларда, агач төбендә очрый, ачкүз, комсыз булса да, мөлаем сыман карашлары белән мескенләнеп күренә. Менә шундый хәйләләр белән кешеләрнең җилкәсенә атланып ала да, теле белән ялап канын эчә башлый һәм хәлсезләндереп үтерә. Мин язган «Рудупай» әсәренең герое Санубәр үзе гашыйк булган Гөляр дигән кызын эзләп юлга чыкканда, Рудупайга дучар була, аның мескенләнүенә ышанып, үзенең җилкәсенә атландырып йөртә. Бара торгач ул интегеп талчыга башлый, ләкин аның канын эчеп туймаган теге әшәке мәлгуньнән бер дә котыла алмый. Ахыр чиктә алма агачының өстенә чыга да Рудупайның башын чатлы ботакка эләктереп үзен җиргә ташлый һәм аны таяк белән сугып, яньчеп үтерә. Уйгырларда «Рудупай тукмактан курка» дигән мәкаль бар бит! Шүрәлеләр дә, мөгаен, агачтан, бүрәнә ярыгыннан шүрлиләрдер.

«Шүрәле» белән «Рудупай»ның арасында охшашлыклар бар. Риваятьләрдә Шүрәле дә, Рудупай да халыкларны җәберләүчеләр, аларга һәлакәт, бәхетсезлек китерүчеләр итеп тасвирлана, берсе кешеләрне «кети-кети уйнарга» дип алдап кытыклап үтерсә, икенчесе кешеләр алдында мескенләнеп, ялагайланып җилкәсенә атланып канын эчеп үтерә. Әбылтыр белән Санубәр исә шул җәберләүче көчләргә каршы көрәштә җиңеп чыгучылар.

Мин Габдулла Тукайга мәфтун булган кеше. Аны яратып, сокланып укыдым, хәзер дә дәртләнеп укыймын, андан өйрәнәмен, аның алдында баш иям. Син Хәмит Түһфә (уйгырларда Төхфә сүзе Түһфә дип языла һәм шулай укыла), элекке бер сөхбәтемездә «Тукай – ул бөек һәм даһи шагыйрь» дигән идең. Бу чын хакыйкать, «Шүрәле» поэмасы шуңа бер дәлил. Тукай мәзһүр әсәрендә татар дөньясын, татарларның элекке даншәүкәтле, саулатле дәверләрен, дәүләтчелегеннән мәхрүм булганнан соңгы хәлләрен, эшлекле, эчкерсез, тынычлык сөюче, кыю кешеләрен, матур да гүзәл табигатен, уңдырышлы бай җирләрен күз алдына китереп бастыра. Тукайдан үрнәк алмаган, илһамланмаган хәзерге заман уйгыр язучылары, шагыйрьләре юк. Мин үз халкымның әдәбияты хәзинәсендә сакланган «Рудупай»ны аның «Шүрәле»сеннән илһамланып кәгазь битенә төшерергә ирештем. Ләкин, ул шигъри әсәр түгел, чәчмә әсәр. «Рудупай» кайчан да булса бер вакытта Тукай поэмасы дәрәҗәсендә дөньяга чыга алса, уйгыр поэзиясе өчен тагын да бер зур уңышлы адымнардан булган булыр иде», – дип үз фикерен йомгаклады Зонун Кадири.

Үз чорымның танылган зыялылары арасында утырып, аларның дәртләндергеч, кыйммәтле фикерләрен ишетү минем өчен көтелмәгән шатлык иде. Без сабый чакта әнкәмез Бикчәнтаева-Ерзина Фәрзанә кулына гармун алып Тукайның «Сак-Сок» бәетен җырлаганда, аны якяктан кочаклап: «Әнкәй, син безне каргама, сине һаман да тыңлыйбыз, рәнҗетмибез!», – дип үкси-үкси сулкылдап елый идек. Әллә шул сабый чаклар искә төшкәнгәме, әллә әңгәмәләрдән яңа хисләр уянгангамы, ике күземнең яшькә тулганын үзем дә сизми калдым. Хәмит абзый нигәдер миңа кат-кат карап алды.

Менә 1950 нче ел да җитте. Баштарак – 1944-1945 нче еллар Шәркый Төркестан җөмһүриятенең вакытлы хөкүмәте дип, ә 1946 нчы елның июленнән соң аерым өч вилаять вакытлы хөкүмәте дип йөртелгән чаклар да үтеп китте. 1950 нче елдан башлап Кытай Коммунистлар партиясенең җитәкчелегендә яңа хакимият барлыкка килде. Без эшләгән «Инкыйлаб Шәркый Төркестан» газетасы урынына «Элә газеты» чыга башлады. Элеккеге журналистларның, редакторларның барысы да диярлек провинциянең үзәге – Өремче шәһәренә чакыртылып, шунда эшкә урнаштырылды. Мин Голҗа шәһәрендә «Элә газетасы» редакциясендә калдым һәм 1955 нче елның май аенда Советлар Союзына – Казакъстанга күченеп чыктым.

1956 нчы елны, сентябрьнең урталарында Алматы шәһәренә язучылар Зия Сәмәди, Бокара Тышканбаев, Зонун Кадириләр җитәкчелегендәге Шенҗан-Уйгыр автоном районы әдәбият-сәнгатьчеләр Берлегенең делегациясе килде. Алар Шенҗан уйгырлары һәм казакълары өчен махсус нәшер ителеп торган «Казакъ иле» (казакъ телендә) һәм «Йеңи хәят» (уйгыр телендә) журналларының редакциясендә кунакта булдылар. Кунакларны «Казакъ иле» журналының редакторы Кодышев Омаргали, «Йеңи хәят» журналының редакторы Мәшүр Рузиев һәм язучы-шагыйрьләр каршы алды. Минем редакцияләрнең эшләренә катнашып йөргән чакларым иде, шуңар күрә аларның арасында булырга туры килде. Дусларча әңгәмәләшүләр, фикер, тәҗрибә алмашулар кыза барды. Кунаклар бүләкләрдән коры калмадылар. «Йеңи хәят» редакциясе аларга Габдулла Тукайның дөньяга килүенең 70 еллыгына әзерләнеп 1955 нче елда уйгыр телендә нәшер ителгән «Габдулла Тукай шигырьләре вә дастанлары» исемле 208 биттән торган китапны бүләк итте. Бу җыентыкны уйгыр шагыйре Һезим ака Искиндәров тәрҗемә итеп, нәшергә үзе әзерләгән. Зур бүләккә ирешкән Зонун ака Кадири үзенең куанычын яшереп кала алмады: «Бездә Тукай шигырьләрен аның үзе язганынча укып аңлаучылар аз түгел, шулай да Тукай әсәрләренең уйгыр телендә барлыкка килүе бик зур әһәмиятле вакыйга. Сезләр мөһим эшне башкарып чыккансыз, меңнәрчә рәхмәт», – диде һәм

Тукайның «Туган тел»ен аһәңле тавышы белән күңелдән укып чыкты. Мәҗлес Тукай иҗаты кичәсенә әверелеп бара иде. Аның шигырьләрен уку дәвам итә. Җидесуда, Алматы шәһәрләрендә укып үскән шагыйрь Һезим Искәндәров, язучы Һезмәт Абдуллиннар «Зиләйлүк», «Әллүки», «Тәфтиләү» көйләренә китереп җырлаган Тукай шигырьләре барчаның дикъкатен җәлеп итте. Хосусан Һезим Искәндәров Тукайның «Милли моңнар», «Өзелгән өмид»ләрен бик осталык белән башкарды, дәртләнеп, рухланып җырлады. Бу юлларны язып утырган чагымда Һезим Искәндәров күз алдыма килде. Ул безнеңчә саф, матур итеп сөйләүче, татар дусларына бик игътибарлы озын буйлы, килешкән инсан иде.

Габдулла Тукай иҗатыннан тик уйгыр язучы-шагыйрьләре генә илһамланмады, аның иҗаты уйгыр әдәбиятчы галимнәрен дә үзенә җәлеп итте һәм җәлеп итеп килә. Алар Тукай әсәрләренең бәдигый – художестволык осталыгын, тирән маһиятен, тәрбияви әһәмиятен, туган җиренә, халкына, милләтенә мәхәббәтеннән килеп чыккан ватанпәрвәрлек идеяләрен төптән тикшеренеп өйрәнәләр. Менә шуның нәтиҗәсендә уйгырлар, арасында Тукайшонаслар – Тукай иҗатын белгеч галимнәр җитешеп чыга. Шул галимнәрнең берсе – танылган әдип һәм синолог Үткер Абдуреһим. Ул яшь чагыннан башлап Тукай әсәрләрен ашкынулы омтылыш белән укып, җиренә җиткереп өйрәнә бара. Шулай итеп, Тукайның бай иҗади мирасын, уйгыр әдәбиятына йогынтысын җитди тикшереп ачыклап чыга. Әдәбиятка кагылышлы гыйльми конференцияләрдә аның иҗаты турында чыгыш ясап, үзенең нигезле фикерләрен, күз карашларын бәян итә.

Аның Габдулла Тукай иҗатына биргән бәясе 1987 нче елның декабрендә Өремче шәһәрендә уздырылган «Татар теле – әдәбияты гыйльми конференциясе»ндә укылган һәм Шенҗан университеты гыйльми журналының 1988 нче елның 2 нче санында игълан ителгән «Уйгыр әдәбияты белән татар әдәбиятының үзара тәэсире» дигән мәкаләсендә тәфсилле язылган. «Габдулла Тукайның татар милли шигъриятен булдыру һәм аны камилләштерүдә уйнаган ролен берәр мәүҗүд (бар) үлчәм белән үлчәү мөмкин түгел, ул язда яшенләгән яшен кебек кыска гына гомерендә татар әдәбиятында бөтен бер дәверне яктырткан гениаль шагыйрь булу сыйфаты белән татар поэзиясе күгенең мәңге үлмәс якты йолдызы… Татарның милли телендә иң гүзәл шигырьләрне тудыру мөмкинлеген беренче булып дәлилләп, татар әдәби телен югары баскычка күтәрде… Тукай шул вакыттагы бөтен татар җәмгыятен кечкенә генә бер күзгечеккә сыйдырып, аны җанлы рәвештә чагылдырып бирә алды», – дип яза Үткер Абдуреһим.

«Мәшһүр татар шагыйре Габдулла Тукай шигырьләренең бәгъзе үзенчәлекләре хакында» исемле хезмәтнең авторы, Тукайшонас

Рәхмитулла Җари (1926-1999) Тукай иҗаты буенча төпле тикшеренүләр йөртә. Ул Тукайны татар матур әдәбиятын нигезләүче, татар әдәбиятында сәяси лириканы башлап җибәрүче, татар балалар әдәбиятының нигезен салучы, татар әдәбиятында сатира һәм юморны камилләштереп киңәйтүдә иң элек көч салган сатирик шагыйрь, татар шагыйрьләре арасында беренче булып фольклорга әһәмият бирүдә инициатива күрсәткән һәм үзе дә халык авыз әдәбиятыннан файдалануның иң яхшы үрнәкләрен белүче, татар әдәби теленең нәфислегенә, аның камилләшүенә, гүзәл, матур тел сыйфатында нурланып торуына, лөгать фондының баюына аеруча көчен сарыф итеп, бу өлкәдә мисле күрелмәгән төхфә кушучы, рус һәм Европа классик әдәбияты вәкилләре әсәрләренә беренче булып татар әдәбиятына урын алдыручы затлы бөек шәхес сыйфатында күрсәтә.

Рәхмәтулла Җариның фикеренчә, Тукай шигырьләре күбесенчә Гаруз вәзенендә язылган, ул Гаруз вәзененнән осталык белән файдаланган. Дәрвакый, Тукай бармак вәзенен күп кулланмаган.

Тикшеренүче Рәхмитулла Җари Тукай шигырьләренең татар әдәбияты дәреслекләрендә генә түгел, бәлки төрки телдә сөйләшүче барча халыкларның әдәбият хрестоматияләрендә дә түр башыннан урын алып килгәнлеген ассызыклап үтә.

Уйгыр кардәшләр арасында Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү эшләре XX гасырның 80 нче елларыннан соңгы вакытларда тагын да киң рәвештә дәвам итә. Бу чорда танылган әдәбиятчылар, тел белгечләре һәм галимнәрдән Ибраһим Мотыйгыйның «Габдулла Тукай һәм яңа уйгыр әдәбияты», Рәхмитулла Җариның «Татар күгендә мәңге үлмәс якты йолдыз», «Шенҗан-Уйгыр автоном районы (түбәндә ШУАР) педагогика университеты филология факультетының доценты Адил Алмасның «Хәзерге заман татар әдәбиятының вәкилләре хакында», «Габдулла Тукай шигырьләренең бәдигыйлеге (художестволыгы) турында», «Габдулла Тукай шигырьләрендәге ватанпәрвәрлек рух», ШУАР әдәбият-сәнгатьчеләр берлегенең җитәкчесе, фәнни тикшеренүчесе Мөхәммәт Полатның «Габдулла Тукай иҗадиятенең уйгыр әдәбиятына булган йогынтысы хакында кыскача бәян», ШУАР Сәнгать институтының элекке ректоры Имин Әхмәтнең «Сөйләп бетергесез Габдулла Тукай», ШУАР Педагогика университеты филология факультетының доценты Абдубәсир Шөкеринең «Урал садасы», Шинҗаң университеты филология факультетының доценты Хөрмәтҗан Фикрәтнең «Габдулла Тукай әсәрләренең эчтәлек төзелеше турында уйлар», ШУАР Педагогика университеты филология факультетының доценты Ришат Асимнең «Яңа заман татар мәдәнияте кыңгыравыннан уйгыр мәгарифендәге яңгырашы», ШУАР Мәгариф нәшриятенең җитәкчесе, мөхәррире

Абдусадлам Пухтының «Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай һәм аның уйгыр әдәбиятына тәэсире», ШУАР Телевизия станциясе кино-телевизия театры Тәрҗемә үзәгенең җитәкчесе тәрҗеманы Мусаҗан Әзизнең (Газизнең) «Пушкин белән Габдулла Тукай арасындагы охшашлыклар хакындагы баштагы карашларым» кебек мәкаләләре дөнья күрә. Шенҗан университетының профессоры, үзбәк вә уйгыр әдәбияты вәкилләреннән берсе Абдушөкер Ялкынның Габдулла Тукай иҗаты буенча студентлар алдында укыган бай эчтәлекле лекцияләре дә аерым урында тора.

Тикшеренүчеләр бу хезмәтләрендә Тукай иҗаты буенча һәрьяклап гыйльми фикерләр йөртә, аның яңа уйгыр әдәбиятына тәэсир итүенең объектив, тарихи шартларын җентекләп күрсәтә. «Габдулла Тукай үз халкын, үз илен җаныннан да артык күргән ватанпәрвәр шагыйрь иде. Ул үз тәкъдирен халкына тәкъдирдәш дип исәпләгән. Халык башына төшкән золымга чиксез хәсрәтләнеп иҗадият юлына кергән көннән башлап милләттәшләренең шатлыгы белән шатланса, кайгысы белән кайгыра.

Бу хезмәтләрнең Габдулла Тукай иҗатының тугандаш халыклар әдәбиятына тәэсирен өйрәнүдә файдалы булуында шик юк, әлбәттә.

ШУАРның башкаласы Өремчедә 1996 нчы елның 16 нчы апрелендә Габдулла Тукайның дөньяга килүенең 110 еллыгын, 2006 нчы елның 13 нче октябрендә исә 120 еллыгын искә алу буенча тантаналы чаралар уздырылды. 2006 нчы елның 13 нче октябрендәге тантаналы җыелышка татар, уйгыр, казакъ, үзбәк язучылары, шагыйрьләре, галимнәреннән 200 дән артык кеше катнаша. Тантанада ШУАР Әдәбият-сәнгатьчеләр Берләшмәсенең рәисе Һейтәм Һүсәен һәм ШУАР язучылар Берлегенең рәисе Азат Солтанлар тәбрикләп чыгыш ясый. Шагыйрь Очкынҗан Умәр: «Уйгырларның чын дусы Габдулла Тукай» дигән шигырен укып бирә. Бу тантаналы чаралар ШУАРда яшәүче төрки кардәшләрнең бөек һәм даһи шагыйрь Габдулла Тукайга дигән хөрмәт-ихтирамының һәм татар халкына булган фикердәшлегенең дәлиле булып калачак.

**Мөнир Ерзин,**
**Тарих фәннәре кандидаты, уйгырчы, синолог,**
**Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге әгъзасы,**
**Татарстан Республикасы Журналистлар конкурсының**
**«Бәллүр каләм» бүләге лауреаты**

# Атакент

*Алматыдагы дусларыбыз: «Кытайга виза эшләтергә 5-6 көн вакыт кирәк», – дигәч, Казакъстанның көньягына сәфәр кылырга булдык. Андагы кардәшләр ничек яши? Бу якларга гомергә бер килеп, дигәндәй, туганнарны да күрәсе бар. Аннан соң «дала иле» – Көньяк Казакъстан ниндирәк икән? Шундый уйлар белән юлга чыктык.*





## Горур дөяләр

Казакъстанның чакырлы-чокырлы тар юллары буйлап җилдергәндә, казакъларның милли киеменнән, янәшәсенә дөясен утыртып, шешәләрдә нәрсәдер сатып торучы егет янына туктамыйча булдыра алмадык.

Егет шубат сатып утыра икән. Дөя сөтеннән ясалган шифалы кымызның бәясен очсыз дип әйтеп булмый. Сөтнең бер литры – 500 тенге (безнең акчага әйләндерсәк 100 сум) тора.

Егетнең шубатын сатып алгач, үзе, гаиләсе турында сораштык. Азамат Җанбәковка 19 яшь икән. Акчатау тирәсендә урнашкан кечкенә генә авылда яшәп ята.

– Авылың да ерактарак урнашкан. Юл чатында сату табыш китерәме соң? Дөя сөтен алалармы? – дип кызыксынабыз.

– Алмыйча! Ничек кенә әле. Дөя сөте сыерныкыннан биш тапкырга файдалырак та, тәмлерәк тә, – ди Азамат. Әмма әлеге сөйкемле хайваннарны асрау бер дә җиңел түгел икән.

– Дөя асрау – нәселебез һөнәре. Әби-бабаларым да аларны яратып караган. Дөяне асрый белсәң, аның файдасы бик күп. Әйтик, бер дөя 400 килограмм ит, 2,5-7 кг йон, мул итеп сөт бирә. Әни кайвакыт сөтлебикәләрне көненә 4 мәртәбә сава! Дөя сөте иммунитетны ныгыта, бик күп чирләрдән дәвалый. Безнең беркайчан да авырып, хастаханәгә барганыбыз юк. Гаиләбезнең 20 дөясе бар. Биш бала арасыннан иң өлкәне мин булгач, шубат сатып акча эшләү миңа йөкләнгән. Энеләрем көтү көтә, – ди ул.

– Дөяләр ничә яшькә хәтле яши?

– Бу хайванның гомер озынлыгы – 35-40 яшь. Дөяләр кыйммәт йөри хәзер. Сезнең акча белән ата дөя 75 мең сум тирәсе тора. Ә ана дөя кыйммәтрәк – якынча 85-100 мең сум. Кешеләр, гадәттә, иткә нәни дөяләрне сатып алырга тырыша, тел йотарлык деликатес ул!

– Дөяңнең исеме ничек соң?

– Наташа! Аңа – 3 яшь. Наташабыз бик иркә. Дөяләр көтүе арасыннан бары тик ул гына сыйпата, атланып йөрергә рөхсәт итә. Йөреп тә карый аласыз. Курыкмагыз, ул төкерми!

Дөядә йөреп маташмадык. Наташа белән кочаклашып фотосурәткә төшкәч, кымызны алып, юлыбызны дәвам иттек.

Чү, тигәнәк чәчәге түгелме соң бу?! Нинди матурлык: безнең илдәге кадерсез тигәнәкләр мондагы далада шыр чәчәккә күмелеп утыра! Чәчәкләре дә эре – йодрык кадәрле. Алар – казакъ дөясенең татлы ризыгы… Тигәнәк кайда – дөя дә шунда инде. Артыбызга борылып карасак, далага чәчелеп горур дөяләр килә! Чәнечке ашарга гаиләләре белән чыкканнар. Болар зоопарктагы йончылган, кәефсез дөяләр түгел – бөтенләй башка: ул шоколад төсендәге затлы ефәктәй озын йон, киң тояклар, ике өркәч һәм горур караш, дисеңме. Гаҗәеп сөйкемле, серле хайваннар инде менә!

Изге Коръәндә: «Мөселманның иң зур байлыгы – дөя», – диелгән. «Җире күп булган бай түгел, дөясе күп кеше – бай», – дигән гыйбарә дә бар. Аллаһ та безгә дөянең нинди могҗизалы хайван булуына игътибар итәргә куша.

Дөяне юктан гына «Аллаһның яратканы» дип йөртмиләр. Бу хайванның горурлыгы хакында шундый риваять тә бар. Баксаң, дөя Аллаһның кешеләргә мәгълүм булмаган 100нче исемен белә икән. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.с.) мөселманнарга Аллаһның 99 исемен генә әйтеп калдырган. Ә 100нче исемне үзенең ак дөясенең колагына пышылдаган. Хәзер дөяләрнең безгә горур караш белән «өстән аска» караганы аңлашыла инде: бездән күбрәк беләләр.

Дөресен генә әйткәндә, дөяләр мине балачактан ук кызыксындыра иде. Алар турында күбрәк укыган саен, үзем өчен яңадан-яңа ачышлар ясадым. Гарәпләр дөянең уникаль хайван булуын ассызыклап, аны «чүл көймәсе» диләр. Ул ике атна бер тамчы су да эчмичә көненә 80-90 чакрым юл үтә ала. «Чүл көймәсе» бер яки ике өркәчендә 200 килограммга кадәр май саклый икән. Дөя итен авыз иткән кешеләр аның иң тәмле җире дип шушы өркәчләрне атый да. Гарәпләр ата-ана дөяләрне яшь зурлыгына, төс чуарлыгына карап төрле исемнәр белән атап йөртә. Казакъстанда да аларга хөрмәт зур: Астана шәһәрендә ике дөягә һәйкәл куйганнар хәтта!

Галимнәр раславынча, дөянең сөте һәм сидеге белән 99 чирне дәвалап була икән! Судандагы Әл-Джазира университеты галимнәре дөя сидегендә бик күп күләмдә калий, аксым протеиннары, аз гына натрий һәм кератин булуын ачыклаган. Дөя сидегеннән ясалган кайнатмалар дөньядагы беренче антибиотик булган. Аны кулланып, төрле бактерия, вируслар, зарарлы гөмбәчекләрдән котылырга, ашказаны, үпкә, бөер, тире авыруларын, кан тромбларын, хәтта ракны дәваларга мөмкин. Шулай ук, калын, ялтырап торган озын чәч үстерергә теләүчеләргә бернинди «Shamtu» шампуньнәре кирәкми, дөя сидеге белән юсаң, чәчтәге кавыкны да коярга була, чәч тә тизрәк үсәчәк, ди.

## «Туган якны ташлап китмәгез!»

*Халыкның бер йорты бар, ул да булса – туган ил.*
*Халык мәкале.*

Көньяк Казакъстанның сәүдә үзәге саналган Шымкент шәһәренә җитәрәк Кыргызстан чиге янынннан узасы. Әнә, еракта танылган кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов әсәрләрендә яратып тасвирланган Кыргыз иленең баһадир таулары күренә. Ирексездән кадерле Камил бабаемның кыргыз тавындагы могҗизалар турында сөйләгәнен искә төшердем: «Кызым, ул могҗизалы тауда мин бер булдым, шунда йөрәк авыруымны гомерлеккә калдырып кайттым. Бу тау – Сүлүктә шәһәре белән Макеевка бистәсе арасында урнашкан. Без кыргыз җиренә бертуган Гомәр абзыйларыма кунакка килгән идек. Туганнар өйдә калды, мин шушы тауга күтәрелдем. Андый гүзәллекне беркайда да күргәнем булмады! Өч сәгатьләп тау башына менгәч, Миргазиян Юнысның: «Кайда да булса барсаң, берәр әйбереңне калдыр», – дип язганы искә төште. Кесәмдә йөрәк авыртканда эчә торган «Кардиамин»



шешәсе бар иде, ташлар арасына шуны кыстырып калдырдым. Шуннан бирле, Аллаһка шөкер, инде 20 ел узды, йөрәгем бер дә авыртып карамады, дару да эчкәнем юк».

Могҗиза, дими, ни дисең. Камил бабайны юктан гына телгә алмадым. Без аның иң якын туганы – Кәбир Зиннәтуллин гаиләсенә барабыз. Атакент бистәсенә…

Мең чакрымнарга сузылган Сырдәрья елгасын узабыз. Сырдәрья – Урта Азиядәге иң озын елга. Аның ярларында Хуҗанд, Шардара, Кызылорда, Байконур, Казалинск, Сырдәрья, Бекабад шәһәрләре урнашкан. Грек тарихчылары Сырдәрья елгасын «Танаис», соңрак «Яксарт» дип йөрткәннәр. Исемнәрне елга буенда яшәүче борынгы скиф, сакс кабиләләре кушкан булса кирәк.

Караңгы төндә Атакент бистәсенә килеп җиттек. Газиз туганнарыбыз Оркыя һәм Кәбир Зиннәтуллиннар безне болын кадәрле иркен өйләрендә кунак итте. Сәяхәтебездәге беренче һәм соңгы мунчаны биредә кердек. Рәхмәт яусын!

Оркыя апа белән Кәбир абый ике бала үстергәннәр. Кече уллары Рөстәм гаиләсе белән Казакъстанның Шымкент шәһәрендә яши. Ул – тәҗрибәле акушер-гинеколог. Рөстәм Зиннәтуллинның

тормыш иптәше Әлфия ханым белгечлеге буенча математик, уллары – Илдар белән Дамир Санкт-Петербург шәһәрендә укый. Илдар – ординатурада, булачак табиб-пульманолог. Дамир икътисад өлкәсендә белем эсти.

Кәбир абыйның өлкән улы Зөфәрнең гомере юл һәлакәтендә өзелгән… Урыны җәннәттә булсын. Нишләтәсең, язмыш безгә нинди генә сынаулар китерми. Ходай сабырлык бирсен!

Зөфәр абыйның хатыны Альмира белән улы Марат Атакент бистәсендә гомер кичерә. Кызы Земфира италияле Фабрициога кияүгә чыгып, Венеция янындагы шәһәрчектә үз гаиләсе белән яши икән.

Оркыя ханым – уңган хуҗабикә. Гомере буе сату белән шөгыльләнгән. Кәбир абый исә – җитмеш һөнәр иясе. «Төрле эштә эшләргә туры килде», – ди ул үзе турында. Бакчадагы ике метр биеклектәге кукурузларны, гранат агачларын Кәбир абый карап үстергән. Сараенда – дистәгә якын сарыгы бар.

«Сырдәрья якларына без туган ягыбыз – Ютазы районыннан 1960 нчы елларда чыгып киттек. Күпме сулар аккан… Ә туган як барыбер сагындыра икән. Атакенттан күпме китәргә теләсәм дә, насыйп булмады. Гүзәл табигатькә алданып, шушында калдык инде», – ди Кәбир абый.

## «Ак алтын» ватаны

Никтер, Казакъстанга барсам, күңелдәге «тукран» гел бер теләкне «тукылдата» башлый: мамык җыясым килә. Ул гына да түгел, башыма зу-у-ур казакъ «эшләпәсе» киеп, ап-ак мамык басуларында «йөзәсем» килә! Татарстаныбыз «кара алтын»га бай булса, без гизә торган Казакъ иленең Көньягы – «ак алтын»ның ватаны икән.

Атакент бистәсе Көньяк Казакъстан өлкәсенең Махтаарал районына карый. 1928 нче елда оешкан әлеге районда илнең төп мамык басулары урнашкан. Елына 160 мең тонна уңыш җыеп алына. «Ак алтын»ның бәясе белән кызыксынган идем дә, аннары ник сораганыма үкендем. Чиста мамыкның бер килосы – 5 сум тора! Бу көлке хакка бездә сагыз да тими бит… Дөнья базарында Казакъстан мамыгының бәясен Ливерпуль биржасындагы индекс буенча билгелиләр икән. Анда «ак алтын»ның бер тоннасы – 1350 доллар.

Бүген казакъ мамыгы ул хәтле табыш китермәсә дә, Казакъстанның Көньягында аны һаман да күпләп җитештерәләр. «Бодайдан кала мамык – безнең икенче икмәк. Ансыз яшәп булмый – канга сеңгән», – ди мондагы халык. Без килеп төшкән Атакент бистәсендә хәтта «Мамык

музее» булдырганнар. Ул инде дистә еллар Казакъстан кунакларын үзенә җәлеп итеп тора.

Атакент бистәсе элек Ильич дип аталган, Үзбәкстан чиге янында «утыра». 20 чакрымнан үзбәк җирләре башлана. «Үзбәкләр булмаса, ачтан үләбез, – ди Атакент халкы. – Безгә бөтен сый-нигъмәтне, «оҗмах җимешләрен» үзбәкләр ташып тора. Заманында мамыкны да күп җыйдык. «Бездә бер атнадан мамык өлгерә – калыгыз. Мамык җыйганны күреп китәрсез», – ди туганыбыз. Карале, җир читендә яшәүче гомер күрмәгән газиз туганнар янында мамык җыю хыялы да онытылган. Миннән хәтта: «Атакентта тагын ни күрдегез? Күпме кеше яши?», – дип сорасалар, берни дә әйтә алмам кебек. Кызганыч, вакыт санаулы. Иртә белән безгә гүзәл Сырдәрья буйларыннан, «ак алтын» ватаныннан китәргә кирәк иде.

* * *

Кәбир абый белән хушлашуыбыз бүгенгедәй күз алдымда тора. Яшьле күзләре белән безгә тутырып карады да: «Туганнарым, безне олылап килгәнегез өчен рәхмәт яусын! Сезгә теләгем шул: нинди генә булса да, туган якны ташлап китмәгез! Соңыннан бик үкенерсез. Барлык туганнарга миннән сагынычлы сәламнәр җиткерегез…» – диде.

«Туган илнең кадерен читтә йөрсәң белерсең», – диләр бит. Кәбир абый белән Оркыя апа да ярты гасыр туган илдән читтә яшәп, туган туфрак, туган нигез, туган авыл, туган телнең кеше гомерендәге гаять зур әһәмиятен аңлаган. Шуңа күрә, бер генә мизгелгә дә татар булуларын онытмаганнар, телебезне, динне саклап калганнар. Казакъ-үзбәк арасында үскән балаларын да казакъ, кыргыз, үзбәк яки кытай татары итеп түгел, «үзебезнең» татар итеп тәрбияләгәннәр. Ирексездән, туганымның: «Туган якны ташлап китмәгез!», – дип, ярты гасыр буена туган илне юксынып елаган күзләрендә мин чит дәүләттә яшәүче моңлы татарны күрдем. Алар да сагынудан зар елый… Әмма үзебезчә, татар булып яшиләр. Кайда гына барсак та, безне милләттәшләребез якын туганнарыдай сөенеп каршы ала, елап озатып кала иде.

**P.S.** Кәбир абый белән очрашу беренче һәм соңгысы булган икән… 2010 нчы елның 11 нче октябрь иртәсендә бер-бер артлы ике кайгылы хәбәр ишеттек: мәшһүр галим Миркасыйм Госманов вафат. Икенчесе – иртә белән Кәбир абый Зиннәтуллинның гомере фаҗигале рәвештә өзелгән, аны машина бәрдергән…

**Рәмилә Газизуллина**

# Зәңгәр тауларны эзләп

Сәфәр чыгар вакыт җиткәч, мин иң элек юл төшкән шәһәрдә туган-тумача юкмы дип белешә башлыйм. Сорашам-нитәм, шәҗәрәне карап чыгам. Чыбык очы туганнарга сәлам биреп чыгу мәшәкатьмени ул хәзерге заманда?! Риман абый әйтмешли, «савап кына»! Шөкер, нәселләребез зур вә шанлы безнең. Бурятия, Якутия, Чехия, Франция, хәтта Америкага кадәр чәчелгән. Аннан соң, читкә чыккач, гомер күрмәгән татар кардәш тә үз туганың булып китә. Без еш кына рәсми саннар китерергә яратабыз: татарның 7 миллионы читтә яши, дибез. Тик сәйлән кебек күпме чәчелсәк тә, милләттәшләребезнең тамырлары – Татарстаннан. Кайда гына яшәмәсен – татар татарлыгын итә: үз өендә, үз телендә сөйләшә, милли ризыгын ашый, үз телендә җырлый, намаз укый, мәчеткә бара, күркәм йолаларыбызны саклый. Күпме милләттәшләр белән очрашып та, арасында кеше типкесенә калган, мескен, кулыннан эш килми торган татарны күрмәдек без. Һәрберсе башка милләтләр көнләшерлек итеп тормышын кора алган. Югары урыннарда эшли. Бу горурлык түгел мени?!

Әле революциягә кадәр мәрхүм Тукай да сибелеп яшәүче күпме татарларыбыз белән аралашкан. Ул Ульян өлкәсе, Троицк, Әстерхан, Петербург шәһәрләре дисеңме?!. Кайвакыт без дә үзебезне Тукай эзләреннән атлаучы кебек хис иттек. Әлеге «сибелгән» татар үзе дә Тукаен онытмый. Аның рухы халык хәтерендә, татар йортларында яши. Татарлыкны саклап калулары белән дә милләттәшләр үзләрен Тукайга бурычлы саный…

Кем арбасына утырсаң, шуның көен көйлисең дигәндәй, Риман Солтаныч та кайда барып чыкмасын: «Монда Тукай туганнары юкмы?», – дип сорап куйган була. Костанайда гомер күрмәгән Суфия, Рәйсә, Рафаэль Зәбировлар белән дә иң якын кешеләрдәй очрашты ул. «Казакъстанга кадәр килгәч, без дә туганнар белән күрешәчәкбез, Аллаһ боерса. Киләсебез алдан хәбәр ителгән», – минәйтәм. Тик Риман абый кырт кисте: «Әллә син юләрме? – ди бу. – Кем алдан хәбәр сала? Безнең килү – ул бит сюрприз булырга тиеш!»

Кызганыч, әмма сюрпризланып булмады. Кентауга киләсен Казаннан ук шалтыратып тишкән идем. Сезнең «Зәңгәр таулар» шәһәрендә булган бармы? Юкмы? Алайса, әйдәгез Кентауга!

Кулда карта, алда – 900 чакрымлык юл. Бу юлы без Үзбәкстан чигеннән Русиягә таба «күтәреләчәкбез». Сырдәрья елгасы, Сарыагаш таулары, чүлләр, далалар, гаҗәеп исемле авыллар аша үтә барыр юлларыбыз. Дөя-ишәк, куй көтүләре, аларны саклаучы көтүчеләр – безнең инде тәмам ияләшкән юлдашлар. Казакъстанны шул «дусларыбыз»дан башка күз алдына да китерә алмыйм хәзер!

Машинаның алгы ягында утыргач, табигать матурлыкларын, юлдагы хәлләрне күзәтү минем өстә. Һәр яңалыкны арткы утыргычка «сыешкан» кызларга сөйлим. «Сыешкан» дим, чөнки зур сумкалар бер як тәрәзәне томалап ук куйдылар. Машинада селкенерлек урын да юк: аяк асты, баш очы, як-якта – сумка, биштәр. Казакъстанга юл тотуны ишеткәч, туганнар үземнән дә авыр бер чемодан бүләк-күчтәнәч төягән иде. Аларны минем аяк астына дыңгычладык.

Атакент белән саубуллашып, шәһәргә төнлә белән кергән юлдан кире чыктык. Көндез бу юл бөтенләй икенче икән. Асфальт тар – борылышларга ничек сыешканбыздыр. Юллар такырайган саен, машина да дөңгерт-дөңгерт тавыш биреп куя. Сикәлтәсез юл булмас, капкан саен бал булмас шул. Күнеккәнгәме – әмма юл йөрүе рәхәт!

Кентауда минем әни ягыннан туганнар яши. Фәхрикамал тәтә Гарәфетдин абыйга кияүгә чыгып, Кентауга шахтада эшләү нияте белән киткәннәр. Ул вакытта СССР заманы, союздаш илгә китеп эшләү модада. Бер кайтуларында әнинең әтисе – Хәлим бабамны, бераздан сеңлесе – Мәулидә апаны да үзләренә иярткәннәр. Хәлим бабай бераз яшәгәч, авылга кире әйләнеп кайткан. Мәулидә апай шунда төпләнеп, Оренбург егетенә тормышка чыккан. Кукмараның Туембаш авылында туып-үсеп, 18 яшендә Кентауга күченгән кыз, инде 52 ел читтә гомер кичерә. Сырхауханәдә санитарка, 30 ел трансформатор заводында эшләп, «Завод ветераны» исеме белән лаеклы ялга чыга. Бер ул, бер кыз тәрбияләп үстергән ул. Янәшәсендә бүген кияү-килене, 5 оныгы бар. Шулай да, хат саен бер үк сагыш, бер үк сүз яза ул: «...туган якны сагынам.»

Күңелдән хатирәләр барлый-барлый карбыз-кавын, кабак сатучыларны күзәтеп барам. Ничек иренмидер мондагы халык. Без кояштан качып машина эчендә барганда, алар кызган асфальт өстендә көн буе сату итә. Кипкән камыштан шалаш үреп, кайберәүләр шунда яшеренә. Берәр машина күрсәләр, каршысына чыгып, карбыз тәгәрәткән булалар. «Кайту юлында багажник тулганчы алырбыз әле. Аңарчы машина да бушамасмы. Туганнарыңа бүләкләрне өләшсәк, кавынга да урын булачак», – диде Риман абый.

...Кеше, җан әсәре күренми торган тоташ далага чыктык. Еракта-еракта тимер юл, поезд вагоннары күренә. Мондый «җансыз» юллар

буйлап 300әр чакрым үтәбез. Кайчак юл читендә күркәм йортлы авыллар кала. Фирүзә гөмбәзле бу йортлар – төрбәләр (каберлекләр), мазарлар икән. Мазар дип казакълар зират һәм мавзолейны атый. Бабаджи хатын, Сырлытам, Козы Корпеш һәм Баян сылу, Исмәгыйльата, Кара-Сопы, Лабака, Жубан-ана, Мулкалан – юлда безгә күп очрады алар. Казакъстанда мавзолейларга йөрү изге гамәл. Шәхесләр каберлегеннән кеше беркайчан өзелми: берәүләр савыгу эзләп, икенчеләр дога кылырга килә…

Чү, бишек кебек тибрәлеп барган машинаны кинәт күләгә басты. Тәрәзәдән башны сузсам, борын төбендә – өч бөркет! Тырнаклары түбәгә ябышам дигәндә – машина борылышка китә. Бөркет көтүе машинаны камап, томшыгы белән тишкәләп бетерсә хәзер? Риман абый машинаны боргалап «дала хуҗаларын» үртәли. Бер алга, бер артка очып чыга бөркетләр. Юк, даланы бу кошлар саклаганда юлчы хәвеф-хәтәргә очрамас. Дошманны далага бөркет кертмәс… Риман абый һаман тизлеккә баса. Һавадан бөркет, җирдән – нәни машинабыз оча.

Дала! Чиксез-кырыйсыз, иңсез-буйсыз, әй, төпсез-түбәсез дала! Элек тауларга гашыйк күңелем хәзер шул дала киңлекләрендә яши. Буш түгел Казакъстан далалары. Күпме тарих кайнаган, өйрәнеп бетә алмаслык кыргый җирләр ул! Даланың Тукайга тәэсире тагын да көчлерәк булгандыр, мөгаен. Тукай бездән киңрәк фикерләгән, табигать төсләрен дә нечкәрәк ишеткән бит.

Әкренләп шоп-шома дала калку җиргә әверелде. «Димәк, тиздән Кентауга җитәбез. Зәңгәр тауларны тапсак – Кентавыбыз шунда», – дим кызларга. Маршрутыбызга кергән күп кенә урыннар картада билгеләнмәгән иде. Шуңа күрә кайвакыт юлны юлчылардан төпчендек. Берсендә көне буе шикләнеп кенә дала буйлап бардык та бардык. Инде адаштык дигәндә, ишәккә атланган бер абзыйны очраттык. Ул юлны шәп белә: ял итү, капкалап алу урыннарын да әйтте. Бермәлне, бәйнәбәйнә сөйләп торганда, абзыйның авызыннан протезы җиргә төшеп тә китте. Абзыйны уңайсыз хәлгә куйдык дип, тизрәк кузгалып киттек. Абзыкай исә тешсез авызын ера-ера безгә кул болгап калды. Исемен дә сорарга онытккан бу картка мең рәхмәтләр яусын инде!

## Ишәк язмышы

Элекке шахтерлар шәһәре Кентау – Карлы Каратау итәгенә сыенган. Халыкта аны «Зәңгәр таулар шәһәре» дип йөртәләр. 84 500 кешеле бу кала Ачисай полиметалл чыгу урынын үстерү өчен нигезләнеп, быел 56 яшен ваклаган. Шәһәрне оештыру өчен, Миргалимсай һәм



Кантаги дигән ике бистәне берләштергән булганнар. Кентау исә – Казакъстанның иң кечкенә 59 шәһәрләреннән берсе.

Совет заманында пәйда булган Кентауга репрессиягә эләккәннәр күченгән: грек, рус, немец, кореяле, яһүд, чечен, казакълар һәм үзбәкләр – монда кем генә яшәмәгән. Татарлар шахтага эшкә килгәннәр. 1990 нчы еллар башында рудник һәм промышленностьта эш туктатылгач, Кентау халкы ил буйлап чәчелә.

Исемне дә гади биргәннәр: казакъ сүзе «кен» – рудник, казылма дигәнне аңлата, Кентау – рудник тавы була инде. Яшеллеккә төренгән бу шәһәр, таулардан тыш, чүлләр кочагына да сыенган.

Тормыш ягы да монда бүтәнчәрәк, гадирәк күренә. Йортлар ыспай, нигездә, саман – ләм белән камыш кушып салынган. Койма-капка тоту һәркемнең хәленнән килми, күрәсең. Аның каравы, халык күпкә кунакчыл, күпкә мәрхәмәтлерәк биредә. Ялга туктаган җирдә чәйгә чакыралар. Авыз итәргә җиләк-җимеш китерәләр.

Көньяк халкының тыйнаклыгы транспортта да чагыла. Алматы белән Астана урамында «Лексус», «Тойота» машиналары җилдерсә, монда адым саен дөя, ишәкләр. Халык «Копейка», «Шестерка», мотоциклларны үз итә. Транспорты булмаганнар – арба тарта. Кентауга инде килеп җитәбез дигәндә, тугызау бер арбага төялгән казакъ малайларын күрдек.

– Ишәккә авыр түгелме? – дип сорыйбыз арыган ишәккә ишарәләп.

– Юк, ул бит төнлә ял итә… – ди дәррәү килгән малайлар.

Фотоаппарат чыгарганчы, үзләре арбадан коелып та беттеләр.

– Безне түгел, куланнарны төшерегез, әнә! – диде берсе далага төртеп. Ә анда… ишәк көтүе! Егермеләп ишәк башын да күтәрми чирәм мекертәтә. Барып колакларыннан сыйпадык. Ул арада теге малайлар телефон фотоаппаратына үзебезне эләктереп алдылар. Әй, көлешәләр! Сөйләшеп киттек. Күрше авыл малайлары икән. Көтүлектәге ишәкләр дә шул авылныкы. Ә «кулан» дип ишәкне әйтүләре. Малайлар сөйләве буенча, кулан Урта Азиядә инде 240 ел чамасы яши. Кулан-ишәк иң талымсыз хайван. Ни салсаң, шуны ашый, кайда ауса, шунда йоклый. Аның гомер озынлыгы атныкыннан, бәясе бәрән бәясеннән узмый. Ә Кентауда бер бәрән 40-50 мең тенге (8-9 мең сум) йөри. Әмма малайлар сөйләве буенча, соңгы елларда ишәкләр кырыла башлаган. Элек кеше аның белән генә көн күргән бит. Итен ашамасалар да, ул ат, дөя, мотоцикл, җиңел һәм йөк машинасын да алмаштыруга сәләтле хайван булган…

## Азалия

Кентауда безне өч йортта кунакка көтәләр иде: Мәулидә апа, Фәхрикамал тәтә һәм Руслан абыйлар гаиләсе. Сөйләшенгәнчә, иң элек Мәулидә апаларга килеп төштек. Кызы Альмира, кияве Шаһдар һәм өч оныгы – Тимур, Искәндәр, Азалия бергә яшиләр.

Казакълар арасында яшәсәләр дә, өйдәге мохит «татарча». Балалар – булачак музыкантлар. Тимур белән Искәндәр баян, аккордеон һәм скрипка буенча музыка мәктәбендә укып йөрсә, Азалия әлегә «Әллүки»не үзлегеннән суза.

Ике ир бала тәрбияле, тыйнак булулары белән күңелгә аеруча уелып калдылар. Мин аларның өстәл артына безнең белән утырмауларына, кунаклар сыйлангач, табак-савыт җыюларына, хәтта бер-берсенә дәрес өйрәтүләренә шаккаттым. «Егет кешегә 70 төрле һөнәр дә аз», – дип өйрәтә ахры әбисе белән әнисе. «Тимур белән Искәндәр ашарга да пешерә, өй-җирне дә карап тота», – дип сөйләде Альмира. Әйтергә кирәк, музыкага тартылу балаларга әниләреннән күчкән. Альмира 17 ел музыка мәктәбендә укытучы булып эшли икән.

«Азалиянең иң яраткан 2 курчагы бар, – дигән иде Альмира без ишектән керү белән. – Берсе – Гөлназ, икенчесе – Рәмилә. Сез кыш килгәндә бездә торып киткәч, юксынып, курчакларга шундый исем бирде ул». Күз алдында үскән бу сабый. Хәзер аңа 4 яшь. Кунаклар



**Мәулидә апада кунакта**

килүенә куаныпмы, Азалия: «Безгә бабай кайтты!», – дип кычкырып җибәрде. Яшен һаман 18дә тойган Риман абый «бабай» сүзенә үпкәләп йөрде. Ләкин Азалия үз фикереннән кайтмады.

Җитмәсә, Мәулидә апай да сүз ара сүз чыгып «бабай» сүзен «ычкындырып» куйды. Аннан Риман абыйның үпкәле күз карашын сизепме:

– Бигрәк олы йөрәкле икән нәчәлнигегез. Өч япь-яшь кызны курыкмыйча нинди озын юлга иярткән! Чәче ак булса да, чырае бик яшь күренә, – дип өстәде.

## Бешбармак

Без килүгә табынга казакъ милли ризыгы – бешбармак чыкты. Бешбармак – ул биш плюс бармак. Аны әзерләү өчен кулның биш бармагына биш төрле ризык кирәк: ит, суган, кишер, бәрәңге һәм махсус кискән токмач. Токмачны кисү өчен, җәемне уч төбе кадәр тигез шакмакларга бүлеп чыгасы. Аннан кайнар суда пешекләп, яссы савытка саласы. Өстенә пешкән ит яки казы, пешеп туралган бәрәңге, кыздырылган кишер һәм суган тезәсе. Өстәлгә чыгарыр алдыннан күп итеп, төелгән кара борыч сибәсе.

«Бешбармакны кул белән ашау – йола. Кашык-чәнечке, хәтта кытай таякчыгы да аның тәмен бозарга мөмкин. Ашаганда, токмачка бәрәңге, ит кисәге, суган, кишер салып, «төрәсе». Килеп чыккан «йомгак» – «ляленчка»ны авызга зу-у-ур итеп кабасы! Әгәр авызга биш бармак белән сыйса – бешбармак, димәк, уңган була!», – дип өстәде Альмира.

## Төнге Кентау

Тәрәзә артын караңгылык басканда бүләк төенчекләрен җыйнап Фәхрикамал тәтәләргә чыгып киттек.

Кентау йокламый иде. Чат саен кеше, колак тондыргыч музыка, шау-шу, бәйрәм!.. Әгәр Рио-Де-Жанейрода булсак, билләһи, карнавалга эләктек дияр идек. Альмира: «Күрше урам үзбәкләрендә бүген туй. Җир читендәге туганнарына кадәр кайтып төшә. Безнең кебек, туган җанлы, кунакчыл халык», – диде.

Без барачак йортка юл шәһәр үзәгендәге мәйдан аша икән. Бәрәч, монда ни тамаша тагын?! «Казакъстан Республикасы Конституциясенә 15 ел тулуга багышланган бәйрәм тантаналары бер атна алдан башланды. Бөтен шәһәр урамда бүген», – дип шаккаттырды Альмира. Сәхнә, ә анда концерт. Баганаларга Казакъстан флагы эленгән. Әйтерсең лә урамга сугыш бетү сөенеченнән чыкканнар. Бәйсез тормышка Казакъстанның иң бәләкәй бер шәһәрендә дә ничек сөенәләр бит. Халыкның уртак бәйрәме парк, кафе, фонтан буйларында да гөрли иде. Ирексездән Тукайның да татарны азат, мөстәкыйль, олы милләт итеп күрергә хыялланып язган:

*Шул халыкныңмы хокукка хакы юк,*

Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук… – дигән шигъри юллары искә төште… Кызганыч, Русиядә милли сәясәт икенчерәк шул.

Фәхрикамал тәтә кызы Дания һәм оныгы Фәния белән зур бер фатирда яши. Ул быел 80 яшен ваклаган. Гомере буе «Дом быта»да җыештыручы булып эшләгән. Гади генә хезмәттә булса да, эшендә аны татар булуы өчен бик хөрмәт иткәннәр. 5 баласы өстенә Мәулидә апаны да тәрбияләп үстергән ул. Ире Гарафетдиннең вафат булганына инде 20 ел икән. Чәй артында авыл, Казан яңалыкларын сөйләштек. «Үлгәнче хет бер тапкыр Туембашны күрәсе иде. Яшь вакытта чишмәгә йөргән сукмаклар, кәтү кайтулары төшкә кереп йөдәтә. Сагынам, кызым, сагынудан саргаям. Үзем монда яшәсәм дә, күңелем белән Туембашта йөрим. Бәхил бул, туган як кызы…» – дип озатып калды арттан.

Альмираның бертуган абыйсы Русланнар да шушы шәһәрдә яши. Хәләле Роно – милләте буенча үзбәк. Балалары Рафис һәм Ришат минем белән татарча, русча, үзбәкчә һәм казакъча гәпләштеләр.

Кайтыр юлга чыккач, Риман абый: «Әллә бүген минем чәчне буйыйбызмы?», – дип куйды. «Бабай» дигән сүз тәмам бәгыренә төшкән икән. Тәүлек буе эшли торган бер юл өстендәге кибеттән чәч буявы сатып алдык.

Мытыклы парикмахер эше Альмирага йөкләнде. Менә көмеш төсле чәчкә буй-буй буяу кунды. «Төсе табигый керсә ярый инде, – дип төрттерә Альмира. – Кайвакыт кара урынына шәмәхә дә килеп чыккалый.»

Бер сәгатьтән «Тукай фонды» президенты кеше күзенә күренергә әзер иде. Дөресен генә әйткәндә, без аны башта танымадык. Беренче карашка ул җырчы Иосиф Кобзонга да охшап киткән иде. Әмма имидж үзгәртү Солтанычка бик килеште. Берзаман Азалия кулларын чәбәкләп:

– Вот теперь ты на парня похож! Настоящий мужик! – дип авыз ермасынмы?!

– Сезне Алматыда танымаслар инде, – дибез яшәреп киткән Риман абыйга. – Кытай чигеннән уздырсалар ярый: паспортта чәчегез ак дисәләр… Риман абыйның үзенә дә ошады, ахры, чәч буяу. Көзге янына килгәч, үзен бераз танымаса да, сокланып шактый вакыт карап торды.

Хәер, чәч буятуның тискәре яклары да булды. Моңа хәтле, мәсәлән, Казакъстанның юл полициясе безне туктатып, юк-бар өчен дә штраф чәпи башлады. Бер юл сакчысы, хәтта, Риман абыйның паспорттагы яшенә ышанмады. 30 яшь кенәдер дип, әй, җиңеште безнең белән! Аннан ике тапкыр 30 икәнен ишеткәч – авызы ябылды. Яшь калу серләрен сораша башлады. Риман абый сер бирергә ашыкмады: «Күбрәк Тукайны укырга кирәк», – дип кенә җавап бирде, ә үзенең авызы гел колакта булды.

Әмма ни өчен Тукайны укырга киңәш итүен башта аңламадык. Соңыннан төшендек: ул казакъларның Тукайны белү-белмәүләрен сынаган икән. Чыннан да, юл полициясе арасында Тукайны белүчеләр дә очраштыргалады, алай гына да түгел, Риман абыйның Тукай туганы икәнен дә белгәч, кайберләре штраф салырга да базмады.

* * *

Виноград, мамык басулары белән дан тоткан Кентау якларында халык рәхәт яши. Ризык, тормыш бәяләре арзан, тик хезмәт хакы да әллә нәрсә түгел. Әмма, никадәр рәхәт, табигате җәннәт булган урында да, кеше хәтер төбендә калган балачагын, тупсалары искергән туган нигезен сагынып яши. Кемнәр исән, кемнәр юк булган авылдашларын, яшьлеген юксына. Туган җир, җирсү… Ирексездән күңелгә тагын Тукай килә:

*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;*
*Һәр фосулы әрбәгъәң: язың, көзең, җәй, кыш көнең;*
*Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!*
*Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;*
*Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.*
*(Г. Тукай, «Туган җиремә», 1907 ел)*

Икенче көн кайтыр юлга чыкканда озак кына аерылыша алмый тордык. Бер генә төнгә килгән йортка, ачык күңелле хуҗаларга тәмам ияләшкән идек. Бешбармак пешерү, Азалиянең чыр-чу килүе, төнге Кентау маҗаралары, чәч буятулар хәзер сагынып сөйләргә генә калды… Мәшәкатьмени туганнар хәлен белү, савабыннан бигрәк – күңелгә дәва. Күрешкәнгә кадәр, сау булыгыз, кадерле Кентау туганнар!

**Гөлназ Галимҗанова**

# БӨЕК ЕФӘК ЮЛЫ

*Урта Азиянең кайсы гына почмагына китереп чыгармады безне Тукай. Әле Казанга кайткач та, йөргән юлларны картадан барлый-барлый, сәфәрдә күргәннәрне искә төшереп, «Шул җирләрдә булдык микәнни?», – дип шаккатып утырдык.*

Казакъ далаларын гизгән чакта, безгә еш кына «Җебек Җолы» дигән юл тамгалары очрый иде. Бу галәмәткә башта әллә ни игътибар бирмәдек. Юлда карарлык урыннар болай да җитәрлек бит. Әмма берсендә «Тараз – город Великого Шелкого пути», – дигән язуны күргәч, башка уй төште. Баксаң, без инде ничә көн дөньядагы атаклы Бөек Ефәк юлы буйлап сәяхәт итәбез икән бит! «Җебек Җолы» – казакъчадан «Ефәк юлы» дип тәрҗемә ителә һәм аның бер өлеше Казакъстан аша уза икән.

Дөрес, Тукай бу якларда булмаган. Әмма биредә авыл саен Тукай иҗатын белүче китапханәчеләр, укытучылар яши. Ара-тирә җирле халык белән сүз куертып, Тукай турында сөйләшеп ала идек. Гадәттә, әңгәмә кибет, заправкаларга туктагач корыла иде. Машина номерын күрепме, бездән: «Русиядән үз машинасында Казакъстанга сирәк киләләр. Сез кемнәр?», – дип сорыйлар иде. Без Тукай эзләреннән сәфәр чыгуыбыз турында горурланып сөйләгәч: «Татар шагыйре Тукайның шигырьләрен без казакъча укып үстек. Ул безнең дә

шагыйрь», – дияләр иде. Бөек Ефәк юлында безне бигрәк тә шулары горурландырды.

Заманында «Ефәк юлы» өстендә берсеннән-берсе бай базарлар оешып, аларга дөньяның төрле почмакларыннан сәүдәгәрләр агылган. Ефәк юлын күрергә сәяхәтчеләр Урта Азиягә махсус килеп, соңыннан күргән могҗизаларын истәлекләрендә язып калдырганнар, кешеләргә сөйләгәннәр. Инде бу якларга юл төшкәч, без дә уй-хисләребезне сезнең белән уртаклашырга булдык. Ефәк юлы, чыннан да, могҗиза була. Кеше күзе күрмәгән нинди генә тауар белән алу-сату итмиләр монда. Цивилизация алга киткән, икътисад зур үсеш алган урыннарда хәзер – коры дала. Хәер, Бөек Ефәк юлының исеме генә сакланган дию дә дөрес булмас иде. Ни дисәң дә, сәүдә – җирле халыкның канына сеңеп, нәселдән нәселгә калучы шөгыль. Биредәге шәһәрләрдә бүген дә базарчыклар эшли. Кайсында умарта балы, җиләк-җимеш, кием-салым, келәм, тукымалар, кайсында дөя, куй, ишәк, сарык саталар. Һиндстан, Кытай, Казакъстан, Кыргызстан җитештергән тукымаларны Русия һәм Европага кадәр озаталар. Тарих бит кабатланулардан гыйбарәт.

## Ни өчен Ефәк?

Бөек Ефәк юлының тарихы көнчыгыш әкиятләре кебек: тылсымлы һәм гыйбрәтле. Меңнәрчә чакрымга сузылган, меңнәрчә шәһәр-авылларны тоташтырган бу юл – III (безнең эрага кадәр) – XVI гасырларда да (безнең эра) яшәп килә. Аның төп сәүдә урыннары булып Урта Азиянең төрле шәһәрләре тора. Төркмәнстанда – Мерв, Үзбәкстанда – Бохара, Сәмәрканд, Ургәнч, Хива, Кыргызстанда – Джуль, Суяб, Новокент, Баласагун, Борскоон, Таш-Рабат, Ош, Узген, Казакъстанда – Отрар, Төркестан, Тараз, Испеджаб һәм башкалар. Бу шәһәрләрнең кайберләре исән-имин сакланса да, Бөек юлның маршруты үзгәрә төшкән. Табигать афәтләре, сугышлар Ефәк юлын гына түгел, бу юл өстендәге авылларны, шәһәрләрне, данлыклы базарларны да юкка чыгарган.

Гади генә сәүдә юлы ничек «ефәк» булып киткән дә, һәм аның бөеклеге нәрсәдә? Беренчедән, «Ефәк юлы» Кытайның борынгы Чанъань (хәзерге вакытта Сиань, Шэньси провинциясенең административ үзәге) шәһәреннән башлана, бөтен Урта Азияне кертеп, Европага кадәр сузыла. Икенчедән, «Ефәк юлы» сүзен тәүге тапкыр 1877 нче елда немец галиме Фердинанд Фрайхерр фон Рихтгофен үзенең «Кытай» исемле әсәрендә куллана. Ефәк – Көнчыгыш белән Көнбатышны таныштырган төп алу-сату тауары була ул чакта. Кытайдан кала башка җирдә җитештермәүләре, үз чиратында, ефәкнең ул чорда кыйммәт



**Бөек Ефәк юлы – Кытайдан Якын Көнчыгыш һәм Европага кадәр илтүче кәрваннар юлы системасы. Аның иң зур өлеше Урта Азия һәм Казакъстан аша үтә**

һәм сирәк тукыма булуы хакында сөйли. Ә иң кызыгы – ефәк җитештерү ысулын Кытай осталары гасырлар буена сер итеп саклаганнар. Шулай итеп, мәдәни традицияләре, дини тәгълиматлары, фәнни һәм техник казанышлары белән аерылып торган ике бөек цивилизация – Европа белән Азияне ефәк сәүдәсе үзара тоташтырган, якынайткан.

Гасырлар буе шаулап тора Ефәк юлында базарлар. Әйе, алу-сату өчен уңайлы булсын дип, алар нәкъ юл өстендә урнаша. Асылташлар, тәмләткечләр һәм экзотик җиләк-җимеш, алтын һәм көмеш, көньяк җанвар-кошларының күн-тиреләре, төсле ефәк тукымалар белән европалылар беренче тапкыр әлеге сәүдә юлы аша таныша.

Ефәк юлы сәүдә мәйданы гына түгел, мәдәни һәм сәяси багланышлар урыны да булып хезмәт итә. Тарихта аны Халыкара һәм милләтара конфликтларны булдырмау өчен кулланганнар, дип исәплиләр.

Кызганыч, безнең өчен тарих күп нәрсәне саклап кала алмаган. Гасырлар тузаны юллар, шәһәрләр, шәхесләрне күмеп киткән.

## • ТӨРКЕСТАН

*Төркестан! Иркен казакъ иленең шәһәр-падишаһы! «Чын Казакъстанны күрәсең килсә – Төркестанга бар», – диләр. Базар – бүген дә аның яшәү рәвеше. Могҗизасы – Хуҗа Әхмәд Ясәви мавзолее…*



# Төркиләр мәккәсе

«Икенче Мәккә»гә әйләнгән Төркестан шәһәренә баруны алдан ниятләгән идек. Казакъстанның җиде могҗизасына кергән Ясәви мавзолее, шәркый стильдә төзелгән булуы белән дә кызыксындырды безне. Хак булса, Ясәви каберенә өч тапкыр килү – «кече хаҗ» кылуга тиң икән. «Мәдинәдә – Мөхәммәд, Төркестанда – Хуҗа Әхмәд», – дигән сүзләрнең дә колакка чалынганы бар. Инде Әхмәд Ясәви рухына дога кылмый китсәк, гөнаһ та булыр кебек тоелды.

Казакъ иленең мәдәнияте, рухы, тарихы белән танышу өчен генә булса да барырга киңәш итәбез бу шәһәргә. Биредә «цивилизация» бүтәнчәрәк, тормыш казакъ милли традицияләрендә кайный. Күккә ашкан йортлар Азияне Европага «алмаштырган» заманда, Төркестанда әйтерсең лә, вакыт туктап калган. Бу, бәлки, XVIII гасырга кадәр аның Казакъ ханлыгы башкаласы булып торуы белән дә бәйледер. Һәйкәлләр, борынгы төрбәләр, мәчетләр, тирмәләр күплегеннән без үзебезне казакъ җирендә итеп тойдык. Монда һәр ташның, һәр капканың үз хуҗасы һәм тарихы бар. Халык сәүдә итеп, җирдә эшләп көн күрә. Мозаикалар белән эшләнгән иман йортларында йөреп, без аны Казакъстанның «тере» шәһәр-музеена охшаттык.

Төркестан дигәннән, бу урында шәһәрнең исеменә һәм җисеменә бераз аңлатма бирү кирәктер. Төркестан дөньяда икәү, чөнки. Берсе Казакъстанда, икенчесе Кытайда булып, ул Көнчыгыш белән Көнбатыш Төркестанга бүленә. Көнчыгыш Төркестан – Шенҗан-Уйгыр автоном районы, Кытайның Көнбатышы. Монда гомер итүче халык – кытайлар һәм төркиләр. Ә Көнбатыш Төркестан хәзерге бөтен Урта Азияне алып тора: Казакъстан, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Кыргызстан һәм Таҗикстан. Моңа Көньяк Себер, Иран һәм Әфганстанның төньяк өлешен дә өстәргә кирәк. Күз алдына китерәсезме, нинди зур дәүләт. Инде Көнчыгыш белән Көнбатыш Төркестанны бергә кушсаң, әйтерсең, ярты Җир шары килеп чыга! Экспедициядә без Төркестанның икесендә дә булдык.

Кыш килгәндә Төркестан нинди – җәен дә шундый иде. Кыш дигәннән, биредә ул Франциядәге кебек: кичтән яуган кар иртәнгә эри. Җәен исә монда гөлбакча! Мавзолей тирәләре аллы-гөлле роза аллеяларына күмелгән.

Фарсычадан тәрҗемә иткәндә, Төркестан – «Төркиләр иле». Фарсы дәүләтчелегендә бу төбәк Туран була. Тарих көлендә казынсак, Шабгар белән Яссы (Йаса) – Төркестанның беренче атамалары. Шабгар исеме X гасырга чаклы кулланылып, XII гасырдан Яссыга әйләнә.

Төркестан элек-электән дин һәм мәгърифәт учагы була. Биредә бүген дә Урта Азиянең иң зур уку йорты – Хуҗа Әхмәд Ясәви исемендәге Халыкара казакъ-төрек университеты эшли. Дөньяның төрле кыйтгаларыннан 30 меңләп студент 13 факультетта белем ала.

## Ханака

Шулай да Төркестанның «йөзек кашы» – ул суфи шагыйрь, шәех Хуҗа Әхмәд Ясәвигә торгызылган Мавзолей. Җиде гасыр буе тирә-юньгә нур чәчеп, шәһәр үзәгендә утыра ул.

Читкә чыккан саен чагыштыра башлыйсың икән: бездә ничек тә, аларда? Бездә хәлләр начар түгел кебек: татарча иркен сөйләшәбез, «кысылып» булса да, мәктәпләрдә татар телен өйрәнәбез һәм өйрәтәбез. Тик бездән дә яхшырак яшәүчеләрне күргәч, «ак көнләшү» хисләре күңелне тырнап куя. «Безнең кай җиребез ким?», – диясе килә. Казакъстанда, мәсәлән, Ясәвигә булган кадер-хөрмәтне белү өчен, кырык кат ишеткәнче бер кат күрү дә җитте безгә. Шагыйрьнең, нигездә, риваятьләрдә яшәүче тормышын бала-чага мәктәптән үк белеп үсә. Аның 135 шигырьле «Диване Хикмәт» тупламын да, кирәк икән, яттан әйтеп бирәләр. Милләтне дөньяга таныткан шәхесләрне олылау, гомумән, Казакъстанда элеккедән килә. Әхмәд Ясәви үлгәч, әнә нинди Мавзолей төзегәннәр бит аңа! Ә безнең халыкта Ясәви белән янәшә торырлык шәхесләр юкмы? Ник булмасын ди менә, Тукайны гына алыйк. Кардәш казакълар Ясәвигә «баш игән» кебек, горурлана беләбезме икән Тукаебыз белән? Тугыз гасыр элек яшәгән шагыйрьгә Аксак Тимер Мавзолей торгызган. Аның кабере бүген халык өчен изге урынга әйләнгән. Тукайга Мавзолей кирәк дип әйтү түгел бу, безнең йола буенча Мавзолей төземиләр. Әмма нибары бер гасыр элек вафат булган Тукайның каберен белмәүчеләр дә җитәрлек түгелме арабызда? Аның белән бәйле йортлар, урамнар тарих битләреннән җуелып бара. Тукай яшәгән, эшләгән биналарны җир йөзеннән әкренләп «себерәләр»… Билгеле, Казакъстан белән Татарстанны чагыштыру, бәлки, бик үк дөрес тә түгелдер. Ни дисәң дә, казакълар аерым илдә, без – Русия эчендә яшибез. Ләкин халкыбыз җәүһәрләре белән горурланырга, авыз тутырып татарча сөйләшергә безне беркем дә тыймый. Тәрбия дә, горурлык та бары тик үзебездән һәм үзебездән генә тора.

Кайнар кояш астында бәхәсләшә-бәхәсләшә Мавзолей тирәсен урыйбыз. Биш кат әйләнсәң дә бинаның тышкы гүзәллеген күреп аңлап бетерә торган түгел. Стенаны көйдерелгән кирпечтән өеп,



**Заманында шушы казанда пешкән Корбан ашы белән бөтен Төркестан халкын сыйлый торган булганнар**

зәңгәр төстәге мозаикалар белән бизәгәннәр. Арасында без «Аллаһ», «Мөхәммәд» (с.г.с.), «Аллаһ бөек» кебек язуларны да укыдык.

«Суфи шәехләренә куела торган Мавзолейны биредә «ханака» дип йөртәләр. Гадәттә, ханака яшәү, дәрес бирү, кунак кабул итү өчен дә хезмәт итүче кунакханә ул. Аның тагын мәчете һәм мәдрәсәсе була. Боларга өстәп, пантеон һәм мунча эшли», – дип сөйләде экскурсовод. Туристлар өчен биредә барысы да көйләнгән. Керү юлында 500 тенге түләп сурәткә төшә аласың. Әзер фотоны чыгу юлында кулга тоттыралар.

Гарәп язулы агач ишекләрдән үзәк залга үттек. Безне Казакъ ханнары резиденциясе булып торган залга һәм төрле бүлмәләргә илтүче ишекләр каршы алды. Зал уртасында 7 төр металлдан коелган Тай казан утыра. Ул шәркый мөселман дөньясындагы иң зур казан икән. Заманында корбанга сарык китереп, шушы казанда кайнаган шулпадан бөтен Төркестан халкын авыз иттерә торган булганнар. 2,45 метр диаметрлы, 2 тонна авырлыктагы бу савыт берләшү һәм кунакчыллык символы булып торган. Бүген туристлар бу казанга тәңкә ата. Имеш, шулай эшләсәң, көтмәгәндә йә байыйсың, йә Төркестанга тагын килеп чыгасың, ди.



Бина буйлап йөри торгач, 35 бүлмә санадым. Җәмәгатьханә, гүрханә, олы һәм кече аксарай, китапханә, ашханә, кое бүлмәсе, худжралар… Хуҗа Әхмәд Ясәви каберлеге гүрханәдә саклана. Кешеләр монда тезләнеп дога, намаз укый. Сәдака итеп акча калдырып китә.

Чыгу юлында тагын бер кызыклы мәгълүматка тап булдык. Баксаң, Ясәви ханакасында бер Хуҗа Әхмәд кенә түгел, ә Улугбәк кызы Раби Солтан Бегим, Есим-хан, Аблай-хан, Джангир-хан һәм башка бик күп казакъ ханнары да җирләнгән икән.

## Сайрам улы

Әдипнең тәрҗемәи хәле, әйткәнемчә, хисапсыз риваятьләрдә яши. Хуҗа Әхмәднең 1103 нче елда Шымкент өлкәсе Сайрам шәһәрендә туып, Төркестанда яшәве һәм күмелүе, әтисе Ибраһим, бабасы – Мәхмүд, олы бабасы – Ифтихар, әнисе – Карачәч булуы төгәл билгеле. Әхмәднең әти-әнисе Сайрамда җирләнә. Хуҗа Әхмәд тә Сайрам дип йөртелергә тиеш була. Әмма ул үзенең яшәгән төбәге – Яссы атамасын ала: Ясәви шуннан килеп чыккан.



Әхмәд Ясәвигә тәрбияне һәм рухи белемне шәех Арслан-Баб биргән, диләр. Бер риваять буенча, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.), үләр алдыннан халыкны җыеп: «Кем минем амәнәтне үтәп ислам юлына баса һәм эшемне дәвам итә?», – дип сорагач, халыктан Салмани-Фарс (Арслан-Баб) килеп чыга. Ул вакытта Арслан-Бабка 300 яшь тулып, ул дөньяның 33 динен өйрәнгән мөселман була. Бу вакыйгалардан соң 500 ел үтә. Бервакыт Арслан-Баб дала буйлап барганда, аңа 11 яшьлек малай очрый. Ул Арслан-Бабны туктатып: «Аксакал, минем амәнәтне кире кайтар…» – ди. Бу малай исә Хуҗа Әхмәд Ясәви була.

Арслан-Баб үлгәч, Хуҗа Әхмәд Бохарага күченеп, анда шәех Хуҗа Йосыф Хамадани белән таныша. Әлеге шәех суфи булып, үз белемен Әхмәд Ясәвигә өйрәтә.

Әхмәд – үз чорының популяр шагыйренә һәм дин әһеленә әйләнә. Аны, хәтта Бохара суфилар ыруы башлыгы итеп тә сайлыйлар. Әмма ул Яссыга күченеп, дин гыйлемен Төркестанга тарата.

63 яшькә, ягъни Мөхәммәд (с.г.с) Пәйгамбәрнең үлем яшенә җиткәч, Әхмәд Ясәви нишли дип беләсез? Ул мәчет янында җир асты йорты эшләтеп, шунда яши башлый. Гомеренең соңгы мизгеленә кадәр үзен кояш яктысыннан мәхрүм итә. Бу «йорт» янына Әхмәд Ясәвинең бөтен гаиләсе, шәкертләре килеп урнаша…

## Алматыга кайту

Еракта-еракта Алматының түбәсен кар баскан биек таулары күренә. Ниһаять, тәмам сагындырып бетергән Алматыга кайтабыз!

Әйтергә кирәк, сәяхәт вакытында безнең төп юлдашыбыз табигать булды. Нинди генә озын араны да табигатькә сокланып тиз үтәргә өйрәндек без. Кыялар, төз кәүсәле урманнар һәм юлларны кисүче сирәк-мирәк чүлләр аша аяк-гәүдәләрне бөкләп бара торгач бераз арысак, туктап машинадан төшәбез. Җәйнең җылы җиренә ятып тәгәрибез, ял итәбез. Бөтен арулар, тәннең оюлары бер мизгелдә юкка чыга. Ничек рәхәт табигатьтә сәяхәт итү!

Юлга август аенда чыгуыбызга сөенеп тә куйдык. Ник дигәндә, җиләк-җимеш пешкән, көннәр тәмам матурланган чак бит. Юлда алма, груша, өрек бакчалары җәелеп кала. Һәр бакча турысында юл читенә чиләк-кәрзиннәрен тезеп бакча хуҗалары чыгып утырган. Үткән-сүткән машинага «Минекен ал, минекен!», – дип кул болгыйлар.

– Алмалар күпме тора? – дип сорыйбыз шатлыкларыннан нишләргә белмичә безне кочаклап алган сатучылардан.

– Сортына карап инде. Биш төрле алманың сезгә бөтенесен бер бәһадән җибәрәм. Чиләге 80 тенге.

Тиз генә күңелдән исәплибез: безнеңчә 16 сум! Чиләге дә зур. Ярып күрсәткәннәр иде, сусыл алманың балы ук агып тора. Сливаларын күргәч күзләр бөтенләй тонды. Риман абый сабыйларча, «Ике дә уйламыйбыз, кызлар, машинага сыйганчы алабыз!», – дип куйды.

– Сливаның өч савытта өч төрле сорты. Бакчадан яңа җыйдык, ысвижый. Ошамаса үзегезне кертеп җыйдырам, сулар сибеп тәрбияләдек. Сливаның чиләге 150 тенге (30 сум), грушаныкы – 100 тенге (20 сум), өрекнеке – 200 тенге (40 сум), чияне бушлай бирәм, – ди сатучының берсе татарчага якын казакъча.

– Безгә һәммәсен өчәр чиләк! – диде Риман абый иреннәрен ялый-ялый. Алма төшәрлек тә урын булмаган машинага капчык-капчык җиләк-җимеш төядек. Салонга татлы вә хуш исләр таралды, әппититләр ачылды. Ахшамга күпме вакыт калганын санап кайтабыз. Йоклап та карыйбыз, җырлап та куябыз – вакыт кына әкрен үтә. Бер Риман абый рәхәтләнә: симәнке урынына чия чиртеп кайта. Чиртерсең дә, бушлай диярлек килгән бит!

Соңыннан, ул җиләк-миләк белән күрмәгәннәр калмады. Иң элек безне бал кортлары сарып алды. Икенчедән, Алматыга кайтып җиткәч, ике көн җиләк диетасынды утырып, җимеш күрмәс хәлгә җиттек. «Сабантуй» кунакханәсе хезмәткәрләрен дә күпме кирәк сыйладык. Алар да гаҗиз булгач, Кытайга китәр алдыннан боларны суыткычка дыңгычладык. Тәмен бик сагынып кайтсак, тагын эч күпкәнче ашарбыз, диештек. Кытайдан кайтуыбызга «Сабантуй» ашханәсендә хәлләр мөшкел иде. Бер сакчы эче катканчы көлә-көлә сөйләп бирде безгә:

– Сез киткәч, җиләкләрне бозылмасын дип, суыткычның морозильнигына тутырганнар. Кавын-карбызыгызны да шунда салганнар. Беркөнне эшкә килсәк, ишегалды тулы су: суыткычны сүндергән булганнар да, өшегән җиләк-кавыннар җебеп, асфальтка агып чыккан. Көн буе җыештырды пешекчеләр, ике көн морозильникны җилләттеләр. Хәзер мәзәк итеп сөйләп йөрибез менә!

Урманга утын белән бармыйлар, Алматыга алма белән кайтмыйлар шул, җәмәгать!..

**Гөлназ Галимҗанова**





# Ни хао, Кытай!

*И сез, бөтен дөньяны сәяхәт итәргә теләүчеләр!*
*Сез кайда барсагыз да, дустларыңыз торган җирдән*
*матур, күңелле урын тапмассыз.*

*Г. Тукай, «Ике күгәрчен», 1909.*

## • ХОРГОС

### «Сират күпере»

Сәгатьләр иртәнге сигезне күрсәтә. Таксида Хоргос шәһәренә якынлашабыз. Биредә Казакъстан-Кытай таможнялары урнашкан. Кирәге чыкса дип, кытайча берничә сүз әйтергә өйрәндек.

ни хао – исәнмесез
чунихауюнь – сау булыгыз
цай чинь – хуш
че-че – рәхмәт
туи пучи – гафу итегез
ва щиха ни – мин сине яратам
шаң диан – кибет
ну хау ма? – хәлләрең ничек?
хау – әйбәт
кы фаң – кунакханә
чиа жие – бәйрәм белән
наң – ипи
сен лиң – урам
чиң цуа – утырыгыз



«Өч сәгатьтә Кытайга чыгып өлгермәсәгез, әбәткә эләгәчәксез. Аннары тагын 3-4 сәгатьләп көтәргә туры киләчәк. Уңышлар сезгә!», – дип, Алматы таксисты безгә кул болгап калды.

Казакъстан таможнясына кергәндә үзебезне «сират күпере»н кичәргә әзерләнгән мосафирлар кебек хис иттек. Һәрберебезнең кулында шактый гына кабарган өч зур сумка. Кием-салымны күп алмадык, төп йөк – Кытайда яшәүче милләттәшләребезгә дигән бүләкләр. Абау, мондагы кешенең күплеге! Авызыңны ачып торсаң, бер-береңне югалтасың, валлаһи!

Казакъстан чиген бер сәгатьтә кичтек. Кытайга визаны Алматыда ясаткан идек, әллә ни бәйләнеп тормадылар. «Алматыга кунакка килдегезме? Без татарларны яратабыз», – диделәр. Алай да, адым саен чит ил паспортын күрсәтергә кушалар. Биредә ун гына мәртәбә «фейс-контроль» үткәнбездер.

Хәзер иң авыры калды – Кытайга керү. Безгә, беренче эш итеп, чикне үтәргә кирәк. Урамда унлап «Газель» машинасы тезелгән. Биш-алты кеше: «Соңга калабыз, әбәткә эләгәбез», – дип, шунда йөгерде. Артларыннан без дә иярдек. Иң элек паспортларны тикшерделәр. Аннары һәр кешедән 500әр тенге (безнеңчә 100 сум) акча җыйдылар. Машинага бихисап сумкалар белән бергә уналты кеше шыплап тулдык. Кайберләребез басып барды. Тимер капкадан керәбез. 100 метр уздыкмы-юкмы машинабыз туктады. Руль артындагы казакъ пассажирларга төбәлеп: «Кытай таможнясына чыгасыгыз килсә, акча түләгез. Түләргә теләмәгәннәр ике чик арасында калачак», – диде.

– Без Кытай чигенә җитмәдекмени әле? – дибез.

– Казакъстан чиген генә уздык.

– Күпме түләргә?

– 600 тенге.

Менә тамаша! Бер үк машинага ике мәртәбә түләтәләр.

Кузгалдык. 30 метр үткәнбездер – тагын туктадык. Бу ни бу, ә! Паспортларны тикшерүче керде. Әлеге чик сакчысы бигрәк тә бәйләнчек, кырыс булып чыкты. Һәр паспортны озаклап карый. Тагын акча җыеп алдылар. Хәзер Кытайга керәчәкбез, имеш.

Ун-унбиш метрдан тагын туктаттылар. Нәрсә беләндер машинаның тышын юдылар (кысылып баргач, безгә аермачык күренмәде). Тәгәрмәч асларын карадылар. Басып торган кешеләрне чыгарып, паспорт тикшерделәр. Аннары миназзләгеч белән машинаны әйләнеп чыктылар. Беттек! Пипелдәгән тавыш яңгырады. Кытай хәрбиләре сискәнеп китте: «Берәрегездә шырпы булса, ташлагыз», – диләр. Барыбыз да шырпы эзлибез. Алай тәмәке тартмыйбыз да инде, бездә шырпы

булырга тиеш түгел. Теге пипелдәгән тавыш һаман тынмый. Маңгайга салкын тир бәреп чыкты: берәр сылтау белән Кытайга кертмәсәләр?! Бер мәлне шоферыбыз кесәсеннән тыныч кына шырпы кабы тартып чыгарды да, тәрәзәдән ыргытты. Пипелдәү бетте. Кытай солдаты кузгалырга рөхсәт биреп, кулын күтәрде.

Без ике-өч минуттан кытай иероглифлары белән чуарланган мәһабәт бина янында идек. «Кытайга рәхим итегез һәм… төшегез», – диде шофер. Төшкәч тә, уналтыбызны да тезеп бастырып, янә паспортларны карадылар.

Менә сиңа Кытай! Мондый заманча җиһазландырылган, чиста таможняны Урта Азиядә тапмассың. Биредә эшләүчеләр Русиядән килүчеләргә бик игътибарлы. Инглиз яки кытай телләрен яхшы белсәң, «сират күпере»н кичәргә мөмкин. Иң элек инглиз телендә таможняда бирелә торган кәгазьләрне тутырдык. Алдан ук кисәтеп куйдылар: «Хата ясарга ярамый». Шунысы яхшы: монда русча да бераз сукалыйлар икән. Таможня хезмәткәре безгә русча эндәшкәч, күңелләр күтәрелеп китте хәтта.

Минаэзләгечтән «чп»ларсыз чыктык. Алдагы сынауга чират көтәбез. Күз алдында ике кытай туташын тоткарладылар. Аларны бераз читкәрәк бастырып, ак перчатка кигән ике хатын-кыз (таможня хезмәткәрләре) туташларның сумкасын тентеделәр. Бөтен әйберләрен бушаттылар, кытайча кычкырып, нидер эзләделәр. Туташлар елап, шешенеп бетте. Башта бер генә уй: безнең белән дә шулай кылансалар? Кызларны алга таба уздырмадылар, бер почмакта кием тутырып калдылар.

Күзләр таныш хәрефләргә төште. Рус телендә зур итеп «На обратном пути нужно пройти медосмотр» диелгән. Күрәселәр алда икән!

Алдагы имтихан – «Детектор лжи». Тәртип шундый: сорауга дөрес җавап биргәндә елмайган йөз чыга. Дөрес булмаса – бүселгән йөз. Сораулар бик гади: «Исемең ничек? Кайда тудың? Милләтең буенча кем? Кытайга нинди максат белән килдең?»

Детектор каршына килеп баскач, бераз каушатты. Шул каушау аркасында чын туган көнем дә «дөрес түгел» чыкты. Алай да, монда бераз ялганларга да туры килде: журналист булуыбызны әйтмәдем. Кытай татарлары алдан кисәтеп куйган иде. Үзебезне университет аспирантлары, булачак галимнәр дип таныштырдым. Риман абыйны дәрәҗәле профессор, филология фәннәре докторы, дидем. Унлап сорауга җавап биргәч, детектор артында утыручы хезмәткәр: «Мин сезгә ышанам», – диде. Калган өчебезне сорау биреп азапламадылар.

Алга уздык. Өстәл артына «ак перчаткалылар» тезелгән. Болар – сумкаларны тентүчеләр. Чабаталарны сүтеп, курчакларның эчен




чыгармасалар ярар иде… Иң башта шәхси әйберләрне капшадылар. Кытайлар чабатаның нәрсә икәнен аңламады: «Эта куда одевать?», – дип сорадылар. Курчакка тимәделәр. Әмма татар телендәге дискларны, китапларны якыннанрак өйрәнер өчен билгесез җиргә алып киттеләр. Татар телендәге 30 дискны нәрсәләр эшләтеп тыңлаганнардыр, күз алдына китерә алмадык. Әмма Муса Җәлил шигырьләре язылган өч дисктан «җилләр искән иде» – кайтармадылар. Җаваплары гади: «Безнең илгә мондый рухтагы дисклар кертү тыела!». Нинди рухтагы? Аңлашылмады. Татар шагыйренең патриотик шигырьләреннән шикләнделәр булса кирәк. Һәр илнең – үз таләпләре шул. 1 миллиард 300 миллион кешеле ил белән идарә итү өчен нәкъ шундый кырыс таләпләр кирәктер дә. «Сират күпере»н чыкканда бераз чәчләр агарса да, бер нәрсәне аңладык: кытай законнарын бозмасаң, сине беркем дә кулга алмаячак.

Шулай итеп, Кытай таможнясын өч сәгать кичкәнбез. «Ак перчаткалылар» бинасыннан чыккач, күкрәк тутырып, Кытай һавасын суладык. Әмма, иртәрәк сулаганбыз – тимер капкага җиткәч, 21 нче мәртәбә паспортларны тикшерделәр. Фейс-контроль, ягъни мәсәлән.

## Шәркый Төркестан җирендә

*Вакыт-вакыт читтәге татар кешеләренең язмышы миңа күзгә каенлыкта очкан яфракларны хәтерләтә. Берәм-берәм җилбердәгән, куче-куче белән бөтерелгән яфракларны, сибелгән орлыкларны искә төшерә…*

*Миркасыйм Госманов.*

Кытай дигәч, күбегезнең күз алдына, бәлкем, бөек Кытай стенасы килеп басадыр. Без исә карлы кыялары күкләргә җиткән мәһабәт Тянь-Шань тауларын, иксез-чиксез сахралар, ком чүлләрен, шифалы сулыкларны, татлы карбыз-кавын басуларын, тау сыртларында тирмәләрдә яшәүче халыкларны, барыннан да бигрәк Шенҗанда гомер кичерүче татарларны күз алдына китердек…

Кытай халык республикасында бүген 6 меңгә якын татар бар. Шуларның 5500е Кытайның көнбатышында – Шәркый Төркестан җирендә, калганы илнең төньяк-көнчыгыш биләмәсе булган Манчҗуриядә яши.

Атаклы коммунист Мао Цзедун иленә, ят, билгесез җирләргә ничек килеп төпләнгән алар? Дөньядагы иң алдынгы Җоң Хуя илендә (Кытайда яшәүче халыклар үз илен шулай атый) нинди шартларда яшиләр? Патша булыпмы яки кол булыпмы? Бәлки кайберләре Тукай телен онытып, кытайлашып та беткәндер, кем белә. Ә бәлки…

Менә шундый бетмәс-төкәнмәс «бәлки»ләрне «сорау капчыгы»на салып, юлга чыктык. Кытайдагы «татар утраулары»н күрү теләге безне Шенҗанга китерде.

### Ак калфаклы таулар ягы

Кытайның зурлыгын күрәсең килсә – Шенҗанга бар, диләр Кытайда. Борынгы Шәркый Төркестан җирләре хәзер Шенҗан-Уйгыр автоном районы (ШУАР, русчасы СУАР – Синьцзяньско-Уйгурский автономный район) буларак билгеле. Шенҗанның гомуми биләмәсе 1,7 миллион квадрат чакрым. Англия, Италия, Франция, Германия, Греция җирләрен яки БДБ илләрен сыйдырырлык киң дөнья бу. Монголия, Русия, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Әфганстан, Һиндстан, Пакыстан, Кытай провинцияләре Гансу, Цинхай, Тибәт белән чиктәш.

Шенҗан, үз чиратында, мөстәкыйль өлкә-регионнарга бүленә. Менә алар: Алты шәһәр регионы (Кашгар, Яркәнт, Хутән, Өчторфан, Көчар, Аксу шәһәрләре), Торфан-Хами (Кумул төбәге), Алтай өлкәсе, Тарбагатай вилаяте (үзәге – Чүгүчәк шәһәре), Элә вилаяте (башкаласы – Голҗа шәһәре), Өремче. Соңгысы – Шенҗанның башкаласы.

«Тукай фонды»ның сәфәре шушы алты регионның өчесенә, дөресрәге өч регионның мәркәзләре – Өремче, Чүгүчәк, Голҗа шәһәрләренә иде. Күргәннәребез турында алга таба тәфсилләбрәк, «тәмләп» язарбыз әле.

Шенҗан – ак калфаклы таулар ягы. Памир, Күнлун, Тянь-Шань, Алтай тауларының очлаеп киткән түбәләре ел әйләнәсенә ап-ак кар белән күмелеп, горур булып утыра! Бу – бәрәкәтле яшел үзәннәр, кукуруз, дөге, мамык басулары, гаҗәеп оазислар иле!

Шенҗанның бер өлешен данлыклы Такла-Макан чүле били. Анда бер килсәң – кире кайтмыйсың, диләр. Такла-Макан дөньядагы иң зур 7 чүл арасында беренче урында тормаса да, Гарәбстан ярымутравындагы Руб-әл-Хали чүленнән кала дөньяда икенче урынны били. Такла-Макан – көтелмәгән могҗизалар чүле. Галимнәр аның яшерен серләрен әле дә ачып бетерә алмаган. Гидролог галимнәр әйтүенчә, чүлнең җир асты сулары диңгезне хәтерләтә. Әгәр андагы су бөтен чүлне капласа, тирәнлеге 6 метрга җитәчәк!

Такла-Макан чүле көнбатыштан көнчыгышка – 1 мең чакрымга, төньяктан көньякка 500 чакрымга сузылган. Мәйданы – 300 мең квадрат чакрым. Монда, мәсәлән, Австрия, Венгрия һәм Татарстанны сыйдырып булыр иде. Чүлнең тагын бер могҗизасы – Такла-Макан өстеннән 580 чакрымга (иңе – 72-78 метр) сузылган яшелләндерелгән машина юлы. Җир шарында чүлдәге иң озын юлларның берсе икән ул!

Шәркый Төркестанның иң түбән урыны (диңгездән 154 метр түбәнлектә) – борынгы Торфан каласы биләмәләре. Торфан Шенҗанның иң эссе җире, җәй көне кызулык плюс 49,6 градуска җитә. Буякта яңгыр аз ява яисә бөтенләй яумаска да мөмкин. Ә менә Торфанда үскән баллы йөземгә тиңнәр юк! Йөземдәге шикәр матдәсе 22-26 процент (!) тәшкил итә. Кыскасы, Шенҗанның иң коры, иң эссе, иң баллы, иң түбәндә урнашкан борынгы шәһәрен күрәсегез килсә, Торфанга барыгыз!

Шенҗан «Антарктидасы» Алтай тавы янындагы Көктогәй җирлегендә урнашкан. Мондагы температура минус 51 градуска кадәр төшә икән.

Шенҗан җире файдалы казылмаларга бик бай. 1999 нчы елда табыла башлаган алтын 210 мең тоннага җиткән. Тянь-Шань тавыннан 69 төрле кыйммәтле ташлар – алмаз, сапфир, рубин, малахит, фирүзә, ахак, аквамарин, песи күзе (кошачий глаз), якут табылган. Шәркый Төркестанның Хотән вилаятендә елына 120-150 тонна нефрит табыла икән.

Кытайның мул уңыш бирә торган мамык плантацияләре дә ШУАРда урнашкан. Шенҗан мамыгы сыйфаты ягыннан Каһирәнекеннән бер дә калышмый.

Мондый һава шартларында йөзем, гранат, инҗир, өрек кебек нинди генә оҗмах җимешләре үсми! Кытайда үсә торган йөземнең өчтән бере дә – Шенҗанда.

Ай-һай! Татлыдыр Шенҗан җимешләре. Барасы-күрәсе җирләребезне әнә шулай күңелдән үткәреп, Хоргос шәһәренә чыга торган тимер капка янында дулкынланып торганда милли бизәкле күркәм түбәтәй кигән берәү дәште: «Сез Казаннан бит! Хуш килдегез, туганкайлар! Казан татарлары әллә кайдан күренеп тора».

**Рәмилә Газизуллина**

# Хоргоста беренче чәчәкләр!

Кытайның Голҗа шәһәреннән килгән Татар җәмгыяте вәкилләре – җәмгыять рәисе Рифкать Галимов, Торсынтай Галиев, Гыйззәтулла Хәсәновларны күргәч, чит язулы Кытай каласында якын туганнарыбызны очраткандай булдык. Барысы да милли түбәтәйләрдән, кулларында – чәчәк бәйләме…

Без аяк баскан Хоргос шәһәре 100 еллык тарихка ия. Бөек ефәк юлының бер ноктасы ул. Биредә берничә кунакханә, бер парк, дистәләгән дөңгән һәм уйгыр ашханәләре, автовокзал бар. Әлбәттә, шәһәрчекнең иң төп «бизәге» – ул чик. Татарларның сүзләренә караганда, бирегә хәтта Кытайның ерак почмакларында яшәүче кытайлар махсус автобусларда чик фонында фотосурәткә төшәргә килә икән. Монда ыгы-зыгы: чик төбендә үк туристларны «кара халык» сырып ала. Таксистлар икән. Безне җәлеп итәр өчен ни генә эшләмәделәр! Кытайча, уйгырча эндәшеп карагач, ахыр чиктә урысча сукаларга тотындылар. Милләттәшләребез: «Болар безнең кунаклар!», – дигәч кенә, безгә юл бирделәр.

Кытайдагы санаулы ун көнебезгә милләттәшләребез план да төзеп куйган. «Өч көн Өремче шәһәрендә булсагыз, өч көн – Чүгәчәктә, дүрт көнегез Голҗада узачак. Әлеге шәһәрләр – Шенҗанның «татар утраулары», – дип, безне таксида Өремче шәһәренә озаттылар.



**Безне Кытайның Голҗа шәһәреннән Татар җәмгыяте вәкилләре: Рифкать Галимов, Торсынтай Галиев, Гыйззәтулла Хәсәновлар каршы алды**

## Тәңре тау хикмәтләре

Кузгалдык! Алда – Тянь-Шань тавыннан бара торган 9 сәгатьлек юл. Таксистыбыз уйгыр егете икән. Телләребез охшаш булгач, аның белән тиз аңлаштык.

Кытай Русия түгел инде. Озын, киң юллар! Кытайлар, урынны буш тормасын диптер инде, юл тирәләрендә татлы борыч, кукуруз чәкәннәре киптерәләр. Юл системасы бик тә кызык монда, ә заправкага туктау үзе бер кәмит. Машина «сыйланган» арада пассажирларны урамда көттерәләр. Русиядән икәнебез әллә кайдан күренеп тора, ахрысы. Яныбызда торган кешеләр бездән күзләрен дә алмый. Иң кызыгы, биредә бәдрәф эзләп йөрүче кеше юк. «Йомыш»ларын юл читендә генә үтиләр.

Данлыклы Тянь-Шань тавын күрергә хыялланган идек, баһадир тау өстенә машинада бер сәгать менәргә туры килде. Элегрәк тау тирәләрендә яшәүче халыклар аны «Тәңре тау», ягъни «Рухлар тавы» дип йөрткән.

Тянь-Шань элеккеге Советлар Союзының иң тылсымлы һәм үзенә тартып тора торган җиредер, мөгаен. Серле тауның киңлеге 800 чакрым булса, озынлыгы 2 мең 800 чакрым. Шуның 1500 чакрымы Кытай



биләмәсенә керә. Машинада әлеге котчыкмалы биек таулар арасында барганда, куркып каласың. Өстеңә җимерелеп төшәр сыман… Ярты сәгатьләп таудан баргач, юл ясаучы зур-зур машиналар пәйда булды. Кытайлар киләчәктә Тянь-Шань тавын тишеп, зур автомагистраль төземәкчеләр.

Шулай тау өстеннән салмак кына барганда, зәп-зәңгәр төстәге күл үзенә җәлеп итте.

– Бу нинди күл? – дип сорадык уйгыр таксистыннан.

– Сайрам-Нур…

Сайрам-Нур Шенҗан-Уйгыр автоном районының биек тавында урнашкан иң эре күл санала икән. Түзмәдек, күл һавасын суларга теләп, тәрәзәләрне ачтык. Сайрам – кытай галимнәре өчен һаман да табышмак булып кала бирә. Мең ел буена суның күләме, күлнең чикләре бер дә үзгәрмәгән. Бер кеше дә, бер көймә дә Сайрамны кичеп чыга алмаган. Күл уртасында көчле агымнар бар икән, монда эләккән бер кеше дә исән кала алмый, имеш. Шушы серле күл ярында тирмәләр тезелеп киткән. Биредә казакълар һәм кыргызлар яшәп ята. Таксист сүзләренә караганда, алар туристларны кунак итеп акча эшли икән. Кайнар чәй, бешбармак, атларда, дөяләрдә йөрү – җаның ни тели, рәхим ит! Акчаң гына булсын.



Өремчегә 100 чакрым кала, Тәңре тауның иң матур урынына килеп чыгасың. Биредә Тянь-Шань «энҗесе» – Тяньчи күле сыенган. Тяньчи «күк көзгесе, изге күл» дигәнне аңлата. Риваятьләргә ышансаң, бу күлдә Сиванму алиһәсе госел коена торган булган. Тяньчи кечкенә күл түгел, буйга – 3,3, иңгә 1,5 чакрым. Тирәнлеге – 150 метрга җитә икән. Изге күл буйларыннан диңгез өсте тигезлегеннән 1900 метрга калыккан мәһабәт Богто пигы күренә. Тяньчи «көзгесе»ндә аның очлаеп киткән карлы бүрекләре ялтырый.

Уйгыр егете шәһәргә якынлашканны искәртте. Ерактан ак тапларны хәтерләткән тирмәләр янында бала-чагаларның куышлы уйнаганы, тау култыкларында куй, сыер көтүләре күренде. «Бу җирләрдән ерак түгел, әкәмәт зур динозаврлар паркы бар, – диде шоферыбыз. – Өремченең бөтен баласы шунда күңел ача. Һәм иң кызыгы – паркка керү бушлай». Тау хәтле чып-чын динозаврлар, диме?! Алар үлеп бетмәделәр мени әле?..

**Альбина Газизуллина**

## • ӨРЕМЧЕ



# Өремче – Гиннес китабында!

*Ул өйләрнең биеклеге! Чорт белә:*
*күгең кайда да, кояшың кайда?!*
*Г. Тукай, «Мәкаләи махсуса», 1913*

Кичке сәгать тугызлар тирәсендә Кытайның Көнбатыш провинциясенә кердек. Борынгы монгол телендә «өремче», «җунгар» сүзләре гәҗәеп матур болынлык, көтүлек, яшел дала дигәнне аңлата. Өремче шәһәре Тянь-Шань тавының төньягында, Җунгар иңкүлегендә урнашкан. Шәһәрне еш кына Җунгария дип атаулары шуңа бәйле, күрәсең.

Өремче XIX гасыр ахырында Шенҗан-Уйгыр автоном районының башкаласына әверелә. Ул вакытта шәһәр Дихуа (кытайчадан тәрҗемә иткәндә «мәгърифәт») дип йөртелә торган була. Өремче – Шенҗанның башкаласы, икътисад, сәнәгать, сәясәт һәм мәдәният үзәге. Ул дөньяда диңгездән иң ерак урнашкан (2500 км) зур шәһәр буларак Гиннеслар китабына кертелгән. Биредә 2,2 миллион кеше яши. Әгәр дә Өремче элегрәк кечкенә генә уйгырлар бистәсе булса, хәзер кытайлар мегаполисы. Кытайлар халыкның 75 процентын (1 млн. 567 мең) тәшкил итсә, уйгырлар 13 процентын (266 мең) гына. Барлыгы 45 милләт, ә татарлар меңгә якын.

Соңгы 8-10 ел эчендә шәһәр танымаслык булып үзгәргән. Иске биналар сүтелеп, алар урынына 22-28 катлы йортлар калыккан. Шәһәрдә нефть, текстиль, металлургия сәнәгате алга киткән. Өремче телерадиокомпаниясе дә заманча технологияләр белән эш итә. Монда рәхәтләнеп кытай, уйгыр, казакъ, монгол, рус һәм башка телләрдә милли тапшырулар карарга мөмкин. Өремчедә Кытайның җилдән энергия алу үзәге бар. Җил тегерменнәре шәһәрдән читтәрәк, 60-80 чакрымда урнашкан. Шәһәр аша Алматы-Пекин тимер юлы уза.

Кунакханәдә безне Өремчедә яшәүче татарлар – Илморат Шәриф, Малик Чанышев, Абдулла Аббас, Малик Вәлиев һ.б. каршы алды.

Сөйләшә-сөйләшә кафега таба барабыз. Ни гаҗәп, ярты сүзләрен аңламыйбыз. Әйтүе дә уңайсыз. Аңламаганыбызны сизделәр ахры. Малик Чанышев:

– Безнең татар телебез төрки телләр белән буталып беткән инде. Күбрәк казакъча һәм уйгырча сөйләшәбез. Аңлашылмаса, сорагыз, яме? – диде.




**Буддачылар чиркәве**

Шенҗанда төп ризыклар – пылау белән шашлык, дигәннәр иде. Шулай икән. Өстәлгә тиз арада пылау менеп «кунаклады». Аралашып, тамак ялгагач, янәдән кунакханәгә киттек. Иртәгә безне данлыклы Җунгария буенча мавыктыргыч сәяхәт көтә иде…

## Кызыл тау

Шәһәр белән безне «Алтын чишмә» дигән сәүдә оешмасы җитәкчесе, эшмәкәр Ришат Муллашев таныштырды. Беренче тукталышыбыз – Кызыл тау паркы булды. Ул шәһәрнең үзәгендә урнашкан, мондый исем тау башындагы кызыл ташлар өчен бирелгән. Тауның иң биек ноктасы – 910 метр. Ришат абый фикеренчә, Цин династиясе вакытында (1644-1911) биредә почта бүлеге бинасы урнашкан булган. Кытай Халык Республикасы оешкач, 10,5 метрлы манара һәм павильон төзегәннәр.

Кызыл тау – Өремче шәһәренең төп символы. Аннан бөтен шәһәр белән хозурланып була. Тау астында алтын балыклы матур сулыклар, кешеләр табигать могҗизасы белән хозурланып, катамараннарда


**Чиркәү эчендә тезелеп киткән сыннарны күргәч, гаҗәпләнеп калдык**

йөри. Берсеннән – берсе киң, чиста юллар, биек йортлар, ерактан ук шәһәр уртасында ялтырап ятучы бассейн – боларның барысын да Өремчедә генә күреп буладыр!

Дацанга, ягъни без моңарчы һинд киноларында гына күргән буддистлар чиркәвенә якынлашабыз. Өч яруслы дацанга керү 5 юань тора. Төрле бизәкләр белән, катлы-катлы итеп эшләнгән әлеге бинаны төзергә бик күп вакыт киткәндер. Эчкә керү белән йөрәкләр жу итеп куя: дистәләгән «Аллалар» тезелеп киткән. Бер почмакта таякчыклар сатыла. Шуңа ут төртеп, яраткан «Аллаң» янына иелеп, теләкләреңне телисең.

## Тау кешеләре

Алатау итәгендә аерым бер дәүләт булып, тирмәләрдә казакълар яшәп ята. Алар белән танышу иде ниятебез.

Безне бер көтү бала белән Җанбәк исемле бабай каршы алды. «Хуш килдегез!», – диде ул якын туганнарын кабул иткәндәй. Тирмәләр янында мал-туарлары (сарыклар, ишәкләр, атлар) йөри. Балаларның бер өлеше мәш килеп атта чаба. Кыргый түгел үзләре, безне күрү белән



дә атларында чаптырып яныбызга килделәр. Тау һавасы, үлән, агач исе… Нинди гүзәллек!

– Кыргый табигать кочагында ничек яшисез? Куркытмыймы? – дип сорыйм Җанбәк бабайдан.

– Гомерем буена далада яшим. Миңа монда рәхәт! Оныкларым якында гына урнашкан Кытай мәктәбенә укырга йөри. Балалар кеч-кенәдән атта чабып, чын тормыш мәктәбе уза. Нәрсәдән куркырга?! Әнә, этебез утыра. Берсенә дә комачауламыйбыз. Безгә дә бәйләнмиләр.

– Казакъстанга кайтыр идегезме?

– Мин Кытайда туганмын, Кытайда үләрмен инде. Кайтсам, бөтен туганнарым белән күченер идем. Алар монда, тау артында гына гомер кичерә. Казакъстанда хәзер тормышлар яхшырды. Президент Назарбаевны бик хөрмәт итәм, казакълар өчен барысын да эшли ул.

– Тормышыгызны үзгәртеп, цивилизацияле йортта яшәр иде-гезме?

– Безгә монда – далада яшәве рәхәт. Хуҗалыкны алып барырга да бик уңайлы. Моннан китсәм, атлар, сарыклар, ишәкләремне кайда куярмын? – ди бабай.



**Киң күңелле Җанбәк бабай белән**

Хәер, дөньяның кайсы почмагында да казакъ «җир, тау, дала кешесе» булып кала инде ул! Җанбәк бабай шуның белән бәхетле дә.

Казакълар: «Әйдәгез, калыгыз, бер куй суеп ашарбыз. Кунак булырсыз!», – дип бик каты кыстасалар да, вакытыбыз чикле булу сәбәпле кунып маташмадык. Мондый экзотик шартларда яшәүне киләсе очракка калдырдык.

## Мәчетләр мәркәзе

Өремче безне иман йортларының күплеге белән дә хәйран калдырды. Кытайда барлыгы 48 мең мәчет булса, Өремчедә аларның саны 1500дән артып китә! Машинада җилдергәндә мәчет санап, хәлдән тайдык. Монда хәтта бер урамда 30-50ләп иман йортын очратырга була!

Мәчетләргә татарлар, уйгырлар, кытай мөселманнары – дөңгәннәр йөри икән.

Кытайда мөселман хатын-кызларына мәчетләргә керү тыелган. Без исә, рөхсәт сорап, Өремченең берничә мәчетенә сәдака биреп чыктык.





**Хәзер Нугай мәчете саналса да, аны элекке исеме белән «Татар мәчете» дип йөртәләр**

Өремче мәчетләренең үзенчәлеге шунда, аларның шактые күпкатлы йортларның бер фатирында урнашканнар. Урамда барганда бер яки берничә манара күреп алсаң, димәк, анда иман йорты бар дигән сүз. Кайбер мәчетләр бездәге кебек үзенә күрә бер зәвык белән төзелгән. Казакъстандагы кебек гөмбәзле мәчетләрне дә очратырга мөмкин.

Нугай мәчетенә аерым тукталып китик. Ул XIX гасырда барып төпләнгән татарларның истәлеген мәңгеләштереп торучы бердәнбер сакланып калган бина. Халык телендә һаман да «Татар мәчете» дип йөртелә һәм моңа нигез дә бар: биредә Татарстанның



Апас районы Урта Балтай авылыннан килгән Шакир хәзрәт 30 ел мулла булып торган. Мәчетнең өске өлеше татар архитектурасы үрнәгендә ясалган, манара очында – ярымай. Әлеге манараны «айны күзәтү манарасы» дип атыйлар икән. Бина ислам кануннары буенча төзелгән. Хайван рәсемнәре төшерелмәгән, алар урынына мәчетне төрле чәчәк рәсемнәре бизәп тора. Әлеге мәчет Өремчедә яшәүче уйгырларның, казакъларның, татарларның һәм үзбәкләрнең төп дин йорты булып тора.

Зур Көнчыгыш мәчете үзенең гаҗәеп архитектурасы белән аерылып тора. Ул дәүләт карамагында булган төп мәдәни ядкарь санала. Цинь династиясе вакытында төзелеп, 1906 нчы елда өр-яңадан торгызылган. Кызыл төстәге кырык колонна белән ясалган әлеге йорт – иң матур архитектура һәйкәле! Тагын бер могҗиза – арка астында «Ак Коръән» киселеп бизәлгән. «Ай павильоны» дигән урын да игътибарны җәлеп итә. Бу имамның ай чыкканын күзәтеп, азан әйтә торган урыны. Сигез почмаклы мондый павильонны Шенҗанның башка бер җирендә дә очратмассыз!

## Ике көнлек Хуалин

*Иртә белән кайнамакта ул базар,*
*Анда да монда кызадыр сәүдәләр.*
*Г. Тукай, «Кисекбаш»*

Өремче – Кытайның иң эре сәүдә үзәкләреннән санала. Кытай базарлары дию кебек: бер «кабып йотса» – чыга алмыйсың! Монда, әти белән әниеңнән кала, дөньядагы бөтен кирәк-яракларны табарга мөмкин. Базарлар – муеннан: Бәнҗан, Компьютер, Тун Фан, Локомотив, Хуалин, Шао Мо Чин, Та Симер, Сяо Симер… Шуларның иң «текәләре» – Үзәк базар һәм Хуалин.

Үзәк базар – Шенҗанда яшәүче милләтләрнең гореф-гадәтләрен күрсәтүче иң зур базар. Аның мәйданы – 1 миллион квадрат метр. Биредә данлыклы Хами кавыннарын, Торфан йөземнәрен, Кашгар гранатларын, Голҗа алмаларын, хәтта тимер кадакны да кисә алган Кашгар пычакларын, Янгисәр шәһәре кылычларын, кулдан эшләнгән түбәтәйләрне, милли киемнәрне, чын ефәк яулыкларны сатып алырга мөмкин. Күз алдында әзерләнгән милли ризыкларны шунда ук кафеда утырып ашарга була. Канатларда йөрүче артистларның чыгышлары, милли ансамбльләрнең биюләре – боларның барысы да бар монда!









Хуалин – илнең иң кыйммәтле, танылган базары. Аны ике көндә дә әйләнеп чыкмалы түгел, диләр. Базар каршына килеп туктау белән өч телдә язылган игъланнарга игътибар иттек. Кытай һәм уйгыр сүзләре янәшәсендә урыс хәрефләре белән зур итеп «Хуалин базары» дип язып куйганнар. Ул 1988 нче елны төзелгән. Биредә Мао Цзедун статуяларыннан башлап, кием-салым, җаның теләгән чәчәкләрне, үсемлекләрне, хәтта тере экзотик хайваннарны сатып алырга мөмкин.

Сатулаша белмәсәң, кытай базарында йөрмәвең хәерлерәк икән. Ә кытайча яхшы сатулашсаң, дөя бәясе торган куянны да чеби хакыннан алырсың, валлаһи! Әмма, Кытайның бөтен яме чуты булмаган базарлар, алыш-биреш, акча-макча, зур сәүдәләр генә түгел. Кытай – ул тырыш, хезмәт сөючән, ару-талуны белмәс халкы белән данлыклы ил. Бик күп мөмкинлекләр, фәнни ачышлар, заманча технологияләр, кешелек дөньясы чишеп өлгермәгән могҗизалар иле бу! Анда баргач, күп нәрсәләр турында уйлана башлыйсың: туган ил, хезмәт, илнең үсү мөмкинлекләре… Бөтен нәрсәне бизмәнгә салып үлчәгәч, нишләп без артта да, кытайлар алда, дип куясың.

## Татар учагы

*Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул…*
*Г. Тукай, «Даһигә», 1913*

Өремчегә татарлар 1881 нче елдан күченеп килә башлый. Кызганыч, аларның эзен саклап калган биналардан, әйткәнемчә, Татар мәчете генә калган. Аның Татар бистәсендәге Казан урамында урнашуы, әлбәттә, заманында бистәдә татарларның күпләп яшәгәнлеге турында сөйли. Шунда ук Татар базары гөрләгән, татар мәктәбе һәм клублары эшләгән…

Өремче татарлары безне әби-бабалары тарихын яхшы белүләре, ыгы-зыгылы кытай каласында «татар учагын» буыннан-буынга сүндермичә яшәүләре белән таң калдырды. Малик Чанышев – шушы «татар учагын» кабызып җибәрүчеләрнең берсе, Кытайда милләтебез тарихын, мәдәниятын, язма мирасын өйрәнүче бердәнбер татар галиме. Өремче шәһәре автоном районының милли эшләр комитетында борынгы истәлекләрне өйрәнү бүлегендә эшли. «Кытайда татар мәгарифе тарихы» дигән китап чыгарган. Ул 2000 нче елда Өремче шәһәрендә уйгыр телендә нәшер ителсә, 2005 нче елда кытайчага тәрҗемә ителеп, Пекинда басылган. Һәм, ниһаять, Казанда татар телендә аерым бер басма булып 2007 нче елда дөнья күргән.

– Кытайда яшәүче татарлар турында китап чыгару – күптәнге хыялым иде. 1984 нче елны татарларның кыскача тарихын язу өчен Голҗа каласына бардым. Монда үзбәкләрнең атаклы шагыйре Нәсрулла Пәргатигә юлыктым. Татарлар турында сөйләшкәндә, ул: «Без – үзбәк шагыйрьләре, Габдулла Тукай иҗаты белән танышкач, сәяси лириканы аңлап шигырьләр яза башладык», – диде. Шулай ук эзләнү өчен Чучуң өязенә, Элә, Тарбагатай һәм Алтай вилаятьләренә бардым, халыктан сорашып беренче кулъязма материаллар туплап кайттым, – диде ул.

Малик абый шактый кызыклы мәгълүматлар белән уртаклашты.

1900 нче елның башында Өремчедәге татарлар саны шактый арта. Шуңа күрә балаларга белем бирү өчен мәктәп төзү ихтыяҗы туа һәм шәһәрнең хәлле кешеләре бер кешенең йортын мәктәп өчен бирә. Бина 1912 нче елның көзендә ачылгач, Казаннан махсус килгән Зиннәтулла исемле кеше балалар укыта башлый. 1915 нче елны кызларны укытырга мөгаллимә кирәк булгач, Зиннәтулла әфәндене Өремче татарлары Казанга җибәрә. Ул исә яңа гына педагогика институтын тәмамлаган татар кызы Мәрьям Җегетбаевага өйләнеп, аны Өремчегә алып кайта. 1916 нчы елда кызлар мәктәбенең беренче сыйныфында барлыгы 48 бала: татар, уйгыр, үзбәк, казакъ кызлары белем ала башлый. Дәресләр бирүдән



**Сулдан – Малик Чанышев, Мусаҗан Газиз**

тыш, аларны тегү, чигү кебек кул эшләренә дә өйрәтәләр. 1920 нче елда Борһан Шаһиди, Закир Абдишев, Хәсән Шакуловларның тырышлыгы нәтиҗәсендә мәктәп зурайтыла, китапханә булдырыла. Ул башлангычтан урта мәктәп дәрәҗәсенә күтәрелә. Тора-бара рус һәм кытай теле дәресләре дә укытыла башлый. Моның өчен милләттәшләребез Хисам Бавин, Хәйдәр Сайрани, Гали Ибраһим зур көч куя. Татар мәктәбендә укытучылар әзерли торган курслар ачылгач, бирегә тауларда яшәүче казакъ балалары да йөри башлый. Алар укуларын тәмамлагач, туган җирләрендә мәктәп ачып казакъ балаларын укытканнар. Шулай итеп, казакъ мәгарифенә дә нигез салына.

Малик Чанышев безнең нинди ният белән килүебезне белгәч, тыела алмыйча елап җибәрде. Татар телен камил белүен ул кечкенәдән Габдулла Тукайны укып үсүе, гаиләдә фәкать татар телендә аралашуы белән бәйләде. Әнисе Мөнәвәр Кәрим кызы Чанышева Өремчедә ачылган татар мәктәбендә укыган. 30 нчы елларда гимназияне тәмамлагач, татар мәктәбендә дин һәм кытай теле дәресләре укыткан. Галимнең апасы Гайшә Чанышева да Тукай иҗатына битараф булмаган. Ул да татар мәктәбендә укыган.

«Сигез-тугыз яшьләрдә әнинең Г. Тукай әсәрләрен укуы истә калган. Ул безгә «Эшкә өндәү», «Туган тел» шигырьләрен, «Шүрәле» поэмасын укый иде. Авыр көннәрдә ачлы-туклы яшәгәндә Тукай шигырьләре бердәнбер юаныч иде», – ди галим.

Малик Чанышевның Тукай белән бәйле һәр яңалыктан хәбәрдар булуына, шагыйрьнең һәр китабын тарихи ядкарь итеп, кадерләп саклавына сокландык без. Галим безгә 1966 нчы елда бөек шагыйребезнең китаплары югалып торуын, 1980 нче елда Абдулла Имин исемле уйгыр журналистының үзенә 1914 нче елда чыккан Тукай китабын бүләк итүен сөйләде. Гаҗәп бит, ә: уйгырлар Тукайны хөрмәт итеп, китабын саклап калганнар! Сүз уңаеннан, Казанда яшәүче бер татар агаеның көлемсерәп: «Сез Тукайны идеаллаштырып бетерәсез инде», – дигән сүзләре искә төште әле. Белмим, миңа калса, без үз Тукаебызны идеаллаштырудан куркабызмы, әллә оялабызмы шунда. Уйгыр язучылары Сәләй Аңка, Хәмит Төхфи, Ибраһим Мутигыйлар, үзбәк, казакъ, кыргыз әдипләре дә Тукай иҗатын Коръән сүрәседәй кадерли. Ә без – оялабыз…

Малик Чанышев белән сөйләшкәннәрне уйлап утырам да, татарның аның кебек тугъры уллары булганда Кытайдагы «татар учагы» сүнмәс, дип күңелемне юатам.

## «Татарга хезмәт ит, улым!»

Эшмәкәр Ришат Муллашев татарлар өчен җан атып тора, милли чараларга акча кызганмый. Татар халык җырларына мөкиббән киткән кеше ул. Хәтта машинасында барганда да татар көенә кушылып үзе дә җырлап җибәрә. Ирексездән үзеңне Кытайда түгел, татар илендә дип хис итәсең! «Әйдәгез, җырлап күрсәтегез инде. Казан татарларының җырлаганын бик тә тыңлыйсы килә», – дигәч, дискны сүндереп, җырларга туры килде. «Ай, былбылым», «Эх, сез матур кызлар», «Җидегән чишмә», «Яратыгыз», «Зәңгәр күлмәк» – бер җырланмаган җыр калмады. Иң сокландырганы, Ришат абый күп җырларның сүзләрен белә, безгә кушылып җырлый.

Хәер, моңа аптырыйсы юк, әби-бабалары – Казан татарлары. Кечкенәдән милли тәрбия алган, татар халык җырларын тыңлап үскән милләттәшем «Казан тамырлары» белән кызыксынуын, бабаларының сәүдәгәр булганын әйтте. Ришат абыйның Галиәхмәт исемле ерак бабасы (бабасының бабасы) Кытайга 1918 нче елда күченеп килгән. «Ул бик тә акыллы кеше булган. Әти-әни сөйләвенчә, кытай юаньнарынә язу язган, бабамның шәхси алтын порошогы да булган», – ди әңгәмәдәшебез.





**Татар өчен җан атучы Ришат Муллашев**

Нәселдән килгән сәүдәгәрлек иртәме-соңмы үзенекен итә. Ришат абый 16 ел үпкә авырулары табибы булып эшләгәннән соң, сәүдә белән шөгыльләнергә ниятли. Яңа эш башлар алдыннан, иң беренче итеп, әтисеннән хәер-фатыйха сорый. Зирәк әтисе улының хезмәтен хуплап: «Татар өчен эшлә, улым. Татарга хезмәт ит», – ди…

2004 нче елда Ришат абый ике татар егете – Равил Вәлиев, Нигъмәт Абдулказыр белән «Алтын чишмә» дигән сәүдә оешмасы төзи. Бүген алар Кытайның иң яхшы тауарларын Русиягә чыгару белән мәшгуль. Нигә «Алтын чишмә»ме? Ришат абый болай аңлатты. Алтын – зиннәтле, кыйммәтле металл, ә чишмә – яшәү, тереклек символы. Шуңа күрә сәүдә ширкәте оештырганда, әлләни озак баш ватырга туры килми.

Ришат Муллашев кына түгел, Кытайда бик күп татар сәүдәгәрләре бизнесларын «татарлаштырырга» омтыла. Аларның максаты да изге: сәүдә аша халкыбызны бөтен дөньяга таныту.

Ришат Муллашев Казанда 1993 нче елны булган. «Казан бик матур шәһәр! Татар телендә сөйләшмәүләре генә борчуга салды. Ул вакытта татар кызы белән танышмамын микән дип барган идем. Очрамады. Хәзер өйләндем инде», – диде ул елмаеп.

# Мәгърифәт сагында

*Укымак – үткәннәрдән кичеп, якты киләчәкләр тугърысында пәйгамбәрлек итмәк.*
*Г. Тукай, «Хиссияте миллия», 1913*

## Шенҗан университеты

Өремче шәһәренең Шенҗан университетында алты татар профессоры укытканын белгәч, шунда бардык. Аңа Кытай Халык Республикасының Пекин, Цинхуа, Тянцзин университетлары кебек дәрәҗәле уку йортлары даими ярдәм күрсәтә. Хәзерге вакытта университет 23 институттан, 8 тикшеренү, 4 белем бирү үзәгеннән тора. Биредә 74 һөнәр буенча укыталар, 30 мең студент белем эсти. Шулар арасында 350се чит ил студенты.

Кытай уку йортлары, шул исәптән, Шенҗан университеты да аерым бер шәһәрчек кебек. Уку биналары, китапханә, студентлар тулай тораклары, укытучылар яши торган йортлар, кибет-ашханәләр – барысы да бер ишегалдында. Моның уңайлыклары да күп. Укырга, эшкә





**Шенҗан университеты янында**



**Өремче галимнәре белән очрашу**

барганда беркайчан да соңга калмыйсың, кичкә хәтле китапханәдә утыра аласың. Университет алдындагы фонтаннар, аллы-гөлле чәчәк түтәлләре студентларның кәефен күтәреп, тирә-юньгә ямь өстәп тора.

Шенҗанда доцент һәм профессор дәрәҗәләре алган 80 татар зыялысы барлыгын белгәч, аларның кайберләре белән очрашасы килде. Ярый әле берәнләп дигәндәй эзләп йөрисе булмады: алар безне үзләре ресторанга кичке ашка дәштеләр һәм чәй артында гәпләшеп утырдык.

## «Татар теле – әнием кебек»

Биология фәннәре докторы, Кытай җыены депутаты Абдулла Аббас данлыклы Шенҗан университетында укыта. 1995 нче елда профессор дәрәҗәсенә ирешкән. 56 аспирант тәрбияләгән, шуларның уналтысы докторлык диссертациясе яклаган. 105ләп фәнни мәкалә авторы. Полиглот. Татар теленнән тыш, кытай, инглиз, уйгыр, кыргыз, казакъ телләрен камил белә.

Беренче карашка, мондый дәрәҗәле профессор янында югалып каласың, әмма Абдулла әфәнде бик тә мөлаем, гади кеше булып чыкты. Безнең белән ачылып сөйләште.

Аның мөһим тикшеренүләре нәтиҗәсендә Кытайда мүкнең яңа 48 төре, Шенҗанда 208 төре булуы ачыкланган! «Татарстанның табигате гаҗәеп! Андагы үсемлекләрне өйрәнеп, китап язу – минем иң зур хыялым», – ди профессор.

Галим инде 18 илнең университетында үз тәҗрибәсе белән уртаклашкан. Бигрәк тә Гарвард һәм Казан (Идел буе федераль) университетларында лекция укуын аеруча сагынып искә ала ул.

– Сез Казанда дәресләр бирергә кай арада өлгердегез? – дим.

– Берничә ел элек биология фәне буенча укытырга чакырдылар. Бу минем өчен зур шатлык иде. Лекцияләремне татар телендә укыдым, тәрҗемәче рус теленә тәрҗемә итте. Тагын чакырсалар, һичшиксез, барыр идем, – диде ул.

Абдулла Аббас тумышы белән – Өремче шәһәреннән. Нәсел тамырлары – Башкортстан белән Татарстанга барып тоташа. Әтисе Әхмәтзыя Аббас – Башкортстанның Борай авылыннан, әнисе Мәгърифә Сафина – Кукмараның Арпаяз авылыннан. Аббаслар милли җанлы җиде малай һәм ике кыз тәрбияләп үстергәннәр.

Абдулла әфәнденең хатыны Гадәләт уйгыр милләтеннән булса да, бердәнбер уллары Гадел ике телне дә камил белә икән. Милләт



Профессор Абдулла Аббас үзенең шәкертләре белән



турында сөйләгәндә: «Мин әниемне яраткан кебек – татар телен дә бик каты яратам», – дип кат-кат әйтте профессор.

Абдулла әфәнде әле милли ризыклар пешерүгә дә бик хирыс кеше. Университет шәкертләренә дә бик күп төрле тәмле камыр ризыклары әзерләргә өйрәткән ул. 1990 нчы елда казакъ һәм уйгыр телләрендә 39 мең тираж белән «Гаиләдә прәннек пешерү технологиясе» дигән китап та бастырып чыгарган. Үзенчәлекле хезмәтнең күп өлешен татар милли ризыклары алып тора.

Абдулла әфәнденең иң зур хыялы – Татарстанга күченеп кайту икән.

– Мин Казанда югалып калмас идем. Университетта биология фәнен укытудан тыш, милли ризыклар турындагы китабымны татар телендә нәшер итәр идем. Аннан, Татарстанда бик күп файдалы үсемлекләр үсә бит. Шуларны фотога төшереп, менә дигән җыентык чыгарыр идем… – дип, күңелендәге якты хыяллары белән уртаклашты ул.

## Берсе – адвокат, икенчесе – географ…

Очрашуга килгән икенче галимебез Алим Сәйфуллин да Шенҗан университетында укыта, канун факультетының мөдир урынбасары, җинаять эшләре кафедрасы мөдире. Шенҗан университетында укытудан тыш, адвокатлык хезмәтен дә башкара.

Нурбай Абдусалих та Шенҗан университеты галиме. Болгар, серб, төрек, кытай, уйгыр телләрен яхшы белә, русча, татарча «сукалый». «Үсемлекләр географиясе», «Көнбатыш икътисад белеме», «Сәяхәттә рус теле», «Шенҗан университетлары географиясе», «Биохимиядә тикшеренү ысулы һәм рус теле» кебек дәресләр алып бару өстенә гыйльми эзләнүләр белән дә шөгыльләнә.

Язмыш җилләре татарны кая гына илтеп ташласа да, кадерсезгә әйләнмәгән ул. Безнең белән бер өстәл артында чүкердәшеп утырган милләттәшләребезне генә әйтәм әле: Кытай җәмгыятендә дә үзләренә абруйлы урын алып, дәрәҗәләрне белеп яшиләр. Бары тик «бабам Казаннан», «…бабам Татарстаннан» дигәндә генә йөзләре моңсулана, күзләре яшьләнә.

Әнә, зоотехния галиме, профессор Әнвәр Шәриф тә: «Олы әтием (бабасы – *А.Г.*) Рөстәм Шәриф Татарстаннан иде, монда 1918 нче елда килеп, мөгаллимлек иткән. Сезне күргәч, туган нигезгә кайткан кебек булдык», – дип куйды.

Компьютерлар галиме Каһарман Хәким дә: «Бабам Шәяхмәт Казаннан килгән», – ди.



**Тукай туганы булгангадырмы, фонд җитәкчесенең галимнәр арасында абруе тагын да артты**

Күзләрен мөлдерәтеп безгә карап-карап алулары, «без дә сезнең кебек үк Казан, Татарстан кешеләре бит инде» дигәнгә ишарә кебек иде. Әлбәттә, шулай, кардәшләребез, без – бер нигездән, бер тамырдан. Аермабыз, бәлки, шунда гынадыр: сезнең үзәгегез ныграк, Татарстанның кайбер татарларына караганда, күңелегезне корсак кайгысы түгел, ә милләт кайгысы күбрәк били кебек тоелды.

**Альбина Газизуллина**

# Тукай белән Шаһиди таныш булганнармы?

Кытайда яшәүче милләттәшләребезнең үзләрен «татар» итеп тоеп, чын күңелдән горурланып яшәүләре сүзләреннән дә, кылган гамәлләреннән дә һәрчак сизелеп тора. Без булган шәһәрләрдә: «Казан татары Борһан Шаһиди Мао Цзедунның киңәшчесе булган», – дигән сүзләр еш ишетелә иде. Әлеге шәхеснең тормыш юлы, Кытай дәүләтендә күренекле җәмәгать эшлеклесе буларак башкарган эшләре турында мәгълүматлар бик каршылыклы. Бәлки шуңадыр да, кардәшләребез дә безгә Борһан Шаһиди турында артык җәелеп сөйләмәделәр. Гәрчә аның кабере Өремчедә булса да. Аңлавымча, Кытай бүгенгәчә шактый ук «ябык» дәүләт булганга, артыгын әйтеп, сәясәткә кереп китүдән шикләнәләрдер. Чөнки, Борһан Шаһиди – каршылыклы вакыйгалар шаһиты һәм, ни гаҗәп, һәр вәзгыяткә яраклаша, һәр хакимият белән уртак тел таба белгән.

Академик Миркасыйм Госманов, мәсәлән, аны Кытайның бөтенлеген саклауда артык тырышып башка милләтләргә зыян китерүче кебегрәк итеп сурәтләсә, Ринат Мингалиевнең «Борһан Шаһиди. Тарихта калдырган эзләр» китабында ул, киресенчә, башка милләтләр, бигрәк тә Кытайда яшәүче уйгыр, татарларның мәнфәгатьләрен яклаучы итеп бирелә. Безнең максат әлеге шәхескә тарихи бәя бирү түгел. Ни генә булмасын, Кытай Халык Республикасы җитәкчелегендә унбишкә якын вазыйфа башкарып, сәяси, иҗтимагый, дипломатик, фәнни һәм мәдәни эшчәнлек алып барган ватандашыбызның тарихта үз эзе бар.

Безне исә аның тормыш юлындагы бер факт кызыксындырды. Борһан Шаһиди 1907 нче елда Казанга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга килә. 1909 нчы елны Гыйльметдин Шәрәф җитәкләгән «Мәгариф» басмаханәсендә эшли башлый. (Аның абыйсы – Зиятдинның хатыны Зифа белән Гыйльметдин Шәрәф апалы-энеле булганнар – *Р.Г.*) Әлбәттә, басмаханәгә хезмәтче булып урнашкан Борһанетдинның «эшчәнлеге» китап бәйләп почтага илтү, адреслар буенча озату кебек вак-төяк йомышлар белән генә чикләнә. Әмма ул зиһенле, сәләтле бала булып, китап белән мавыга, рус классиклары әсәрләрен йотлыгып укый башлый.

«Мәгариф» басмаханәсе ул вакытта Казанның хәзерге Мәскәү урамында, «Болгар номерлары» бинасында урнашкан була. Ринат Мингалиевнең китабында «Болгар номерлары»нда тукталган Тукай белән Шәрәф арасында дусларча мөнәсәбәт урнашуы, Шаһидинең дә шагыйрь



**Борһан Шаһиди Мао Цзедунның өендә кунакта**

белән аралашуы искә алына. Әмма, ни гаҗәп, әлеге танышлык турында Шаһиди истәлекләрендә бернинди мәгълүмат юк, Тукай да Шаһидине бер мәртәбә дә телгә алмаган. Тукай, бер уйлаганда, аңлашыла да инде. Чөнки, Борһанетдин ул чакта Тукай даирәсе кешесе булмаган һәм танышлык әле ул – дус, фикердәш дигән сүз түгел. Аннан соң, Тукай яшь-яшь килеш истәлек-мемуарлар язса, бу шактый сәер тоелыр иде. Ә менә Тукай шәхесе ул чорларда инде бөтен татар, алай гына да түгел, төрки дөньяга билгеле була һәм Кытайга 1912 нче елны гына киткән Борһан Шаһидигә олуг шагыйребезне өйрәнергә, аралашырга, истәлекләр калдыру өчен, нинди дә булса фикер тупларга вакыт җитәрлек булган дип әйтергә телим. Икенче яктан әлеге ике шәхеснең ни өчен бер-берсен телгә алмавын аңлатып була да кебек. Теләсә кем белән аралашмау Тукай характерындагы бер сыйфат икәнен искә төшерсәк, ул елларда әле Борһанетдинның «әллә кем» булмавы үзара якынаймауның бер сәбәбе түгел микән? Аннан килеп, Б. Шаһидине «Кытай идеологиясе» бераз сагайтмады микән. Хәтта, бүгенге көндә дә Кытайда артык ачылып китеп сөйләшү, дәүләт сәясәтен тәнкыйтьләү шактый ук куркыныч нәрсә. Кытайда яшәүче кардәшләребез әле бүген дә Тукайның кайбер кыю фикерләрен кычкырып әйтергә шикләнәләр. «Сәяси лириканы, сатираны Тукайдан өйрәндек», – дисәләр дә, шагыйрьнең җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне, иҗтимагый идеологияне тәнкыйтьләгән шигырьләренә,

гомумән, сатирасына да сак карыйлар. Инде экспедициядән кайтып, төрле газеталарга мәкаләләр бирә башлагач та, Казанда укучы Кытай студентлары безгә: «Басмага бирер алдыннан мәкаләгезне карап алып булмас микән? Сәясәтне тәнкыйтьләгән урыннары булып, безгә – Кытай татарларына зыян килмәсен тагын», – дип әйткәлиләр иде. Борһан Шаһиди дә шактый каршылыклы милли сәясәт алып барылган, вәзгыять еш алышынып торган Кытайда Тукай идеяләрен таратып йөрсә, аркасыннан сыйпамаслар һәм ул шәхсән үзе, бәлки, югары дәрәҗәләргә ирешмәгән дә булыр иде.

Язганнарым – фараз гына. Тик менә ике шәхеснең таныш булулары, ни дәрәҗәдә аралашулары хакында бернинди язма мәгълүмат булмавы гына аптырашта калдыра. Инде «тузга язмаган» тагын бер фикер әйтеп карыйм. Әле XX гасыр башларында ук (Тукай үзе исән чагында һәм вафат булгач та – *Р.Г.*) Кытайда яшәүче төрле милләтләрнең шигъриятенә Тукай иҗатының йогынтысы бик зур булган. Татар мәктәпләрендә «Тукай кичәләре» уздырылган, анда башка төрки халык вәкилләре дә катнашкан. Халыкның Тукайга карата шундый олы мәхәббәтендә инде Кытайда шактый гына йогынтылы урыннар биләгән Борһан Шаһидинең дә өлеше булмады микән дигән өметле уйлар да бар әле минем күңелдә. Безнең, ягъни «Тукай фонды» өчен олуг шагыйребезгә кагылышлы кечкенә генә вакыйгага да, факт та бик кадерле. Шуңа күрә бу юлларны Тукай шәхесен өйрәнүчеләрнең игътибарын җәлеп итәр өчен дә яздым. Бәлки, тарихи документлар, кульязмалар актарганда моңарчы билгеле булмаган мәгълүматларга юлыгырлар. Чөнки, галимнәр, тарихчылар үзләре дә: «Тукайны өйрәнәсе дә, өйрәнәсе әле», – диләр бит.

**Риман Гыйлемханов**

# Малик хыялы

*Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;*
*Саулыгың – минем саулык, авыруың – минем авыруым.*
*Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле;*
*Дөнья бирсәләр дә, сатмам милләт, миллиятемне.*
*Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы;*
*Шаша калсам, тик шул хыялдан гына булыр…*
*(Г. Тукай, «Милләткә»)*

Кытай, Австралия, Америка, Төркия, Русия буйлап сибелгән Вәлиевлар нәселенең бер вәкиле – Малик Газиз улы Өремче шәһәрендә туып-

үскән, хәзер биредәге татар яшьләренең әйдәп баручысы. «Безнең әби-бабайлар Кытайга Татарстанның Кукмара, Апас якларыннан күченеп килгән. Аннан язмыш җилләре аларның балаларын дөнья буйлап тараткан. Океан уртасындагы Австралиядә гомер итүче икенче, өченче буын туганнарыбыз да Өремчедән күченгән. Берләре сәүдә эшләре белән, икенчеләре Ләйлә апа һәм Сәгыйть абзый Садрилар чакыруы буенча барып чыкканнар. Кытайда да бик күп без. Әмма кайсы гына илдә гомер итсәк тә, бер-беребезне танып-белеп, аралашып яшибез. Кайгы-шатлыкларыбыз да уртак», – дип сөйләде Малик.

Татарның иҗтимагый тормышында кайнаган кеше буларак, ул Өремчедәге милли яшәешне һәм проблемаларны биш бармагы кебек белә. Күптән түгел Малик үзе, Госман, Сөләйман, Җәлил исемле өч хәзрәтне җыеп, татар яшьләре өчен «түгәрәк өстәл» оештырган. Бу инде яшьләрдә милли хисләр тәрбияләү, дин-әхлакыбызны аңлата тору дигән сүз.



Малик Вәлиев

– Аерым үзәгебез булмаса да, без – яшьләр, үзебез уйлашып, Яңа ел, Нәүрүз, сабантуй бәйрәмнәре, «Тукай кичәләре» уздырабыз. Сабантуйны инде 1986 нчы елдан бирле үткәрәбез. Узган ел 300ләп татар һәм башка милләт вәкилләре дә килгән иде. Бәйрәмебездә аларның да катнашуы юкка түгел. Гомер-гомергә Кытай җирендә безне – татарларны аеруча хөрмәт иттеләр. Хәтта хөкүмәт тә уңай караштa: татарларга рестораннар ачарга рөхсәт бирделәр менә. Әмма без – мәгърифәт кешеләре. Үзем агрономлык университетын тәмамлап, хәзер мал табибы хезмәтендә. 2004 нче елда 3 китап нәшер итеп һәм 40 мәкалә бастырып «доцент» булдым. Тагын 2 китап әзерләнеп ята. Аларын шушы елларда тәгәлләп, профессор дәрәҗәсен алырга исәп. Безнең шулай аң-гыйлемгә тартылу – әби-бабайларыбыздан киләдер. Үзләре зыялы кешеләр булып, халык өчен файдалы эшләр башкарганнар. Киләчәк буынның да мәгърифәтле булуын теләгәннәр, күрәсең. Безнең аңыбызда рухи байлык матди байлыктан өстенрәк тора. Безне «болар кәсеп итә белми икән», дип

уйлый күрмәгез тагын. Сәүдә дә каныбызда – әби-бабайлар гыйлем ияләре булулары өстенә игелекле сәүдәгәрләр дә булганнар бит. Шенҗанга килеп төпләнгәч тә, алар алу-сату белән тормыш корганнар. Бүген дә кәсеп юлында йөрүчеләребез байтак безнең. Мәсәлән, Ришат Муллашев, Равил Вәлиев, Нигъмәт Абдуказырлар, берләшеп, «Алтын Чишмә» дигән бизнес ачтылар. Алтай Чингел, Ирҗан Манәп исә татар ашамлыкларын базарга күрсәтү ысулын уйлап тапканнар. Ягъни, киләчәктә эремчек, корт, сары май ясау, барбекю һәм шашлык пешерү серләрен компьютердан өйрәнеп булачак. Татар кайда да тик тора белми шул ул, – дип сөйләде Малик Вәлиев.

– Сез – Кытайдагы татарлар, милләтебез эчендә ничектер үзгә, аерылып торасыз кебек.

– Бәлки, бәлки… Ләкин минем: «Без милләтне тегеләй-болай саклыйбыз», – дип мактанасым килми. Шулай да Тукайча әйтсәк, «Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын, без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын», – дип яшәргә омтылабыз. Тик без бүген милләтне сөю түгел, «милләтне саклау» дип авыз ачарга мәҗбүр. Ә милләт сагында торуның асылы – татар булып яшәүдә. Гади генә яшәргә кирәк, әти-әниләр, әби-бабайлар тәрбияләгәнчә. Үрнәк милләт булып яшәүне исә тамырлардан эзләргә кирәктер. Һәр милләт бер-берсеннән шул тамырлары, буыннар чылбыры белән дә аерылып тора түгелме?! Тамырларыбыз тирәндә безнең – Сөембикә, Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Тукайларда… Сезгә, Тукай илчеләре буларак, Тукайның безгә булган йогынтысын әйтми булдыра алмыйм. Асылда, ул милләтебезнең йөзе, безне башка халыкларга танытучы. Ул һәр заман өчен рухи маяк һәм кумир булды. Ел да үзара акчалар җыешып, юкка гына «Тукай кичәләре» уздырмыйбыз. Хикмәт шунда: безнең күңелләрдә Тукай «җаны», милләтпәрвәрлек яши. Моның хаклыгын Татарстаннан читтә яшәүче татарлар күбрәк беләдер шул…

– Синең сүзләреңдә Татарстан татарларына карата ниндидер үпкә сизелә. Әллә без Тукай белән горурланмый дисеңме?!

– Юк-юк, алай димим. Киресенчә, мин дә, Кытайдагы һәр татар баласы кебек, халкыбызның югары дәрәҗәләргә ирешүенә сөенеп-куанып яшим. «Тукай фонды» килә дигәч тә, үзегезне зур профессорлар, галимнәр дип күз алдына китергән идек. Ә сез – Тукайның туганы һәм япь-яшь милләтче кызлар булып чыктыгыз. Исем китте, никадәр фидакарьлек, борчылу, энтузиазм бар сездә. Олы юллар гизеп килүегез өчен рәхмәт, безне табуыгыз өчен тагын бер рәхмәт. Кытай татарлары тарихында эзегез җуелмас. Без сезнең турында күп еллар, гасырлар буе сөйләрбез әле.

– Шулай да, Татарстанда яшәүче татарларга карашың нинди синең?

– Татарстан – ул безнең төшләргә кергән, хыялларда яшәгән ил. Бер якта туган җиребез булса, икенче якта – «Татарстан» дигән милләтебез йорты. Ләкин шуны да әйтим: сез Русиядә яшәгәч, үзегезне башкачарак тотасыз. Шул ук милли тамырларга әйләнеп кайтсак, татар гомер-гомергә тормышны гаилә корып алып барган бит. Бездә, мәсәлән, югары уку йортын тәмамлау белән кызлар-егетләр парлашырга тырыша. Ә сездә иң беренче урында – карьера, бизнес. Туйларыбыз да аракысыз, ислам кануннары кушканча уза. Аннан кеше тормышында дүрт зур туй булырга тиеш дип саныйбыз. Аның беренчесе – бишек туе. Балага исем кушу, бәбинең дөньяга аваз салуын каршылау көне. Икенчесе – фәкать малайлар өчен – сөннәт туе. Өченчесе – никах туе. Дүртенчесе – өйләнү туе. Бездә туйларга 400-500 кеше җыела һәм ул өйләдән соң башлана. Өремчедә аз санлы булгач, бер-беребезне хөрмәт итеп яшибез. Табынны да хатын-кызлар бергә җыелып әзерли. Ә хәләл җефетем Сәнәвәр белән безнең бу дүрт туй да үтте инде. Хәзер ике кызыбыз – Сөембикә белән Мәрданә үсеп килә», – диде Малик.

Тамырлар дигәннән, Малик Вәлиев үзенең нәсел шәҗәрәсен дә төзегән! 7 буын бабалары ачыкланса да, эзләнүләр әле дә дәвам итәчәк, диде ул. Малик Газиз улының бабасының бабасы Зыя хаҗи – Өремчегә 9 яшендә килә. Үсеп-буйга җиткәч, Шенҗанның данлыклы баена әйләнгән. Ул вакытта Русия акчасы белән аның 3 миллион сумга якын капиталы булган. Маликның тагын бер бабасы Мәҗит тә – атаклы бай булган. Әйткәнемчә, бу нәсел җебе Кукмараның – Арпаяз, Апасның – Урта Балтай авылларына барып тоташа.

– Ата-бабалар җиренә еш кайтасызмы?

– Соңгы тапкыр 2010 нчы елның маенда, Өремчедән бер төркем татар җыелып, 9 көнгә кайтып килдек. Казан, Апас, Болгар, гүзәл Кырлай якларына сәяхәт иттек. Әби-бабайларыбызның кендек каны тамган җирләрдә догалар кылып йөрдек. Заманчалашкан Казан бик ошады. Әмма борынгы урамнарда үзебезнең татар рухын эзләп таба алмагач, татар авылларына киттек. Ичмасам, Арча, Теләче, Кукмара, Апас, Болгар авылларында (Малик шушы төбәкләрдә генә йөргән) булса да яши икән әле милли рухыбыз. Хәзер сезне дә күргәч, миндә тагын бер хыял туып куйды бит әле: берәр авылның җитәкчесен «көйләп», Кытайның татар яшьләрен шунда бер ай чамасы яшәтеп булмас микән? Өйрәнсеннәр авыл эшенә, күрсеннәр безнең традицияләрне! Үзем дә бәрәңге эшкәртеп, сыер саварга, көтү көтәргә, кичләрен аулак өйдә гармун сузып утырырга ризамын. Яшьләр авыл халкына ярдәм дә итәр, туган

телләрен һәм рухларын да ныгытып кайтырлар иде. Бәлки, насыйп ярларын да шунда табарлар! Сезнең «Тукай фонды» аша миһербанлы түрәләр бу мәсьәләне хәл итүдә ярдәмнән баш тартмаслар әле, иншаллаһ, – дип хыялларга бирелде кардәшем Малик.

* * *

Маликка: «Хуҗа Насретдин турында уйгырча мультфильм карыйсы килә», – дигәч, ул безне шәһәрнең иң бай китап-диск кибетенә алып барды. Җаныбыз теләгән әйберләрне дә бүләк итте. Тик без Өремчедән китәр алдыннан Малик белән саубуллашмадык һәм аерылышып торулар озакка китмәсен, дидек. Чөнки хыялларыбыз уртак безнең…

**Гөлназ Галимҗанова**

# Шенҗан уйгырлары

*Җилсез агачлар селкенми…*
*Уйгыр халык мәкале.*

Дәүләтләре – Кытай, президентлары – кытай, җирләре дә кытай кулында… Уйгырларның язмышлары һәм телләре генә татарныкы белән аваздаш.

## Хуэйгу – магул – таранчы…

Уйгырлар… Кемнәр алар? Бу халык турында беренче тапкыр мәктәптә укыганда ишеткән идем. Алар бит, дөньяда кытайлардан кала, кәгазь кулланган икенче халык! VIII гасыр урталарында күпләп кәгазь җитештерүләре дә мәгълүм.

Уйгырларны төрле дәвердә төрлечә атап йөрткәннәр. III гасырда – хуэйгу, Чыгытай Улусы чорында – магуллар (Уйгыр иле – Магулстан булган – *Р.Г.*), XVII-XVIII йөзләрдә Голҗа шәһәрендә төпләнгән уйгырларны таранчылар (монголчадан «игенче» дигәнне белдерә) дип атаганнар.

Халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча Шенҗанда 1 миллион казакъ, 800 мең дөңгән, 140 мең таҗик, 40 мең шива, 6 мең татар, үзбәк, рус кебек 54 милләт вәкиле яши. Сан ягыннан кытайлар, әлбәттә, беренче баскычта. Икенче баскычта – уйгырлар. Аларның саны – 8 миллионга җитә. Күпчелеге Уйгыр автономия районының Голҗа, Өремче, Торфан,

Хотән, Яркәнт, Кашгар, Аксу кебек калаларында яши. Бер өлеше – Үзәк Кытайда (Ганьсу провинциясендә), Казакъстанда, Үзбәкстанда, Әфганстанда, Төркмәнстанда һәм Төркиядә яши. Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, дөньяда 20 миллионга (!) якын уйгыр бар.

Борынгы уйгырлар 745 нче елда үз каганатларын төзи. Урта Азия һәм Шәркый Төркестанның күп җирләрен алып, халыкларын үзләренә кушып, 840-1212 нче елларда яшәгән Караханыйлар дәүләтендә дә хәлиткеч урынны алып торганнар.

«Уйгыр язуы» дип аталган әлифба да кешелек тарихында зур урын тота. Тора-бара уйгыр теле үзе дә халыкара дипломатик һәм рәсми телләрнең берсенә әверелә.

Уйгырлар – бик борынгы һәм бай мәдәниятле халык. Гасырлар дәвамында алар төрле чорда төрки, хуэйгу, гарәп язуларын куллана. XI йөздә иҗат иткән мәшһүр әдипләрдән Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» («Бәхет китабы») дигән поэтик әсәре, Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгать-әт-төрек» исемле энциклопедик хезмәте – уйгыр әдәбиятының күренекле үрнәкләре.

Борынгы уйгырлар турында кыскача мәгълүмат иде бу. Сәяхәт вакытында без бик күп уйгыр зыялылары – профессорлар, укытучылар, язучылар белән күрештек. Аларның барысы да: «Без бит татарлар белән тугандаш халык», – дип, «Тукай фонды» вәкилләре белән очрашуга олы хөрмәт белән килделәр. Бер галим хәтта: «Тукай булган җиргә без килми кала алмыйбыз», – диде. Уйгыр зыялылары турында алдагы язмалардан укый аласыз.


Безне таныйсызмы?

## Түбәтәй, озын толым, чәк-чәк…

«Керер алдыннан ничек чыгасыңны уйла», «Ләйләне күрер өчен Мәҗнүн күзләре кирәк», «Сорамаган балага

ими каптырмыйлар», «Ике тәкә башы бер саганга сыймый», «Йөзә белмәсәң – суга кермә», «Ерактагы туганыңа карый, якындагы күршең якынрак», «Ялкауның беркайчан вакыты юк», «Кеше чәчәктән назлырак һәм таштан катырак», «Кешеләр аркылы кеше арасына чыгалар» кебек мәкаль-әйтемнәр дә безгә уйгырлардан кергән.

Җор телле, гыйлемле, зирәк халык булуларыннан бигрәк, аларның тамак төбе белән югары тембрда, үзенә күрә бер ләззәт белән җырлаганнарын ишетеп, шакаттык. Уйгырлар – тумыштан менә дигән җырчылар һәм музыкантлар икән. Бер бәйрәмнәре дә җыр-биюсез узмый. Безнең мәҗлесләрдә гармун чыкса, уйгырларда рабоб белән дутар тавышы тынмый. Хатын-кызлары яратып җырлый торган уйгыр халык җырыннан бер мисал китерик:

*Аһ урармән, аһ урармән,*
*Аһләрим туткай сәни;*
*Күз йәшим дәрья булып,*
*Бәликлири җуткай сәни.*

(Аһ орырмын, аһ орырмын, аһларым тотсын сине; Күз яшьләрем дәрья булып, балыклар йотсын сине).

Игътибар иткәнсездер, телләребез охшаш. Уйгыр теле бераз үзбәк әдәби теле белән дә аваздаш, төрки телләр арасында «уйгыр-карлук» төркеменә керә. Шуңа күрә Шенҗанда кытайчаны белмәвебез әллә ни зур «фаҗига» тудырмады. Уйгыр кардәшләр белән рәхәтләнеп татарча аралаштык.

Уйгырларның зәвык белән тегелгән милли киемнәре беркемне дә битараф калдырмый: салават күпередәй балкып, кәефне күтәрәләр! Ир-атлар күбрәк якасыз чапан яки халат кияргә ярата. Элек хатын-кызлар киң җиңле чуар күлмәкләрдән йөргән булса, хәзер гади блузка белән юбкага өстенлек бирәләр. Сылу кызлар яңа ел чыршысы кебек баштан-аяк алка, йөзек, беләзекләр белән «бизәлгән» булыр. Уйгырстан кызларының иң зур байлыгы – күптолымлы чәч. Алар кара, озын чәчләре белән горурланып, аны унлап толымга үреп куя.

Уйгыр базарларында йөргәндә төрле «сортлы» түбәтәйләргә күз төште. Баксаң, «Уйгырны түбәтәенә карап каршы алалар» гыйбарәсе уйгырларны базарга түбәтәй сайларга «йөртә» икән. Аннары милли түбәтәйне олысы-кечесе, ирләр-хатыннар – барысы да кадерләп кия. Уйгыр түбәтәе ике төргә бүленә: чиимән һәм бәдәнмү. Чиимән түбәтәй гадәттә алтын-көмеш җепләр белән чигелгән була. Уйгыр халык биюләренә яшь кызлар белән егетләр ансыз чыкмыйлар. Бәдәнмү түбәтәй исә өлкән кешеләр баш киеме. Ул гаҗәеп орнаменты, сурәте белән аерылып тора: саф чишмә буенда үскән мул җимешле агачлар ак ефәк җепләр белән чигелгән.




**Йомшак келәмдә сабыйлар китап-журналлар укып ята**

Уйгырлар – бик кунакчыл халык. Көндәлек тормышта җимешләр һәм кавын белән ачы көлчәләр ашарга, чәй эчәргә яратсалар да, кунак килгәндә токмач, пылау, кабартма әзерлиләр. Уйгыр хуҗабикәләре исә татарлардан бавырсак, чәк-чәк, өчпочмак, токмачлы аш пешерергә өйрәнгәнне яшерми. «Татар ашлары тел йотарлык!», – диләр.

Уйгырларның да, нәкъ безнең шикелле ике зур дини бәйрәме бар: Ураза һәм Корбан Гаетләре. Ураза бәйрәмендә Шенҗан мөселманнары өч көн ял итә. Мондагы бәйрәм тантанасы да үзенчәлекле. Бәйрәм иртәсендә мөселманнар мәчеткә барабан тавышына җыела. Ә намаздан соң, мәчет каршында борынгы биюләр башлана.

Өремчедә яшәгән икенче көнебездә үк уйгырларның гаҗәп бер тамашасына эләктек. Тыныч кына кунакханәдән чыгып киләбез. Бер мәлне әллә кайдан 6-7 машина пәйда булды да, нәрсәдер шартлап яна башлады. Тирә-якта төтен, сасы ис, «шарт-шорт»! Дүртебез дүрт якка ташландык. Ни булды, бу?! Кунакханә каршында халык җыелган – кул чабалар. Безгә шәһәрне күрсәтеп йөргән Ришат абый Муллашевның моңа исе дә китмәде, бездән рәхәтләнеп көлде генә: «Бүген уйгыр пары кавыша. Курыкмагыз, йоласы шундый: кияү белән кәләш бәхетле булсын дип, аларны шартлаткыч белән «сәламлиләр». Менә сиңа «бәхет»!

## Байлыклары – китап

Һәр урында, һәр җирдә, дигәндәй, кытайдан кала, беренче булырга омтыла уйгырлар. Шенҗанда элмә такталар, белдерүләр, рекламалар ике телдә язылган: кытайча һәм уйгырча. Уйгырлар гарәп язуын куллана. Аллаһка шөкер, гарәп имлясын белүебез ярап куйды әле.

Халыкның акылын тикшерәсең килсә, китапханәсенә кер, дигән борынгылар. Өремчедә уйгыр китап кибете бик бай. «Бер керсәгез, чыга алмассыз», – диделәр безгә. Китап ярминкәсен хәтерләтүче әкәмәт зур кибет икән бу! Уйгыр телендәге әдәби җыентыклар, сүзлекләр, Коръәннәр, 60-80 төрле газета-журналлар, бүлмәнең буеннан-буена сузылган «башлары күккә тигән» киштәләрдә рәсемле балалар китаплары тезелгән… Шунда ук идәнгә йомшак келәм җәелгән һәм анда сабыйлар китап-журналлар укып ята! Ә бездә? Идәндә тәгәрәп китап укумы соң! Китап кибетенә кергән бала бар микән әле?!

«Тел шартлатып» балалар китапларын карап йөргәндә таныш рәсемгә текәлдем. Юан гәүдәле, озын чапан кигән хәйләкәр абзыйны кайдадыр күргәнебез бар кебек. Хуҗа Насретдин түгелме соң бу?! Нәкъ үзе! Хуҗа Насретдин – уйгырларның яраткан персонажы. Аның турында 20 дисктан торган фильм да төшереп өлгергәннәр инде. Мондагы ассортимент шул хәтле бай, әйтерсең, уйгырлар кинофильмнар гына төшереп яткан!

Кибеттә Шенҗан татарлары турында берничә җыентык таптык. Элегрәк сатуда Габдулла Тукайның уйгырчага тәрҗемә ителгән шигырь китаплары да булган. Алар бик тиз сатылып беткән. Без исә «Хуҗа Насретдин» фильмы дискларын, татарлар турындагы ике китап алып: «Эх, нигә бездә шундый китап кибетләре юк икән!», – дип, ак көнләшү белән чыгып киттек.

Әле мәгърифәт өлкәсенә кагылсак, монда да уйгыр халкына тиңнәр юк. Шенҗанда уйгырларның йөздән артык мәктәбе бар. Уйгырстанда гына түгел, алар булган бөтен илдә уйгыр мәктәпләре, театрлары, радиосы, милли каналлары, үз нәшриятләре эшләп тора. Бер генә мисал: Казакъстанның Талдыкорган өлкәсендә уйгырларның алтмыш, Алматыда – өч мәктәбе, уйгыр театры, радиосы, «Уйгыр авазы» газетасы редакциясе, дәреслекләр чыгара торган уйгыр «Мәктәп» нәшрияте, үз мәчетләре бар. Боларның барысына да матди ярдәмне Бөтендөнья уйгыр конгрессы бирә икән. Бик кызганыч, без уйгырлардан күпкә калышабыз шул: авылларда татар мәктәпләре, балалар бакчалары ябыла, татар китаплары киштәләрдә тузан җыеп ята, телебез онытыла бара… Ә бит кайчандыр, XIX гасыр башында Уйгырстанга күченеп килгән татарлар уйгыр халкын мәгърифәтле иткәннәр, беренче уйгыр

мәктәпләрен ачканнар. Аларда Зәйнәп Габитова, Гөләндәм Хәбибуллина кебек «мәгърифәт аналары» укыткан.

Заман үзгәрдеме, үзебезме? Уйгыр халкының бик тә мәгънәле мәкале бар: җилсез агачлар селкенми… Хәер, уйгырлардан бераз үрнәк алсак, безнең тарафка да Шенҗан җилләре исеп куймасмы?!

**Рәмилә Газизуллина**

# «Тукай – дөньяга күзләребезне ачкан шагыйрь!»

Малик Чанышев: «Радио-телевидение идарәсенең тәрҗемә бүлегендә Мусаҗан исемле бер галим эшли. Кытай, татар, рус телләреннән уйгыр теленә әдәби әсәрләр тәрҗемә итә», – дигәч, аның белән таныштыруын үтендек.

Икенче көнне үк, Малик Чанышев белән Мусаҗан Газиз безне кунакханәдән үзләре эзләп тапты.



**Мусаҗан Газиз**

– Күп минем тәрҗемәләрем! Достоевскийның «Преступление и наказание», «Записки охотника» әсәрләре, Пушкин, Лермонтовның шигырьләре дисеңме… Татар әдәбиятында иң яраткан шагыйрьләрем Габдулла Тукай белән Һади Такташ. 2006 нчы елны Габдулла Тукайның 23 шигырен уйгыр теленә тәрҗемә иттем. «Китмибез!», «Мәхәббәт булмаса», «Даһига», «Теләнче» шигырьләре һ.б. Сөйләп тә күрсәтә алам! «Күз карашында синең дөнья күренде мәңге төн; киттең эзләп син аны яктырмага идеал утын…» Әлеге шигырьләр «Җомга татарлары» дигән журналда басылды. 2006 нчы елда «Дөнья әдәбияты» журналында Тукай турындагы мәкаләм чыкты, – диде уйгыр галиме.

Мусаҗан абый Тукай иҗаты белән беренче тапкыр 1948 нче елны танышкан. Беренче ятлаган шигыре – «Ата илә бала». Г. Тукайның «Мәхәббәт», «Мәхәббәт булмаса» шигырьләрен исә Кадер Хәсән атлы совет-уйгыр шагыйренең уйгырча китап тупланмасыннан укыган.

Мусаҗан Газизнең әти-әнисе беркайда да укымаса да, балаларына белем бирергә көч тапкан. Мусаҗан абый башта Пекинга барып, Милләтләр институтында Кытай телен өйрәнгән, соңрак Өремче шәһәренең Шенҗан институтының әдәбият факультетында белем алган.

– Тәрҗемә итү – күп вакытны сарыф итә торган хезмәт. Мәсәлән, Достоевскийның «Преступление и наказание» романы 28 ай вакытымны алды. Тәрҗемә иткән беренче шигырем – Һади Такташның «Байрагы» иде. Ул 1956 нчы елда «Шенҗан әдәбият сәнгате» журналында басылып чыкты, – дип сөйләде галим. – Габдулла Тукай – безнең, уйгыр язучыларының, дөньяга күзләребезне ачкан шагыйрь. Тукай китапларын Кытайга 1920-30 нче елларда Советлар Союзында белем алган сәүдәгәрләр алып кайткан. Гомумән алганда, 1950 нче елларда безгә Совет әдәбиятының йогынтысы көчле булды. Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», Г. Бәшировның «Намус» кебек әсәрләре безгә бик нык тәэсир итте. Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, Каюм Насыйри, Галимҗан Ибраһимов һ.б татар әдипләренең бик күп әсәрләрен тәрҗемә иттек.

Әллә кайдагы Кытайда яши торган уйгыр галиме олы ихтирам белән татар әдипләре, аларның тормыш юлы, иҗаты турында сөйләгәндә «ул бездән күбрәк белә» дип, оялып та куйдым. Кызык кына мәсьәлә килеп чыга бит әле. Татарстанда татар язучыларының әсәрләре укылмыйча, китап киштәләрендә тузан җыеп яткан заманда, уйгыр дусларыбыз: «Күпме гениаль татар әсәрләре тәрҗемә ителмәде әле», – дип кайгыра. Монда уйланырга нигез бар. Димәк, татар илендә татар әсәрләренең бәясе «ташка үлчим» булса, Кытайда алар өчен ул әйтеп бетергесез кыйммәтле хәзинә дигән сүз. Уйгыр галименә Тукай шигырьләре язылган дискны бүләк иткәч, шатлыгы эченә сыймады: «Рәхмәт, бу минем өчен бик зур бүләк. Татар язучыларының яңадан-яңа әсәрләрен тәрҗемә итәргә илһам бирдегез!», – диде.

**Альбина Газизуллина**



Кытай

## ЧҮГҮЧӘК •

*Юк, кояшым, мин беләм: син*
*батмагансың мәңгегә;*
*Син дә, вөҗдан, бер торырсың:*
*ятмагансың мәңгегә.*
*Г. Тукай, «Өмид», 1908 ел*

# Әй, Чүгүчәк, Чүгүчәк!

Әйтергә кирәк, Чүгүчәккә инде бер гасыр буе Татарстаннан бер генә татарның да аяк басканы булмаган. Без – «Тукай фонды» вәкилләре беренче идек. Алай гына да түгел, «Безгә Кытайның башка шәһәреннән дә татарлар сирәк килә», – диде чүгүчәклеләр. Ник дигәндә, шәһәр юл өстендә утырмый, ә Шенҗанның төньягында, Тарбагатай сырты итәгенә сыенган. Без дә анда Өремчедән такси яллап бардык.

Өремче-Чүгүчәк арасы 800 чакрым, 12 сәгатьлек юл. Шәһәргә төн уртасында килеп төштек, бер генә ут яктысын, урамда бер генә кеше затын да күрмәгәч, аптырап та калган идек. Соңыннан шуны белдек: шәһәр биек тупыллар арасында утырганга, йортларны да, тротуарларны да агачлар каплый икән.

– Төшегез, Зәйтүнә апа шушында яши, – диде шофер. Без машинадан коелган арада капка төбендә ике шәүлә күренде.

– Исәннәрмесез, Казан кунаклары! Иртәдән бирле көтәбез үзегезне…

Зәйтүнә апа турында Голҗада яшәүче милләтәшебез Торсынтай Галиевтән күп мәртәбә ишеткән идек. Әлеге ханым ике ел элек Татар үзәген торгызуга алынган. Җыелу өчен биналары, бәйрәм уздыру өчен матди мөмкинлекләре булмаса да, Чүгүчәктә Татар үзәге яши. Милләттәшләр кирәк-яракка акчаны үзара җыелышып таба. Татар һәм мөселман бәйрәмнәрен дә шул рәвешле уздыралар.

Капка төбендә безне каршы алырга чыккан кешеләр – Зәйтүнә апа һәм аның ире Рәфәт Кәримовлар иде. Әлеге йорт – Зәйтүнә апаның әти-әнисененнән калган икән. Аның никадәр зур, киң ишегаллы икәнен иртән уянгач кына күрдек. Үзебезгә, Татарстан якларына тартым ишегалдында «ухалла» арбасыннан башлап, агачтан үрелгән әрҗәләргә кадәр бар.

Кәримовлар үзләре аерым фатирда яши, ә бу йортны карап тоту – Зәйтүнә апа өстендә. Бер катлы булса да, 5-6 бүлмәле таш өйнең һәр бүлмәсе үзенчә бизәлгән. Гаилә монда ял көннәрендә, татарлар белән күрешү өчен килә икән. Моның өчен ишегалды уртасына өстәл-эскәмия урнаштырганнар. Йокыбыздан торып чыгуга, өстәл янында тезелешеп утырган милләттәшләрне күргәч шаккаттык. Рәфәт абый киләсебезне әйтеп, барысын да кичтән кисәтеп куйган. Әлбәттә, безнең өчен бу бераз көтелмәгән хәл иде, чөнки башка бер шәһәрдә дә татарларның болай җыелуын күрмәгән идек без. Милләттәшебезнең һәрберсе үзе белән Тукайга кагылышлы ниндидер мәгълүмат алып килергә тырышкан.



**Безнең килгәнне белгәч, Зәйтүнәләр өенә татарлар агыла башлады**

XX гасыр башында басылган Тукай әсәрләреме, кадерләп саклаган фотосурәтме, әти-әниләре сөйләп калдырган истәлекләрме… Көне буе сөйләшсәк тә, сүзләр бетмәде, чөнки Чүгүчәктә яшәүче һәр татар – үзе милләтнең бер өлеше, тарихы. «Кытайда татарлар яши», – дигәч, булмас дип, бездән кычкырып көлүчеләр дә табылган иде сәяхәтебез алдыннан. Яши икән шул, җәмәгать, яши. Әле ничек кенә! Авырлыкка бирешмичә, тормышны үз көенә җайлап яши. Алар, хәтта, Татарстанда күпме дин әһеле, галим, язучы, нинди җырчылар барлыгын, мәчетләр санын белеп тора. Бәйсез Татарстан өчен сөенеп-горурланып туялмый алар. Безгә Тукайның туган авылы – Кушлавычның, торган җире – Кырлайның, Болгар, Биләрнең төшләренә керүләрен сөйләгәч, ихтыярсыздан күзгә яшьләр килде. Алар һәрбер татарның исәнлеге өчен намаз саен дога кыла. Зәйтүнә апаның ишегалдына җыелган милләттәшләрнең дә дөньяга сибелеп яшәүче кардәшләребезгә әйтер сүзе, җиткерәсе теләге бар иде…

## «Казанны күрмәсәм дә сезне күрдем»

Гани абзый Садыйк, мәсәлән, гомере буе Казанны, Казан татарын күрергә хыялланган. Миңа бераз экспонат сыман карап утыргач, кулымнан тотып: «И-и, кызым. Карт булсам да, өметемне өзмәдем. Аллаһның рәхмәте бу. Инде Казанны барып күрмәсәм дә, сезне – Казан татарларын күрдем. Бездән чибәррәк икәнсез, алай дисәң, без дә үзебезчә матур. Сөйләшегез дә башка, сүзләрегез чишмә кебек челтери…» – диде ул.

Гани абзый үзе турында җентекләбрәк сөйләргә тырышты. «Оныкларым бабалары турында бөтен мәгълүматны сезнең «Истә калганнар» китабыннан табарлар», – диде.

Гани Садыйкның әтисе Хәкимҗан бу якларга Күктомадан 1930 нчы елларда күченә. Ә бабасы Садыйк – Күктомага Казакъстаннан килә. Шуңа күрә Гани абыйның бүген бик күп туганнары Казакъстанда яши. Аның үтенече буенча, ел да Казаннан «Мөселман календаре» кайтаралар икән. Гани абый бу календарь артыннан үзе дә ел саен казакъ иленә чыгып керә. «Миңа аннан да олысы юк. Казанский числолыктан башка яши алмыйм. Бу сәер ягымны гаиләмнән сорый аласыз. Алар да сезгә шуны әйтер», – диде ул күзен хәйләкәр генә кысып.

Гани абзыйга заман «таләпләре» буенча өч төрле мәктәптә укырга туры килгән. Башлангыч белемне хәзер бинасы гына сакланып калган «Туран» исемле татар мәктәбендә, 5-7 сыйныфларда – уйгыр, 8-10 сыйныфларда – казакъ мәктәбендә алган. Шул белем белән яшь Гани казакъ телендә сабак бирүче мөгаллим булып китә. Гомумән, аның берничә туганы да укытучы һөнәрен сайлый.

«Бар иде күңелле чаклар, – дип искә ала Гани абый. – Чүгүчәктә гөрләтеп берьюлы әллә ничә мәктәп эшләр иде. Кызлар, малайлар өчен аерым ачтылар. Хәзер сагынып кына искә алабыз шул. Ярый әле Зәйтүнә белән Рәфәт Кәримовлар, Таир Ташбаевларыбыз бар. Алар инде безне җыеп-барлап торучылар. Нишләр идек, күрешми торсак. Чит җирдә гомер буе яшәп, ул җирнең халкы, гореф-гадәтенә күпме ияләшсәң дә, үз каныңдагысына җитми. Безнең канда бу кадәр миллилек каян дисезме? Без бит балачактан Тукайны укып үстек. Әти-әниләребез аның әкиятләрен сөйләп шаккаттыралар иде. Китапның иң кадерле чаклары иде ул. Балаларга җыелышып Тукайны укыганда барыбыз да авыз ачып, әсәрләнеп тыңлар идек. Үсә төшкәч, «Туган тел»не укып еладым. Тукай бит безнең – туган иленнән тамырлары аерылган татар турында язган. Бәлки, ул Кытай якларына да барып чыккандыр. Югыйсә шулкадәр чын итеп яза алмас иде милләтебез турында. Хәзер Тукай кебек дөньяви

фикерләүче шагыйрьләрне белмим мин. Тукай безнең өчен бер генә булды. Шуңа күрә аның шигырьләрен ятларга тырыштык. Андый-мондый китапларсыз калсак, оныкларга сөйләп булса да бирербез, дидек. Әлхәмделиллаһ, Тукайның китаплары кулдан төшми, хәзер дә укыла. Яшьләр дә Тукайны белеп үсә. Картлык көнендә моннан да зур сөенеч була мени?! Безнең яшькә җиткәч, исегезгә алып, бер карт әйткән иде, диярсез!»



Гани абзый Садыйк

## «Тукай рухына дога укыйм»

«Мин Рәфәтнең апасы булам», – дип сүз кушты янымда утырган апа. Мөкәррәмә Чанышева. Ул, шулай ук, Чүгүчәк Татар үзәгенең активисты, сабантуй, Корбан, Ураза Гаетләрен оештыручыларның берсе. Туганнары Зәйтүнә-Рәфәт Кәримовларның милли эшләр буенча ярәмчесе икән.

«Минем әни – Разыя Гәрәева атлы. Әтием – Самат Кәримов. Ишетеп беләсездер, Кәримовлар дигән күренекле нәсел булган, алар китап бастыру белән шөгыльләнгән. Имамнар булганнар. Без шушы олуг нәселдән өч бала туганбыз – мин, Җәгъфәр һәм Рәфәт. Чүгүчәк мәктәбеннән соң Өремчедә медицина буенча укып кайттым. Хәзер үпкә-йөрәк авырулары буенча баш табиб булып эшлим. Нигә Чүгүчәккә кадәр килгән болар, башка җирдә урын беткәнмени дип, шаккатасыздыр инде безгә карап. Дөресен генә әйткәндә, элек Чүгүчәк – хәсиятле җир иде. Монда яшәү бик тыныч булган. Шәһәр кешеләрне табигате, төзелеше, яшәргә уңайлыгы белән әсир иткән. Инде нишләтәсең, һәркемнең үз язмышы. Аллаһка шөкер дим, Казакъстан белән Үзбәкстанда әнинең сеңелләре яши. Туганлык җебен өзмичә, кунакларга йөрешәбез

Мөкәррәмә ханым безгә һәм Тукай рухына кат-кат рәхмәтләрен укыды. «Сезгә – Казаннан ук килеп хәл белешүегезгә, Тукайга исә, сезне бу якларга китерүенә рәхмәт», – диде.

## Татарны кайгырткан уйгыр

Милләте буенча уйгыр булган галим Таир Ташбаев төрки халыклар дөньясын өйрәнә. Шул исәптән Тукай иҗатын, аның тормыш юлын да биш бармагы кебек белә.

«Казаннан Тукай эзләреннән йөрүчеләрне күптән көтеп яшим. Фаразлау гына түгел, хәтта исбат итә алам, 1907 нче елда Тукай Чүгүчәккә килгән. Ул заманда Мөхәммәтҗан исемле бер фотографның кызы үз хәтирәләрендә: «Әтинең Тукай белән күрешкәнлеген күрдем», – дип яза», – ди Таир Ташбаев. Кызганыч, безгә ул замандагы Тукай фотосын яки берәр истәлек күрсәтүче табылмады. Таир әфәнде аларны безгә Казанга да җибәрәм дип вәгъдә иткән иде. Әмма бүгенгәчә аңардан бер хәбәр алмадык әле.

Тик безгә шунысы да мәгълүм: Кытай татарлары Тукайның авыруы турында ишеткәч, аны дәваларга теләп үзләренә алып китмәкче булганнар. Шагыйрьнең Кытайга чакырылуы, Чүгүчәккә «сәфәре» турында безгә бер Таир абый гына сөйләмәде. Кардәшләребезнең берсеннән: «Ничек уйлыйсыз, килер идеме Тукай Кытайга?», – дип сорагач, ул: «Казакъстанга ерак түгел Кытай. Ул заманныкын кем белеп бетергән, бәлки килеп тә киткәндер. Утсыз төтен булмый, «Тукай Кытайга килгән» дигән сүзләр тиктомалдан таралмас иде», – диде. Ничек кенә булмасын, чүгүчәклеләр әлеге «вакыйга» белән горурланып, шагыйрьне «сәламәтләндерә алмауларына» көенеп яши.


**Таир Ташбаев**

Ташбаев Чүгүчәктәге татарлар тарихын да өйрәнгән. Биредә әүвәлге татарлар VI-VII гасырдан ук яши дип фаразлый. Алар Байкал күленнән гарәп илләренә күчкән вакытта Чүгүчәк аша үтеп, шушында төпләнеп калганнар. Ә хәзерге татарлар 1764 нче елларда, Кытайга сәүдә белән килә. Аларның күпләп күченүе – 1852 нче елларга карый. Ул чакта Кытай хөкүмәте рус таможнясына сәүдә юлы ачарга ирек биргән була.

Тагын бер кызыклы мәгълүмат – заманында татарлар Чың-



**Таир абый гаиләсе**

гызхан армиясендә хезмәт итеп Чүгүчәк җирендә утырганнар. Гомумән, Таир әфәнденең сөйләгәннәре хак булса, Чүгүчәк күп еллар татар халкы өчен милли-мәдәни учак булып торган.

Таир әфәнденең ерак бабалары – уйгырлар Шенҗанның Кашгар шәһәреннән икән. Кытай хөкүмәте уйгырларны Шенҗан буйлап таратып, Өремчедән Алтайга кадәр чәчкән. Казанга кайткач, бу һәм башка мәгълүматлар турында төпченеп, танышыбыз Фәрит Мөслимовка мөрәҗәгать иттек. Үзе Кытайда туып-үсеп, Казакъстанда яшәгән кеше буларак, ул без экспедициядә күреп-белеп өлгергән мәгълүматларга кыскача аңлатма бирде. Аннан соң 2000 нче елда Алматыда басылган «О днях минувших…» (Алматы, 2000 ел) җыентыгын бүләк иткән иде. Бу уникаль басманы Казанда табуы кыен, тиражы да кечкенә. Фәүзия Кәримова, Надия Хәсәнова, Рәүф Бекбасов, Айтуган Юничев авторлыгындагы бу китап та кайбер фактларны ачыклау өчен ярдәм итте.

Таир Ташбаевның бу кадәр күп белүенә шаккатасы юк – ул үзе чирек гасыр буе тарих яза икән. Тарих белән шөгыльләнү өчен аны Чүгүчәккә

махсус чакыртып алганнар. Аңарчы 5 ел мәктәптә мөгаллимлек иткән. Бүген җитлеккән тарихчының һәр нәрсәгә үз аңлатмасы бар. Мисал өчен, Чүгүчәкне безгә «җир астыннан бәреп чыккан чишмә», «болак» мәгънәләренә ия дип сөйләгәннәр иде, ә Таир әфәнде аны «чәчмә» сүзенә бәйләде. «Мәхмүд Кашгарыйның «Диване-лөгать-әт-төрек» әсәрендә «чәчмә» – «ялун» дигәнне аңлата. Атылып чыга торган чәчмә – чукчи ялун була. Шуңардан «чүгүчәк» килеп чыккан да. Чүгүчәк – ул шәһәр генә түгел, округ, район да. Элекке Русиягә Тарбагатай вилаяте буларак билгеле», – дип тә өстәде.

Чүгүчәк белән таныштырып чыккач, Таир әфәнде безне өенә кунакка чакырды. Дөресен генә әйткәндә, уйгырларның тормыш-көнкүреше белән танышырга менә дигән мөмкинлек иде. Әллә ни аерма тапмадык дисәк тә, биредә без ике нәрсәгә гаҗәпләндек. Берсе – Таир әфәнденең 40 ел буе җыйган 5 мең китаплы китапханәсенә. Шенҗан университеты шәкерте, белеме буенча тәрҗемәче булгач, Таир әфәнденең нинди генә телдә китаплары юк. Иманым камил, монда сирәк очрый торганнары, кулъязма басмалар да күптер. Медицинага аерым урын бирелгән: Ташбаевның хәләл җефете Сәгадәт ханым – эчке органнар табибы. Киштәләрдә Тукайның сайланма әсәрләре берничә телдә. Истәлеккә татар тарихына кагылышлы калын бер китап биреп җибәрмәкче иде Таир абый, соңыннан таможнядан үткәрмәсләр, дип шүрләде.

Безне таң калдырган икенче нәрсә – ата-ананың балалары белән горурланып яшәүләре иде. Табын артында сөйләшеп утырганда да, үзара мөнәсәбәтләрен күзәтеп торганда да сизелде бу. Артист, режиссер һәм хореограф кызлары Сәяраның телевидениегә яздырган чыгышын бик дулкынланып карадык без. Сәяра анда Пекинда узган дәрәҗәле бию конкурсында төрле ил биюләрен башкара. Ә рәссам уллары Талипҗан – Ташбаевларның икенче горурлыклары. Аның картиналары белән бизәлгән фатир эчендә галереядагы кебек йөрисең. Икенче уллары Илһамҗан – нефть өлкәсендә инженер. «Бөтен уйгыр гаиләләре дә сезнең кебек уңган-булганмы?», – дип сорыйм шаяртып Таир абыйдан. «Без уйгырлар – тырыш халык. Куйган максатыбызга ирешә беләбез. Балаларны да шулай тәрбиялибез. Безнең өчен иң изгесе – гаилә», – дип җавап бирде ул.

Тагын шунысына игътибар иттек: биредә татармы, уйгырмы, казакъмы – кайсы мөселман гаиләсенә кермә, стенага гаилә белән төшкән сурәт элгәннәр. Нәселләре, туганнары белән төшкән фотоларны да зурайтып куйганнар. Баксаң, биредә бу бик тә күркәм гадәтләрнең берсе икән. Балалар кияүгә, эшкә, укырга таралышкач,



**Без Татар үзәге әгъзалары белән**

бу фоторәсем өйдәгеләрнең сагыну хисләрен басу өчен кирәк ди, имеш.

Сөйләшә торгач, Таир абый үзенең дә татар иҗтимагый эшләрендә катнашып торуын әйтте. Казаннан кунаклар килүен ишеткәч, китапларын кыстырып Зәйтүнә апаларга да иң беренче булып йөгергән ул. «Озак еллар үткәрелми торган сабантуйны 1986 нчы елдан яңадан башладык. Милли бәйрәмгә Чүгүчәккә якын-тирә авыллардан да татарлар җыелды. Төп оештыру эшләрен күренекле тарихчы, дини публицист, язучы һәм тәрҗемәче Морат Рәмзинең оныгы – Әсхат Рәмзи күтәрде. Шул вакыттан бирле Чүгүчәктә сабантуйлар гөрләтәбез. Мәйдан карарга 400ләп кеше җыела. 1995 нче елда Чүгүчәк Татар җәмгыятен кордык. Әсхат – җитәкчесе, мин уйгыр булсам да – аның урынбасары. 2003 нче елга кадәр эшләдек без. Аннан соң Үзәк эшләүдән туктаган иде. 2010 нчы елдан яңадан торгыздык», – дип сөйләде Таир Ташбаев.

# Тирән тамырлар

*Чүгүчәк татарларының шәһәр һәм Тарбагатай өлкәсе тормышындагы рольләре Голҗа татарларыннан соң икенче урында торган.*

*Мөнир Ерзин*

Уйгыр җиренә татарлар 170 еллар элек кенә күчеп килсәләр дә, аларның инде дүртенче буыны барлыкка килде. Аерым елларда Уйгырстанда 10 мең татар яшәгән, бу – зур сан. Кардәшләребез бирегә үз ихтыяры белән күчеп килмәгән. Сәбәпләрнең иң беренчесе – 1552 нче елда Явыз Иванның татар җирен яулап, көчләп чукындыруы, рекрут сәясәтен оештыруы белән бәйле, дип саный чүгүчәклеләр дә, галимнәр дә.

Ә иң беренчеләрдән булып, гүзәл Чүгүчәк каласына 28 яшьлек Корбангали хәзрәт Халиди килгән, дип саный Мөнир Ерзин. Халиди биредәге мәчеттә имам вазыйфасын башкарган. Ул моннан 165 ел элек Семей өлкәсе Аягуз шәһәрендә дөньяга килгән. Бабалары исә, Казан өязе Орнашбаш авылыннан чыккан. Корбангали Халиди үтә гыйлемле шәхес булган. Туган теленнән тыш, гарәп, фарсы һәм төрки халыкларның уртак булган чагатай телләрендә дә сөйләшкән. Казакъ, уйгыр, татар һәм башка борынгы халыкларның тарихын өйрәнүгә гомеренең шактый өлешен сарыф иткән. «Ата-бабалар сукмагыннан» китабында Мөнир Ерзин аның кешелек цивилизациясенең алтын бишеге – Торфан шәһәренә сәяхәтен тәфсилләп биргән. Корбангали Халиди бу могҗизалы якларга XIX гасыр ахырында бер төркем гыйлем ияләре белән экспедиция оештырган булган. Әлеге сәяхәтне матди яктан тулысы белән меценат Рамазан хаҗи Чанышев күтәрә. Сәфәрдән кайткач, 1889 нчы елда Халиди Казан университеты типографиясендә «Тарихи җәридәи җәдидә» («Записки по новой истории») исемле китап бастыра. Корбангали Халиди Чүгүчәктә, Тукай вафат булган елның 14 нче мартында бакыйлыкка күчә.

Халидинең сәяхәтеннән соң әле 12 ел үткәч, Д.А. Клеменц бу якларга беренче Европа экспедициясен оештыра. 1902-1907 нче елларда пруссияле Грюнведель һәм А. Лекокалар, соңыннан француз П. Пеллио, японлы М. Отани һәм Цз. Татибаналар, рус С. Ольденбург, кытайлы Хуан Вэнбилар да Торфан җирлегенә экспедиция белән барып чыгалар. Хәзер бу исемлектә, Корбангали Халидидән тыш, тагын бер төркем татар эзтабарлары өстәлде, ул – «Тукай фонды».

Риман Гыйлемханов җитәкчелегендәге журналистлар экспедициясе. Торфанга ук барып җитмәсәк тә, япон һәм башка милләтләр йөргән Чүгүчәкләрне күрдек без. Бер гасырга якын вакыттан соң, кабат эзләнүләр, өйрәнүләр башладык.

Әмма «Тукай фонды»на кадәр бу якларны тарихчы, сирәк телләр белгече, гарәп, фарсы, төрек телләре остасы Мөхәммәтморад Рәмзи үз итә.

Мөнир Ерзин язуынча, Морад Рәмзи Чүгүчәккә 65 яшендә, 1919 нчы елда, Русиядән Петропавел һәм Семей шәһәрләре аша килеп җитә. Тумышы белән ул Әлмәт авылыннан була. Мәккәдә гыйлем алган, Минзәләви тәхәллүсе белән иҗат иткән Морад Рәмзинең фәнни тикшеренүләре, тәрҗемә эшләре бүген дә галимнәрне гаҗәпкә калдыра. Ә бит заманында, Морад Рәмзи Мәккәдә Корбангали Халиди белән очрашкан була. Һәм Рәмзи, Халидинең юлын кабатлап, Торфанга да сәфәр кыла. 80 яшен тутыргач, күренекле галим дөньядан китә.

Татар халкы дөньяга китергән бөек галимнәр, талант һәм гакыл ияләренең берсе – тарихчы, гарәп, фарсы, төрки телләренең сирәк очрый торган белгече – Мөхәммәдморад-хаҗи Баһадиршаһ улы Рәмзи.

Морад Рәмзи 1854 нче (кайбер мәгълүматларда 1855 нче) елның декабрь аенда Татастанның хәзерге Сарман районы Әлмәт авылында гади татар гаиләсендә дөньяга килә. Аның «Минзәләви» дигән кушамат йөрткәне дә мәгълүм. Бәлки, ата-бабаларының берсе Минзәлә якларыннан булгандыр. Дөньяга хосусый талант иясе булып яралган малай Әлмәт авылы мәдрәсәсендә укып йөргән чакта ук яшьтәшләре арасында зирәклеге белән аеруча күзгә чалына. Кыска вакыт эчендә гарәп һәм фарсы телләрен үзләштереп ала.

Белем һәм гыйлемгә омтылучанлык аны шәһәрдән шәһәргә укырга куа. Ул Казанда Шиһабетдин Мәрҗани, Троицкида Мөхәммәтҗан мәдрәсәләрендә укып, Ташкентта мәшһүр галимнәрдән белемен тирәнәйтеп, 1877 нче елда Бохарага килеп җитә. 1878 нче ел Җиддә шәһәрендә, Мәккәдә хаҗда булып, аннан Мәдинә шәһәрендә «Әмин ага», «Кәш-Шифа», «Әл-Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала.

М. Рәмзи Гарәбстанда 30 еллар чамасына кала. Ә 1919 нчы елның җәй айларында ул Кызылъяр (Петропавловск) һәм Семей шәһәрләре аша хәзерге Шенҗан-Уйгыр автоном районы, Чүгүчәк шәһәренә барып җитә. Шәһәр халкы аны кочак җәеп, куаныч белән каршы ала. Ә ул үз чиратында халыкның рух күтәрүче остазы булып кала.

1921 нче ел, Чүгүчәк шәһәрендә урнашуына күп тә үтми, гыйльми кызыксынучанлык галимне инсаниятнең мәдәният учакларының берсе булган Торфан якларына сәяхәткә алып китә.

Торфанда Рус-Европа экспедицияләреннән күп еллар элек татар галиме Корбангали Халидинең сәяхәттә булганы билгеле. Көнбатыш һәм Кытай галимнәренең фикерләре буенча, XV гасырга хәтле Торфанда буддизм хөкем сөргән. Ләкин ислам дине анда X гасырларда ук керә башлавы мәгълүм. Бу вакыйгадан М. Рәмзи хәбәрдар булган, әлбәттә.

IX-XIII гасырларда барлыкка килгән Идекот-уйгыр мәмләкәтенең борынгы шәһәрләре урнашкан Торфанга галим Өремче шәһәре аша барып җитә. Анда ул Торфанда булган тарихи вакыйгаларны, ислам диненең таралу шартларын тикшерү эшләрен алып бара, халыкның иҗтимагый көнкүреше белән кызыксына.

Торфан халкы Морад Рәмзине голяма-галим дип танып, хөрмәт-ихтирам белән каршы ала, аның эшләренең уңышлы булуына ярдәм итә.

Тикшеренү эшләрен бетереп кайтыр чагында торфанлылар аны Өремче шәһәренә кадәр озатып баралар. Җирле халыклар арасында М. Рәмзинең хөрмәте арта бара.

Морад Рәмзи исән чагында Кытайда яшәүче дөңгән (мөселман динендәге халык рәсми телдә хойцзу милләте дип атала) халкы арасында да ихтирамлы, данлы кеше булып санала. Вафатыннан соң аны изгеләр хисабына кертеп, хәзерге вакытларда да каберен зиярат кылып, рухына изге догалар багышлап торалар. Дөңгәннәр М. Рәмзинең китапларыннан файдаланып, күбәйтеп бастырып торганнар. Вафатыннан соң, аның үзеннән алып торган кульязмаларын, китапларын гаиләсенә кире кайтарып биргәннәр.

1927 нче елда М. Рәмзи мөселманнарның мөкатдәс китабы Коръәннең тәрҗемәсенә вә тәфсиренә өлкә әһленең ихтыяҗын күздә тотып Коръәнне төрки телгә тәрҗемә итү хезмәтенә тотына.

Матбугатта аның бу эшкә керешүенең икенче бер сәбәбе турында язмалар бар. XX гасырның егерменче елларында Шенҗан өлкәсенең хөкүмәт башлыгы Ян Ценсинь М. Рәмзине Өремче шәһәренә чакыртып ала, һәм аңа: «Ишетүебезчә, сез мөселманнарның гали затларыннан берсе икәнсез, сезнең динегез, Коръәнегезнең эчтәлеге мине бик кызыксындыра, укып аңларга телимен. Сез аны тәрҗемә итеп бирсәгез иде», – ди. М. Рәмзи аңа: «Мин кытай телен белмимен. Коръәнне төрки телгә тәрҗемә итеп бирермен, ә сез шул телдән кытай теленә тәрҗемә иттереп алырсыз», – дип җавап биргән. Бәлки, булган хәлдер. Ихтимал, хакимнең Татарстанда дөньяга килеп, Гарәбстанда белем алган мәшһүр галимне үз күзе белән күреп сөхбәтләшәсе килгәндер.

Ләкин җирле халыкның Коръән тәфсиренә ихтыяҗы бу үтенечтән өстенрәк икәнен аңлап белеп, галимнең бу эшкә керешкәненә шик юк.

Коръәннең тәрҗемәсен М. Рәмзи 1927 нче елның октябрь аенда башлый һәм 1931 нче елның май аенда тәмамлый.

1961 нче елда Шенҗан-Уйгыр автоном районы Иҗтимагый фәннәр академиясе белән Үзәк милләтләр институтының гыйльми хезмәткәрләре М. Рәмзинең кызы Ситдиканың кулында сакланып калган тәрҗемәнең төп нөсхәсенең бер өлешен алып китәләр. Калган өлешләре, галимнең кулъязма хезмәтләре, Торфанга сәяхәте турында язган әсәре вә аның шәхси китапханәсеннән 500ләп китаплары Кытайда мәдәни инкыйлаб чорында утта яндырыла. Һич нәрсә белән алмаштыра алмаслык югалту! Менә шулай рухи байлыкларыбызның югалуына кайгырудан башка ни чара?

Бурчум шәһәрендә яшәүче Сәгъдулла хаҗи Гыйззәтулла улы Бикчәнтәев белән күрешергә һәм Алтай якларында яшәүче халыклар белән танышып, аларның тормышын, тормыш шартларын өйрәнү нияте белән 1933 нче елда (79 яшендә!) М. Рәмзи Алтайга сәфәргә юнәлә.

Ләкин «Дөңгән сугышы» дигән чуалышлар башланып китү сәбәпле, ул ярты юлдан Чүгүчәккә кире кайтып китәргә мәҗбүр була.

Давыллы, чуалыш елларда, катлаулы һәм гыйбрәтле тормыш заманында тарих, дини идеология өлкәсендә иҗат юлын басып узган бөек галим, Морад хаҗи Баһадиршаһ улы Рәмзи, Чүгүчәк шәһәрендә 80 яшендә 1934 нче елның 2 нче апрелендә вафат була.

## Безнең көннәр

Шулай итеп татарлар, Шәркый Төркестанга килеп җиткәч, Чүгүчәк, Голҗа, Алтай, Өремче шәһәрләрендә төпләнеп кала. Йөрәкләре кушканча, татар мәктәпләре, мәчетләр төзиләр. Шәркый Төркестанның мәдәни, сәяси тормышына, башка халыклар кебек, җиңел генә кереп, татарның уңган, зыялы халык булуын исбатлый башлыйлар. Бу турыда милләттәшләребез хәтерендә сакланган аерым истәлекләр сөйли.

Әле 1930-1955 нче елларда Чүгүчәк 10 мәчетле шәһәр булып, биредә СССР консуллыгы (бу бина әле дә саклана, биредә элек «Тарбагатай вилаяте кунакханәсе» урнаша), «Совсиньторг» җәмгыяте (Шенҗан белән Советлар Союзының мәдәни һәм сәүдә буенча алмашу оешмасы), күн-йон эшкәртү заводы эшли, кибет-базарлар гөрләп тора. Татар, казакъ, уйгыр, рус, кытай телләрендә белем бирүче 20ләп мәктәп була. 1955 нче елда 45 меңле халыкның иң күбе – татарлар, иң



**Татарлар, Шәркый Төркестанга килеп җиткәч йөрәкләре кушканча, мәктәпләр, мәчетләр төзиләр**

әзе – кытайлар була. Хәзер исә, киресенчә, кеше саны буенча иң соңгы урында татарлар тора. 1934-35 нче еллар Чүгүчәк өчен иң бәхетле чор санала, чөнки хакимлеккә «Народное правительство» килә. Халык үз тормышы белән үзе идарә итә башлый. Кыскасы, коммунизм төзелә.

«Чүгүчәктә мөселманнар күп булганлыктан, шәһәрнең рухи тормышы белән «Аксакаллар шурасы» идарә иткән», – дип сөйләде Таир Ташбаев. Мәккә, Төркия, Казан, Уфада гыйлем алып кайткан имамнар бу шурада халыкка хезмәт куя. «Аксакаллар шурасы»н җитәкләгән Хәсән хаҗи Беришев җитәкчелегендә мәчет, мәдрәсә, мәктәпләр торгызалар. Бу шура турында бер гыйбрәт тә ишеттек: Рамазан ае җитсә, аксакаллар уку йортларында укучыларның ураза тотуын, спиртлы эчемлекләр кулланамы-юкмы икәнен күзәтеп торганнар. Ә намазга балаларны 4-5 яшьтән үк бастырганнар. Хәтта, кызларга егетләрне дә үзләре табып бирә торган булганнар. Иң мөһиме, халык аларга үз язмышын ышанып тапшырган. Шуңа күрә татарларны монда башка милләтләрне әдәп-әхлакка, тәрбиягә өйрәтүчеләр дип йөрткәннәр.

Чүгүчәктә шәхси мәктәпләр ачу, аларны карап тоту да татар байлары өстендә була. Хисам Бавин, Ибраһим Бекбулатов, Гариф Бурнашев, Хәмит Вәкили, Солтан Хәнәфи, Мертемир Җамали, Сәгдулла

Абдрәшитов, Мәсхүт Халитов, Сайфетдин Азизи – ул заманның алдынгы карашлы мөгаллимнәре, Шәркый Төркестанның интеллигенциясе була. Әле 70 еллар элек аларның гыйлем учакларында хезмәт куюларын Союзда да белеп торганнар. Милләттәшләребез бүген дә остазлары, белем йортлары турында иң якты хатирәләр саклап яши. Таир Ташбаев та мәктәп-мәдрәсәләр исемлеген күңелдән әйтеп бирде: «Туран» (Хәсән Чанышев төзетә, директорлары – Хисам Бавин, Солтан Хәнәфи. Мәктәп егетләр өчен була. Бинасы сакланган, хәзер бишенче мәктәп буларак билгеле), Гомәргали хаҗи үз акчасына салдырган Кызыл мәчет каршындагы «Гомәрия» мәктәбе (директоры – Мертемир Җамали). Чүгүчәктә 1910 нчы елда төзелгән беренче җәдитчә белем бирү йорты, Хәсән хаҗи Беришев Күк-мәчет каршында торгызган мәдрәсә, Гөлсем абыстайның «Хәсәния» кызлар мәктәбе, Гөләндәм абыстай Хәбибуллина үз өендә ачкан «Гөләндәмия» кызлар мәктәбе, «Намуна» (директоры – Әнвәр Закири, егетләр өчен, «Максудия» (директоры – Фатима Җамали), «Махмудул Кашгари» (директорлары – Сафура Мәхмүдова, Махия Исхакова), «Дүрт ууыл» (директоры – Торсын Мостафин), «Кара Дон» (директоры – Мәрьям Морадова), рус мәктәбе (директоры – Назаров), ир-атлар гимназиясе (инспекторы – Мәсхүт Халитов), хатын-кызлар гимназиясе (тәрбия буенча директор урынбасары Мөнирә Абдулатыпова), Молотов ис. мәктәп (директорлары – Корбангали Измайлов, Хисам Бавин).

Мәктәпкә уку әсбаплары, кирәк-яракларны чүгүчәклеләр үзләре Советлар Союзыннан кайтара. Кызларга, егетләрдән аермалы буларак, өстәмә рәвештә тегү, чигү, уен коралларында уйнау дәресләре бирәләр. Мәктәпләр арасында фән олимпиадалары, конкурслар уздыралар. Күпләр укуларын Өремченең югары уку йортларында дәвам итеп, Шенҗанның һәм Казакъстанның төрле өлкәләрендә күренекле белгечләр булып эшләп китәләр.

Чүгүчәктә милли-мәдәни тормыш шулкадәр алга китә ки, «Безнең тавыш» газетасы, татар театры һәм кыллы оркестр оеша. Әлбәттә, болар да меценатлар хисабына тормышка аша. Әйтик, «Безнең тавыш» газетасы редакциясе мәктәпләр өчен уку әсбаплары, гитара һәм мандолинада уйнау өчен ноталарга кадәр нәшер итә. Мир-Йосыф Мирильхам улы Мирзаитбаевның Союздан типография кирәк-яраклары кайтаруы мәгълүм. Соңрак «Безнең тавыш»ны «Тарбагатай хәбәрләре»нә үзгәртеп, 1945 нче елдан аны «Халык авазы» итеп чыгара башлыйлар.

Кыскасы, СССРда тормыш үзенчә кайнаганда, уйгыр илендә милләттәшләр үзләре бер дәүләт булып яшәгәннәр.

1931-1933 нче елларда Чүгүчәкнең СССР консуллыгы клубына яшьләр җыелып, спектакльләр куя башлый. «Үзсүзле кыз», «Кызлар менә шулай кызык итәләр», «Галиябану», «Банкрот» пьесаларын сәхнәгә әзерләү өчен Казаннан махсус режиссер Әхмәтҗан Сәйфуллин килеп йөри. Театр белән идарә итү – татар үзәге рәисе Зариф Бекбасов һәм Әхмәтҗан Әбдрәшитовка йөкләнә.

Ләкин Чүгүчәк татарларына язу өчен матбугат мәйданы һәм сәхнә генә җитми. Казан консерваториясен тәмамлап, Чүгүчәккә күченгән Фоат Әкрам улы Монасыйпов шул елларда татар яшьләрен җыеп кыллы оркестрга нигез сала. Фәүзия ханым Кәримова үзенең «Чүгүчәк турында истәлекләре»ндә болай дип яза: «Ике Фатыйма – Бекбасова һәм Бекбулатова, консуллык клубының фойесында буфет оештырып, лотерея билетлары уйнаталар иде. 1937-1938 нче елларда Халык клубы төзелгәч, концерт-театрлар шунда күчте. Сәхнәгә «Асылъяр», «Башмагым», «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл»ләр менде. Шунда, 1944 нче ел иде бу, «Таһир-Зөһрә»не куя башлагач, татар үзәгенә жалобалар килә башламасынмы?! Таһирны палач җәзалавы шулкадәр чын килеп чыккан ки, халык: «Театрда көн дә бер кешенең башын чабалар», – дип зарын белдергән. Ә бит әлеге спектакльләр аркылы без «Каз канаты», «Аккош маршы», «Сүнмәс дәрт», «Кура җиләге», «Алсу», «Баламишкин»ны ишетеп тәрбияләндек».

Уйлап карасаң, бу тамашаларга бер татарлар гына йөрмәгәндер. Казакъ, үзбәк, уйгырына яки дөңгәненә дә кызык булмагындыр дисезме болар?! Чүгүчәктә татарлар сәнгать, мәгърифәт чәчү белән генә чикләнмәгән, шәһәр, дәүләт тормышына да шактый өлеш керткән. Әйтик, әле 1936 нчы елда ук, Чүгүчәкнең дәүләт карамагындагы бер генә сырхауханәсе һәм даруханәсе дә булмаган чорда, шәхси акушер Павел Калинкин, Нигъмәтулла Җәләлетдин улы Сәйфуллин ярдәме белән, авыруларны санаулы көндә аякка бастыра башлый. Чөнки Нигъмәтулланың ул елларда шәхси даруханәсе була. Чүгүчәкнең медицина эшчәнлегендә татар исемнәре шактый: балаларны чәчәк авыруыннан коткарган Сәйфулла Беришев, акушер-әбиләр – «Бызау әби», Мәрьям Беришева, сугышчылар гомерен саклап калган хирург – Әхәт Әбдрәшитов… Гани Фәткулла улы Кулунчаков исә «Совсиньторг» аркылы үз машинасында Союздан дарулар ташыган. Ул сеңелләре Маһирә, Зәйнәб, энеләре – Мифтах, Рәүфне фармацевтка укытып, Мөхәммәтҗан Йосыпов ярдәмендә үз даруханәсен булдыра. Ә менә авылларга халыкны тифтан дәвалау өчен җибәрелгән Нигъмәтулла Сәйфуллин, Сәйфулла Беришев, үзләре авырып китеп, вафат булалар. Ул чакта медицина ярдәме бушлай күрсәтелә, дарулар да, Союздан



**Мәчетләр дини бәйрәмнәрдә халыкны сыйдыра алмый**

ташылган булуына карамастан, бик очсызга сатыла. Мондый «татар тормышы»н хәзерге чүгүчәклеләр ничек хәтерләмәсен һәм ничек сагынып яшәмәсен, ди…

1949 нчы елда, Кытай халык республикасы төзелгәч, милләтләр өчен «мәдәният инкыйлабы» башлана, ягъни кытайлаштыру сәясәте алга китә. Тарихи биналары, традицияләре, телләре белән саубуллашырга туры килсә дә, татарлар үзләрен саклап кала алалар. Дөрес, бүген Чүгүчәктә өч мәчет эшли, әмма бер урта һәм сигез башлангыч мәктәп арасында бер татар классы да юк. Аның каравы, җир җимертеп Татар үзәге эшләп килә. «Милли бәйрәмнәр үткәрү, балаларга тел өйрәтү өчен ачып җибәрдек үзәкне. Югыйсә, соңгы буынның кытайлашып бетүеннән куркабыз. Дөрес, кытай телен белмичә яшәп булмый бездә, бөтен җиргә юллар ябыла – эшкә дә, укырга да керә алмыйсың. Әмма туган телеңне, тарихыңны белмәү – үзе бер наданлык! Затлы Кәримовлар нәселе дәвамчылары буларак та безнең бурычыбыз бу. Бабаларыбыз яшәгән Казанны күрү хыялы белән гомер итәбез инде», – дип сөйләделәр Зәйтүнә ханым белән Рәфәт әфәнде.

## Кәримовлар

Кытай татарларында кунаклар өчен тагын бер күркәм гадәт бар: иртәгә китәсе дигән көнне татарлар ресторанда мул табын әзерләтәләр. Бу кичне җырчыларның авызы ябылмый, гармунчы кулыннан гармун төшми. Кунак булу дигәннән, безгә бигрәк тә шул Рәфәт Кәримовларның кадерле кунагы булып өч көн сыйланырга туры килде дә инде. Зәйтүнә апа: «Ярый әле Рәфәт бар. Эштән кайтуыма көн дә яңа ризык әзерләп куя. Бездә ирләр аш-суга бик һәвәс», – дип әйткән иде. Чүгүчәктән соң күпме җирдә булдык – әмма Рәфәт абый әзерләгән ризыкларны гел сагынып йөрдек.

Зәйтүнә апаның Кәримовларга килен булып төшкәненә инде 22 ел икән. Кызлары Руфиягә – 19 яшь. Кытайның Чуң-чиң шәһәре университетында журналистлыкка укый. Пекинда узучы милләтләр бәйрәменә ике тапкыр татар вәкиле булып барган. Уллары Гакифка – 16 тулган, кытай мәктәбендә белем ала, икесенең дә хыялы – Казанга укырга килү. Зәйтүнә апа үзе балалар бакчасы мөдире.

Кытайда халык бик ишле булу сәбәпле, бакчада балалар саны да ел саен арта бара. Зәйтүнә апага бу сабыйларны урамда калдырмау, һәр балага тәрбия бирү йөкләнгән. Шундый катлаулы һәм җаваплы



эшеннән вакыт табып, ул безгә дә күз-колак булырга җитешә иде. Әлеге балалар бакчасы – Чанышевлар йорты янында, ә Чанышевлар биләмәсе – без яши торган йортка ярты чакрым. Зәйтүнә апа ике араны велосипедта урый. Ике тәгәрмәчле дусты булмаса, бу ярты чакрымны көненә ничә генә мәртәбә үтә алыр иде икән ул.

Бервакыт без Кәримовларның фатирына бардык. Кытай – Кытай инде! Фатир эче – бик заманча. Бездә андый телевизор, җиһаз-җайланмалар юктыр әлегә. Өстәл, кәнәфи япмалары татарча бизәкләп чигелгән. Киштәләрдә – татар китаплары. Өстәлдә – чәк-чәк.

Балалары да милли җанлы Кәримовларның. Руфия көннәр буе яныбыздан китмичә кая барсак – шунда озатып йөрде. Күңелебезгә бик ошады Чүгүчәк. Голҗага киткәндә саубуллашыр алдыннан Зәйтүнә апа: «Гаепләмәссез инде, кунакханәдә яшәтерлек мөмкинлегебез юк әлегә. Яңа оешып киләбез. Инде башка килүегездә, Аллаһ кушып, башкача кунак итәрбез», – дигән иде. Димәк, Чүгүчәк татарлары алга карап, үз-үзен тәэмин итә торган булып яшәргә омтыла. Болай булгач, татарлар Чүгүчәктә эреп юкка чыкмаячак. Безне шунысы куандырды да инде.

Туган җирем, туган шәһәрем Чәуәчәк.
Кайда барсам да, күңелем сине сөячәк.
Телем исә сине мактап: «Чәучәгем,
бөтен шәһәрләрдән артык ул», – диячәк.
Синең миңа кадерең зур, Чәучәгем
Кайда йөрсәм сине уйлап йөрәчәгем.

Фатих Мөхибулла улы Хәбибуллинның бу шигырен кардәшләребез көйгә салып җырлап йөриләр.

**Гөлназ Галимҗанова**

# Җырлы гаилә

Чүгүчәктә әкәмәт кызыклы бер гаилә белән таныштык. Танышу әлеге дә баягы Зәйтүнәләрнең бакчалы өйләренә килгән Нәҗметдин абзыйдан башланып китте. Гади генә киенгән, берничә алгы тешеннән «коры калган» бу абзыйның табиб икәнен белгәч, баштарак икеләнеп тә калдык: табиб кеше тешсез була ди мени?! Алай гына да түгел, Нәҗметдин абыйның өч бабасы да табиб булган икән. Һәм шуннан киткән инде «ак халатлы»лар нәселе.

Әти-бабайлардан бик калмыйм әле, дипме, Нәҗметдин абзый да ике баласын – Рәфкать һәм Мәдинәне табиблыкка укыткан. Калган дүрт



баласы – төрле һөнәр иясе. Телчәт – почта хезмәткәре, Исаметдин – музыкант, Хәерттен – мәдәният хезмәткәре, Фәрхәт – астроном. Әмма, аларны берләштергән бер һәвәслек бар, ул да булса – җырга мөкиббән киту.

Нәҗметдин абыйның нәкъ авылча, бездәгечә, бераз тамак төбе беләнрәк җанга якын җырларны сузып җибәрүе бүген дә күз алдында. Әйе, көйләре, җырлавы да безнеңчә иде аның, тик сүзләре генә икенчерәк иде. Халкыбыз көйләренә сагыну-сагышлы да, тапкыр да, шаян да куплетларны үзләре чыгарган Кытайда яшәүче татарлар. Аларның кайберләрен язып та алган идек һәм бу китапка да керттек (алдарак танышырсыз).

Нәҗметдин абзый гаиләсендә барысы да җырлый: хатыны да, балалары да, оныклары да. Исаметдин исә баянда, аккордеонда, гитарада, балалайкада һәм, әлбәттә, тальянда да уйный. Сәфәрдә ай буе йөреп ни Казакъстанда, ни Кытайның Голҗа, Өремче шәһәрләрендә татар өендә тальян күрмәгән идек. Ә менә Чүгүчәктә бар тальян, ул да булса – Нәҗметдин абый өендә. 1918 нче елгы бу гармун бүген дә уйнарга яраклы һәм өйдә иң кадерле ядкарьләрдән санала. Каян килгән ул гармун, кем ясаган – хуҗа кеше тәгаен генә әйтә алмады. «Әтидән калган», – дию белән генә чикләнде. Аның әтисе – Әнвәр, әнисе Сәнәвәр – Казан татарлары. Алар әти-бабалары Татарстан районнарыннан булса да, әнә шулай «Казан татарлары» дип гомумиләштереп әйтеп куялар.

Казан мондагы кардәшләребезне гел үзенә тарта. Нәҗметдин абзый да татар башкаласына барып-күреп кайту, балалары белән Казан сәхнәләренә чыгу турында хыяллануын яшермәде. Насыйп итсә, балалары бер җыенып килеп Казан сәхнәләрен шаулатыр әле. Сәфәрне оештыруга «Тукай фонды» да үз өлешен кертер. Әмма, Нәҗметдин абзыйның үзенә бу сәхнәгә чыгу насыйп булмаячак. Чөнки, Казанга кайтып берничә ай вакыт узуга, без җырлы гаилә башлыгы Нәҗметдин Хәсәновның вафат булуын ишеттек. Аның хыялын өлешчә булса да тормышка ашыру нияте белән, балаларын «Татар моңы» бәйгесенең



йомгаклау концертына кунак итеп чакыру турында мондагы җитәкчеләр белән сөйләшүләр дә алып бара башлаган идек. Әмма, Кытайдан килеп Казан ВУЗларында укучы дусларыбыз: «Беренчедән, виза эшләтү өчен айлар кирәк. Өлгереп булмас. Икенчедән, Кытай татарлары гадәте буенча, мәет чыккан гаиләдә бер ел буе җыр-көйләр бик ишетелмәскә, шау-шулы бәйрәмнәр узмаска тиеш», – диделәр. Бу – кәгазьгә түгел, ә Кытайдагы кардәшләребезнең күңеленә язылган әхлак кагыйдәсе икән.

Ә без Нәҗметдин абый гаиләсен Казанга чакырудан өмет өзмибез әле. Мөхәммәт ага Мәһдиев «Кеше китә – җыры кала», – дип юкка гына язмагандыр һәм бу сүзләрне язганда Тукайның «Халык җырлары – халкымыз күңеленнән һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер», – дип әйткәннәрен дә күңеленә китерми калмагандыр, шәт.

Җырларыбыз турындагы әлеге хакыйкатьне яхшы белгән һәм аңлаган (ә бәлки, нәкъ менә Тукай аркылы) Нәҗметдин абзый бөртекләп җыйган, китап итеп чыгарган, үзе дә башкарган җырларыбыз да, һичшиксез, калачак һәм яшәячәк.

**Риман Гыйлемханов**

# «Бөтен татарның күңелендәге адәм…»

*Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше;*
*Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.*
*Г. Тукай, «Ата илә бала», 1908*

Чүгүчәктә безнең белән очрашуга килүчеләр арасында Гөләндәм абыстай мәктәбендә укыган, татар мәдәниятен хөрмәт итүче Мәрьям Әбдерәим кызы Тордыева да бар иде.

Гөләндәм ханым Хәбибуллина исә (1887-1974) Шәркый Төркестан тарихында уйгырча махсус кызлар мәктәбе оештырган беренче мөгаллимә булган. Кызларга яңача белем бирү тәҗрибәсе дә аның исеме белән бәйле. 1925 нче елда Гөләндәм ханым Чүгүчәктә ике кызлар мәктәбе ача. Аларның берсен уйгырлар «Гөләндәмия», икенчесен «Максудия» дип атый. Әни: «Югары укыйсың килсә, татар мәктәбенә кер», – дигәч, өч ел Гөләндәм мәктәбендә укыдым», – дип горурланып сөйләде безгә Мәрьям Тордыева. Горурланмаслык мени. Гөләндәм Хәбибуллинаны «Яңа уйгыр мәгърифәтчелегенең сөекле анасы» дип олылаганнар бит!



Мәрьям Тордыева

Хәзерге вакытта Мәрьям ханым Чүгүчәктәге «Миһербанлы аналар» җәмгыятен җитәкли. Бу җәмгыять инде 8-9 ел буена ятим, укый алмый торган балаларга, авыру кешеләргә ярдәм итә. «Мин кечкенәдән Габдулла Тукай шигырьләрен укып үстем. Ул да ятим булган бит. Ятимнәргә ярдәм итүне төп бурычым дип саныйм. Мин Тукайны белә башлаганнан бирле, аның бер рәсемен саклыйм, 1912 нче елда төшерелгән фото бу. Күп кеше бу




**Гөләндәм мәктәбе (1939-40 нчы еллар)**

рәсемне күргәч: «Бабаңның яшь чагымы әллә? Кем бу?» – дип сорый иде. Мин һәрвакыт: «Бу – Габдулла Тукай, безнең вә бөтен татарларның күңелендәге адәм», – дия идем. Тукай шигыре язылган блокнотымны да кечкенә чактан бирле саклыйм», – диде ул. Борынгы блокнотта гарәп хәрефләре белән пөхтә итеп, әлеге шигырь язылган иде:

Яз, газиз углым, кара тактага сыз акбур белән.
Кара күңелне раушан кыл сызып ак нур белән…

«Кая барсам да, мине татар, диләр. Гөләндәм мәктәбендә укыганда аш-су дәресләре була иде. Әле дә чәк-чәк, куллама, пәрәмәч, токмач ашы пешерәм. Мин уйгырлар арасында татарчаны белгән беренче мөгаллимә булдым. Моның белән чиксез горурланам. Балаларым да Тукай шигырьләрен укып үсте. Гомерем булса, Казанны бер күреп кайтыр идем…» – диде Мәрьям ханым.

Мәрьям Тордыева безгә Гөләндәм мәктәбендә укыган вакытта төшелгән фотоларны биреп җибәрде (1939-40 нчы еллар). Уйгыр мөгаллимәсенең йөрәк түрендә сакланган Тукай фотосы – безнең өчен иң кадерле бүләк иде.

# Чанышевлар йорты

Бик борынгы, тарихи кала бу Чүгүчәк. XVI гасырда кашгар һәм атуш уйгырлары тарафыннан төзелгән. Русиягә Шенҗандагы иң якын сәүдә шәһәре булганга күрә, анда татарлар күпләп яши башлаган. Чүгүчәктә татар сәүдәгәрләре – «ак байлар» күп булган. Алар мохтаҗларга ярдәм иткән, мәктәп-мәдрәсәләр салдырган, үз хисапларына Казаннан мөгаллимнәр китерткән, уку алдынгыларын чит илләргә белем эстәргә җибәргән… Чүгүчәк халкын мәгърифәтле иткән Рамазан хаҗи, бертуган Хәсән белән Хөсәен Чанышевлар да шушы «ак байлар»га кергән.

Рамазан Чанышев Кытайга килгәнче үк «чәй магнаты» булып саналган. Революциягә кадәр чәй белән сәүдә итүче рус байларының вәкиле буларак, Кытайга килеп Чүгүчәктә төпләнеп калган. Өремче сәүдәгәре Насыйрбай Бурнашев белән «Җишаңйүән ширкәте» ачып, Кытайдан Русиягә чәй, йон, тире, тере мал чыгарганнар. Кытайда иң бай ширкәтләрдән саналган ул. Рамазан хаҗинең байлыгы турында риваятьләр дә йөргән. Имештер, аның акчасы Николай акчасы белән 10 миллионнан артык булган! Тагын шунысы билгеле: үзе үлгәч, аның бөтен байлыгы агасының уллары Хәсән белән Хөсәенгә күчкән. Сүз



**Чанышевлар йорты Чүгүчәкнең нәкъ уртасында тора**



**Чүгүчәктә искиткеч архитектура үрнәкләре адым саен очрый**

уңаеннан, Хәсән бай исә Өремчедә яшәүче галим Малик Чанышевның бабасы икән.

Шәһәрдә Хәсән байдан соңгы истәлек – сәүдәгәр Чанышевлар йорты сакланып калган. Кызыл кирпечтән төзелгән бу мәһабәт бина Чүгүчәкнең нәкъ уртасында тора. Чанышевлар гаиләсе 1937 нче елга кадәр биредә яши. 1938 нче елда йорт-җирләре конфискацияләнә, Чанышевлар күченеп китәргә мәҗбүр була. 1941 нче елда исә, Шәркый Төркестан хөкүмәте йортны яңадан үз хуҗаларына кайтарган. Игелекле гаилә исә йортны Шәркый Төркестанга бүләк итеп калдыра.

1949 нчы елда Кытай Халык Республикасы төзелгәч, Чанышевлар йортында хөкүмәт конторы урнаша. Биредә «Тарбагатай» исемле кытай-казакъ газетасы чыкканы да мәгълүм. Тарбагатай – җирнең аты дигәнне аңлата.

Чанышевлар йортының стенасында уйгырча шундый сүзләр язылган: «Бу корылма 2006 нчы елны мәмләкәт дәрәҗәсенә (ягъни тарихи һәйкәлгә) әверелә. 2007 нче елдан Чүгүчәк тарихы музее статусын йөртә». Кызганыч, музейга керергә насыйп булмады. Ул көнне тарихи йортның ял көне иде.

Чүгүчәктә бер урта, сигез башлангыч мәктәп эшләп килә. Биредә 1920 нче елларда милләтпәрвәр Хәсән бай Чанышев «Туран иңкүлеге» исемле мәктәп тә салдырган. Халык арасында ул «Туран мәктәбе» дип аталган. Әлеге белем йорты бүгенгәчә хезмәт итә, ул – бишенче башлангыч мәктәп.

# Чүгүчәк прокуратурасы

*Мин – вольная птица: кайда телим, шунда кунам!*
*Г. Тукай, «Мәкаләи махсуса», 1913*

Истәлекле урыннарны тамаша кылып йөри торгач, шәһәр үзәгендәге мәчеткә якынлаштык. Сизми дә калганбыз: яныбызга Кытай полициясе вәкиле килеп баскан. Без – мосафирларга карап, нидер сөйли – сүзен аңлап кына булмый… Ниһаять, Таир әфәнде ул әйткәннәрне безгә тәрҗемә итте: «Сез кемдә яшисез? Нигә кунакханәдә тукталмадыгыз? Хәзер үк прокуратурага бармасагыз, сезне 24 сәгать эчендә Кытайдан куып чыгарабыз…» Нәрсә өчен куалар, диген?! Татарларда бер төн йоклаган өчен. Башны иеп булса да, прокуратурага барырга кирәк иде. Анда дүртәүләшеп йөрсәк, Чүгүчәктәге бердәнбер көнебез «тозланыр» иде. Шуңа күрә прокуратурага үзем генә барырга уйладым…

Кәримовлар йортында тукталган булгач, минем белән прокуратурага Зәйтүнә ханымның кызы Руфия дә барды. Дөресен генә әйткәндә, мин бу җирнең прокуратура икәненә шикләндем. Беренчедән, безнең илдә урамда йөргән чит ил гражданинын туп-туры прокуратурага җибәрмиләр. Шигемне әйтеп, Руфиядән кая баруыбызны кабат сорадым. Җитди генә итеп: «Прокуратурага!», – диде. Кытай язуы белән бизәкләнгән бинага үттек. Куе зәңгәр төстәге хәрби киемнәрдән җитди кыяфәтле ир-атлар һәм хатын-кызлар утыра. Тәрҗемәчем Руфия Русиядән килгәнебезне кытайча аңлатып бирде. Мин боларга: «Ни хао!», – дип елмайдым. Алар да миңа елмаеп: «Здравствуй!», – ди.

Бер ир артыннан кечкенә генә бүлмәгә кердек. Ул миңа: «Садистка», – ди. Башта бу сүздән куркып киттем. Әллә террорчылыкта гаепләмәкчеләр инде?! Аллаһ сакласын! Хәер, бармагы белән урындыкка төрткәч кенә, «садистка» түгеллегемне аңладым. Аннан соң, тәрҗемәчем Чүгүчәккә нинди максат белән килүебезне тәфсилләп сөйләде. Сорау алучы Руфиянең сүзләре белән канәгатьләнмәде, миннән «допрос» алуны дәвам итте. Ләкин нинди телдә? Әңгәмәдәшемнең русча өч кенә сүз белгәнен аңлап алдым. Тутый кош сыман



утырып булмый бит инде, максатны татарча аңлатып карадым. Сискәнеп китте бу. Икенче бүлмәгә чыгып, уйгыр хатынын чакырып кертте. Кара чалбар-күлмәк кигән, билдән кара озын чәчле мөлаем бер ханым иде ул. Алдан ук әйтим әле. Уйгыр хатыны миңа бик күп сораулар яудырды. Үземне чит телдән имтихан тоткандай хис иттем. Ул – минем, мин – аның сүзләрен, бәлкем, аңлап та бетермәгәнбездер. Шулай да, аңлаган кадәресен булса да, ике яклы әңгәмәне татар телендә бирергә булдым. Кызык, беренче сораудан ук телемә бәйләнде ул:

– Сез уйгыр телен кайда өйрәндегез? – диде.

– Мин уйгыр телен белмим. Сезнең белән анам телендә – татарча сөйләшәм.

– Ә казакъчаны каян беләсез? Сез бит казакъча да сөйләшәсез…

– Казакъстанда дуслар, туганнар яши. Казакъчаны шунда өйрәндем.

– Дусларыгыз кайсы шәһәрләрдә инде?

– Күп алар, күп. Алматы, Шымкент, Уральски-и-и…

Ул миннән тагын әллә ниләр сорамакчы иде дә, барып чыкмады. Үзен эш буенча чакыртып чыгардылар. Миңа утырган урынымда калырга кушып, Руфияне шәхси документлары артыннан өенә кайтарып җибәрделәр.

Менә күпмедер вакыттан соң ишектән Руфия һәм тагын ике ир күренде. Алар хәрби киемнәрдән түгел иде. Безнең кебек гади генә киенгәннәр, кулларында кара портфельләр.

Алар артыннан иң элек урамга чыктык, аннары икенче бинага уздык. Чын лабиринтка килеп эләктем: очы-кырые күренми торган озын коридор буенча бардык та бардык…

Караңгы бүлмәгә уздык. Тәрәзә пәрдәсе ябылган. Кара өстәл һәм кара төстәге тимер урындыклар. Шомлы. Утырырга куштылар. Берсе тәмәкесен көйрәтеп җибәрде. Вакытны сузалар. Башымда бер генә уй: болар – кытай шымчылары!

Агентларның берсе генә минем белән уйгырча аралашты:

– Уйгыр телен монда килгәч өйрәндегезме?

– Мин сезнең белән үз телемдә – татарча сөйләшәм.

– (Көлә). Сез татармы?

– Татар.

– Чәүчәктә дә 250 татар бар. Сез килгән Алматыда ничә татар яши?

– Алматыда – 25 мең татар, ә бөтен дөньяда беләсезме күпме татар?

– Күпме?

– 7 миллионга якын татар!

– Шулай укмы? Тиздән Кытайны куып җитәчәксез икән!

– …

Ике сәгать буена ике кытай агентына татар халкы һәм мәдәнияте турында сөйләдем. Татар халык ашларына кадәр сораштырдылар. «Бик күңелле яшисез икән. Татарлар – Кытайда иң акыллы һәм эшчән халык. Безнең дә Татарстанны күрәсе килә», – диделәр.

Ишектән погоннардан, ялгышмасам, майор күренде. Риман Гыйлемхановның чит ил паспортында төшкән фотосын күземә терәп: «Бу кем?», – ди.

– Ул – безнең җитәкче. Филология фәннәре докторы, профессор Гыйлемханов, – дим.

– Бусы – сез, ә бу кем? Фамилияләрегез охшаган.

– Альбина Газизуллина – минем сеңлем. Казан университеты студенты, музей хезмәткәре…

– Әйдәгез, минем арттан!

Кабат беренче бинага бардык. «Көтегез» дип, биш-алты кеше киңәшмәгә кереп югалды. Без Руфия белән хәлсезләнеп, урындыкка «сеңдек». Бездән – җитте! Туйдык…

Әле Кытай прокуратурасында арып-талып утырсам да, күңелем белән уйгыр хатынын да, кытай агентларын да, майорны да ихтирам итә идем. Эшләрен ничек төгәл, җиренә җиткереп башкаралар бит! Бер карасаң, аларның су буе кадәр сорау яудыруы да табигый хәл. Кем белсен, бәлки без Русиядән килгән берәр шпиондыр?!

Ишектән Зәйтүнә ханым күренде. «Хәзер мин алар белән сөйләшеп чыгам», – дип, бер бүлмәгә кереп югалды.

Кытай шикелле алдынгы ил булыр өчен шундый «каты куллар» кирәктер дә. Әйтик, монда халык ришвәт бирүдән яки алудан, урлашудан курка. Кытай законнары буенча ришвәтнең күләменә карап, гаепләне йә төрмәгә утырталар, йә атып үтерәләр икән. Кытай армиясенең дә үз кагыйдәләре. Монда егетләрне хәрби хезмәткә барырга мәҗбүр итмиләр. Армиягә барасы килгәннәр бик зур конкурс үтәргә тиеш. Хәрбиләр – «ак сөякләр» бу илдә. Кытайда яшәүче татар егетеннән: «Син кытай армиясендә хезмәт итәр идеңме?», – дип сорадым. «Кая анда, Кытай армиясенә эләгү безнең төшкә дә керми! Анда хезмәт итү – бик зур дәрәҗә», – диде ул. Ә кытай шымчылары, миңа калса, алар бит ватан алдындагы изге бурычын гына үти – илдә тәртип саклыйлар…

Унбиш минуттан бар да хәл ителде. Паспортларны кулга тоттырдылар да: «До свидания», – дип, озатып калдылар. Зәйтүнә ханым тиз генә котылуыбызны аңлатырга кереште: «Сине бүген бөтенләй җибәрмәскә иде исәпләре. Сөйләштем. Иртәгә китәләр, дидем. Бездә тәртипләр бик кырыс шул. Сез туристлык визасы алгач, Кытайның һәр шәһәрендә дә кунакханәдә генә кунарга һәм анда теркәлү узарга тиешсез. Безнең туганнар буларак кунак визасы алган булсагыз, шәхси йортыбызда яшәргә рөхсәт итәләр. Монда эшләүчеләр мине яхшы белә. Балалар бакчасының җитәкчесе булып эшлим бит. Сабыйлары миңа йөри. Шуңа күрә, сүземә каршы килә алмадылар», – диде.

Чүгүчәктә бер генә балалар бакчасы һәм монда 13 мең бала йөри икән. Әле 10 мең бала чиратка баскан, ди. «Минем баланы ал инде дип, ата-аналар артымнан елап киләләр, төннәрен телефоныма шалтыратып азаплыйлар. Киләчәктә татар сабыйлары өчен аерым төркем булдырасым килә», – диде Зәйтүнә ханым. Шунысы да бар: Кытайда кытайларга – бер, татарларга – өч бала табарга рөхсәт ителә. Аннан да күбрәк бала үстерәсең килсә, хөкүмәткә гариза язып, зур күләмдә акча түләргә тиешсең…



# Кытай безне үзгәртте – оялмаска өйрәтте…

Чүгәчәктән Голҗа шәһәренә 17 сәгатьтә барып җитәргә мөмкин. Безгә автобус белән барырга киңәш иттеләр. Төнлә Тянь-Шань тавы буенча таксида бару куркыныч, янәсе. Каршы килмәдек. Кытай автобусында кайчан йөрер идек әле…

Иртә белән ике катлы автобуска билетлар алдык. «Иң яхшы урыннар беренче катта», – диделәр безгә. Икенче катта селкенеп барачакбыз, икән.

Кытайлар өчен махсус ясалган тар баскычтан автобуска үрмәлибез. Аяк киемнәрен салырга кушып, кулга целлофан пакет тоттырдылар. Монысы күңел болганган очраккадыр, дисәк, ялгышканбыз, аяк киемнәре өчен икән. Салонга күз салдык. Икешәр катлы өч рәткә аякны сузып ята торган утыргыч-караватлар урнашкан. Көч-хәл белән урыннарны эзләп таптык. Йомшак булсын өчен керләнгән матрацка хәтле бар. Белгән булсак, җәеп ятар өчен берәр җәймә сатып алган

булыр идек. Урын-җир дә нәзек гәүдәле кытайлар өчен ясалган, ахрысы. Ул караватның тарлыгы! Камыр ашап кабарган Русия туристлары монда сыймаячак, сыйса да кысылып калачак…

Ай, сикертә! Төн буе Тянь-Шань буйлап бардык. Беренче катта баруның да үз михнәте. Баш өстендә утыручыларның бар ашаганы – ипи валчыгы, кәнфит, көнбагыш чүпләре салмак кына өстебезгә коела бара.

4 сәгатьтән автобус шып туктады. Шофердан: «Без кайда?», – дип сорадык. Ул: «Перевалда. 30 минуттан китәбез. Чәй эчеп керегез», – ди.

Уйгыр кызыннан бәдрәф сорадык. Ул күзен дә йоммыйча: «Кызлар – уңга, егетләр – сулга», – диде. Шаккатмалы манзара! Ирләр автобустан төшүгә үк йомышларын үтәргә кереште. Без кызлар артыннан уңга киттек. Як-ягыбызга каранабыз. Тау башында ир-атлар тезелеп киткән. «Утырыгыз шунда. Перевалда кеше-кешене күрми», – диде кызлар. Тормышмы бу? Күңелдән Хәсән Туфанның шигырен үзгәртеп куйдым: «Кытай безне үзгәртте, оялмаска өйрәтте»…

Перевал чәйханәләрендә халык тамак ялгый. Ә безнең бер генә теләк: өйгә кайтып, мунчага яки ваннага чумарга иде. Эх!..

Күршеләребез төн буена кычкырып, кытайча нидер сөйләп барды. Каян шундый тавыш, сүз запасы, диген! Без үзебезне дөньядагы иң шапшак кеше кебек хис итә идек.

**Рәмилә Газизуллина**



## • ГОЛҖА



# Татар Голҗасы

*Шенҗанның матурлыгын күрәсең килсә – Голҗага бар…*
*Кытай гыйбарәсе.*

Шенҗанда татарлар күпләп яшәгән өченче «татар утравы» – Голҗа шәһәре. Казакъча – Колҗа, уйгырча – Голҗа, кытайча – Инин. Шулай да, җирле халык, шул исәптән татарлар да, аны күбрәк «Колҗа» дип йөртә. Шәһәр Элә елгасының Төньягында, күз явын алырдай гүзәл гөлбакчалар эчендә утыра. Чыңгызханның улы Чагатай да уңдырышлы, мул Голҗа җирләренә кызыгып, анда калырга теләгән. Хәер, монда кем генә яшәргә омтылмаган. Шактый күп яулап алулар нәтиҗәсендә бай каланы йә «таранчы Голҗасы», йә «кытай Голҗасы» дип атап йөрткәннәр. Тарихи мәгълүматларда ул «татар Голҗасы» дип теркәлмәсә дә, борынгы архитектурасы белән XIX гасыр татар провинциясен хәтерләтә.

Автовокзалдагы тынлыкта кытай автобусындагы шау-шулы төн күптән онытылды. Эчемнән яраткан шигырь юлларын көйлим: «Бер кеше юк бер урамда, нинди тын һәм нинди буш…» Карале, бу кытай ыгы-зыгысыннан соң, тынлык харап нәрсә икән. Риман Солтаныч кына «үз репертуарында» – бер дә тик тормый: әле вокзалга кереп чыга, Торсынтай әфәндегә шалтыратып ала, әле тәмәкесен көйрәтә һәм, янәдән вокзалга китә. Минәйтәм, күпме энергия бу Риман абыйда,



кәефе шәп – «Тукай фонды»ның хитына әверелгән «Зәңгәр күлмәк»не сузып җибәрде. Ә без селкенмибез дә, тораташтай катып, таныш йөзләрне эзлибез.

Ниһаять, ерактан таныш кешене күреп алдык. Май кояшы кебек балкучы егет безнең дустыбыз Рифкәт Фәхретдинов иде. «Хуш килдегез, дусларым. Үзегезне күрмәсәм Кытайга килгәнегезгә ышанмас идем,» – дип сәламләде безне Рифкәт. Үзе генә килмәгән. Аның янәшәсендә милләттәшләребез: татар җәмгыяте «аксакалы», мөгаллим Ильяр Габитов, депутат, эшмәкәр Торсынтай Галиев, кытай теле укытучысы Гыйззәтулла Хәсәнов…

Хөрмәтле укучым! Хикәятебездә кунакханәгә урнашу, бизәнү-төзәнүише көндәлек мәшәкатьләрне озын-озак сурәтләп тормыйбыз. «Татар Голҗасы»на – милләттәшләребез «өф» итеп, кадерләп саклаган Татар зиратына, «Нугай город»ка, Ташләпкә базарына, татар мәктәбенә, Тукай күчәсенә сәяхәткә чакырабыз.

## Голҗа каберстаны

*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,*
*Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!*
*Г. Тукай, «Өзелгән өмид», 1910*



**Монда бабалары утырткан агачларны да кистермичә саклап торалар**

Борынгыдан килгән гадәт буенча, Голҗадагы сәяхәтебез изге җирдән – Татар зиратыннан башланды. Татарлар аны үзләренчә «Колҗа каберстаны» дип йөртә. Зиратның шәһәр үзәгендә урнашканын белгәч, хәйран калуыбызны яшерә алмадык. Бу бит татар рухы Кытайның түрендә, йөрәгендә дигән сүз!

Милләттәшләребез каберстанны күз карасыдай кадерләп саклый. Бар җирдә тәртип. Монда беренче тапкыр аяк баскач, онытылып китеп, үземне бер мизгелгә гөлбакчада итеп тойдым. Горур карагач агачлары, «бөдрә» куаклар тезелеп киткән. «Бу – татарлар җире. Кы-



**Сәяхәтебез татар зиратыннан башланды**

тай хөкүмәте тарафыннан рәсми документларда расланган хәләл җиребез. Менә бу карагачны 1890 нчы елда бабаларыбыз утырткан. 2004 нче елда агачларга элмә такталар куйдык – алар безнең җанлы тарихыбыз», – ди Ильяр абый горурланып. Мәһабәт карагач исә татар зыялысының сүзләрен куәтләгәндәй шаулап куйды.

Татарлар Голҗа каласына 1800 нче елның башларында ук күченә башлый. 1850 нче елга аларның үз мәхәлләсе булуы билгеле. Голҗа каберстаны тарихы да шул чорга барып тоташа. 1900 нче елларда аксакал Фазылҗан Юнич зиратны мәңгелеккә Татар каберстаны итеп саклау шарты белән, бу җирне саф алтынга сатып алырга уйлый, теләген Кытай хөкүмәтенә җиткерә. Шулай итеп, җир хуҗалары – уйгырлардан Нур аксакал, дөңгәннәрдән (кытай мөселманнары) Нурахон аксакал килешү төзеп, кәберстанны рәсми рәвештә татарларга тапшырганнар.

Зирәк Фазылҗан аксакал каберстан җирләре чит кулларга төшәсен сизгән, күрәсең. Кытайда «мәдәният инкыйлабы» кызган мәлдә, кайберәүләр каберстан тирәсендәге җирләрне үзара бүлешеп, анда йортлар салып куя. Караучысыз калган татар зираты танымаслык хәлгә килә: коймалары җиргә ава, биредә үләксә базы, чүплек, бәдрәф пәйда була…

1999 нчы елга кадәр зират шул хәлдә ята. Татар зиратында җирләнгән кешеләрнең туганнары күбесе (90 проценты!) чит илләрдә яши. Зиратның аянычлы хәлен күреп, күңеле тулган Ильяр абый аларга мөрәҗәгать яза, бөтен әрнү-сагышлары, үлгәннәргә карата мәңгелек хөрмәтен шигырь юлларына да сала:

*...Бу мөкатдәс җирне саклап калу шарты бер генә:*
*Атрафы урман – бакчалы, эче тулган гөл генә*
*Булмыенча бу хәрәбә кала алмас сакланып,*
*Алып ташланыр, һаман да шәһәр эче урталык*
*Булып калды күптән инде аяк асты тапталып,*
*Сукмак төште, шуңа яздым бу хатымны уфтанып.*
*Сәлам белән Ильяр Габит, әй Колҗа татарлары!*
*Иясе без – саклап калыйк, борчымыйк бабаларны.*
*Җаны җәннәттә булсын дип, дога кылалар икән*
*Яткан җирең оҗмах булыр, тик гөл «игеп» асрау кирәк...*

Бу – тапшырылмаган хатның бер өзеге. Төрле сәбәпләр аркасында, Ильяр абыйның мөрәҗәгате милләттәшләребезгә барып җитә алмый. «Голҗада яшәгән «бер уч» татарны җыеп, бергәләшеп Татар каберстанын чистарттык. Кытай хөкүмәтенә җирнең татарларныкы булуын аңлаттым. Әле ярый, XIX гасырдан «аксакаллар килешүе» сакланып калган. Фазылҗан Юнич алтыннарына сатып алынган каберстан җирләре турында бернәрсә дә дәлилләнмәгән булыр иде», – ди ул. Күпме тартышулардан соң, Ильяр абыйның мөрәҗәгатенә Кытай хөкүмәте уңай җавап бирә. Татар каберстаны кабат үз варисларына кайтарыла. Иң сөенечлесе – хәзер ул хөкүмәт тарафыннан саклана торган тарихи ядкарьләр исемлегенә кертелгән. Татар зиратына ел да чит илләрдән милләттәшләребез кайтып, ата-бабалары рухына дога кыла.

Без дә татар мәгарифе һәм мәдәниятен үстерүгә гаять зур өлеш керткән милләтпәрвәр Юничләр, Госмановлар, Габитовлар каберләре янында дога кылдык. Шунда ук, Алматыда яшәүче эшмәкәр Торсынтай Габитовның үз нәселе каберлегенә куелган истәлек тактасы да бар. Урыннары җәннәттә булсын!

Фазылҗан Юничнең бәрәкәтле алтыннары турында әйттем инде. Татар яшьләреннән шактый кешене чит илләргә җибәреп укыту, үз өендә җәмәгатьчелек файдаланырлык хосусый китапханә оештыру идеяләрен беренчеләрдән булып тормышка ашырган кеше ул. Андагы китапларның әкәмәт күп булуы турында риваятьләр йөргән. Фазылҗан Юнич сәүдә белән шөгыльләнгән, егерме елдан артык Голҗа Татар җәмгыятен җитәкләгән. Гомере буена мохтаҗларга ярдәм итеп яшәгән

аксакал үзеннән соң да игелек калдырган: 1925 нче елда бар мал-мөлкәтенең өчтән бер өлешен мәгариф эшләренә һәм фәкыйрьләргә тапшырырга васыять иткән.

Хәбиб Юнич – Фазылҗан аксакалның улы, 30-40 нчы елларда Голҗада иң күренекле мәгърифәтче, азатлык өчен көрәшкән җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче. Ул Республиканың мәгариф министры, «Азат Шәркый Төркестан» исемле рәсми газетасында баш мөхәррир дә булган. Шуңа өстәп, «Элә дәрьясы» дигән беренче уйгыр газетасына нигез салучы да, Голҗада беренче шәһәр китапханәсен оештыручы да. Гыйлем иясе бар эшкә дә өлгергән! Вафатыннан соң, ул нигезләгән басмаханәгә, Нугай каласында ул яшәгән үзәк урамга Хәбиб Юнич исеме бирелә. Илдә Мао Цзедун хакимияте урнашкач, бу исемнәр юкка чыккан.



Татар зиратында сугыш вакытында үзен һәм хатынын атып үтергән Равил Таҗетдинов, унбиш мең сабыйның сөт анасы булган Бәдрикамал Сәмигулла кызы, инкыйлаб корбаны Хәмит Мөслимов, милләт үсешенә хәләл өлешләрен керткән Бурнашевлар, Җылкыбаевлар, Садрилар, Аллаһйарилар, Сәфәргалиевләр, Садретдиновлар һәм башка милләтпәрвәрләрнең каберләре урын алган. Шуңа игътибар иттем: монда җирләнгән бер татар да белемсез, йомышчы, ярлы-ябагай булмаган. Киресенчә, мәгърифәтле, һөнәрле булып, милләткә хезмәт иткәннәр. Үзләреннән соң, күпме кибетләр, мәктәп-мәдрәсәләр, китапханәләр, газета-журналлар, горур карагачлар, меңьяшәр имәннәр калдырганнар!

Әйе, бүген Голҗа уртасындагы зират «татар хәтере»н саклап, Кытайда татар яшәвен искәртеп тора. Әмма, җитәкчеләр, законнар, идеология үзгәреп торган заманда сакланырмы бу милли ядкарь? Ильяр Габитов та: «Голҗада күпме каберлекләр күчерелеп, дистәләгән зират өстендә яңа йортлар төзелә бара. Бер көнне шәһәр күркәмлеген боза, дип, Голҗа каберстанын да юк итәргә мөмкиннәр. «Татар хәтере» дә катлы-катлы йортлар астында калачак», – дип, борчыла. Атна саен каберстанны чистартып, андагы үлән-агачка су сибеп торучы Голҗа татарлары моңа юл куймас, дип ышанабыз.

## Нугай каласы

Голҗага килгәч тә, катлы-катлы биек йортларны күреп, татарлардан: «Сез дә бу ташпулатларда яшисезме?», – дип сораган идем. Алар исә, ничектер горурланып, күкрәк каккандай: «Юк ла, без үзебезнең калада – Новый гурытта яшибез!», – диделәр. Шулчак, ничек инде татарлар урыс «гурыт»ында яшәсен, дип, аптыраган идем аны. Соңрак, һәр кич татарларга ифтар ашларына йөри башлагач, аңлашылды: «Новый город» – татар каласы икән.

20 нче еллар башында, әйткәнемчә, биредә татарларның саны күзгә күренеп арткан. Шуның белән ишле татар гаиләләренә күпләп яңа йорт салу ихтыяҗы туган. Милләттәшләребез Голҗа каласының хөкүмәт хакиме – Хәкимҗан хуҗа белән килешеп, халык телендә «Сай буе» дип атала торган Гулча (шәһәрнең исеме дә шуннан килеп чыккан булырга мөмкин, монголчадан – «үзәнчек» дигән мәгънәдә – *Р.Г.*) инеше артындагы буш җирләрне сатып алганнар.

«Булгач-булгач йорт түгел – шәһәр булсын», – дип, Фазылҗан аксакал, Хәсән Биктимер, бертуган Закирҗан, Ситдыйк һәм Фатих Аллаһйарилар, Низаметдин Шәмсетдин, Галиәхмәт Садриләр бергә киңәшләшеп, тротуарлы, тәрәзәләре урам якка балкып торучы милли йортлы, киң урамлы, иркен бакчалы заманча татар каласы төзергә уйлаган. Иң элек белемле рус инженерларын чакыртып, булачак шәһәрчекне киң урамлы кварталларга бүлгәннәр. Татар каласына «Новый город» дигән шартлы исем дә руслардан «ябышып» калган, күрәсең. Җирле халык телендә ул «Нугай город», ягъни «Татар каласы».

Яңа кала Уйгырстан шәһәре архитектурасына зур яңалык керткән. Күп очракта йортлар чи кирпечтән салынган булса, түбә кәрнизләре һәм нигезләр яшькелт-соры төстәге яндырылган кирпеч белән тышланган. Мондый йортлар эссе җәйләрдә кызмаган, кышларын таштан салынган йортлар кебек суынмаган.

Бүгенге «гурыт»та исә саман йортларны хөкүмәт ташпулатлары алыштырган. Сирәк-мирәк аерым хуҗалыклар булып, заманча татар йортлары утыра. Мондагы «нугай капкалары» безнең кайбер авыллардагы кебек: печән төялгән трактор сыярлык зур итеп эшләнгән. Ураза гаетендә милләттәшләребезне гаетләп йөргәндә шундый «нугай капкалары»ннан болын кадәрле иркен татар йортларына күп кердек без. Уйгырлар, үзбәкләр кебек идәнгә утырып, ризык муллыгыннан сыгылган тәбәнәк табыннардагы уйгыр, татар сыйларыннан авыз иттек.

Дустыбыз Рифкәт Фәхретдинов гаиләсе дә Нугай городта үз йортлары белән яши. Архитектурасы ягыннан Кырымның Бакчасарай



**Рифкәт Фәхретдиновлар гаиләсе дә Нугай каласында үз йортлары белән яши**

каласындагы йортларны хәтерләтә бу йорт: биек, иркен, зур тәрәзле. Ишегалдында өрек, йөзем агачлары үсә.

Монда йокы бүлмәләре бик үзенчәлекле икән: зур сәкедән кала артык бер җиһаз да юк. Бу якларда ашханәне төп йорттан аерым салу гадәте бар. Ишегалдының бер читендә уйгырча «ипи миче» – танур тора. Рифкәтнең әнисе Саҗидә апа бакчада суган, борыч, кишеркәбестә утыртып мәшәкатьләнми икән. «Кытайда яшелчә бик очсыз. Көндәлек кирәк-яракларны урамда «сәйвәңзәләр»дән – яшелчә белән сату итүче кытайлар һәм дөңгәннәрдән алып була», – ди ул. Кытай халкы җиләк-җимешне, яшелчәне бездәге кебек граммлап, килолап алырга күнекмәгән. Арбалап кына кайтарып аударалар!

Үзебездәге кебек каен, имән, юкә, мәтрүшкә исләре бөркелгән кайнар мунчаларны без Нугай каласында тапмадык. Әллә кыстаучы булмадымы?.. Уйлап карасаң, Голҗада заманында җиде мунча эшләгән. Шуның иң зурысын Себер бае Миркасыйм хаҗи Миршан төзеткән, диләр.

Фәхретдиновлар өендә без әйтеп бетергесез җан рәхәте, күңел тынычлыгы кичердек. Чын «татар сахрасы» иде бу! Рифкәтнең бер сүзе генә кәефне җибәрде: «Ышанасызмы, дусларым, берничә елдан туган йортыбызны җимерәчәкләр. Монда күпкатлы кытай йортлары калкып чыгачак. Бөтен балачагым шунда үтте бит…» – диде ул яшьләнеп. Кызганыч. Мондый борылышны көтмәгән идек. Татар Голҗасының «йөзек кашы» булган Нугай каласының да әкренләп кытайлаша баруы микән бу?!

**Рәмилә Газизуллина**

# Татар башың белән куркасыңмы?

Кытайдагы татар гаиләләренә кунакка баргач, ис-акылыбыз китте: ул милли тәрбия дисеңме, әдәп-әхлак, олыны-олы, кечене-кече итү дисеңме – балага барысын кечкенәдән сеңдерәләр. Мондый рухта, татар рухында үскән яшьләр кая да югалмый. Әнә, Казанга килеп укучы 70 студент, гөрләтеп татарча да сөйләшә, хәзер урысчасын да сукалый. Бездән уздырып татарча җырлыйлар, Тукай шигырьләрен яттан беләләр. Кытайда татар гаиләләре ничек яши? Милли рух, горурлык ничек тәрбияләнә? Татарлыкны саклау җиңелме? Шулар хакында Рифкәт белән кич буе рәхәтләнеп гапләштек.

**– Рифкәт, милләтне саклау кирәклеге турында уй синдә кайчан туды?**

– Казанга килгәч.

**– Кытайда яшәгәндә мондый борчулы уй юк идемени?**

– Борчылырга – бездә татарның берние юк бит. Радио, телевидение, газета, интернет – бар да кытайча һәм уйгырча. Әмма ниндидер бер рух бар бездә. Буыннан-буынга күчә торган татар рухы. Уйлап карагыз, безнең әти-әни Казанны барып күрмәгән, әмма гомер буе шунда тартылалар. Әби-бабайларыбыз да Казанга ашкынган. Безне дә Казанга тамырлар тартты.

**– Рифкәт, син еш кына: «Татарча тәрбияләндек», – дияргә яратасың. «Татарча тәрбия» нинди була соң ул?**

– Мәсәлән, бала чакта әтигә: «Төнлә ишегалдына чыгарга куркам», – дисәң, ул: «Татар башың белән куркасыңмы? Татар курыкмаган ул, куркыткан гына!», – дип әйтә иде. Бервакыт мәктәптә уйгыр дусларның татар булуыма миннән көлгәнен ишеттем. Имеш, кем соң ул татар? Нинди билгесез милләт? Мин моны өйгә кайтып сөйләдем. Әти: «Барып әйт, синең бабаларыңны татар укыткан диген»,– диде. Берәр эштә гаепләсәләр әти тагын: «Барып әйт, без – татарлар, шулай эшлибез, диген. Ялкау булма, улым, манкорт булма!», – дип өйрәтте. Уйгыр дуслар, соңыннан, иләштеләр. Хөрмәтләре генә артты. Без укудамы, башка берәр эштәме, уңышка ирешсәк, уйгырлар инде: «Нәрсәсенә шаккатасың, алар бит татарлар!», – дия башладылар.

**– «Татарча тәрбиядә» ата кулы аңлашылды. Ә әнинең өлеше нинди булды?**



**Фәхретдиновлар гаиләсендә**

– Әниләр гаиләдә 7 бала булганнар. Аларны әби Тукайның «Бишек җыры» белән йоклата торган булган. Бу 7 бала шаулаша башласа, әби өстәлгә зу-у-ур патефон чыгарып, татар көйләрен җибәргән. Балалар тынып, өстәл кырыена тезелешә торган булганнар… Безне дә әни «Бишек җыры»н көйләп йоклата иде:

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

**– Рифкәт, тамырларың белән кызыксынасыңмы?**

– Әти ягыннан бабайның бабасы Фәхретдин – Кукмара кешесе. Әнинең әтисе ягыннан Вәли бабай да – Кукмараныкы. Әнинең әнисе Сәгадәт әби – Апасның Урта Балтай авылыннан. Ул – 14 бала анасы. Сәгадәтнең бабасы Хәким, Ефәк юлы аша сәүдә белән килеп, Кытайда төпләнеп калган. Сәгадәт әбинең әтисе – Шәяхмәт бай, үз өендә татар балаларына мәктәп оештырган. Бабайның бабасы – Зыяхаҗи революциягә кадәр Кытайга күченгән. Зыяхаҗи бабай укымышлы, матди яктан хәлле имам-хатыйб булган. Кытайның Өремче шәһәре янында Няньсань тавы бар. Элек ул Зыяхаҗи тавы дип аталган. Кыскасы, сәүдәгәрләр һәм муллалар нәселе без. Мин Кытайда дүртенче буын

татар. Әтием – Әхәт, әнием – Саҗидә исемле. Абыем Әсхать, сеңлем – Рәгънә бар. Голҗада әле әбиебез Шәмсебану да исән-сау.

**– Заманында Голҗада татар мәктәбе булганын беләбез. Әмма анда уку сиңа тәтемәгән.**

– Әйе, 1936 нчы елда Голҗада татар мәктәбе, аның каршында «Нур» кызлар мәктәбе ачыла. Татар сәүдәгәрләре үз акчаларына торгызган һәм тоткан аны. Ул мәктәпкә Казаннан, хәтта, китаплар һәм укытучылар китерткәннәр. Безгә татар мәктәбе эләкмәсә дә, татар китаплары, Тукай шигырьләре белән үстек. Тукай теле белән тәрбияләндек. Татарлыкның өч алтын баганасы бар бездә. Болар: дин, гаилә һәм Тукай. Татар рухы безгә Тукай аркылы да килеп кергән. Ул кытай милләте өчен дә билгеле шәхес.

«И, туган тел, һәрвакытта, ярдәмең белән синең, кечкенәдән аңлашылган шатлыгым-кайгым минем», – бу юлларны җир йөзендә белмәгән татар юктыр. Кытай татарлары өчен ул халкыбыз гимны да. Бер кичә-очрашу да «Туган тел»сез башланмый һәм тәмамланмый. Ул татарның «Бисмилласы» кебек… Аннан соң балачакта өйдә артыгын кыланып җибәрсәк, безне: «Шүрәле килә, Шүрәле алып китә», – дип куркыталар иде.

**– Син, димәк, Тукайның Шүрәлесен дә ишетеп-белеп үскәнсең. Ә менә Казан, Татарстан турында ни белә идең?**

– Казанны ишеткән бар иде, чөнки сирәк кенә кемдер барып кайткалый иде анда. Ә менә «Татарстан» дигән Республика барын, беренче тапкыр, 1996 нчы елда, Голҗа Сабантуенда белдем. 8 яшь иде миңа ул вакытта. Сабантуйга Казакъстаннан Салаватның кассетасын алып килгәннәр иде. Ә анда – «Мин яратам сине Татарстан!» дигән җыр бар иде. Шул көннән иң яраткан җырым ул, ә Салават – иң моңлы артист. Мин дә кечкенәдән сәнгатькә тартылам. Җыр-моң – алар «мин», «минеке». Кечкенәдән аккордеон тотам. Төннәр буе гармун сузып чыга алам… Берсендә, безнең күрше Мүлек абзый, йомышы төшеп, Татарстанга китте. Милләте буенча казакъ, әтинең дусты ул. Голҗага кире кайткач, без аны авыз ачып тыңладык. Баксаң, Татарстанның үз флагы бар икән. Казанда трамвайлар татарча гына сөйли. Һәм транспортта юл бәясе бик арзан, имеш. Без Татарстанны чеп-чи Татар иле дип күзаллап яшәдек.

**– Ә монда килгәч, Татарстанның чеп-чи татар иле булуын үзең күрдең инде.**

– Чеп-чи үк түгел икән шул. Чып-чын татар безнең Кытайда түгел микән дигән уйлар да башка кергәли.

**– Уйгырларның татарга мөнәсәбәте ничек?**

– Без уйгырлар белән ит һәм сөяк кебек дип әйтимме? Безне аерсалар, яшәү кыен булыр иде. Татарның иң якын дусты – уйгыр, уйгырныкы – татар була ала. Уйгыр халкында бер мәкаль бар: «Ерактагы туганнан якындагы күрше якын». Ике милләт арасында шундый туганлык мөнәсәбәте. Уйгырлар дингә һәм иманга тугры халык. Әхлаклы. Алар татарның Кытай җиренә мәгърифәт китерүен таныйлар, шуңа күрә безне бик хөрмәт итәләр.

**– Кытай хөкүмәте дә шундый караштамы?**

– 1 миллиард 300 миллион кеше яши Кытайда. Шуның 98 проценты – кытай, 2 проценты – башка милләт. Кеше саны буенча, татарлар арттагы урында. Ә инде зыялы, укымышлы, тырыш булу ягыннан – беренче урында! Кытай хөкүмәте моны таный һәм бу мәгълүматны билгеле бер статистикага таянып әйтәм. Уйлап карагыз, Кытайда иң аз санлы милләтнең 78 профессоры бар. Татар укытучылары кытай балаларына кытай грамматикасын өйрәтә хәтта. Милләттәшебез Борһан Шаһиди –кытай-уйгыр сүзлеген төзегән галим, кытай телен кытайлардан яхшырак белгән. Шуңа күрә Мао Цзе Дун аны үзенең киңәшчесе итеп билгеләгән. Голҗа урамында теләсә кемне туктатып, 56 милләтне сана дисәң, берсе-бер тәгаен генә әйтеп бирә алмас, ә менә «татар» дигән милләт барын әйтерләр. Кытайларның безгә хөрмәте турында бер генә мисал сөйлим. Университет ашханәләре ураза вакытында төнлә эшли, мөселманнар өчен хәләл ризык пешерелә. Сәхәр җиткәч, студентларны уятып ашаталар. Ифтар җиткәч, авыз ачтыралар. Бу Кытай ягыннан әдәп тә, әхлак та. Махсус автобуслар Ураза белән Корбан гаетләрендә студентларны мәчеткә намазга алып барып кайта. Ә Татарстанда? Голҗа мөселманнары Корбан гаетендә 3 көн ял итәләр. Казанда – 1 көн, ә узган ел (2009 ел – *Г.Г.*), мәсәлән, КДУ студентлары анысын да күрмәде. Чөнки Федераль университет дигәннәр. Русия законнарының башка милләтләр өчен ни дәрәҗәдә «кулай» булуы шуннан аңлашыла инде. Татар бүлегендә Кытайдан килеп укучылар, татар филологиясе факультеты деканына кереп: «Абый, нишләп мөселман бәйрәмендә ял юк. Без бит хәләл факультетта укыйбыз!», – дип, бәреп әйткәннәр, тик ни файда?! Мин Казанда бишенче ел яшим. Гает көнне беренче курстан бирле укырга бармыйм. Хәләл белән хәрамның исен аеру каныбызга татарлык кебек сеңгән. «Бисмилланы әйтеп ашадыңмы?», «Догаңны укыдыңмы?», – дип, кечкенәдән өйрәттеләр табын яныннан киткәндә. Без бер Аллаһтан куркабыз. Тәрбиябез шундый. Әле беркөнне үземә ачыш ясадым: иң күп мәчет – Кытайда икән. Җәмгысы 40 мең. Юкса, Кытай һич кенә дә мөселман иле түгел. Әмма нинди мәһабәт иман йортлары торгызыла анда.

**– Рифкәт, үзенчәлекле сезнең гаилә. Әллә артык кунакчыл инде сез?! Сездә авыз иткән тәптилә (тефтели – *Г.Г.*) искә төшеп, авыздан гел сулар килеп торыр әле!**

– Балачактан шуны беләм: безнең өй Голҗада – «приемный». Кабул итү өе кебек. Әти сөйли иде: аның әтисе – Муса бабай – кунакны сәпид белән каршы алып, сәпид белән вокзалга озатып куя торган булган. Хәзер моны мәзәк итеп сөйләсәк тә, бабайның кунакчыллыгын инкарь итеп булмый. Әтием дә шундый. Ул бабай тәрбиясен алган. «Күперне узгач, күперне бозма», – ди уйгыр мәкале. Әти шуны гел искәртеп тора. Ягъни, кешене бер кунак иттең дә, шуның белән ике ара бетте түгел…

Рифкәт Фәхретдинов үзе дә ике ил арасындагы татарларны бәйләүче күпер кебек.

**Гөлназ Галимҗанова**

# Татар мәктәбе

*Каз канатлары ак булыр,*
*Ир канатлары ат булыр.*
*Сабыйларның канатланыр вакъты*
*Мәктәпләрдә укыр чак булыр.*
*Г. Тукай, «Сабыйлар җыруы», 1912 ел*

Кытайга килүебезнең тагын мөһим бер сәбәбе – атаклы Голҗа татар мәктәбен дә күрү иде. Бик күп татар мөгаллимнәре укытып чыгарган данлыклы мәктәпнең юбилее якынлашканын ишеткәч, Голҗа татар җәмгыятенә Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе, Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты җитәкчеләреннән рәхмәт хатлары алып бардык.

Голҗа татар мәктәбенә ничә яшь соң? Безгә аны милләттәшләребез дә төгәл генә әйтә алмады. Берәүләр – 100, 75 яшь, икенчеләре – 80, 105 яшь, диләр.

Кытайдагы татар мәгарифенә кагылышлы ике кабатланмас хезмәт бар. Берсе – Кытайда яшәүче галим Малик Чанышевның «Кытайда татар мәгарифе тарихы», икенчесе – Голҗа татар мәктәбендә укыган мәшһүр академигыбыз Миркасыйм Госмановның «Ябылмаган китап яки чәчелгән орлыклар» китаплары. Андагы бай мәгълүмат Голҗа татар мәктәбе тарихын аңларга, яшен ачыкларга ярдәм итә.



**Академик Миркасыйм Госманов укыган класс бүлмәсе**

Кытайдагы милләттәшләребезнең халыкны гыйлемле итүдә бер күркәм гадәте булган. Алар Кытайга Казаннан укымышлы имамнарны, мөгаллимнәрне чакырткannaр. Чүгүчәк имамы Корбангали Халиди, Голҗаның яңа мәчетенә имам булып килгән Кәшфеләсрар Ваһаб та шундыйлардан. Кәшфеләсрар хәзрәт исә Татар мәчете каршында мәдрәсә ачып җибәрә. Шулай итеп, 1900 нче елдан алып, Голҗада рәсми рәвештә татар мәктәбе эшли башлый. 1910 нчы елларга кергәндә, мәктәптә укучылар саны артканлыктан, Голҗа татарлары яңа мәктәп салырга уйлый. 1913-1914 нче елларда иске мәдрәсә урынына ике катлы яңа мәктәп төзелә. Әлеге уку йорты Шенҗаңда беренчеләрдән булып ачылган заманча татар кызлар мәктәбе – «Мәктәби нур» буларак билгеле. Нигез салучылары – атаклы мәгърифәтче Габдулла Бубый һәм аның хатыны Хөснифатыйма. Мәгълүматларга таянсак, 1913 нче елда төрмәдән азат ителгәч, Бубыйлар Шәркый Төркестанның Голҗа шәһәренә сөреләләр. Алар биредә кыз һәм ир балалар өчен мәдрәсәләр ачалар, дүрт ел буена (1913-1917 нче еллар) Голҗа халкына гыйлем-мәгърифәт тараталар.

1914 нче елның көзендә яңа «Нур» мәктәбе җәдитчә укыта башлый. Мәктәп белән бергә меңнән артык китап-журналлары



**Бер гасырдан артык элек ачылган татар мәктәбе**

булган «Нур кыйраәтханәсе» (китапханәсе) ачыла. Монда алдынгы карашлы татарлардан җыелган төрле эчтәлектәге китаплар, Оренбург, Казан якларында чыккан бихисап журналлар, газеталар, чит илдән кайтартылган төрки басмалар туплана.

«Нур» мәктәбендә сиксәнләп кыз укыганы билгеле. Алар арасында уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргыз, кытай, шибә кызлары да белем алган. Мәктәп кызлары традицион милли кием нигезендә тегелгән көрән төсле, ак якалы күлмәк, чигүле ак алъяпкыч, башларына энҗе-мәрҗән белән бизәлгән калфак, түбәтәй кигәннәр. Кытай халыклары өчен ят кием була ул. Чөнки бу чорда кызлар яулык бәйләп йөргән.

Башлангыч сыйныфларда кызларга татар әлифбасы, әдәбият, инша, «Мөгаллим сәни», әхлак тәрбиясе, тән тәрбиясе, җыр, кул һөнәрләре дәресләре кергән. Урта мәктәптә исә тел-әдәбият, алгебра, геометрия, ботаника, зоология, сәламәтлек саклау, тарих, астрономия, гарәп теле, тән тәрбиясе, шигырь, дин дәресләре укытылган.

Кызлар мәктәбендәге укытучылар тел-әдәбиятка аеруча игътибар биргәннәр. Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай шигырьләре нигезендә балаларда ватанны ярату, халыкны сөю хисләре тәрбияләргә, аларны әдәпле, гыйлемле итәргә омтылганнар. Шул чорда мәктәптә беренче «Тукай кичәләре» үткәрелүе дә мәгълүм.




**Элекке татар мәктәбендә укучы уйгыр балалары**

Уку программасы эчтәлекле итеп төзелгәнгә, мәктәпнең беренче төркем кызлары дүрт ел эчендә урта мәктәп программасын узып, укыту хокукына ирешәләр. Шулай итеп, Голҗадагы татар кызлар мәктәбе мөгаллимәләр әзерли торган уку йорты дәрәҗәсенә күтәрелә. «Нур» мәктәбен беренче кызлар төркеме 1917 нче елда тәмамлый. Мөнирә Вахит, Хәдичә Хәсәнева, Маһи Мохтарова, Мәликә Хәсәнева, Мәмдүхә Мохтаровалар Габдулла Бубый чәчкән мәгърифәт орлыкларын мөгаллимлек тәҗрибәләрендә гомер буе файдалана.

Олуг мәгърифәтченең Голҗадагы эшчәнлеге озакка бармый. Габдулла Бубый каты авырып, туган иленә кайтырга карар кыла. Ул үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «Голҗадан 1917 нче елда, майның берендә чыктым. Доктор Мәсгудь әфәнделәр, шәһәрдән 3-4 чакрым читтә, Йосыфҗан аксакал бакчасында бер хөрмәтләү мәҗлесе бирделәр. Уйгыр, нугай, кашгар, татар... озата чыккан кешеләрнең һичбер хисабы юк иде... Бигрәк тә, мәктәбебезнең ир вә кыз шәкертләребездән аерылу бик кыен булды...»

Габдулла Буби яшәгән чорларда һәм аннан соң да Голҗада гына түгел, Кытайның башка шәһәрләрендә дә заманча карашлы җәдит мәктәпләре, кызлар мәктәпләре ачылган. Бүген исә татар мәгърифәтчесенең: «Беренче чиратта кызларны укытабыз. Беренче

укытучы гаиләдә әни булыр», – дигән сүзләре Пекин дәүләт музееның Шенҗан мәгарифе бүлегендә саклана.

Бертуган Бубыйлар турында кыскача мәгълүмат. Бөтен дөньяга мәгълүм Иж-Бубый мәдрәсәсенең «көле» Әгерҗе районы Иж-Бубый авылында саклана. XX гасыр башында бертуган Гобәйдулла, Габдулла, Мөхлисә Бубыйлар нигез салган ирләр һәм кызлар мәдрәсәләре Русиядә дәрәҗәле уку йорты саналган. Габдулла Бубый биредә алдынгы уку ысуллары кертүгә, урыс телен өйрәтүгә ирешкән. Париж университетын тәмамлаган Гобәйдулла Бубый мәдрәсәдә укытучы булып эшләгән.

Мөхлисә Бубый исә Иж-Бубыйда хатын-кызлар өчен беренче кызлар мәдрәсәсен ачып җибәргән. Троицкига күченгәч, Яушевлар исемендәге кызлар урта мәктәбендә мөдир булган, төрле фәннәрдән укыткан. Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда Мөхлисә абыстайны Уфа мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенә казыя итеп сайлаганнар. Ул тарихка беренче һәм соңгы хатын-кыз казыя буларак кереп калган. Мөхлисә абыстайның гомере Троицки төрмәсендә өзелә: аны бер гаепсезгә атып үтерәләр. Хәзер акланган.

1936 нчы елда мәктәп Нугай каласында төзелгән яңа бинага күчә. Мәктәптә ун меңләп татар, уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргыз, хойзу, кытай, шибә кебек милләт балалары белем алган. Алар арасыннан күпләгән галимнәр, язучылар, мәгариф, дәүләт хезмәткәрләре чыккан. Татарча дәресләр 1959 нчы елда туктатылгач, мәктәп уйгыр башлангыч мәктәбенә әйләнә. Бүген ул – «Голҗа шәһәренең 6 нчы башлангыч мәктәбе».

Димәк, Голҗа татар мәктәбенең 110 еллык тарихы бар. Голҗа татарлары – Ильяр Габитов, Торсынтай Галиев, Гыйззәтулла Хәсәнов, Рифкәт Фәхретдиновлар белән мәктәп бинасына таба атлыйбыз. Күзебез капкадагы бик матур элмә тактага төште. Тактаның 2008 нче елның 6 нчы апрелендә куелуы күрсәтелгән, анда уйгыр һәм кытай телендә «Татар мәктәбе» дип язылган. 75 ел элек төзелгән аксыл төстәге мәктәпнең үзәк ишегендә – йозак. Уйгыр балалары мәктәпнең икенче «канатында» укый икән. Мәктәп сәркатибе Шәмсинур Әбдесәлам рөхсәте белән бина эченә уздык. Нинди тарихи бина! Биредә бит күпме татар зыялысы белем алган. Киң, озын коридор буенча мәшһүр академик Миркасыйм Габделәхәт улы Госманов укыган класска кердек. Якты бүлмәдә укып утыручы шаян уйгыр, кытай, казакъ балаларын, мөлаем укытучыларны күргәч, Миркасыйм әфәнденең без юлга чыгар алдыннан әйткән сүзләре искә төште: «Минем туган җиремә, укыган мәктәбемә бара калсагыз, барчасына да миннән күп сәлам җиткерегез! Хәерле юл сезгә, фидакарь сәяхәтче кызларым…»



**Татар мәктәбе янында**

Голҗа татар мәктәбен бетергән яшьләрнең күбесе чит илләргә барып, белем эстәп кайтканнар. Хәбиб Юнич, Малик Биктимер, Мәсгут, Мәхмүт һәм Мәхрүсә Аллаһйарилар ике-өч ел Төркиядә белемнәрен үстереп, аннары Германиядә укып кайталар. Нигезле белемне Голҗада алып, Алматы, Ташкент, Мәскәү югары уку йортларын тәмамлаган табиблардан – Шафика Садри, Шамил Таҗетдин, теш техниклары Нәҗат Ваһап, Австралиядә яшәүче шагыйрә Ләйлә Садри, Зөһрә Таҗетдин, Ришат Юмачиковлар, укытучылардан – Зәйнәп Габитова, Ильяр Габитов, рәссам Бәхтияр Табиев һ.б. әйтергә мөмкин.

Заманында «Тукай кичәләре» гөрләгән актлар залында милләттәшләребез әле дә әдәби кичәләр, Тукай көннәре, милли бәйрәмнәр уздыра икән. «Монда ата-бабаларыбыз рухы – татар рухы саклана», – диде алар. Тарихи залда уйгыр мәктәбе директоры, мөгаллимнәре белән бергәләшеп фотога төштек. Татар мәктәбендәге онытылмас хатирәләр күңелләребездә мәңгегә уелып калды. Ышанасы килә, бәлки киләчәктә Кытай хөкүмәте рөхсәте белән Голҗа татар мәктәбе бинасы ышанычлы кулларга – Татар җәмгыятенә тапшырылыр.

**Рәмилә Газизуллина**

# Остазларга ихтирам

*…Синнән алды белем татар баласы*
*Уйгыр, казакъ, кыргыз, дөнгән – барчасы.*
*Тәрбияләп әхлак, намус, оят илә*
*Армадың әйдәп белемнең арбасын.*
*Кайсы татар онытыр сине, остазым,*
*Кайсы татар башын имәс, остазым.*
*Тәңрем сиңа җәннәт түре биргәе*
*Ышанамыз иман илә, остазым…*
*Н. Госманова, «Остазыма», 2000 ел.*

Голҗа татар мәктәбе турында язганда, аның остазларын искә алу да кирәк. Экспедициядән кайтып, бу китапның язылуы инде төгәлләнеп килгәндә, юлыбыз Татарстанның Балтач районына төшкән иде. Белүебезчә, мондагы Сосна Пүчинкәсе авылы – Тукайның әнисе Бибимәмдүдә җәсәден сыендырган урын. Балтачлылар бу кабер урынын белеп яшиләр. Хәтта район хакимиятендә бер абзый: «Әнисе күмелгәнгә күрә булса да, Тукай ул безнеке дә!», – дип, кистереп әйтеп куйган иде. Алай гынамы соң?! Инде 1990 нчы елдан башлап Балтачта «Тукай көннәре» уздырып киләләр. Бу көнне Татарстан Язучылар Берлеге вәкилләре, Балтачның һәр авылыннан балалар, яшьләр, өлкәннәр, зыялылар, журналистлар, дин әһелләре, сәнгатькәрләр, галимнәр 194 йортлы Сосна Пүчинкәсенә кайталар. Мәчеттә Бибимәмдүдә һәм аның гаиләсен искә алып, рухларына дога кылалар. Каберенә чәчәкләр куялар. Субаш авылы мәдәният йортында шигырь бәйрәме уздыралар.

«Изге Тукаебызның әнисе шушы авылга килен булып төшкән. Җәмәгате вафат булгач, Мөхәмммәтшакир хәзрәт 1888 нче елның 22 нче декабрендә аның белән никахлашкан. Бу вакытта хәзрәткә 69, Бибимәмдүдә абыстайга 23 яшь булган. Сосна Пүчинкәсендә кыска гына гомер яшәсә дә, Бибимәмдүдә авыл кешеләре күңелендә якты истәлекләр калдырган. Авылның инде бакыйлыкка күчкән өлкәннәре аның бик чибәр булуын, күркәм моңлы-мәкамле тавышы белән бик тә тәэсирле итеп Коръән аятьләрен укуын, эшкә бик тә җитез, елдам булуын искә ала торган булганнар. Аның бик тә пөхтә киенүе, кешеләр белән ягымлы, итәгатьле мөнәсәбәте дә халык күңелендә. Ул кыз балаларны өенә җыеп дәресләр укыткан, аларны укырга-язарга

өйрәтүгә өстенлек биргән. Шигырьләр, бәетләр иҗат иткән. Кайбер истәлекләрдә Коръәнне укыганда ак перчаткадан булуы искә алынган. Күрәсең, шанлы Кышкар мәдрәсәсендә укып төпле-нигезле белем алган әтисе Зиннәтулла хәзрәтнең йогынтысы зур булган. 1970 нче елларда «Югары уңышка» район газетасы журналисты Риф Якупов, 1890 нчы елда вафат булган Бибимәмдүдә язмышын өйрәнергә кереште. Архив материалларын эзләп тапты, Мөхәммәтшакир хәзрәтне, Бибимәмдүдә абыстайны анык хәтерләгән өлкәннәр белән аралашты. Аларның ярдәме белән изге ананың кабере ачыкланды. Һәм бөек шагыйребезнең тууына 100 ел тулган көннәрдә Бибмәмдүдә каберенә архитектор Р. Билалов проекты буенча эшләнгән мәрмәр таш куелып, аның кабере төзекләндерелде. Мәрмәр ташта Габдулла Тукайның:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,

Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы… – дигән шигъри юллары язылган», – дип сөйләде Балтач зыялысы Гарифҗан Мөхәммәтшин.

Кытайдагы татар мәктәбе тарихын ерактан әйләнеп, Балтачка бәйләп яза башлавым юкка түгел. Нәкъ менә Балтач районында, дин эшлеклесе, мөгаллим Фәтхетдинов Кәшфеләсрар Фәтхетдин улы (Кәшфеләсрар бине Фәтхетдин бине Габделваһһаб бине Ишмөхәммәт бине Миңлеш) дөньяга килгән. Ул – Голҗаның «беренче һәм олы остазы», мондагы татар мәктәбенә нигез салучыларның берсе булган. Бу мәгълүматларны районның «аяклы тарихы» – Гарифҗан Мөхәммәтшин сөйләде. Гарифҗан әфәнде, читтәге милләттәшләребез кебек үк, үзе дә төбәк тарихын өйрәнеп, бихисап китаплар язган кеше. Аның инде юлы төшмәгән архивы, юк дияргә була. Балтачның ике томлы энциклопедиясен дә берүзе төзегән. Беренче томда – Кәшфеләсрар Фәтхетдинов та урын алган.

«Мөгаллим Кәшфеләсрар турында күп китапларда хаталы язалар. Миркасыйм Госманов, мәсәлән, «Ябылмаган китаб»ында аны Казан губернасы Малмыж өязе Пыжмара Пүчинкәсендә дөньяга килгән дип әйткән. Чынлыкта, Кәшфеләсрар хәзрәт Балтач районы Пархода авылыннан чыккан», – диде Гарифҗан әфәнде.

Ә географик ялгышның тарихы мондый: ул чорда хәзерге Мари Республикасына керә торган Пыжмара Пүчинкәсе – Яңа Пыжмара дип аталган. Балтачта да Пыжмара дигән авыл булган. Аның кешеләре икенче бер җиргә күченеп, Пыжмара Пүчинкәсе дигән авыл төзегәннәр. Әлеге авыл янында Хода дигән ике елга акканга, соңга таба аны «пар Хода», ягъни Пархода дип йөрткәннәр. Шактый вакыт үткәч, Пыжмара кешеләре хәзерге Мари Иле республикасы җиренә

күченеп тагын бер авыл салганнар. Аны инде Пыжмара Пүчинкәсе дип атаганнар. Миркасыйм абый, Назилә Госманова һәм башка авторлар, шушында буталып, Кәшфеләсрар хәзрәтне Балтачныкы итеп түгел, ә Мари Иле республикасы кешесе итеп язганнар да.

XIX гасыр ахырында төрле сәбәпләр аркасында Шәркый Төркестанга – ягъни Шенҗанга күпләп күченүчеләр арасында инде ир уртасы булган, тирән белем туплаган Кәшфеләсрар да булган. Аны Голҗаның бер мәчетенә имам итеп билгеләгәннәр. Тиздән ул мәчет каршында татар мәктәбе ачып җибәргән. 1911 нче елда Иж-Буби мәдрәсәсе ябылып, эзәрлекләүләр башлангач, Габдулла Буби да шушы якка килеп чыккан. Аның ярдәме белән бу мәдрәсә 1913-1914 нче елларда яңа ысуллы зур җәдиди уку йортына әверелгән.

Кәшфеләсрар хәзрәт Голҗа халкының танылган рухи җитәкчесе, лидеры булып киткән. Ул эшчеләрнең хокукларын яклау буенча зур эшләр алып барган. Эреле-ваклы предприятиеләрдә хезмәт шартларын яхшырту уңаеннан, капиталист Мусабаевларның күн эшкәртү заводы эшчеләре өчен атналык мәҗбүри ял көне булдыруга ирешкән.

Хәзрәт 57 ел буе имам, мөдәррис, мөгаллим, казый вазыйфаларын башкарган. Аның укучылары арасыннан күренекле кешеләр үсеп чыккан. Танылган галим, академик Миркасыйм Госманов та Кәшфеләсрар шәкертләреннән.

Кәшфеләсрар Фәтхетдинов 1957 нче елның 29 нчы мартында, йөз яшькә берничә генә ел кала, күп балалар һәм дистәләгән оныклар калдырып вафат булган. Аны Голҗа татар зиратында җирләгәннәр. «Җеназасына тирә-яктан ун меңнән артык кеше җыйналган, диләр. «Нинди күренекле шәхес чыккан бит безнең яктан!», – диде Гарифҗан Мөхәммәтшин.

Мин исә Гарифҗан әфәндегә Назилә Госманованың «Остазларга ихтирам» китабын тапшырдым. Шагыйрә ханым да бу шәхес турында эзләнүләр алып барган. «Голҗа халкы Кәшфеләсрар хәзрәтне беренче һәм олы остазы дип санаган. Голҗа халкы арасында гадел казый булуы белән шөһрәт казанганга, уйгур халкы аны Нугай Дамелла дип хөрмәт белән атаган», – диелгән әлеге китапта. Ә Гарифҗан абый Кәшфеләсрар хәзрәтнең фотосы Голҗада саклануына һәм мөгаллимнең тормыш юлын әле дә өйрәнүләренә гаҗәпләнде. Аңардан Кәшфеләсрар хәзрәтнең нәсел шәҗәрәсе һәм исән булган туганнары белән кызыксындым. Чөнки Гарифҗан Мөхәммәтшин үзе дә атаклы Үтәгән Уразмәтовлар нәселеннән. «Кызганыч, моңа әле кулым җитмәде. Тик атаклы шәхесебезнең гаилә тарихын өйрәнмәсәк – гөнаһ булыр», – диде ул.

Бу вазыйфа «Тукай фонды»на да йөкләнгән дип уйлыйм. Ни дисәк тә, әлеге остазлар булмаса, читтәге татарлар туган телен, Тукаен кемнән өйрәнер иде? Инде 1910 нчы елларда ук, әле шагыйрь исән чакта (!) Мөһиди атлы берәү Русиягә сәяхәт иткәч, Казан татарларының гыйлемле булуын күрә һәм иленә кайту белән заманавый мәктәпләр ачарга тотына. Бу эштә аңа Казанның татар зыялылары ярдәм итә. Ул вакытта Казан университетын тәмамлаган Хәйдәр Сайрани белән алты кеше Кытайга барып, уйгыр балаларын укытырга керешәләр. Назилә апа язуынча, җыр дәресендә алар Тукайның «Туган тел»ен, әдәбиятта – шигырьләрен өйрәнгәннәр.

Кытайда туып-үскән, хәзер Казанда яшәүче Фәрит Мөслимов исә – Кәшфеләсрар хәзрәт турында бабайлары сөйләвен ишетеп калган. «Зур хикмәт иясе Кәшфеләсрар Фәтхетдинов гаилә тазалыгы өчен дә борчылып яшәгән. Аның акыллы кеше булуы бигрәк тә никах укыганда күренгән. Никах – ул «Коръән тотып ант итәм, нинди генә кыенлыклар булмасын, үлгәнгә кадәр шушы никахны саклыйм», – дигән мәгънәне белдерә, дия торган булган остаз. Кызганыч, хәзерге никахларда муллалар бу йоланың асылын аңлатып бетерми дә төсле. Ә Кәшфеләсрар хәзрәт яшәгән заманда гаилә таркалуы – гайре сирәк күренеш булган. Чөнки хәзрәт тагын болай дип әйткән: «Талак – ул ир белән хатын аерылышканда өч тапкыр «талак» дип кычкыру гына түгел, ә өч төрле килешү төзү дә. Беренчесе – ир белән хатынның «аерылышабыз» дигән фикергә килүе. Икенче талак – ике як ата-ана, туганнарның бу аерылышуга килешүе. Өченче талак – ул мәхәллә имамының ризалыгы, аның: «Сез дөрес эшлисез, аерылыгыз», – дигән сүзе.» Кәшфеләсрар әүлия дә булган димме – яңа туган балаларны аерым журналга теркәп барган ул. Кешеләр Кытайдан күпләп күченә башлагач, бу журналны Совет Консуллыгына, алары аны – Мәскәүгә тапшырган. Шулай итеп, соңыннан метрика, паспортларын югалтучылар, Мәскәү аркылы бүген дә документларын яңадан эшләтәләр икән», – дип сөйләде Фәрит әфәнде.

Читтәге кардәшләрнең инде олы яшькә җитеп, югары дәрәҗәләргә ирешкәч тә, укытучыларына гомер буе баш иеп яшәүләре сокландыргыч хәл. Татарстанда остазларга кадер-хөрмәт юк дип әйтәсем килми. Быел Арча төбәге җитәкчесе Алмас Нәзиров, Буа районы башлыгы Рафаэль Әбүзәров, мәсәлән, үз районнарында Укытучыга һәйкәл куйдырдылар. 2010 нчы ел Татарстанда «Укытучы елы» дип игълан ителгән иде. Әмма үзе дә мөгаллимә, Кытайдагы бик күп татарларга кириллица язуы белән татар китапларын укырга өйрәткән Зөлфия ханым Чапаеваның сүзләре әле дә колагымда: «Остазларның да остазы була. Без – укытучыларның – илһам һәм белем чыганагы Тукай булды», – дип әйткән иде ул.

Тукай, чыннан да, инде бер гасыр буена милләтебезнең рухи остазы булып тора. Каләм, сәнгать әһелләре: «Тукайдан илһам алабыз,» – дип, аны үз мөгаллимнәре итеп күрә, иҗатын өйрәнә-өйрәнә, яңа шедеврлар тудыра. Киләчәк буынны да Тукайсыз яшәр дип тә әйтеп булмый. Тукай – ул һәр заманның классик остазы, милләтләр укытучысы. Ә классика, кем әйтмешли, ул әчеми дә, төчеми дә. Хәзерге заман мөмкинлекләре безгә – яшьләргә Тукайны, телебезне, тарихыбызны тагын да күбрәк, төрле яклап өйрәнергә яңа мөмкинлекләр бирә. Интернетта Тукайга багышланган сайтлар эшли. Шагыйрь әсәрләре дөньяның төрле телләрендә яңгырый.

Шагыйрьнең «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгы белән әле мәктәп бусагасында ук танышкан идем. «Остаз» дигән бөек исемнең асылына беренче тапкыр мин дә, Тукайны укыганда төшендем. Укытучы бит ул, кашык тотудан узмаган кулларга – ручка-дәфтәр тоттырып, бездән икенче Аристотель, Пифагор, Ньютон, Пушкин, Тукайларны тәрбияләүче… «Үземезнең яңа үсеп килмәктә булган милли әдәбият бакчамыздан җыеп, яшь балаларымыз кулына шуның чәчәкләреннән ясалган бер чәчәк бәйләме (букет) тоттырмак күптән үк безгә лазем иде. Монда төрле багъбаннарымызның хәссас күңелләрендә җитешкән әдәбият гөлләреннән берәр-берәр чәчәкләр алынды. Безгә, сабый балаларымызның кулында моңарчыга кадәрле булган әрекмән, кычыткан вә балтырганнарны алып, алар урынына шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирергә тиештер. Таки балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә ияләшсен. Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр», – дип яза Тукай «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» җыентыгында (1910 нчы ел). Аның нинди остаз булуы шушы юлларда ярылып ята кебек.

…Бу китапны язганда без дә көч-илһамны, белемнәрне Тукаебыздан алдык. Аның кебек, язуда яңа юллар, яңа фикерләр эзләргә тырыштык. Тукайчалап әйтсәк, «Русларның «вкуста шәрик юк» дидекләренчә, бәлки, минем бу язганнарымны (автор – *Г.Г.*) тәнкыйть итүчеләр булыр, ләкин мин андый кешеләргә алдан ук:

*Кара карлыгач буласың,*
*Кара камзулың кигәч;*
*Кеше теләсә ниәйтсен,*
*Үземнең җаным сөйгәч, –*
*дип җырлап кына җавап биреп куям».*

**Гөлназ Галимҗанова**

# Татар күгендәге сүнмәс нурлы йолдыз

*Алматыдан Кытайга чыгып киткәндә Торсынтай Габитов: «Минем туган якларга барасыз, абыйга сәлам әйтегез», – дип калды. Абыйсы Ильяр Габитов Голҗаның иң зыялы татарларыннан берсе икәнен ишетеп белә идек. Язмыштан шактый кыйналган, чал чәчле, әмма, күзләрендә һаман да яшьлек уты сүнмәгән әлеге абзый безнең белән очрашуга дип әзерләгән чыгышын куен дәфтәренә язып килгән иде. Соңыннан аны мәкалә итеп безгә – Казанга юллаган. Сәлам хатында «Тукай фонды»ның Голжага килүен мондагы татарлар өчен зур горурлык, шатлык дип бәяләгән.*

*Ә безнең ничек шатланганны һәм сезнең белән ничек горурланганны белсәгез иде сез кардәшләр! Сезнең милли рух безгә дә күчте. Татарның бетмәячәгенә тагын бер кат инандык. Ә милли рух, үзегез үк әйткәнчә, Тукай рухы ул.*

*Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ.*

*(Автор язмасындагы бүгенге әдәби тел нормаларына ятрак тоелган кайбер грамматик, стилистик үзенчәлекләрне махсус калдырдык).*

Колҗада, Абдулла Буби җитәкчелегендә, «эсул кәдими» укыту методын гамәлдән калдырып, «эсул җәдит» укыту методы белән танылган татар мәктәбе ачылгач, анда татар балаларын гына түгел, уйгыр, үзбәк, казакъ, кыргыз, дөңгән балаларын да укыта башлыйлар. Ул дәвер таләбе буенча кардәш милләтләр ача башлаган җәдитчә мәктәпләргә дә укытучылар әзерләнә.

Узган гасырның 20-30 нчы елларында Тукай шигърияте йогынтысында уйгыр прозасы барлыкка килде һәм бу өлкәдә Өмәр Мөхәммәди, Абдыхалык Уйгырлар аеруча танылды. 36-40 нчы елларда татар мәктәбендә укып, Тукай шигырьләре белән танышып, язган шигырьләренең үткерлеге белән танылган Лутбулла Метоллип Гоминдаң төрмәсендә һәлак була.

Абдулла Буби нигез салган мәктәпләрдә укып чыккан яшьләргә Габдулла Тукай шигырьләре бик нык тәэсир иткән. Һәр ел Колҗа халкы татар мәктәбендә үткәрелгән Тукай кичәләренә җыелган. Гадәттә,

монда «И, туган тел»не җырлаганнар, шигырьләр сөйләгәннәр, татар спектакльләре куйганнар… Шулар йогынтысында шәһәрнең хәзерге Тянь-Шань яки Хан Тәңре күчәсенә (урамына) Тукай исеме бирелгән. Бу хакта 2009 нчы елда басылган «Элә (Голҗа) тарихына катышлы хатирәләр» китабында Голҗа шәһәренең партком мөдире Исхак Басит менә ниләр язган: «Русиянең мәшһүр татар шагыйре Габдулла Тукай исеменә бирелгән бу урам 1963 нче елда янәдән Тянь-Шань, ягъни Хан Тәңре исеменә үзгәртелде. Ул хәзерге Галбият урамыннан башланып, Аэродром урамына хәтле дәвам итә»…

Колҗада хәзерге «Тянь-Шань» урамының узган гасырда Габдулла Тукай исеме белән аталуы да, Колжа халкының татарның бөек шагыйрен ни хәтле олылавына бер мисал түгелме?

Колжа татарлары сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның сәламәтлеге турында да бик кайгырткан. Аның үпкә чире авырлаша башлаганын ишеткәч, Колҗа татарларының аксакалы Хәйрулла улы Фазылҗан Юнич, Тукайны үзенә алдыртып, Элә (елга исеме – *Авт.*) җәйләүләрендә кымыз белән дәваларга уйлаган, ләкин бу эш насыйп булмаган. Тукай вафатыннан соң Колҗа татарлары һәр ел «Тукай кичәсе» уздырып, Тукайны искә алып киләләр. Тукай кичәләрендә «Шүрәле», «Өч хакикать» һәм башка поэмалары сәхнәләштерелеп, укылып торды. Шундый кичәләрнең берсендә әни Тукайның Клячкин хастаханәсендә ятканда иң соңгы төшкән фоторәсемен алып кайтып, безне атрафына утыртып, йомшак куллары белән мәрхүм Тукайның битләрен сыйпый-сыйпый: «Балаларым, инсан баласының олылыгы, аның хакыйкый гүзәллеге сырткы (тышкы) кыяфәтендә түгел, ә эчке дөньясында, һәрберәүнең эчке дөньясы аның эш-хәрәкәтендә, сүзендә чагылмый калмый. Бардыр шундый салафатлы белем ияләре, ләкин шәхсиятлеге белән алар кемгә кирәк, алардан халыкка ни файда? Белегез, эчкерсез, шәхсиятсез, бөтен барлыгын халкына биреп, милләт рухын яктыртып балкыган милләт кояшы ул Тукай. «Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта милләтем. Саулыгың – минем саулык, авыруың минем авыруым», – дип язган шагыйрьне халкы язмышы белән бәйле ачыну, көенү ялкыны яндырып, аны бездән алып китте. Ләкин «Тукай рухы татар өчен мәңге сүнмәс илһам ташкыны», – дигән иде мәрхүмә әни. Бу ташкын Көнбатыш төркиләрдән Көнчыгыш төрки булган уйгырларга хәтле барып җиткәнгә, Тукай иҗаты, гомумән, татар һәм төрки шигъриятенең меңъеллык үсеше дип танылa.

Күренекле казакъ галиме П.И. Исхаков: «Яңа гасыр таңында патша Русиясенең төрки халыкларына шул кадәр көчле һәм уңышлы йогынты ясаган кардәш әдәбият, бары тик татар әдәбияты гына, шагыйре бары



**Хәзерге Тянь-Шань урамы узган гасырда Габдулла Тукай исеме белән аталган**

тик Тукай гына булган». Тукай бөтен дөнья классикасы рәтендә абруйлы урынга лаек булган әсәрләрне барлыкка китерә алды», – дип язган.

Әнә шуңа күрә берләшкән дәүләтләр тәшкилатенең матди булмаган гайри мәдәният байлыкларын асырау органы 1986 нчы елны Тукай елы дип игълан иткән иде. Һәм дөнья буенча күпләгән илләрдә татар халкының бөек улы Габдулла Тукайга багышлап тантаналы кичәләр уздырылды. Менә инде 2011 нче ел Татарстанда Тукай елы дип игълан ителде. Олпат шагыйребез юбилеена минем дә шигъри күчтәнәчем бар.

**Татар күгендәге сүнмәс нурлы йолдыз**

Тым карангы җем-җем иткән күк йөзенә
Карыйсың да эндәшәсең үз-үзеңә:
Нәрсә күрәм! Аңа шаһит күкдәге ай,
Йолдызлар да сүнәме суң? Әйе, шулай:
йолдыз күчә икән, сүнә, күккә кара –
Инсаният дә туа, үлә – эзе кала.
Калган эзләр мактала, я каргыш таба,
Иктибарсыз үлән каплап, я югала.
Андый эзнең булганы ни булмаганы,
Үкенечле эз калдыра инсан аңлы.
Бер көн гомер күрсәң, булсын искә алырлык,

Иктибарлы инсаниятдә эз калырлык.
Шулай Тукай, хәтта, әҗәл тырнагында
*Менә нинди эз калдырган җырларында:*
*«Җырлый-җырлый үләрмен, мин, үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә*
*Мин китәмен, сез каларсыз, дип җырлармын,*
*Җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә».*
*Нинди ант бу!.. Баянаты белән Тукай*
*Хәстә килеш ятканда да хәтта шулай*
*Сакратда да рухы сүнми илһам аша.*
*Нинди горур нинди мәгрур бәхилләшә…*
*Шундый чиксез киң дөньяның тарлыгында,*
*Явыз язмыш, җәмгыятьнең хурлыгында*
*«Бетте көч, сынды кылыч…» – дип каурый очын*
*Төртте бугай сарыф итеп актык көчен.*
*Актык сулыш, актыкы рәт йөрәк тибеп,*
*Җан өзелде, күз йомылды, ялт-йолт итеп.*
*Ятимлеккә күзен ачкан тәүге көне,*
*Йолдыз булып күзен йомган актык төне.*
*Үтте, китте, ачлы-туклы һәм горурлы*
*Матбугатларда ялкынлы узган гомере.*
*Аралыгы шундый кыска, тынмас тургай.*
*Вакыт җитми нигә инде тындың, Тукай!?*
*Яшәр булсаң тагы купме язар идең,*
*Юк, үлмәдең, син яшисең – ага Идел.*
*Сулышларың агышында дулкынлана,*
*Ярларында син уйлаган таңлар ата.*
*Синең таушың яшәү маршы телдән-телгә*
*Яши күченеп, яңрый халкың белән бергә.*
*Шигъриятең – фикер атың юргасында,*
*Композиторлар баш вата нотасында.*
*«Туган тел»ең үз-үзеннән безнең гимын*
*Булып калды, анысыз узмый аш-су җыен.*
*Сәхнәләрдә сөйләнүдә синең эзләр.*
*Рәсемеңнән күз алалмый сансыз күзләр*
*Балачакта гәрчә булдың артык үксез,*
*Ә индече, син кадерле һәм дә тиңсез.*
*Елдан-елга яктырасың, даһи, шиксез,*
*Татар күгендәге сүнмәс нурлы йолдыз.*

***Ильяр Габитов. Кытай.***
***Колҗа шәһәре. 2010 нчы ел.***

# Ильяр абый мәктәбе

Габитовлар нәселен барлап, туганнары белән элемтәне ныгытып торган Ильяр абый бик катлаулы тормыш юлы үткән. Нинди генә авырлыклар килсә дә, татар икәнен, туганнарын онытмаган ул. Ильяр абый Кытайда яшәүче татарларның тарихын биш бармагы кебек белә. Ул – галим дә, шагыйрь дә, музыкант та. Аның хәер-фатыйхасы белән Кытайда туып-үскән йөзләгән татар баласы Казанда белем ала.

Ильяр Габитов – Кытайдагы «мәдәният инкыйлабы» корбаны. Нахакка гаепләнеп, тормышының иң гүзәл унсигез елын төрмәдә уздыра. Аңа ул вакытта нибары 25 яшь була. «Мин шагыйрь дә, музыкант та түгел идем. Йөрәктән тамган җырларымның күбесе – төрмәдә язылды», – ди ул.



**Ильяр Габитов**

Тау сәнәгате югары техникумын рус телендә тәмамлаганнан соң, Голҗа шәһәрендәге Совет консуллыгында вакытлы тәрҗемәче булып эшли Ильяр абый. Аннары – унсигез елга сузылган «тәмуг», сынау артыннан сынау, ачы күз яшьләре… Бу хәтле сынауларга адәм заты түзәр иде микән?! Яшь егетне татар теле, шигырьләре, гаиләсе белән күрешү, ата-бабалар җиренә кайту теләге яшәтә.

Язмыштан шактый кыйналып, иреккә чыккач та югалып калмый ул. Голҗа татарларын җыеп, 1996 нчы елда аэродром бакчасында сабантуйлары үткәрә башлый, рус мәктәбенә нигез сала.

Татар кешесенең Кытайда рус мәктәбе ачуы бер уйлаганда сәер кебек, чөнки милләттәшләребез гомер бакый кытайларга кытайчаны да, уйгырчаны да өйрәткән бит. Әмма Кытайда рус теленә ихтыяҗ арткан заманда, рус мәктәбе ачу зур мактауга лаек хезмәт! Шуңа күрә Ильяр Габитов нигез салган «Кульджинская городская русская школа» турында язуны урынлы саныйм.

Бүген Голҗа шәһәрендә рус гаиләләре аз яшәсә дә, һаман да Ленин һәйкәле тора, Сталин урамы бар. 1940-1950 нче елларда шәһәрдә өч рус мәктәбе эшләгән. «Гимназия», «Победа», «Сталин мәктәбе» дип аталган

алар. Бу мәктәпләрдә ике сменада татар, казакъ, уйгыр, үзбәк, шибә, рус балалары укыган. Кытайда рус мәктәбе программалары Советлар Союзының мәгариф программалары буенча барган. «Мәдәният инкыйлабы» чорында рус мәктәпләрендә дәресләр вакытлыча туктатылып тора. 1970 нче елга кадәр сузылган инкыйлаб тәмамлангач, Кытай хөкүмәте шушы елларда эшләгән хаталарын төзәтә башлый. Рус мәктәпләренең филиаллары ачыла. Ильяр абый да алтынчы урта мәктәп канатында оешкан рус сыйныфында мөдирлек итә. «Рус мәктәбенең мөдир, укытучы, сакчы вазифалары миңа йөкләнде. Кытай хөкүмәтенең милли сәясәтен гамәлгә ашыру мәктәбе иде ул. Монда йөрүче балаларның әти-әниләре ничек укытуны таләп итсә, мин шулай укытырга тиеш идем», – ди ул.

Бу мәктәпкә унсигез бала йөргән. Ләкин аларны ничек укытырга? Мәктәптә дәреслекләр булмаган. Ильяр абый Русиянең Кытайдагы консуллыгына мөрәҗәгать итә. Бер ел да үтми, Мәскәүдән бер машина уку әсбаплары, газета-журналлар, әдәби китаплар кайтарыла. Тора-бара рус мәктәбенә шәһәр тирәсендәге авыллардан да балалар килә башлый. Укучыларның күпчелеге ярлы гаиләләрдән була. Ильяр абый аларга яңа формалар тектерә. Шулай итеп, гади сыйныфтан башланган мәктәп Кытайда иң алдынгы рус мәктәбенә әверелә. Ильяр абый тырышлыгы белән әлеге мәктәп ике катлы яңа бинага күчә. Хәзер биредә 200ләп төрле милләт баласы укый. Мәктәп мөдире Лунев Николай Иванович исә Ильяр абыйның укучысы икән.

Ильяр Габитов – Голҗа татарлары арасында русчаны яхшы белгән бердәнбер кеше. Кытайдан Казанга килеп укучы татар балалары иң башта Ильяр абый мәктәбен үтә. Остаз аларга шактый гына урыслашкан Казанда югалып калмас өчен көндәлек рус сүзләрен, аралашу текстларын ятлата, шулай ук, татар теле һәм мәдәнияте серләренә төшендерә. Русиягә сәфәргә җыенган өлкәннәр дә мөгаллимнең өенә рус теле өйрәнергә килә икән. «Кытайда рус телен белсәң, зур дәрәҗә. Эштә дә аның кирәге чыга, Казанга барганда да. Ә татар теленә килгәндә, Кытайда яшәүче татарлар өчен татар теле – гаилә теле ул. Без аны элек-электән гаиләдә саклап киләбез», – диде Ильяр абый.

Татар мөгаллименең телләргә мәхәббәте нәселдән килгән, күрәсең. Ильяр абыйның әнисе Зәйнәп Габитова да укытучы булган. Голҗадагы татар, уйгыр, үзбәк, казакъ мәктәпләрендә озак еллар татар, уйгыр телләрен укыткан. Уйгыр мәгарифе тарихын яктырткан китапта (А. Талип. «Уйгыр мәгарифе тарихыннан») мөгаллимәнең эшчәнлегенә «Зәйнәп ханым» дигән махсус сәхифә багышланган. Хәзерге заман уйгыр зыялылары Зәйнәп ханымны «Зәйнәп ана» дип олылый.

Ильяр Габитов гаиләсендә бер генә таләп бар – татарча сөйләшү. Тормыш иптәше Гөлнур ханым, ике газиз баласы да ата сүзен кадерләп, өйдә татарча гына аралаша. Ильяр абыйның олы кызы Ильфира да мөгаллимлек юлын сайлаган – Голҗа педагогика университетында рус теле укыта. Ильдарлары Казан (Идел буе) федераль университетының юридик факультетында белем эсти.

Ильяр Габитов Голҗа татарларының атасы кебек: Кытайдагы татар тормышын җайлап, һәркемгә үз киңәшен, хәер-фатыйхасын биреп яши. Казанны сагынып, көн дә яңадан-яңа шигырьләр иҗат итә, алар еш кына җырга әйләнә. «Ватансыз ил булмас» җыры Казанның меңьеллыгында яңгыраган. Аны Ильяр абыйның укучысы Әхмәтҗан Торсынтай җырлаган:

*Ватансыз ил булмас һәм дә бәндә,*
*Булмый бит кыйбласыз хәтта Мәккә.*
*Кыйбла ул – мөкатдәс изге Кәгъбә*
*Тез чүгеп, күз йөртәм зәңгәр күккә.*
*Һавада йолдызлар сан-санаусыз,*
*Күңелемдә йолдызым бер син ялгыз.*
*Балкыдың, балкыйсың, балкы һаман*
*Татарның кәгъбәсе – Нурлы Казан!*
*Мең еллык чал башың күрәм япь-яшь,*
*Яшәртә тазарган нәсел каны…*
*Милләтнең дәвамы шундый алмаш*
*Җырларда яңгырасын Ватан даны!*

**Рәмилә ГАЗИЗУЛЛИНА**

# Габитовлар эзеннән…

*Яхшы булыр, тапшырсак без дөньяларны*
*Абразауный егетләргә имди.*
*Г. Тукай, «Дустларга бер сүз», 1905 ел*

Габитовлар… Кайсы дәвердә, нинди илләрдә яшәсәләр дә, милләтебезнең «тоткасы», абруе булган алар. XIX гасыр башында татар яшьләренең «Шимбәчеләр» түгәрәген башлап йөргән Зәйнәп һәм Рәбига Габитовалар, хәзер Алматыда яшәүче эшмәкәр Торсынтай Габитов, Голҗадагы милләтпәрвәр мөгаллим Ильяр Габитов, Австралиядәге шагыйрә Ләйлә Садри (Габитова) да күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәрәфетдин Габитов нәселеннән.

## Ширеп бай җилгесе

Габитовлар шәҗәрәсе Шахнар, Карасакал, Шәмәкү мирза, Госман Габитлардан башлана. Шәрәфетдин Габитов исә Габит бабайның үндүртенче баласы – сөекле төпчеге була… Язмыш җилләре Габитовларны төрле илләргә илтеп ташлаган. Бохара һәм Сәмәркандлар аша узып, XIX йөзнең беренче яртысында Идел буена, Казанга килеп чыкканнар. Аннары ерак Кытайдагы Голҗа шәһәрендә яшәп, XX гасырның 60 елларында – Алматыга, 70 елларда янәдән Казанга күченгәннәр.

Узган гасырда ук Шәрәфетдин Габитов Голҗадагы рус консуллыгында хезмәттә торган, күп кенә Көнчыгыш телләрендә сөйләшә алган. Аның Австралиядә яшәүче оныгы Ләйлә Садри хәбәр иткәнчә, Шәрәфетдин Габитов 1830 нчы елларда ук Голҗада сәүдә белән шөгыльләнә башлаган. Иң элек Караханилар солтанлыгы аны Голҗа каласына кертмәгән, ул сәүдәсен Элә елгасы буенда оештырган. Монда көнозын сәүдәләр кызган, ярминкә гөрләгән. Бу җирләрне Голҗа халкы әле дә «Ширеп бай җилгесе», ягъни «Шәрәфетдин бай елгасы» дип атый. Соңрак, Караханилар солтанының ышанычын яулаган Шәрәфетдин бай Голҗаның шул вакытта «Иске бистә» дип аталган татар каласын төзегән. Бередә яндырылган кирпечтән кырык лавкалы кибет салдырган. Аны халык хәзер дә «Ташләпкә» – «Ташлавка» дип йөртә икән. Күпчелек татар йортлары Ташләпкә тирәсендә булган. Шәрәфетдин хаҗи Голҗада мәгърифәт үсешенә дә үз өлешен кертә. 1885 нче елда Бәйтулла мәчетенең көньягында дүрт сыйныфлы мәктәп салдырып бирә. Бу мәктәп «Мәктәбе кәшфия» дип аталган.

Габитовлар нәселеннән, нигездә, күренекле сәяси лидерлар, җәмәгать эшлеклеләре, сәүдәгәрләр, мөгаллимнәр чыккан. Аларның алтын приискасы хуҗалары, бертуган Рәмиевлар белән туганлашуы да мәгълүм. Фатыйма Габитова Шакир Рәмиевка кияүгә чыккан. Аларның улы Әхмәтмидхәт Льеж техник институтын тәмамлап, озак еллар Бельгиядә яшәгән. Ә Фатыйманың туганы Харис Габитов Рәмиевләрнең Балкан төбәгендәге приискаларында баш идарәче булган.

## Габитовлар йорты

Шәрәфетдин Габитовның ун баласы булган: Әхмәт, Ситдыйк, Габдрахман, Габдулла, Хәдичә, Исмәгыйль, Гариф, Нурмөхәммәт, Зәйнәп һәм Рәбига. Никтер «Татар энциклопедиясе»ндә аның дүрт кенә баласы телгә алынган. Зәйнәп, Рәбига, Исмәгыйль һәм Гариф Габитовлар Казанда татар яшьләренең «Шимбә» түгәрәген оештыручылар буларак билгеле. Габитовларның Первая Горадагы (хәзерге Ульяновлар урамы)



**1906-1908 елларда «йорт уеннары»нда катнашучылар, уртада кара күлмәктән Зәйнәп Габитова**

йортына Мулланур Вахитов, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов, Хөсәен Ямашев, Шәриф Сүнчәләй, Газиз Гобәйдуллин, Ибраһим һәм Әбүбәкер Терегуловлар «йорт уеннары»на килә торган була. Алар катнашында 1903 нче елда биредә беренче татар спектакле куела.

Фатих Әмирхан татар театрының унъеллыгы уңае белән язылган «Сәхнәбезнең ун яше мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсендә, ул заманда бик популяр булган «йорт уеннары», «Шимбә» түгәрәгенең эше турында болай дип яза:

«Бу түгәрәкнең әүәлге татарча уены Гафифә ханым Габитованың Первая Гора урамындагы квартирасында булды. Хәтеремдә ялгыш калмаган булса, уйналган нәрсә «Кызганыч бала» иде…»

Татар сәхнәсенең бу дәверен сөйләгәндә Габитовлар гаиләсен, гомумән, Ибраһим абзый Терегулов гаиләсен һәм мәрхүм Шаһбазгәрәй Әхмеров балаларын әүәлге мәшариклар (катнашучылар – *Р.Г.*) вә әүәлге күңелле уенчылар буларак зикер итми (телгә алмый – *Р.Г.*) китәргә мөмкин түгелдер».

Фатих Әмирханның Габитовлар гаиләсенә аерым басым ясавы бик әһәмиятле. 1890 нчы елда Гафифә ханым балалары белән Казанга күчкәндә, гаилә башлыгы Шәрәфетдин Габитов инде үлгән була. Габитовларның уллары Гариф Казан университетын тәмамлый, соңрак

Кытайга китеп, патша Русиясенең Голҗа шәһәрендәге Баш консулы вазифасында тора. Исмәгыйль исә 1900 нче елга кадәр Казандагы «реаль» училищеда укый. Укуын тәмамлагач, Мәскәүгә күченә. Беренче рус инкыйлабыннан соң, Ташкент шәһәренә китеп, анда үзбәк телендә «Тәрәккый» («Прогресс») дигән газета чыгара башлый. Яңа карашлы газетаның беренче саны 1906 нчы елның 14 (26) нче июнендә басыла. Үзбәк милли матбугатының туган көне бу. Шул көннән башлап, газета редакторын җирле халык Исмәгыйль Тәрәккый дип олылаган. Туры сүзле «Тәрәккый» газетасы өч кенә ай чыгып өлгерә. Сталинның шәхес культы чорында контрреволюцион эшләрдә нахакка гаепләп, Исмәгыйль Габитовны Ташкент төрмәсенә ябалар. Аннары Краснояр краена сөргенгә җибәрәләр. Шуннан Исмәгыйль Тәрәккый эзләре юкка чыга… 1956 нчы елга кадәр ул «халык дошманы» санала. Габитовлар нәселеннән булган һәр кеше гел күзәтү астында торган.

Сәфәребез вакытында Шәрәфетдин байның оныкчыклары Торсынтай Габитов белән Ильяр абыйны очраткач, алар бездән Казанның Ульянов-Ленин урамындагы (элеккеге Первая Гора урамы) 31 нче йорт – Габитовлар йортын карап кайтуыбызны, югары даирәләрдән аның язмышы турында кызыксынуыбызны үтенгәннәр иде. Ильяр һәм Торсынтай Габитовлар ата-бабалары ватаны – Казанга беренче тапкыр 2003 нче елда килгәннәр. Татарстан президенты Минтимер Шәймиев белән эшлекле очрашуда Габитовлар шул йортта үз акчаларына ремонт ясап, анда мөһаҗирләр музее оештырырга, аннары аны Татарстанга бүләк итеп калдырырга теләүләрен җиткерәләр. Илбашы милләттәшләребезнең изге ниятен хуплаган, әлбәттә. Әмма беренче татар спектакле куелган тарихи йорт һаман да элеккеге урынында боегып утыра бирә.

Ике катлы, зур тәрәзле, шактый гына «йончылган» агач бина бу. Өй янында чүп басып киткән берничә сутый җир дә бар. Хәзер бу йортта ике яһүд гаиләсе яши, дип әйткәннәр иде. Монда күпме




**Голҗа зиратында Габитовларның ерак бабалары кабере**




**Рабит Батулла, Торсынтай һәм Ильяр Габитовлар, Рабин Сәфәргалиев Казандагы тарихи йорт янында**

барсак та, хуҗаларны очрата алмадык. Әллә безнең белән сөйләшергә теләмәделәрме?! Кем белсен…

Габитовлар йорты буенча милләттәшләребез әйткәнчә «югары даирәләр»гә мөрәҗәгать иткәч, эшнең тагын да катлаулана баруын сиздем. Мәдәният министрлыгының тарихи һәйкәлләрне саклау бүлегендә әлеге йортның бөтенләй башка исем белән аталуы, тарихи һәйкәлләр исемлегенә кертелгәне ачыкланды. Хәзерге вакытта Габитовлар йорты «Сухановлар усадьбасы» дип йөртелә икән. ТАССР Министрлар Советының 320нче номерлы карары нигезендә 1987 нче елның 27 нче июленнән Сухановлар йорты Татарстан Республикасының тарихи һәйкәле булып санала. Л. Девятыхның «Из истории казанского купечества» китабында Первая Горадагы (хәзерге Ульянов-Ленин урамы, 31) ике катлы агач йорт приказчик Мартирий Николаевич Сухановның шәхси милке булуы, аның бу йортны төрле кешегә арендага бирүе турында язылган. 1905 нче елда исә Сухановлар йортында РСДРП Казан комитетының кабул итү бүлмәсе урнашкан була. Архив материаллары күрсәтүенчә, Габитовларда Казан жандармериясе тарафыннан тентүләр ясалган. Шулай ук Сухановларда да тентү булганлыгы мәгълүм. Кыскасы,

бу йортка Габитовларның бер катнашы да юк, дигән сүз бу. Димәк, алар монда вакытлыча яшәп, вакытлыча «Шимбә» түгәрәкләре, беренче спектакльләр оештырган булып чыга. Первая Горадагы агач йортка кагылышлы кайсы гына китапны ачсам да, гел Сухановлар хакында язылган. Эзләнүләр мине Татарстан милли архивына китерде.

Бер ай буе Казан сәүдәгәрләренең 1880-1907 нче елларда төзелгән гаилә исемлеге, Казан гражданнарының йорт төзергә рөхсәт сорап язган гаризалары, шәһәрдә ачылган сәүдә йортлары турындагы документлар, Казан өязенең шәхси милек хуҗалары исемлеге һ.б. тикшерелде. Дөресен генә әйткәндә, бу китап өеменнән Габитов фамилияле дүрт кенә кешене таптым. Алар арасында Гафифә ханым да, Зәйнәп-Рәбига, Гариф-Исмәгыйльләр дә юк иде. Юк! Архив фондларын караганда юнәлеш биргән белгеч Хәсәншина Ләйлә Җәүдәт кызы да, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты галиме Зөфәр Мөхәммәтшин да аптырады моңа. Галимнәр өчен дә чын табышмак иде бу!

Дүрт Габитов та 1906-1907 нче елларда теркәлгән (119 фонд, опись 1, №1047) «җир салымын түләү өчен бирелгән оклад битләрен алган Казан шәһәренең йорт хуҗалары исемлеге»ндә табылды. Менә алар: Габитов Гыйсмабетдин, Габитов Исхакъ, Габитов Билалетдин һәм Габитов Мөхәммәтситдыйк. Мөхәммәтситдыйк дигәне Шәрәфетдин бабайның улы, Торсынтай Габитовның бабасы түгел микән? Шулдыр… Кытайда яшәүче милләттәшләрдән Ситдыйк хаҗи Габитовның Казан белән элемтәдә торуы, XVIII гасыр ахырында үз акчасына башкаладан атаклы татар рухание Кәшфеләсрар хәзрәтне Голҗага чакыруы һәм аны татар мәдрәсәсенә мөгаллим итеп куюы хакында ишеткән идем. Архив материаллары аның Казанда арендага фатир алып торганын, соңрак үз йортында яшәгәнен раслый. Тарихи журналларның берсендә Ситдыйк Габитовның 1907 нче елның 11 нче апрелендә Заводская урамында урнашкан шәхси йортына 15 сум салым түләгәне күрсәтелгән, имзасы да куелган. «Мухаметъситдикъ Габитовъ» исеме 1880 нче елгы арендаторлар исемлегендә дә (98 фонд, 3 опись, №11) бар. Монда ул Казанда фатир «снимать» итеп яшәгәнгә салым түләп, унөченче кеше булып имзасын куйган.

Эзләнә торгач, Мөхәммәтситдыйк Габитовның адресы да табылды: Заводская урамы, 8-165 нче йорт, 241 нче фатир. Архив мәгълүматлары буенча, бу агач йорт 1916 нчы елга кадәр Ситдыйк хаҗи исемендә булган. Элеккеге Заводская – хәзерге Тинчурин урамы ул. Шул чорда биредә Габитовлар янәшәсендә Хәлфиннәр, Әхмәровлар, Ваһаповлар, Давытовлар, Аитовлар да гомер кичерә…

Димәк, Габитовларның Казанда үз йортлары булган. Ул сакланып калганмы? Хәер, бүгенгә кадәр мөһаҗирләр музее була алмаган

Габитовлар йортының язмышы да, бу татар гаиләсенең тагын бик күп серләре дә билгесез калды миңа. Димәк, архивта эзләнүләрне дәвам итәргә кирәк. Габитовлар темасы ачык кала әле…

**Рәмилә Газизуллина**

# Милли моңнар яңгырый әле

*«…безнең халыкта җырлар өчен әүәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. Әүәлге ике юл анчак, скрипка уйнаганда, бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер».*

*Г. Тукай.*

Кытайдагы татарлар – җырлы-моңлы халык. Аларның бер бәйрәме дә татар халык җырларыннан, дәртле биюләрдән башка узмый. Бергә җыелган вакытларда «Агыйдел буйлары», «Күзләрең», «Баламишкин», «Сарман», «Казан кичләре» кебек җырларны яратып җырлыйлар, аннары барысы да «Атнушка»га тыпырдый. «Атнушка» – Кытайда яшәүче татарлар арасында киң таралган татар биюе икән. Бездәге татар биюләреннән аермалы буларак, ул бераз рус биюләренә охшаган. Милләттәшләребез аның Татарстанда онытылуын, Кытайда әби-бабайлардан сакланып калган татар биюе булуын горурланып сөйләде.

Ә мондагы татар җырлары хакында аерым диссертация язарлык! Кытайда татар халык җырларына багышланган өч китап дөнья күргән. Бәлкем, алар тагын бардыр әле. Минем кулга килеп эләккән өч китап та – уйгыр телендә. Әлеге басмаларның авторы – Кытайда яшәүче сәнгать белгече, гармунчы Гарифулла Шәриф. Күрән төстәге беренче китап 1984 нче елда басылган. Анда 151 татар җыры тупланган. 1988 нче елда чыккан икенче басмада – 168 җыр бар! Өченчесендә исә милләттәшләребез яратып башкара торган «Галиябану», «Иске кара урман», «Рәйхан», «Хафизәкәй», «Сарман», «Әпипә», «Рамай», «Зөләйха», «Фирдәвескәй», «Баламишкин» җырларының ноталары да бирелгән.

Чүгүчәк шәһәрендә яшәгән Нәҗметдин абый Хәсәнов та гомере буена халык җырларын туплаган. Халыктан сөйләтеп, бөртекләп җыелган татар җырлары биш мең куплетка җиткән! Алар халкыбызның әйтеп бетергесез милли хәзинәсе. Һәм иң үкенечлесе шул: бу җырлар әле

беркем тарафыннан да өйрәнелмәгән. Чүгүчәктәге милләттәшләребез татар халык җырлары тупланган берничә диск та чыгарган. Гаҗәп: чыгымнарны Кытай хөкүмәте каплаган. Татар мәдәниятенә олы ихтирам билгесе бу. Бездә ул дискларның өчесе бар. «Бүләк» исемлесе – Нәҗметдин абый гаиләсенеке. Монда аның бөтен гаиләсе чыгыш ясый: балалары Исаметдин – тальян гармунда уйный, Хәерттен белән Мәдинә җырлый, оныкчыклары бии. Бу дискта күңел кылларын тибрәтә торган салмак җырлар да, дәртле такмаклар да, заманча татар җырлары да, гармун, курай моңнары да бар. Хәерттен Хәсәнов башкаруындагы «Азалия» җырын Габделфәт Сафин ишетсә, шаккатыр иде! «Азалия» Кытайда бик популяр икән. Мәдинә Хәсәнованың «Либи-либи Җамал», «Туганнар» җырлары да бик үзенчәлекле башкарыла. Аның «сандугач тавышы» җырга аерым мәгънә өсти кебек.

Ак күгәрчен канатына
Исәнлекне язамын?
Бәхет-шатлык арасыннан
Туганнарны табармын.
Туганнарны уйлый-уйлый
Күземнән яшь түгелә…
Башыма күп моң төшкәндә
Минем күңлемне кем белер?!
Язылачы көйләремдә
Чәчим микән алмадан?
Туганнарга бәхет телим
Яратучы Алладан.

Хәсәновлар дискындагы унике җыр арасында кызыклы исемле «Лимонад» дигән җыр да бар. Милләттәшләребез аны үзләренчә «Лимана-а-ат» дип, дәртләнеп туй мәҗлесләрендә суза икән:

1. Самавырлар котлы булсын,
Чәйләре сөтле булсын!
Җырым белән тәбрик итәм –
Туйлары котлы булсын!
Кушымта: Ай-һай, лиманат!
Сусаганда эчәргә…
Сагынганда барыр идем
Юк канатым очарга.
2. Әй угыз, угыз,
Кемдә сезнең угыз?!
Үзеңне сөйгән җегет белән
Бергә булсын туегыз!



**Нәҗметдин абый гаиләсе җырсыз яши алмый**

Ә Нәҗметдин абый башкаруындагы «Гөлкәй», «Озату», «Әти-әни» кебек «бәгырь җырларын» ишетсәң, еламый түзеп булмый…

Күрдем Голҗаның каласын,
Алдым былбыл баласын.
Әти-әнине рәнҗетсәң,
Хәсрәт чигеп каласың.

«Җырла-бие» дип исемләнгән икенче дискта Чүгүчәк татарларының «каймагы» күңелнеачa. Милләттәшләребез биегән шаян биюләргә, алар кигән затлы милли киемнәргә, бизәкле читекләргә карап туймаслык. Милли кием дигәннән. Кытайда һәр татарның үз милли костюмы бар. «Казаннан күреп кайтабыз да, үзебездә тагын да зәвыклырак итеп татар калфаклары, бизәкле читекләр, бәбәй итәкле матур күлмәкләр тегәбез», – ди алар. Сабантуй, Нәүрүз бәйрәмнәренә, татар туйларына барысы да калфак-түбәтәйдән, милли киемнәрдән килә икән. «Җырла-бие» дискында «Цыганочка», «Сагыну», «Ризык», «Күзләрең», «Казан кичләре», «Баламишкин» һәм башка җырлар бар.

Милләттәшләребез җырлавы бездәгедән бераз аерыла. Мисал итеп, «Баламишкин»ны алыйк. Габдулла Тукайның «И, туган тел»е Голҗа татарларының гимны булса, «Баламишкин» – төп җырлары икән. «Бездә бер бәйрәм дә «Баламескен»сез узмый», – ди милләттәшләребез. Игътибар иткәнсездер, алар аны «Баламескен» дип әйтә. Кытайдагы «Баламишкин» шаянрак, тиз җырлана. Җыр сүзләре дә үзгә: милләттәшләребез уйлап тапкан такмаклар белән үрелеп бара:

1. Мескен көе, Мескен көе,
Мескен көе күңелле.
Мескен көйләренә җырлап,
Күтәрәек күңелне!
2. Мескен көе, Мескен көе,
Мескен көен яратам,
Мескен көйләренә җырлап,
Бар хәсрәтне таратам.
3. Баламескен суга баткан
Егерме биш яшендә,
Суга батса да үлмәгән
Иптәшләре каршында.
4. Мескен көен уйнаганда
Җырлый торган гадәтем.
Җырым белән тамагымның
Аллаһ бирсен мәдәтен (куәтен).
5. Дөнья, дөнья, и, димәгез!
Дөнья гамен имәгез,
Дөнья өчен уфтансагыз,
Рәхәт күрәм димәгез…

Голҗа татарлары «Каз канаты», «Сагыну», «Күзләрең» кебек популяр җырларны да башка көйгә салган. «Каз канаты» ничектер дәртлерәк итеп җырланса, «Күзләрең»нең көе – руснкы. Безнең мәҗлесләрдә «Күзләрең» кебек татар халык җырын очратмассың! Дәртле, мәгънәле гашыйклар җыры икән ул:

1. Күзләреңне, күзләреңне,
Күзләреңне күзләдем.(2 тапкыр)
Күзләреңне күзләгәндә
Күзләреңне сизмәдем.
2. Күзләреңдә бармы магнит?
Син гел үзеңә тартасың.
Күзләреңне миңа тартып,
Син тагын саргайтасың.
3. Күзләреңне, күзләреңне,
Күзләреңне карыймын.
Күзләреңә генә карап,
Керфегеңне саныймын.
4. Иркәм, иркәм, ай, гүзәлем!
Кайда баскан эзләрең?
Эзләреңне эзли-эзли
Күрмәс булды күзләрем.

Милләттәшләребезнең туй мәҗлесләреннән төшмәгән «Цыганочка» җырының көе дә элек Голҗада күпләп яшәгән руслардан үтеп кергән, күрәсең. Алар аны яратып «Сөйгәнечкә», диләр:

Уйна, дускай, гармуныңны,
Көйлә тургай көйләргә.
Уйный дустым, кайта җырлап,
Белә торган көйләргә.
Сез уйнаган, без җырлаган
Калды сагынып сөйләргә.
Кушымта: Цыганочка, цыганочка, цыганочка ты моя…

Голҗа татарлары Кытайда үткәрелүче җыр-бию фестивальләрендә катнашып, татар халык җырларын башка милләтләргә дә танытып тора. 2004 нче елда Шенҗанда 56 милләтнең җыр фестивале узган. Милләттәшләребез монда да сынатмаган: «Бер егет гармун сайлый» җырын башкарып, гран-прига лаек булганнар. «Кырык көн әзерләндек бу бәйрәмгә! Килгән тамашачыны дәртләндереп, тальян гармуннар белән чыктык. Яшьрәк егетләр уйнады, мин җырладым», – диде Торсынтай Галиев. Кытайны гына түгел, 2011 нче ел яз көне ТорсынтайГалиевҗитәкчелегендәге кызлар-егетләр төркеме «Татар моңы» сәхнәсен «дер» селкетте. Алар «Баламишкин» көенә театральләштерелгән җырлы-биюле тамаша күрсәтеп, «Татар моңы» конкурсы лауреатлары булдылар!


**Нәҗметдин абый Хәсәнов**

Кытайның кайсы «татар утравы»на барып чыксак та, безне милләттәшләребез гармуннар, күңелгә якын милли моңнар белән каршы алды. Без Кытайда үзебездә сирәк яңгыраган халык ядкарьләрен дә, яңача көйгә салынган татар җырларын да ишетеп кайттык. Иң сөендергәне – монда һәр кичә Тукай байрагы астында уза. Хәзерге заман яшьләренә татар телен өйрәтүнең менә дигән чарасы бу! Тукай әйткәнчә, халык җырларын «туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар сәламәт әле, алар яңгырый әле»…

**Рәмилә Газизуллина**

# Торсынтай кәнетендә

*Әйдә халыкка хезмәткә,*
*Хезмәт эчендә йөзмәккә.*
*Г. Тукай, «Мәдрәсәдән чыккан*
*шәкертләр ни диләр?», 1907*

Милләттәшләр белән Голҗа киңлекләрен күзәтәбез. Элә елгасы дулкыннары ташларга бәргәләнеп, күңелләрне күтәрә. Элә елгасыннан сузылган тарихи күперне кичсәң, табигать кочагына килеп эләгәсең. Шәһәр читендә кечкенә авылларга охшаган шәхси хуҗалыклар урнашкан. Кешенең хуҗалыгы яки бакчасы уйгырча «итезлык» дип атала. Торсынтай Галиевнең да монда үз итезлыгы бар. Милләттәшләребез аны «Торсынтай кәнете (авылы)», дия. Чынлап та, ишегалдында йөгерешкән тавык-чебеш, каз-үрдәк, дүртпочмаклы таш йорт, сарайлар бәләкәй генә авылны хәтерләтә. Бакчада кабак, кыяр-помидор, кытай кәбестәсе, карбыз, алма, груша агачлары, кукуруз, бодай үсә. Уңышны җыеп алгач, аны Казакъстанга, Русиягә илтеп саталар. Ә алмагачлар арасында үсүче люцернаны күргәч, тел шартлаттык. Кытайда бу үсемлек нигә инде? Голҗа татарлары аны «ялпуз» дип йөртә. «Сез Татарстанда ялпузның кадерен белеп бетермисез. Ул сәламәтлеккә бик файдалы: кан басымын төшерә, организмны чистарта. Аны бер ашасаң, ел буена авырмыйсың», – диделәр безгә. Люцернадан милләттәшләребез пилмән, төрле тәмләткечләр ясыйлар икән. Кызганыч, без килүгә бакчадагы карбызны җыеп алганнар иде. Торсынтай әфәнде безне шәһәр читендәге башка итезлыкка алып барды. Басуда рәхәтләнеп кытай карбызлары җыйдык! Алар вак, әмма бик сусыл һәм баллы була икән.

## Гали белән Вәли кыйссасы

Торсынтай Галиев – сәүдәгәрләр нәселеннән. Нәсел җебе Татарстанның Арча районына барып тоташа. 1892-1894 нче елларда бертуган Гали белән Вәли Арчадан Кытайга барып чыга. Гали Голҗада сәүдә белән шөгыльләнә башлый, ә Вәли Кытайның Харбин шәһәренә хәрби хезмәткә китә дә, эзсез югала. Аның язмышы һаман да билгесез. Шулай итеп, Гали белән Вәли кыйссасыннан башланган Кытай тормышында Галиевләр нәселе ике гасырдан күбрәк гомер кичерә. Гали-Әхмәт-Хәлил-Торсынтай… «Мин Кытайда дүртенче буын татар. Ничек кенә булмасын,



**Голҗа татарлары тату гаилә кебек**

күңел туган якка – Арчага, Казанга тарта. Арчадагы туганнарымны эзләп табасым килә», – ди Торсынтай әфәнде.

Галиевләр гаиләдә ун бала үскәннәр. Әтиләре Хәлил Голҗа мәдәният идарәсендә эшләгән. Аны шәһәр халкы Хәлил Нугай дип йөрткән. Ул язучы, шагыйрь, мөхәррир дә булган. Әмма «мәдәният инкыйлабы» Нурниса ханымны – ирсез, ун нарасыйны әтисез калдыра. 13 яшьлек Торсынтай эне-сеңелләрен туйдырыр өчен көн-төн төзелештә эшли. Әтисенең: «Беренче чиратта туганнарыңа, үз милләтеңә яхшы эш эшлә, башка милләтләргә дә ярдәм ит», – дигән сүзләрен истә тотып, бертуганнарын аякка бастыра ул. «Иң элек дүрт сеңлемне югары уку йортларында укыттым. Гаиләдә хатын-кыз белемле булса, туачак балалар өчен яхшы бит. Айгөл, Лилүфәр, Айнур – укытучылар, Рәмилә Америкада банкта эшли. Энеләрем дә тормышта үз урыннарын тапты», – дип, горурланып сөйләде милләттәшем. Горурланырлык та. Дулкын – Норвегиядә, Җәлил – Голландиядә, Ялкын – Казакъстанда, Иркен Кытайда яши, барысы да югары белемле. Торгыш исә оста гармунчы булган. Хәзер ул якты дөньяда юк инде… Урыны җәннәттә булсын.

## «Татар ялкау булмаган»

«Татар халкы тәмле сүзле, якты милләт, кайда яшәсә дә булдыра. Татар ялкау булмаган», – дияргә ярата Торсынтай әфәнде. Кытайда яки башка чит илләрдә яшәүче милләттәшләрен күз алдында тотып әйтсә дә, бу юллар аның үзе турында. Кытайда үз бизнесын булдырган, шәһәр Думасында депутат. Ялкау татар шундый үрләргә менеп җитәр иде микән?!

«Эшмәкәрлекне Кытайда берничә базар ачудан башлап җибәрдем. Аннары – беренче хәләл ресторан. Кытайда ресторан ачу бик авыр, мәшәкате дә күп. Биредә туйларны, туган көннәрне хәмерсез уздыра идек. Хәзер Голҗада чат саен хәләл кафе яки ресторан. Тора-бара ресторан эшен ташлап, башка эш белән шөгыльләнә башладым», – дип, искә алды ул. Голҗада әле дә «беренче хәләл ресторанны татар китерде», диләр икән.

Торсынтай Галиев депутат булгач, Голҗа татарларының борчу-мәшәкатьләрен хәл итеп, җайлап кына тора. Әйтик, ел да сабантуй уздыру өчен шәһәр хакимияте акча бирә икән. «Кытайда иң яхшы сабантуй Голҗада үтә. Бер атна кала татар гаиләләреннән сөлге җыябыз. Хуҗабикәләр өчпочмак, чәк-чәк, гөбәдия пешерәләр. Бәйрәмебездә төрле милләт кешеләре катнаша. Гадәттә һәр елны бисмилла әйтеп, бозау суябыз һәм сабантуй кунакларын сыйлыйбыз. Сабантуйларын элек-электән хәмерсез уздырабыз. Шулай итеп балаларыбызны аракысыз, сырасыз тәрбиялибез», – ди депутат.



Кытай хөкүмәте татарларны бик хөрмәт итә икән. Шуңа күрә татар балаларын Пекин, Шанхай университетлары 6-7 ел бушка укыта. «Балаларыбыз монда укыса, хезмәт тә әзер. Ә без аларны татар мәдәниятен өйрәнсеннәр дип, акча түләп, Казанга җибәрәбез», – ди милләттәшем. Торсынтай әфәнденең ике баласы – Әхмәтҗан белән Гөлмирә дә Казанда белем ала.



## «Иң яратканыңны кешегә бир»

Галиевләр йорты Милләтләр гореф-гадәтләре урамында урнашкан. Капкадан керүгә йөзем бакчасына эләгәсең, аннары биек баскычлардан өйгә күтәреләсең.

Хан сараена килеп эләктекме соң – бүлмә эчендә бүлмә! Беренче катта кунак, аш, тәһарәт, намаз бүлмәләре булса, икенче катта – Торсынтай әфәнденең эш бүлмәсе һәм йокы бүлмәләре. Тыныч, рәхәт монда, барысы да татарча сөйләшә. «Кечкенәдән балаларыма өйдә татарча сөйләшегез, дип өйрәттем. Минем белән татарча сөйләшмәсәләр – эндәшмим. Минемчә, кырыс кешедән әйбәт бала чыга. Әти дә шундый иде. Безне якшәмбе көнне кичке алтыдан тугызга кадәр генә урамга чыгара иде. Башка көннәрдә урамда йөрим дип авыз да ачмадык, эшләдек. Эш булмаган гаиләдә – тәртипсезлек», – диде Торсынтай әфәнде. Хөршидә ханым исә милләте буенча үзбәк, бик дини хатын. Балалары Гөлмирә, Әхмәтҗан, Гөлзирәне ислам дине кушканча әтиләрен олыларга, хөрмәт итәргә өйрәткән. Балаларына күз тимәсен: тугыз яшьтән намаз укыйлар, ураза тоталар, әти-әниләрен ихтирам итеп «Сез» дип дәшәләр…

Гөлмирә Казан федераль университетының юридик факультетында 5 нче курста укый. Ата-ана хакын яхшы белә ул: «Гаиләдә әти сүзе һәрчак

баш булды. Аның ачуын чыгарудан куркабыз. Әти-әнигә беркайчан да үпкәләргә ярамый, алар безнең бәхет өчен тырыша бит», – ди.

Әхмәтҗан Торсынтай Казан тамашачысына шактый таныш. Үзенчәлекле уйгыр, татар халык җырлары белән җыр-моң сәхнәсенә килеп керде ул. 15 яшьлек Гөлзирә исә Голҗаның югары мәктәбендә укый, абыйсы һәм әтисе кебек бик матур итеп җырлый.

«Дингә керсәң, рәхәтләнеп яшәрсең, күңелләрең чистарыр, йөзең ачык булыр, дия иде әти. Аллаһка шөкер, инде ун ел биш вакыт намазымны калдырмыйм, ураза тотам. Елда мохтаҗларга зәкят бирәбез. Казанга баргач, Кол Шәриф мәчетендә Рамил хәзрәт Юныс вәгазьләрен тыңларга яратам», – ди Торсынтай әфәнде. Иң яратканыңны кешегә бир! Әтисенең бу зирәк сүзләрен онытмый ул. Мәктәп-мәдрәсәләргә, мәчетләргә, мохтаҗ уйгыр, татар, үзбәк, дөнгән балаларына ярдәм итә. Башкарыласы эшләре әле шактый: Голҗада Татар мәчете төзетү, Татар җәмгыятен биналы итү, Казанда профнастил заводы ачу, кызларны кияүгә бирү, малайны өйләндерү… Кыскасы, Торсынтай Галиевкә исәнлек-саулык бирсен Ходай!

# Әйдәгез, вальс биергә!

«Бездәге халык иртән йоклап ятмый, «Халык паркы»на җыела», – дигәч, гаҗәпләнгән идек. Бер көнне тәвәккәлләдек тә, Рифкәткә ияреп шунда киттек.

Иртәнге 5:00. Бөтен җиһан шау-гөр килә! Урам буйлап йә капчык, йә чиләк тоткан хатыннар, сәпитенә арба таккан ирләр агыла. «Кая бара бу халык?», – дим Рифкәткә. Базарга икән. Бераз атлагач, без дә урамның буеннан-буена сузылган иртәнге базарга төртелдек. Рифкәт әйтүенчә, Кытайда өч төрле базар бар. Иртәнге базар таң белән 5тән – 8гә кадәр эшли, көндезгесе – 10нан – 18 сәгатькә кадәр, төнге базар исә 20:00дән – 24:00гә кадәр.

Иртәнге базарда кытайлар күбесенчә яшелчә, азык-төлек сата. Кып-кызыл борыч, кытай кәбестәсе, борчак, дөге, кукуруз, карбыз-кавын, ташкабак, парда пешкән бәрәңге, тозланган помидор-кыяр, яңа гына мичтән чыккан кытай икмәге му-му, тәмләткечләр, төрле җимешләр – барысы да бар монда. Бик арзанлы базар икән бу. Әйтик, кызыл борычның килосы 1 юань, безнеңчә 4 сум 50 тиен тора.

«Халык паркы»на җитәрәк, милләттәшебез йөзьяшәр имәннәрне күрсәтте. Бөтен Кытайга бер икән алар! Татарлар өчен бик кадерле





имәннәр бу. Аларны Газраил исемле татар сәүдәгәре Казаннан алып кайтыпутырткан,ди.Берничәелэлекшәһәрхакимиятеюлларныкиңәйтү максатыннанбуагачларныкисәргәдигәнкараркабулитә.Әлегехәбәрне ишеткән милләттәшләребез бик борчыла, бергә җыелып, «бабайлар хәтере»н саклап калуны үтенеп, Голҗа җитәкчелегенә мөрәҗәгать итәләр. Кыскасы, хакимият горур имәннәрне саклап кала. Алар бүген дә милләттәшләребезгә Казанны хәтерләтеп, «серләшеп» утыралар.

«Халык паркы»на уздык. Парктагы агачларны да Моталлиб исемле татар кешесе утырткан икән. Монда тормыш кайный! Бер тирәдә олы яшьтәге апалар, абыйлар вальс бии, икенче җирдә – кунг-фу белән шөгыльләнәләр. Берәүләр тренажерларда мускуллар ныгыта. Менә хикмәт: бездә кеше иллешәр мең түләп, фитнес клубка йөри, ә бiредә тренажерларны табигать кочагына – паркка урнаштырганнар. Безгә Кытайга җиткәнче әле… Тәртип ягыннан бигрәк тә калышабыз. Паркта, җәмәгать урыннарында җирдә аунап яткан бер чүп-чар да тапмассың.

«Халык паркы»нда нинди генә күнегүләр ясамыйлар. Агачлар арасында бер төркем кешенең җырлаганын күреп алдык. Үпкәләрен сәламәтләндерәләр икән. Берәүләр йөгерә, берәүләр кылыч белән уйный. Кунг-фу белән шөгыльләнүче Хуан Ванг исемле кытайлы янында тукталдык. «Үземне белгәннән бирле иртәләрен кунг-фу белән



**Берәүләр йөгерә, берәүләр кылыч белән уйный**

шөгыльләнәм. Күптән түгел кылыч белән күнегүләр ясый башладым», – ди ул. Кызык өчен танышыбызның ничә яшьтә икәнлеген сорадык. Миңа әле 70 кенә, ди. Егылып китә яздык. Ә без аңарга 40 яшь биргән идек…

Яши беләләр Кытайда! Иң мөһиме, һәр кеше ихластан елмая! Сәгать сигезләр тирәсендә парк бушап калды. Бар да эшкә ашыга. Бераз сөякләрне язганнан соң, без дә кайтырга чыктык. Базарга барасыбыз бар!



**Иртән җырлау үпкәгә файдалы ди**

# Голҗа базарлары

*Һәркемнең уе бары бер: кем кемне оста хәйләләр*
*һәм кем кемне яхшы утыртыр.*
*Г. Тукай, «Сәүдәгәр», 1913*

XIX гасырда Голҗа шәһәре Русия һәм Кытай дәүләтләренең эре сәүдә үзәгенә әверелә. Шәһәр халкының өчтән берен татарлар тәшкил иткән. Кытайдагы татарлар, нигездә, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Голҗада берничә зур сәүдә ширкәте булган. Бертуган Исхак, Ибрай, Гариф байлар төзегән «Тянь-Шан ширкәте», алты татар бае оештырган «Алтай ширкәте» эчке һәм тышкы сәүдәгә өстенлек биргән. Халыкка һәрчак ярдәм итеп торган ширкәт хуҗаларын, Голҗа татарлары әле дә сагынып искә ала.

Без ике җирдә: кытай һәм уйгыр базарларында булдык. Базар базар инде: ни генә юк! Кием-салым күбрәк. Без әйтергә гадәтләнгән «кытай аламасын» очратмадык. Яхшыдан-яхшы сыйфатлы әйберләр генә сатыла. Ә менә тауарга бәя куйдыру үзенә бер кызык. «Монда сатулашканны яраталар. Мин әйткән хакка бирергә теләмәсәләр, башка җирдән алам, дип китәм дә барам», – ди Рифкәт һәм үз әйткәннәрен раслар өчен



**Кытайларның төп транспорты мопед һәм велосипед**





бер сатучы янына килде. 15 кенә минут сатулашты болар, ахыр чиктә Рифкәт әйберне алмыйча китте дә барды. Сатучылар аны куып җитеп, тауарларын арзан бәядән бирергә ризалашты. Рифкәткә кушылып без дә кәсебенә керештек. 20-40 данә кызлар көзгесе алырга уйладык һәм Рифкәт ярдәме белән көзгеләр бәясен безнеңчә 300 сумнан 30 сумга тикле төшерттек. Казанда ул көзгеләр 240 сум тора.

Хәлдән тайдык! Берзаман базарда таныш келәмгә күз төште. Рәсемдә – Кол Шәриф мәчете. Безнең гаҗәпләнгәнне күргән Рифкәт: «Кытайлар бик җитез халык. Бер күреп кайталар да, ясап саталар. Казанда бу келәмне бер мең сумга алсагыз, Кытайда – 300 сум. Оста сатулашсаң, 150 сумга да бирүләре бар», – диде.

Кичке тугызда янәдән базарга бардык. Төнге базарда ашау-эчү саталар: татлы шулпада яңа пешеп чыккан бәрән башыннан алып, бәрән күзләренә хәтле бар! «Кытай деликатеслары» базары шушы була инде. Халык төнге уникегә кадәр бертуктаусыз ашый, эчә. Безнең тамаклар тук – күргәннәребез дә хәттин ашкан.

Кытайда төнге уникедән соң, төнге клублар, базарлар ябыла. «Шулчак урамда беркем дә калмый. Закон белән тыелган чөнки», – ди Рифкәт.



Уйгыр дискотекасын да күреп кайтырга булдык. Ничегрәк икән? Безнең белән биш татар егете дә барды. «Милан» клубы иде ул. Монда һәр җыр тере тавышка башкарыла. Алдан яздырылып куйган көйләр куймыйлар, сәхнәдә шулай ук тере музыка. Биюнең үз кагыйдәләре, бары тик парың белән генә биергә мөмкин. Ялгыз биючеләргә сәер карыйлар. Көй туктауга, яшьләр өстәл артына утыра. Әз-мәз капкалагач, егетләр кызларны биюгә чакыра. «Нигә җыр тәмамлангач, утырып маташырга соң? Шунда гына торсаң ярамыймени?», – дип сорадык егетләрдән. «Биш егет белән килсәң, бишесе белән дә биеп карар өчен, шулай гадәткә кергән бездә», – диделәр. Аңлашылды… Голҗадагы кытай, уйгыр, казакъ, шибә яшьләре бик әдәпле тоелды миңа. Төнге клубта үбешеп, кочаклашып торган бер парны да күрмәдем. «Сездә әллә үбешү дә закон белән тыелганмы?», – дим татар егетләренә. Алар да югалып калмады: «Кытай урамнарында, җәмәгать урыннарында үбешеп, кочаклашып тору – зур әдәпсезлек, оятсызлык ул. Тирә-яктагыларны хөрмәт итмисең дигән сүз. Кытай законнары кырыс кебек тоелса да, халыкны әдәп-әхлакка, бер-береңне хөрмәт итәргә өйрәтә», – диде егетләр.

**Рәмилә Газизуллина**

# Ураза гаете

*Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар;*
*Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!*
*Г. Тукай, «Киңәш», 1909 ел*

Кытайга сәяхәтебезне Ураза гаетенә махсус туры китергән идек.

Милләттәшләребез Ураза гаетенә ун көн алдан әзерләнә икән. Төрле тәм-томнар пешерү, яңа күлмәк, түбәтәй-яулык хәстәрләү кебек күңелле мәшәкатьләрдән башлана бу бәйрәм. Уйгырстанда гает иртәсендә барабан тавышына уянасың. Борынгыдан килгән уйгыр гадәте бу. Шул тавышка барлык мөселман ир-атлары мәчеткә җыела башлый. Хатын-кызлар исә намазны өйдә генә укый. Иртән Риман абый да, тәһарәтләнеп, матур киемнәрен киеп, үзәк мәчеткә намазга чыгып киткән иде. Әбәтләр тирәсенә кунакханәгә үзе кайтып кермичә, таба алмадык аны. Баксаң, ул милләттәшләребез белән аймыл булган да, азан, барабан тавышы буенча бер уйгыр мәчетенә барып чыккан. «Үзәк мәчетнең кайда урнашканын сораштырдым. Җавап бирүче булмады. Әллә мине аңламадылар, әллә мин аларны аңламадым. Ярый әле барабан кагалар», – диде Риман абый һәрвакыттагыча шаяртып.





**Монда кадерле кунакларне ресторанга чакыру гадәте дә бар**

Бу көндә мөселманнарның икенче изге бурычы – зиратка бару. Намаздан соң, олысы-кечесе мәрхүмнәр рухына дога кылып кайталар.

Гает бәйрәменең иң саваплы һәм татлы мизгеле – туган-тумачаңны, әти-әниеңне, якын кардәшләреңне кунакка дәшү. Без дә 8 гаиләгә чакырулы идек.

Һәр өйдә милләттәшләребезгә Казан күчтәнәчләре тапшырдык, Татарстаннан сәламнәр җиткердек.

Голҗа татарлары – бик кунакчыл халык. Тәмле сүзле, якты йөзле булулары белән күңелләребезне күтәрделәр. Бәйрәм бар кешегә бер булса да, һәр татар гаиләсенең үз тормышы, үз язмышы иде. Мөнирә Хәсән кызы Сәлимова-Акчурина – шанлы Акчуриннар нәселеннән. Аның әтисе Казан, Бохара мәдрәсәләрендә укыгач, Әстерхан шәһәрендә имам булып торган. Хәсән Акчурин Тукай белән Казанда очрашкан булган. «Әтием – 1890 нчы елгы. Бервакыт Тукайның үзенә багышлап шигырь язганын әйткән иде ул», – ди Мөнирә Акчурина. Нинди шигырь? Анысын ачыклый алмадык. Үзе исә акушер-гинеколог булып эшләгән, озак еллар Өремче университетларында укыткан. Голҗага күченгәч, татарларга бию дәресләре оештырган. Мөнирә апаның ире Иминҗан Сәлимов – үзбәк. Белгечлеге буенча математика



**Равил Шакир белән Әдибә Вәкил**

укытучысы икән. Үзбәк белән татар – тугандаш халыклар бит. Уртак гадәтләребез дә бар: рәхәтләнеп яшибез», – дигән иде ул.

Рифкәт Фәхретдиновлар йортында булганны язган идек инде. Рифкәтнең Шәмсебану исемле әбисен дә очраттык әле. Шәмсебану Вәлиеваның күпчелек туганнары Австралиянең Аделаида шәһәрендә яшәп ята икән. «Андагы бөтен Вәлиевләр – безнең туганнар инде», – дип елмайды ул. Шәмсебану әбинең тормыш иптәше Саттар Салих бик укымышлы кеше булган. Кытайда дөя турындагы беренче китапны да ул чыгарган. Шәмсебану әби гомере буе кытай теле укытучысы булып эшләгән, 7 бала анасы.

Голҗа татар мәктәбендә укыган Хөршидә әби Усманова өендә дә кунак булдык. 80 яшьлек Хөршидә ханым улы-килене тәрбиясендә гомер кичерә. Атаклы Голҗа татар мәктәбендә укыганлыгы белән бәхетле иде ул: «Сыйныфта утызлап бала идек. Мәктәп татар каласындагы яңа бинага күчкән иде. Ул озын, киң коридорлардан очынып чапканнар әле дә истән чыкмый. Туган тел дәресләрендә Тукайның шигырьләрен укый идек. Әй, ул рәхәт чакларны!». Оныкларының Казан югары уку йортларында белем алулары белән дә чиксез горурлана иде Хөршидә әби.




**Кардәшләргә Казан күчтәнәчләре**

Татар мөгаллимнәре Ильяр Габитов, Зөлфия Чапаевалар өендә дә безне мул табынлы татар өстәле көтеп тора иде. Бер карасаң, мөселман тормышындагы нинди әһәмиятле бәйрәм бу Ураза гаете! Кытайдагы татарлар аны без Яңа елны көткән кебек сагынып көтеп ала. Милләттәшләребез кечкенәдән үк балаларын Гаеттә катнаштыра. Туганнар белән таныштыруның, дуслар белән аралашуның бер чарасы булып тора ул. Безне Кытайдагы татарлар белән очраштырды, ике ил татарлары арасында дуслыкны ныгытты гает.

**Рәмилә Газизуллина**

# «Милли тәрбия бишектән башлана»

Белеме буенча алгебра фәне укытучысы туган телгә мәхәббәт уятырлык итеп дәресләр бирә аламы? Ала икән шул менә! Кытайда һәр күрешкән татар Зөлфия Чапаева исемен телгә ала иде. Ниһаять, Голҗа

шәһәрендә яшәп ятучы атаклы татар теле укытучысы Зөлфия ханым белән безгә дә танышырга насыйп булды.

Күңелле дә соң Зөлфия апада! Өй эче бала-чага тавышыннан чыңлап тора!

– Тавышка аптырамагыз! Оныкларым уйный! Фәрзәнә белән Зәйтүнә, – диде дә, өч яшьлек оныгын яныбызга дәшеп чыгарды һәм кечкенә Зәйтүнәгә сораулар бирергә тотынды Зөлфия апа.

– Кызым, Казан кунакларына «Кәҗә белән сарык» әкиятен сөйләп җибәр әле!

Кызчык оялып, помидор сыман кып-кызыл булып, дәү әнисенең артына качты.

– Кызым, – ди Зөлфия апа. – Кәҗә белән Сарыкның капчыгында нәрсә булган?

– Бүре башы.

– Кәҗә белән Сарыкка Бүре башы нигә кирәк соң?

– Бүреләрне куркытарга, – дип самими генә җавап бирде кызчык.

Шулай итеп, Зөлфия ханым, оныкларына бишектән үк Тукай әкиятләрен укып, шагыйрь иҗатына мәхәббәт тәрбияли икән.

Аралаша торгач, Зәйтүнә белән Фәрзәнәнең «Шүрәле» поэмасын да бик яхшы белүен аңлап алдык. «Олы оныгым Шүрәлене елгыр бармаклары өчен ярата, кечкенәсе бик курка. Шуңа күрә тыңламый башласа, хәзер Шүрәле килеп җитәчәк», – дип әйтәбез», – диде Зөлфия ханым.

Зөлфия ханым белән аралашканда, теленең йомшаклыгына, һәр әйткән җөмләсенең мәкаль-әйтемнәргә бай икәнлегенә сокландык. Кытайда туып-үскән кеше бу хәтле камил итеп туган телдә сөйләшергә кайдан өйрәнә алды икән, дип гаҗәпләндек.

Сере бик гади булып чыкты.

– Университетта укыганда тел онытмыйм дип татар китаплары еш укый идем. Мин милләтче түгел, милләтпәрвәр. Тукайсыз, туган телсез үземне бик ялгыз хис итәм. Тукайның шигырьләрен укыган саен, аларда яңа мәгънә ачам. Казанга берәрсе барып чыкса, шагыйрьнең яңа чыккан җыентыкларын алырга кушам. Оныкларыма да иң беренче итеп Тукай шигырьләрен ятлаттым, – диде ул.

Зөлфия Чапаеваның ике баласы да (кызы – Зөмрәт, улы – Кодрәт) татар телен «су кебек эчә». Улы Кодрәт бу елны Казанның (Идел буе) федераль университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлаган. «Беренче югары белемем – Голҗаның педагогика университетының физика факультеты булса, икенчесен туган телем буенча алырга булдым. Әниемнең йогынтысы зур булды дип саныйм. Кечкенәдән миңа Тукай шигырьләре, татар хикәяләре укый иде. «Казанда белем



**Зөлфия Чапаева гаиләсендә кунакта**

аласы килә», – дигәч, каршы килмәде, куанды гына. Укырга кергәндә дә бик нык ярдәм итте, киңәшләрен яудырып торды», – дип сөйләде татар теле белгечлеге буенча диплом алган егет.

«Зөлфия ханым алгебра фәне буенча белгеч булса да, тумыштан татар теле укытучысы», – дип әйткән иде миңа берәү. Чыннан да, Зөлфия Чапаеваны башка өлкәдә күз алдына китерүе авыр.

Ул 1990 елларда Голҗадагы татар балаларына туган тел дәресләре укыта башлый. Әлбәттә, телне камил белсә дә, аңарга чын татар мөгаллимәсе булу өчен бик каты тырышырга туры килә. «Мин бит татар теле генә укытмадым. Татар тарихы, бай әдәбиятыбыз буенча да белем бирергә тырыштым. Шуңа күрә, бик каты эзләнергә туры килде. Бер карамаган календарь, китап калмады», – дип сөйләде мөгаллимә.

Дәресләр укыту өчен бина мәсьәләсе дә үзеннән-үзе чишелә. Бер мәктәп җитәкчесенең әбисе татар булып чыга.

Зөлфия ханым бу мизгелләрне зур дулкынлану белән искә төшерде.

– Әле дә хәтердә, өйдәге телевизорымны, кассеталарны төяп, таксида татар теле укытырга чыгып китә идем. Миңа 7 яшьтән алып

72 яшькә хәтле кешеләр йөри иде. Аларның һәрберсенең күңеленә татар рухы сеңдерергә тырыштым. Бушка укыттым, беркайчан да акча сорамадым, – диде ул.

Зөлфия ханымның туган тел дәресләрен укыту хәбәре тора-бара бөтен Кытайга тарала башлый. Бер тапкыр КХРның Чишмә исемле милли татар авылына баргач, мөгаллимәне төрле шәһәрләрдә яшәүче татарлар үзләренә укытырга чакыра. Милләт өчен җанын бирергә әзер булган укытучы тәкъдимнәрне кире какмый.

2009 елны Зөлфия ханымга таныш түгел берәү чылтырата. Кытайның Чүгүчәк шәһәреннән милләттәшләр булып чыга. «Балаларыбыз кытайлаша бара, ярдәм итегез!», – диләр. Мөгаллимә вакытны озак сузмыйча, мең чакрым ераклыктагы Чүгүчәк шәһәренә кузгала.

– Анда бер ай буена туган тел буенча дәресләр бирдем. Бик авырга туры килсә дә, татар телен төшендерә алдым. Ник дисәгез, яшьләр кытай телен генә белә. Урта буын аз-маз казакъча, уйгурча сукалый. Шуңа күрә өч телдә укытырга туры килде. Татарча, уйгурча, кытайча аерым сүзләрне өч баганага тезеп өйрәндек. Өч атна дигәндә, шәкертләрем әзрәк кириллицада укый, мине аңлый башладылар», – диде мөгаллимә.

Зөлфия Чапаеваның әнисе Гөлчәһрә бик укымышлы кеше булган. Татар мәктәбен тәмамлаган. 14 яшендә кияүгә чыгып, 5 бала тәрбияләп үстергән. Балаларына һәр кичне татар язучыларының әсәрләрен укый торган булган. Кызганыч, бәхетле мизгелләр озакка бармаган. Әнисе 30 яшькә дә җитмичә дөньядан китеп барган. 5 нарасый бала әти тәрбиясенә калган.

– Әти! – диде дә, Зөлфия ханым өзгәләнеп елап җибәрде. – Әниебез үлгәч, әтиебез безнең өчен дөньядагы иң кадерле кеше булып калды, – диде ул яшьләренә буылып.

Мөгаллимәнең әтисе Әхмәди әфәнденең тамырлары Чиләбе өлкәсенең Чишмә районы Яңа Рәдүт авылына барып тоташа. Бүген дә анда әтисенең туганнары яшәп ята икән. Зөлфия ханым берничә ел элек аларның хәлен дә белеп кайткан. «Ничек аңлашырбыз? Бик каты ятсынырмын инде, дип курыккан идем. Аллаһка шөкер, мине бик җылы кабул иттеләр. Гадәтләре дә әтинекенә бик нык охшаган. Алар да, Кытайда гомер буена яшәгән туганыбезны ничек аңларбыз икән, дип курыкканнар. Саф татарча сөйләшүемне ишеткәч, бик гаҗәпләнделәр», – дип сөйләде ул.

Зөлфия ханым бүген: «Ник әтиемнән исән чагында нәселем турында сораштырып калмадым микән?», – дип үкенә. Фамилиясенең килеп чыгу тарихы турында да уйлана булып чыкты. «Мондый



**Зөлфия апа оныгына сабак бирә**

фамилияле кешеләр бик сирәк бит. Әлмәт районында Чапай дигән кечкенә генә авыл бар икән. Әнә шушы авылдан нәселебезнең төп фамилиясе чыкмады микән?», – ди.

…Зөлфия Чапаева белән безгә, Тукай фонды хезмәткәрләренә, нәкъ бер елдан соң Казанда күрешергә насыйп булды. Бөек шагыйрьнең 125-еллык юбилеена басылып чыккан Тукай китапларын күргәч, Зөлфия ханымның сабыйларча ничек куанганын күрсәгез иде сез!

Еллар үткән саен, кеше үз тамырына кайта, дип юкка гына әйтмиләр шул. Зөлфия апа да яшәргә Казанга күчеп кайтмакчы икән. Улы Кодрәт тә Яшел Үзән кызы – Лилия белән гаилә корып, Казанда яши башлаганнар. Зөлфия Чапаева туй бүләге итеп киленгә үз куллары белән ясалган калфак биргән. Лилия әлеге бүләкне шулхәтле ошаткан ки, туйда киеп йөргән. Миңа калса, булачак татар кәләшләренә фәлән мең сумлык эшләпәләр эзләп йөргәнче, милли калфакларыбыз койган да куйган инде.

Кызык инде бу татар: җанына һаман да тынычлык таба алмый. Башта бәхет эзләп читкә китә, аннан соң яңадан тарихи Ватанына тартыла. Ул моны матур сүзләр белән аңлата да алмый. Зөлфия апа да: «Гомер буе монда кайту турында хыялландым», – дию белән генә чикләнә. Аның һәм башка бик күп милләттәшләрнең «тарихи ватаннан» күңелләре генә кайтмасын иде.

**Альбина Газизуллина**

# Кытайдагы иң бәхетле гаилә

Андый гаилә нинди була? Гыйззәтулла һәм Хәлимә Хәсәновлар моның серен бик яхшы белә. Алар 2009 нчы елда Кытайда яшәүче 56 милләт арасында узган «Иң бәхетле гаилә» бәйгесендә җиңүче дип табылган.

Бу йортка килеп кергәч, башта әллә Татарстанга эләктекме дип аптырап калдык. Ишектән үк башына бик матур итеп яулык чөйгән, алъяпкыч бәйләгән хуҗабикә саф татар телендә безне табынга дәште. Гаилә башлыгы Гыйззәтулла абый: «Милли ризыклардан авыз итегез инде», – дип гел кыстап утырды. Ниндидер нур, әйтеп бетергесез ягымлылык бар иде бу татар өендә. Гыйззәтулла һәм Хәлимә бер-берсенең фикерләрен тулыландырып торалар, кирәк икән, парлашып җырлап җибәрергә дә кыенсынмыйлар. Голҗа сабантуйларында да ел саен икәүләшеп чыгыш ясыйлар икән.

Чыннан да, гаиләдә ничек бәхетле булырга соң? Моның сере нәрсәдә?



**Җырлап яшибез!**



**Хәсәновлар гаиләсе кунактан өзелми**

«Бәхет турында кешеләрнең төрле фикерләре була. Гаилә кору, балаларың тууы, аларның югары уку йортларында укуы – боларның барысы да зур бәхет», – диде Хәлимә апа. Гыйззәтулла абый исә гаиләдә бәхетле булуның биш шартын тезеп салды: «Беренче шарт – ир белән хатынның тату яшәвендә, икенчесе – хезмәттә күренекле нәтиҗәләргә ирешүдә, өченче шарт – туганнар белән тыгыз, дустанә мөнәсәбәттә булуда, дүртенчесе – «күрше хакы – Тәңре хакы» икәнен онытмауда һәм соңгысы – өлге булырлык эшләр башкаруда».

Хәсәновлар гаиләсе боларның барысына да ирешкән. Өч малай тәрбияләп үстергәннәр. Өч баласын да Гыйззәтулла абый Казанда укыткан. Өлкәне Нәгыйулла югары уку йорты тәмамлап, Казанда эшмәкәрлек белән шөгыльләнә. 2010 нчы елда Арча районыннан татар кызы белән гаилә корып җибәргән. Әсхәт Казан медицина университетын тәмамлап, ординатурада белемен дәвам иттерә. Төпчеге Вәлиулла К(И)ФУның татар филологиясе факультетының өченче курсында белем ала.

Милли җанлы, татарча камил итеп сөйләшүче Гыйззәтулла Әнвәр улының кытай, казакъ, уйгыр, үзбәк кебек милләтләргә кытай



**Кытайда һәр татар туганга әйләнде**

теле дәресләре укытуын белгәч, соклануымны яшерә алмадым. Әңгәмәдәшем кытай телендә 10 сыйныфны тәмамлагач, Пекинда Милләтләр институтында белем ала. 1991-1993 нче елларда Элә өлкәсе кадрлар институтында укый һәм шунда ук кытайчадан казакъчага тәрҗемәче булып эшли. Яхшы укыганы өчен алып калалар үзен. Хәзер аның биредә эшләвенә ике дистә елга якын вакыт узган. 2004 нче елдан татар үзәгенең урынбасары булып, милли-мәдәни чараларда да катнашырга өлгерә ул.

– Мин Кытай телен өйрәнә аламмы? Ярдәм итә аласызмы? – дип сорыйм.

– Әлбәттә. Кытай телендә 3500 иероглиф белсәгез, Кытайда яшәп була. 7 меңне белсәгез, мәкаләләр яза аласыз, – диде ул.

Хәсәновларның стенасында Тукай шәҗәрәсе эленеп тора. Ә хуҗаның эш бүлмәсендә – Тукай сурәте. Гыйззәтулла абый бер соравы белән барыбызны да аяктан ега язды.

-Бу кем? – диде ул шагыйрь фотосына төртеп.

– Габдулла Тукай, – дибез.

– Яхшырак карагыз!

– Тукай булырга тиеш, – дибез икеләнеп.

– Бөтен кешегә минем яшь чагым дип таныштырам. Әйтегез инде! Охшашканбыз бит аның белән, әйеме?! – Шушы «охшашлык» белән горурлана иде ул.

Гыйззәтулла Хәсәнов Тукайның шигырьләрен кытай, казакъ телләренә тәрҗемә иткән. Алты шигыре «Шенҗан» газетасында дөнья күргән. Казакъ телендә төрле газета-журналларда җиде мәкаләсе басылган. Бер тапкыр интернетта утырганда Гыйззәтулла абый шагыйрь турында бик кызыклы мәгълүмат тапкан. Анда: «Тукай – Кытай халкының бөек шагыйре», – дип язылган. Компьютерны кабызып аны безгә дә күрсәтте. Тукай Кытайда булмаса да, аны биредә халык шагыйре дәрәҗәсендә яраталар һәм хөрмәт итәләр.

Бәхетле булуга ни җитә? Хәсәновлар гына түгел, Кытайда яшәүче башка татар гаиләләре дә бер генә «бәхет рецепты»н белә: «милләт, тел, дин, гаилә, күрше хакы, хезмәт»…

**Альбина Газизуллина**

# Габдулла Тукай Кытайда яши

Г. Тукай эзләре буенча Казакъстан, Кытай якларына сәфәргә барып кайткач, безгә: «Тукай Кытайда да булганмыни?», – дигән сорауны еш бирделәр. «Әйе», – дигәнгә бәгъзеләрнең исе китмәде, икенчеләре исә: «Кайчан барган, нишләп йөргән ул анда?», – дип төпченергә тотынды.

Әйе, инде язганыбызча, бара язган ул анда. Сәламәтлеге начарлануын ишеткәч, Кытайда яшәүче милләттәшебезнең берсе Фазылҗан Юнич Тукайны үзенә алып килеп, кымыз эчертеп дәваламакчы булган, әмма ниндидер сәбәп аркасында, ниятен тормышка ашыра алмаган. Гаҗәп бит: аның хаста хәлен Кытай хәтле Кытайда белеп, ярдәм итәргә әзер торганнар. Үзе булмаса да, Кытайда шагыйрьнең рухы яшәгән. Татар зыялылары белән очрашулар вакытында фондның башкарма директорлары – Гөлназ Галимҗанова, Рәмилә Газизуллина, аның сеңлесе, Татарстан Милли музее фәнни хезмәткәре Альбина Газизуллина төрле китап-журналлар, газеталар җыеп йөрделәр. Ул чакта мин, бик белдекле генә кыяфәт чыгарып: «Бу макулатура

нәрсәгә соң?» – дигән идем. Казанга кайтып, әлеге «макулатура»ны барлый башлагач, ник әйткәнемә үкендем. Ә университет эскәмияләрен яңа ташлап чыккан кызларым миннән күпкә акыллырак булып чыктылар ләбаса. Әлеге китап-журналларны сабакташым, танылган галим Әнвәр Хәйригә күрсәткәч һәм ул: «Бу китапларга бәһа юк», – дигәч, гомумән, җир тишегенә керердәй булдым. Баксаң, Кытайдагы кардәшләребез Тукайны даими укыганнар, өйрәнгәннәр. Һәм бездән аермалы буларак, китап-журналлар, мәкаләләр Тукайның туган көне яки юбилее уңаеннан гына түгел, еллар буе даими рәвештә нәшер ителеп килгән. Казакъның атаклы язучысы, академик Сәбит Мукановның Тукайны: «Көнчыгыш шигъриятенең алыбы»,– дип атавы – төрки халыкларның олуг шагыйребезгә олы бәясе.

Әле 1919 нчы елда ук атаклы казакъ язучысы Әсгать Найбанбай (1867-1922) Кытайның Уйгыр автоном округы газетасында «Габдулла Тукайдай татар кайда?» дигән шигырь бастырган.

Уйгыр матбугатына күз салсаң, «Тарым» исемле айлык әдәби журнал (инде 45 ел чыга) Тукайның «шигырь көлтәләре»н әледән-әле бастырып килә. «Әдәби тәрҗемәләр» журналы (2007 нче ел, 11 нче сан) Рәгънә Акмуллина тәрҗемәсендә уйгыр телендә Тукайның «Исемдә калганнар»ын чыгарган. Хәтта әлеге автобиографик әсәрнең кулдан язылган уйгырча тәрҗемәләре дә Кытайда яшәүче төрки халыклар арасында киң таралган булган.

Уйгыр автоном округының «Татар телен үстерү җәмгыяте» (игътибар итегез, Кытайда ана телебезне үстерү җәмгыяте эшли) «Тукайның сайланма шигырьләре»н китап итеп чыгарган. 1998 нче ел бу. Тукайның туган көне дә, юбилее да түгел. Шуларны карап утырганда Әнвәр Хәйри соклануын яшермәде: «Кайда татар яши, Тукай шунда кыйбла булып тора. Бик затлы китаплар алып кайткансыз, – диде дә: – Тукайга мондый хөрмәт күрсәтергә уйгырлардан өйрәнергә кирәк», – дип куйды.

Тукайның уйгыр әдәбиятына йогынтысы турында күпме гыйльми хезмәтләр язганнар кардәшләребез. Шөкер, фонд кызларының башы җитеп, хәзер әлеге бәһасез хезмәтләр «Тукай фонды» милкенә әверелде һәм киләчәктә галимнәр белән бергә аларны өйрәнүне дәвам итәрбез.

Инде бу китапта Кытайда яшәүче кардәшләребезнең Тукайга мөнәсәбәте турында шактый яздык һәм укучыбыз Тукайның җисеме булмаса да, исеме, рухы Кытайда яшәгәненә ышангандыр.

**Риман Гыйлемханов**

Кытай

КАЙТУ ЮЛЛАРЫ ОЗАК

# Хуш, Кытай



# Хуш, Кытай

*«Юллар, юллар, авыр булса – булсын,*
*Тик соңгысы гына булмасын…» –*

дип көйли-көйли Кытайдан кайту юлына кузгалдык. Килгәндә чикне узу шактый матавыклы булса да, кайтканда Торсынтай Галиев ярдәме белән ярты сәгать эчендә Казакъстан җиренә чыктык. Ничек туры килгәнбез: дүртебез дә бик хисле, нечкә күңелле икәнбез. Алматыга кайтканда кызлар да Кытай хатирәләрен яңартып, очрашулар-күрешүләрне искә төшереп кайттылар. Көлешүләр моңсу уйланулар белән аралашып барды. И, Татарым, кайда гына яшәсәң дә, дәрәҗәңне тота беләсең син! «Риман абый, «Зәңгәр күлмәк»не җырла әле!». Монысы Гөлназ тавышы. Үзалдыма гына дигәндәй, көйлим. Миңа кызлар да кушыла. Бераздан кинәт кенә сорап куялар:

– Кытайга тагын кайчан барабыз?

– Башта өйгә кайтыйк әле.

И-и, сәяхәтче кызларым, чит-ят җирләргә сезне нинди уй-хисләр чакыра икән? Бигрәк яшь бит әле сез. Хәер, бу сорауга җавап аңлашыла инде. Безне Тукай, милләт алдында бурыч йөртә. Һәм әлеге сәфәребез белән бурычның беркадәрлесен үтәдек шикелле. Әмма бит әле «мәңгелек бурыч» дигәне дә бар. Димәк, безгә язмыш юлда йөрергә кушкан. Бу юл озын булырмы, озакка сузылырмы – барысы да Ходай кулында.

Әйе, юллар озын булса булсын, тик соңгысы гына булмасын.

## Алматы белән саубуллашу

Алматыда узган көннәр дә онытылмаслык хатирәләр калдырды. Андагы татарлар белән дуслашып-туганлашып беттек. Безгә бер генә кырын караучы да булмады. Тик Казакъстанда милли сәясәт барыбер дә икеләнүле уйлар тудырды. Бер яктан, төп халык – казакъларга уку, эшләү, яшәү өчен өстенлекле шартлар, казакъ теленә ихтыяҗ тудырыла. Мондый сәясәт алып бару килешле кебек, чөнки ул – мөстәкыйль дәүләт, казакъ иле. СССРдан аерылып чыгып, иркен сулыш, бәйсезлек алган ил җитәкчелегенең төп милләткә аерым игътибар бирергә омтылуы табигый. Тик менә «аерым игътибар» Казакъстанда яшәүче башка милләтләрне бераз кысу хакына түгел микән дигән шик тә туып куя.

Әлбәттә, монда башка халыкларны күрәләтә рәнҗетү юк. Безнең Русиядәге кебек телне, тарихыбызны өйрәнүне, мәгарифебезне чикләү

турында законнар кабул ителми. Шуңа күрә, Казакъстанның мәдәни юл белән аерым дәүләт булып көч-куәт алырга омтылышын хуплыйм да, бездә – титуллы халык исемен йөрткән Татарстанда да, шундыйрак сәясәт алып барылса иде дип көнләшеп тә куям. Башкалардан, бигрәк тә «өлкән туганнан» ким-хур булмый яшисе килә бу Русия дигән җирдә. Тукай бу хакта әле 20 нче гасыр башында:

*«Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?*
*Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук...» –*

дип язган иде. Шуларны уйлагач, күзем түбәнләнеп, күңелем сүрәнләнеп китә, ә казакъ кардәшләргә карата ак көнчелек уяна. Тик без күңелне киң тотып өйрәнгән халык һәм өметне өзмибез әле. Чөнки, кай якка гына баксак та фикердәшләр табабыз. Без барасы Костанайны гына алыйк. Инде милләттәшләребез белән бер очрашкан идек, юк бит: «Кайтышлый безгә тагын кагылыгыз, сөйләшәсе сүзләр бетмәде әле һәм бетәсе дә юк. Икенче килешегезгә татар яшьләрен җыярбыз», – дип калдылар. Ә Татар мәдәни үзәгенә йөрүче Рәисә ханым Сиит: «Мин коттеджда торам, мунча ягармын, бездә кунарсыз», – дип кистереп үк әйтеп куйды.

Якты уйлар белән Алматыдан кузгалып киттек. «Сандугач йокысы» гына йоклаган булсак та, күңел күтәренке, кәеф шәп иде. Костанай арасы мең чакрымнан артык, шуңа күрә телисеңме-теләмисеңме, Карагандада төн кунарга туры киләчәк. Кызларым телефон аша куну мәсьәләсен хәл итеп тә куйганнар булып чыкты. Ярый әле, читтә яшәүче кардәшләребезнең безгә мөнәсәбәте әйбәт. Чит-ят җирдә таяныр кешең, кем әйтмешли, «кунар агачың, сайрар куагың» булмаса нишләрсең?! Милләттәшләр белән очрашу мизгелләрен күз алдына китерәм дә, күңел кыллары бушап бераз «йомшап» та алам. Тәкъдир диген, язмыш безне кайларга гына китереп чыгармады бит. «Бер саплам» гына гомер яшәгән Тукай да шактый җирләр гизеп өлгергән.

Кызлар аның сәяхәт «картасын» ясап куйганнар иде инде. Бу сәфәрдән исән-сау кайткач, шушы якка яңадан юл төшәчәк. Чөнки, Казакъстанның Гурьев шәһәренә барасы бар. Анда яшәүче туган тиешлеләре Тукайга шактый ярдәм итеп торганнар. Инде үсеп җитеп шагыйрь булгач, ул калага Тукай үзе дә барган. Әле Оренбургка, Әстерханга, Петербургка да, Пермь якларына да сәфәр ниятләп торабыз. Мин элек тә хыялый идем, юл йөрергә беркайчан да иренмәдем. Инде яшьлек, иҗат дәрте бөркелеп торган кызларым – Гөлназ, Рәмилә, Альбина белән бергә бер арбага җигелеп «милләт йөген» күпмедер дәрәҗәдә тарта башлагач, тагын да хыялыйга, «йөремсәккә» әйләндем шикелле. Шундый якты уйлар белән барганда, күңелгә килмәгән, төшкә кермәгән хәлләргә тарырбыз дип уйламадым да, бәла аяк астында йөри икән шул.

## Фаҗига

Юл уңаенда очраган кафе-мазарларда туктап, ял итә-итә бара торгач, мең чакрым ара узылды. Карагандага 90 чакрым чамасы калган иде. Юл полициясе бер җирдә туктатып документларны тикшереп алды. Заправкада туктап бак тутырып бензин салдык. Ары киттек. Алда зур гына күпер күренде. Асфальт тигез, юл туры, шактый җилләп кенә барабыз. Күпергә керер алдыннан, машинаның сулъяк тәгәрмәче сәер тавыш чыгарып куйды. Гөлназ: «Риман абый!», – дип кычкырып җибәрде. Аны-моны уйлап өлгермәдем, шактый гына тизлек белән барган машина кинәт сулга каерды… Икенче мизгелдә без һавада оча идек инде. Рульгә чытырдап ябышканмын, машинаның шалтыр-шолтыр әйләнгәне истә калган. Ялгышмасам, өч мәртәбә әйләнүне санадым, аннан соң баш бәрелеп аңымны югалтканмын. Аннан соң машинага: «Тукта инде әйләнүдән!», – дип гозерләнүем истә калган. Янәшәдә утырган Гөлназның: «Риман абый, янабыз!», – дип кычкыра-кычкыра мине төрткәләвенә күземне ачтым. Шөкер, тәгәрмәчтә утырабыз. Капот астыннан да төтен түгел, ә пар чыга икән. Кайнар двигательгә тәрәзә юдыра торганмы, берәр сыеклык тамган, ахрысы. Ә машина сәгать шикелле матур гына эшләп утыра. Ходайның рәхмәте, минем якның ишеге ачылды, ә башкалары яньчелеп-кәкрәеп беткән, һич тә ачарлык түгел иде. Кузов трактор тәгәрмәче астында калган консерв банкасын хәтерләтә. Боларына соңыннан күз төште. Башка беренче килгән уй кызлар турында иде. Арткы ишекнең ватык тәрәзәсеннән Альбинаның бер аягы күренеп тора: яшел чалбарыннан, буй-буй оекбашыннан шундук танып алдык. Альбина үзе сумкалар астында калган. Гөлназ аларны тиз генә тирә-якка ыргытты. Альбинаның галәмәт зур итеп ачылган күзләре күренде. «Риман абый, нәрсә булды бу?», – «Борчылма, бераз гына авария…» – дип мыгырданып тынычландырырга маташам. Безнең күпердән очканны каршы килүче машиналардан күргәннәр, берничә кеше йөгерешеп төште. Гөлназ чатыр чаба, тегеләргә: «Скорый чакыртыгыз!», – дип кычкыра. Альбинаны тәрәзәдән тартып чыгардык, ә апасы – Рәмилә машинада юк. Шулвакыт Гөлназ: «Әнә ул!», – дип якындагы тәбәнәк куаклыкларга йөгерде. Машинадан 15 адым чамасы читтә, ком өстендә Рәмилә ята иде. Бер аягы гайре табигый борылган, үзе: «Авырта…» – дип ыңгыраша. Шөкер, барыбыз да исән. Тик минә Альбина белән Рәмиләнең кай җирләренә зыян килүен белмәү иң зур борчу иде: сөякләре, эчке әгъзалары исәнме…

Ә «скорый» дигәннәре ике сәгатьтән соң гына килеп җитте. Бу ике сәгатьне ничек уздырганымны хәтерләмим. Юл полициясе, тикшерүче-дознаватель тиз килеп җитте үзе. Сорау алдылар,

документларны тикшерделәр, беркетмәләр төзеделәр. Машинаны карап-әйләнеп йөргәннән соң: «Мондый хәлгә килгән машинада исән калу мөмкин түгел», – дип башларын чайкап куйдылар. Машинаны тикшергәннән соң, «выстрелило левое переднее колесо», ягъни алгы сул көпчәк шартлаган, дигән нәтиҗә чыгарып беркетмә яздылар, ә минем таныклыкны кире кайтардылар. Сабыйларым – Рәмилә белән Альбинаның ком өстендә ничек сызланып ятканнары инде айлар үткәч тә күз алдыма килеп күкрәгем чәнчеп-чәнчеп куйгалый, рәсми рәвештә «гаепсез» дип танылсам да, үземне барыбер гаепле хис итү җанны кыйный. Аллаһның рәхмәте яусын, кызларым шундый хәлдә дә мине юатырга тырыштылар: «Без исән бит», – диделәр. Машина әйләнгәндә тирә-якка чәчелгән әйберләрне җыю да, Карагандага шалтыратып безне көткән кардәшләргә хәлебезне аңлату да, машина чакырту да үтә нечкә хисле Гөлназ җилкәсенә төште. Итенә хәтле умырылган аягының сызлауларын ул Карагандага кайтып фатирга урнашкач кына сизде бугай. Аның чыдамлыгына шаклар катарлык… Тик менә айлар үткәч, һәлакәт Гөлназга да үзен сиздерә башлады. Фаҗига төшләренә кереп йөдәткәннәрен әйтмичә йөргән икән, сабыем. Башлары авырта, күңелсез уйларга бирелә башлагач, аны да сырхауханәгә салырга туры килде. Гозеребезне кире какмаган өчен, Казанның 18 нче сырхауханәсе баш табибы, ТР Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Сәйфулла улы Бакировка бик рәхмәтлебез. Мин һәр намазымда фидакарь кызларыма рәхмәтләр укыйм, Ходайдан аларга саулык-сәламәтлек, лаеклы парларын табып, бәхетле гаилә корып яшәүләрен телим.

Тик шунда да күңелгә эгоистлык дигәне кереп ала бит, чукынчык. Алар кияүгә чыккач берүзем каласымны, «Тукай фонды» эшен кем җигелеп тартасын уйлап, күңел боега. Аннан үземне сүгә башлыйм: «Алар сиңа түгел, син аларга бурычлы. Кызларны бәйләп тотарга дөге ярмасы кадәр дә хакың юк», – дим. Кызларым тынычландыра: «Кияүгә чыксак та сине, Тукайны ташламыйбыз. Без фонд эше белән йөргәндә, син безнең балалар белән утырып торырсың», – дип шаярталар.

Утырырмын ла анысы. «Сез миңа үз кызларым кебек, димәк, балаларыгыз да балдан татлы булыр», – дип үзем дә шаяртам.

## • КАРАГАНДА

Әлеге шәһәрдә яшәүче татар яшьләре фаҗига урынына «Ашыгыч ярдәм» машинасыннан иртәрәк килеп җиттеләр. Әле эвакуатор да чакыртканнар. Кызганычка каршы, безнең машина янына төшкән эвакуатор үзе комга батып, машинаны икенче көнне генә алып кайта алдылар. Рәмилә белән Альбина хастаханәдә. Без яшьләр белән алдан әзерләнгән фатирга кайттык. Урын җитмәү сәбәпле Альбинаны да хастаханәдән өйгә кайтардылар. Гәүдәсе гипсланган: өч кабыргасы һәм умрау сөяге сынган булып чыкты. Икенче көнне Гөлназ белән мине тикшерделәр. Гөлназның сынган җире булмаса да, күпердән очып китеп комлыкка барып төшкән машинада 8 мәртәбә әйләнү (моны эзләргә карап юл полициясе исәпләп чыгарган) үзенекен итеп, башлары, гәүдәләре бик каты бәрелеп имгәнгән, шуңа төне буе сызланып яткан иде ул. Ите умырылып чыккан аягы айлар буе төзәлми интектерде. Минем умрау сөяге сынган һәм күкрәк читлеге, янбаш бик каты бәрелеп, бөтен тәнем кара янып шәмәхә төскә кергән иде.

Сынган сөякне гипслатмадым, бердәнбер ир кеше буларак аяк өсте калып кызларыма кулдан (дөресрәге, бер кулдан) килгәнчә ярдәм итәсем килде.



Ярый әле Караганда яшьләре безне язмыш кочагына ташламадылар. Чая, үткен Розалия, әллә авыруларын онытып торсыннар дипме, Караганда телевидениесе белән сөйләшеп «Тукай фонды» эшчәнлеге турында казакъ һәм рус телендә тапшырулар эшләтте. Сөйрәлеп-сөйрәлеп атлап йөрсәк тә «көн үтте – безнеке» дип яшәмәү безгә өстәмә көч тә биргәндер. Яшьләр безгә милли ризыклар пешереп китерә тордылар. Рәмиләбезнең хәле генә авыр иде. Ходайның рәхмәте, аның бот сөяген икенче көнне үк урынына утыртканнар. Умрау сөяге дә сынган икән. Оча сөяге сыну иң хәтәре булса да, сөякләр урыныннан күчмәгән. Димәк, операция дә кирәк булмаячак. Монысы юаныч булса да, көннәр буе чалкан ятарга мәҗбүр булу тик тора белмәгән Рәмилә өчен авыр иде. Аягын тишеп, гер дә асып куйганнар, селкенә дә, борыла да алмый. Янына барган саен авыр күңел белән чыгып китә идек. Рәмиләбез, күрәсең, моны сизә иде, без килгән саен шаяртырга маташа, бүлмәдәшләре турында кызыклар сөйли иде. Каян гына көчләр табып бетергәнсеңдер син, кадерле Рәмиләбез. Мәсәлән: «Беләсеңме, Риман абый, минем янәшәмдә яткан бер хатын 20 мәртәбә кияүгә чыккан. Шуны рәхәтләнеп бөтен кешегә сөйли», – дип елмаерга азаплана. Кызларым, сезгә бер генә ир белән озын-озак гомерләр бәхетле яшәргә язсын иде.

Казанга кайткач, Рәмилә белән Альбинага Республика клиник хастаханәсенең Травматология үзәгендә дәваланырга туры килде. Өч атна буена кызларыбызның сәламәтлеген кайгырткан табиблар – Травматология үзәгенең баш белгече Илгиз Инсаф улы Шәйхетдиновка, Илдар Габделфәт улы Галиевкә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Аларның ярдәме белән кызларыбыз аякка басты.

Шулай Карагандада ун көн узып китте. Ул арада Караганда өлкәсенең «Ихлас» татар-башкорт мәдәният үзәгендә әллә ничә мәртәбә булып өлгердек без. «Без» дигәнебез, шул Гөлназ белән икәү идек. Тора-бара өйдән Альбинаны да «сөйрәп» алып чыга башладык.

## Әнвәр абый

Кызлар: «Әнвәр абый, Әнвәр абый…» – дип өзгәләнгән кеше «Ихлас» татар-башкорт мәдәният үзәге рәисе Әнвәр Керебаев була инде. Һөнәре буенча тау механигы (горный механик) икән. Күрәсең аңа тау-ташлар белән түгел, кешеләр белән күбрәк эшләргә насыйп иткәндер. Мәктәптә укыганда ук, үзе әйтмешли «җәмәгать активисты» булган.

Карагандада татарлар күп, чөнки бу төбәк-шахталар ягы, ә кайда шахта – шунда татар инде ул. Дистә ел чамасы элек кенә өлкәдә 54 меңнән артык татар булса, бүгенге көнгә аларның саны 15 меңгә

кимегән. Шуның өстенә тел югалту дәвам итә. Яшьләрнең күбесе исәнсаумыдан уза алмый. «Ятып калганчы атып кал» дигәндәй, «Ихлас» үзәге татар теле укытуны бераз җайга салган үзе. Атнага бер мәртәбә дәрес үткәрәләр, 25-30 кеше йөри икән. Әле 1996 нчы елда ук Татарстан фән һәм мәгариф министрлыгы, Караганданың мәгариф департаменты һәм «Ихлас» үзәге үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегәннәр. Татарстан бушлай уку әсбаплары, төрле китаплар бирә икән. Үз чиратында без дә «Ихлас»ка Фонд исеменнән шуның ише бүләкләр тапшырдык. Һичьюгы Тукайны ешрак искә төшерерләр дидек.Ә Тукайны онытмаган телен онытмас, иманыннан ваз кичмәс ул.

Карагандада 38 мең татар яши. Бу бик аз түгел кебек, әмма, сан бар – сыйфат юк килеп чыга. «Ихлас»ның максаты әнә шул сыйфат ягын кайгырту. 1995 нче елда үзәк беренче мәртәбә Сабантуе үткәргән, аннан соң бу бәйрәмебез ел саен шәһәр күләмендә уздырыла башлаган. Татарны бергәрәк җыярга ансы да ярап куя. «Ана теленә өйрәтүне гаиләдән, балалар бакчасыннан башларга кирәк», – дип өзгәләнә Әнвәр әфәнде. Өзгәләнсә дә «проблема җебе»н өзеп булмый әле. Гаиләдә әти-әниләр үзләре «тел югалткан буын» вәкилләре. Балалар бакчасында татар төркеме ачарга да хыялланалар, рәсми оешмалар каршы да килми, әмма татар тәрбиячесе юк. Бер төркем яшьләрне Казанга укырга җибәргәннәр үзе, әмма алар кире кайтамы әле? Кайтса, кем булып кайта? Казан бит авылдан килгән «чи татар»ны да 4-5 ай эчендә «чи урыс»ка әйләндереп куярга мөмкин. Мәгариф өлкәсенә кереп баручы төрле законнарны (мәгариф стандартларына кертелгән үзгәрешләрне генә ал. – *Р.Г.*) искә төшерсәк, татарның рухи башкаласы – Казанда гына түгел, авыл-районнарда да хәлнең шактый ук «кәкәй» икәне аңлашылыр. Ярый әле, Карагандада яшәүче кардәшләребездә милли рух, милли «куәт» сакланып килә. Искә төште әле: без инде ике ел буе Казанның Тукай белән бәйле урыннарына, биналарына элмә такталар кую турында сүз кузгатып киләбез, тик «боз кузгалмый» һәм кузгалмас та кебек. Шушы хакта үз фикерләребезне җиткергәч бик милли җанлы, абруйлы (һәрхәлдә шул чутта йөрүче. – *Р.Г.*) бер журналистыбыз: «Нәрсәгә кирәк ул? Казанда Тукай урамы, музей, тагын килеп, Кушлавычта, Кырлайда музей, Татарстанда Тукай исемен йөрткән район бар. Тукайны идолга әйләндерү кирәкме?», – дигән иде. Бөтен төрки дөнья үзенеке итеп таныган, татарлыкның байрагы итәрлек Тукаебыз рухы сакланган урыннар күбрәк булса, начар микәнни ул, кадерле милләтпәрварым минем?!

Ни өчен бу сөйләшүне искә төшердем? Чөнки милли мәсьәләләрдә вак эш, олы эш юк дип беләм. Менә, Караганданың матур бер урынында

Галимулла Хәйруллин дигән кеше истәлегенә мемориаль такта ачканнар. Кем соң ул Галимулла Хәйруллин? Ул 14 яшендә Украинаның Донбасс шахталарына киткән, 1931нче елда Карагандага кайтып «стахановчылар хәрәкәте»н җәелдергән, яшь шахтерлар тәрбияләүгә күп көч куйган кеше, Социалистик Хезмәт Герое, 4 орден кавалеры. Ә иң әһәмиятлесе, ул – татар егете. Карагандада әле тагын бер асыл егетебез, гади шахтердан башлап, «Революциянең 50 еллыгы» исемендәге шахта директоры дәрәҗәсенә күтәрелгән, үзе җитәкләгән шахтаны СССРда тиңсез итә алган Хәмәт Халфин истәлегенә дә мемориаль такта куйганнар. Милләттәшләребез аларны «идол» итмәкче булдылар микән? Әнвәр әфәнде исә менә болай, гади генә аңлатты: «Атаклы егетләребез күп бит Карагандада, халык татарның кем икәнен белеп торсын», – диде. Әле кардәшләребез үзләре исән чакта бик күп изге эшләр башкарган. Бикмөхәммәтов фамилияле байлар нәселен дә мәңгеләштерү уе белән йөриләр. Казакъстанның Җаек шәһәре урамнарын Тукай рәсемнәре бизәгән бер вакытта, татар башкаласы исәпләнгән Казанда аның бер рәсеме дә булмавы һәм бөек шәхесләребезне «идоллаштырудан» курку галәмәтләре минем өчен сәер, бик сәер тоела.



**Әнвәр Керебаев**

Карагандадагы кардәшләребез ничек җай бар – шулай итеп дигәндәй татар рухын яшәтергә омтылалар. Инде матур гадәткә кергән «Чәк-чәк бәйрәме», «Өчпочмак кичәсе» кебек бәйрәмнәр уздырып килү, бер уйлаганда вак әйбер тоелса да, аш-суга да оста булган татар барлыгын гел искә төшереп тора түгелме соң?

Ачуым бер килмәгәе, Әнвәр Керебаевның безгә – Тукай эзләре буйлап сәфәр чыгып, юл фаҗигасында имгәнгән «Тукай илчеләре»нә йөрәген ярырдай булып булышып йөрүе, татар яшьләренең бер алды-

бызга, бер артыбызга төшеп, дигәндәй: «Сезгә тагын нинди ярдәм кирәк, кая барыйк, нәрсә эшлик!» – дип йөрүләре дә Карагандадагы татар рухы, татар «куәте»нең бер чагылышы түгелмени?

*Рәхмәт сиңа, Әнвәр абый!*
*Рәхмәт сезгә, кардәшләребез!*

**Риман Гыйлемханов**

# Караганда яшьләре

*Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:*
*Аңламак, белмәк, тәрәккый (прогресс),*
*мәгърифәт, хикмәт белән*
*Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.*
*Г. Тукай, «Татар яшьләре», 1912 ел*

Шунысы кызык, хәер, кызыктырмы бу, кызганычтырмы, Караганданың татар яшьләре белән безне бәхетсезлек таныштырды.

«Юл газабы – гүр газабы» инде ул. Авариядән соң баштанниләр үткәнне язып, кадерле укучымны азаплыйсы килми. Югыйсә, машина белән 8 тапкыр әйләнүебезне акылым белән санап, соңыннан берүзем аякта булып, башкаларны аңга китерүем әле дә бер могҗиза шикелле. Әмма минем әлеге фаҗигадан соң Карагандада яшәүче татар яшьләренең тормышыбызга тәэсирен бәян итәсе килә. Язмамны шуңа «Караганда яшьләре» дип атауның бер хикмәте булыр. Яшьләр сүзе ике мәгънәне белдерә бит ул: берсе – яшь буын, икенчесе – күз яшьләре дигән сүз.

Роза Сәлимова, Рәшид Мифтахов, Рөстәм Хөсәенов белән без беренче тапкыр салкын кичтә, әнә шулай фаҗига булган урында, далада таныштык.

Әйтергә кирәк, безнең белән бер чама яшьтә булсалар да, кулларына килеп эләккәч, без аларның чын «сабыйларына» әйләндек. Батыр йөзләрен кат-кат искә төшерәм дә шаккатам: безне авариядән соң тәрбияләргә, хәл итеп булмастай мәсьәләләрне чишәргә, кыскасы, рухи яктан «ашыгыч ярдәм» күрсәтергә яшь башлары белән каян шулкадәр көч, сабырлык таптылар икән?! Әлбәттә, алар урынында нәрсәгә сәләтле булуыбызны әйтә алмыйм. Әмма кулдан килгәнчә



ярдәм күрсәткән Әнвәр абый Керебаевка, Роза Сәлимова, Рәшид Мифтахов, Рөстәм һәм Розалия Хөсәеновлар, Ринат Ибраһимов, Владимир Ибраевларга без гомер буе рәхмәтле. Гомер буе дим, чөнки әлеге олы йөрәкле кардәшләр безгә шушы гомерне саклап калуда ярдәм итештеләр.

Танышу – ул язмыш бүләге. Кешеләрне язмыш юкка очраштырмый. Димәк, алда әле кисешәсе юллар, майтарасы эшләр булачак. Һәрхәлдә, кем ничектер, әмма «танышу» дигән сүзнең асылын мин шулай күрәм. Караганда яшьләре белән танышу – анысы нинди бүләктер. Шулай да алар – безнең, без – аларның тормышына ниндидер яңалык өсти алдык шикелле. Әйтик, «алар – безгә» дигәннән, Караганда яшьләре без уйламаганча тәвәккәл булып чыкты. Машина белән эвакуаторны Татар үзәгенең аксакалларына да әйтмичә үзләре табып китергәннәр. «Без бит татарлар! Авырмы, җиңелме – ярдәмләшүдән курыкмыйбыз», – диде Рәшид авариядән соң коелып төшкән йөзебезне күргәч.

Караганданың «Ихлас» татар-башкорт үзәгендә яшьләрнең әйдәп баручысы гына түгел, тормышта да лидер икән Рәшид. Аралашкан саен егетнең үз тамырларына тартылуын, милләте белән горурлана белүен сиздек. «Татар телен белми торып татар булып буламы?» дигән темага



**Роза Сәлимова, Розалия Хөсәенова, Риман Гыйлемханов**

еш бәхәсләштек, белеме буенча программист белән. «Әлбәттә, рус теленнән башка яшәп булмый бүген. Тик син татар һәм татар булып калырга телисең икән – ничек тә туган телеңне аз-маз чамаларга тиешсең. Мин камил сөйләшә белмим, әмма башкалар сөйләшкәндә аңлыйм. Минемчә, татар телендә сөйләшә белү безгә өч зур мөмкинлек бирә. Беренчесе – кардәшләр белән аралаша алу. Кытай, Австралия, Америка илләрендә яшәүче татарлар рус телен белмичә татарча сөйләшә. Дөнья буйлап сибелсәк тә, безне иң элек шул тел берләштерә! Икенчедән, Казанга баргач, «Татарча беләм», – дип, күкрәк киереп йөрү. Бабайлар җирендә басып тору ләззәтен аңламыйсыз шул, нәрсә ул сезгә Казан?! Без генә ул, «Казан» сүзен ишетүгә, бөтен тәнебез чымырдап, тетрәнә башлыйбыз. Күз алдына Кол Шәриф мәчете, Сөембикә манарасы, Тукай мәйданы килеп баса. Өченчедән исә, татар теле – ул буыннан буынга тапшырылган мирас та. Бер тел икенчесен алмаштыра алмый. Тукайның да һәр шигырендә нинди милли рух! Ә аны хәтта иң купшы сүзләр белән дә башка бер телгә дә тәрҗемә итеп булмый. Габдулла Тукай дигәннән, без ел да аның туган көнен шигъри кичәләр оештырып бәйрәм итәбез. Әмма Тукай рухын Риман Гыйлемхановны күргәнчегә кадәр тойганыбыз булмады. Ул Тукайның туганы да, шагыйрьнең аерым фондын оештыручы буларак та соклану уятты бездә. Сез бөтен мәшәкатьләрне читкә куеп, Тукайны өйрәнергә үз машинагыз белән чыккансыз. Тукай сезне Казакъстаннан алып Кытайга кадәр илткән. Менә кем ул татар улы Тукай – милләтләрне, халыкларны берләштерүче шәхес. Без Казакъстанда яшәп, Тукайның Җаек тормышын өйрәнә алмый ятканбыз. Сезнең өчен бернинди чик тә, юл газаплары да юк. «Тукай фонды»ның татар эзләре буйлап сәфәрләре туктамасын иде. Сез бит күпме татарны уятып, күпме кешегә милли рух күтәренкелеге өләштегез. Хәзер Габдулла Тукай дигәндә, күз алдына иң элек «Тукай фонды» һәм сез – Тукай илчеләре килеп басачак», – дип сөйләде Рәшид.

Әлбәттә, мондыйрак фикер-кичерешләрне безгә бер Рәшид кенә җиткермәде. Мактану түгел, әмма экспедиция дәвамында татарлар, шул исәптән Тукайны хөрмәт итүче башка төрки халыклар авызыннан да «рәхмәт»ләр күп ишеттек без. «Тукай-тур» сәфәре – Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан алар өчен дә зур бер вакыйга иде.

Бер көнне Карагандада без яши торган фатирга абыйлы-сеңелле Розалия һәм Рөстәм Хөсәеновлар килеп керде. Кулларына олы гына тартма тотканнар. «Фатирыгызда салкын икәнне Рафис Рәисовичка сөйләгән идек. Ул сезгә җылыткыч җибәрде», – диде чая Розалия. Рөстәм тартмадан тиз генә җылыткычны алып, электрга тоташтырып

та куйды. Көзге салкыннан суынып беткән бүлмәләр җылынып, йөзләребез алсуланды. Әллә нишләп, күңелләр дә тулып китте шул чакта. Җылы өйләрдә, әти-әни янәшәсендә утырган кичләр искә төште. Йөрәкне сагыну хисләре басты…

«Рафис дигәнегез кем соң?», – дим Розалиягә. Ул: «Рафис Вәлиев – «Абзал» сәүдә үзәге директоры. Җиһазлар сату белән шөгыльләнә. Әлеге җылыткычны «Тукай фонды»на бүләк итте», – диде. Күрәсең, хәлебезнең мөшкел икәнен яшьләр аңа шулкадәр итеп сөйләгән, хәтта күреп тә белмәгән Рафис Рәисович безгә бүләкләр юллый башлады. Кызганычка каршы, бу мәрхәмәтле кеше белән без очрашалмый калдык. Әмма аның җылы сәламнәрен ишетеп, җылыткычына Казанга кайтканчы рәхәтләндек. Рәхмәт яусын Рафис әфәнденең үзенә!

Фатир эче җылына төшкәч, юган керләребез дә тизрәк кибә башлады. Кер дигәннән, авария вакытында барлык сумка-чемоданнарыбыз умырылып, туганнарга дип җыйган бүләк-күчтәнәч, өс-киемнәребез шунда чәчелеп, аларны җир өстеннән ком белән бергә җыйган идек. Шул чүпрәк-чапракны фатирның юыну бүлмәсендә Альбина белән икәү көн дә тазартабыз. Киптерү өчен фатир буйлап кер бауы суздык. Кентау туганнар авылга кайткач күчтәнәчкә өләшерсең дип, 4 банка өрек җимеше вареньесы җибәргәннәр иде. Авариядә шуларның берсе дә ватылмаган. Казанга төшкәч карасам, чемоданнардан – варенье ага! Аэропортта бәреп-сугып, өчесен чәлпәрәмә китергәннәр тегеләрнең. Шулай итеп, соңыннан теге киемнәрне комнан түгел, ә вареньедан тагын юарга туры килде…

Розалия белән Рөстәмнең исә тамырлары – Башкортстан һәм Мамадыш районыннан. Розалия – журналист, Рөстәм – программист. «Шулкадәр туган җанлы сез. Абыйлы-апалы буларак та сокландырасыз», – дип берсендә комплимент ясадым Рөстәмгә. Сер бирмәде егет: «Әйе, безнең нәселдән килә ул. Татар телен, гореф-гадәтләрен дә гаиләдә күреп-өйрәнеп үстек. Рәшид белән дә туганнар без. Дуслар, туган-тумача, әти-әниләр – барыбыз да татар үзәгенә берьюлы, 1994 нче елдан йөри башладык. Дөресен генә әйткәндә, телне мин бию аркылы өйрәндем. Татарча бию көе ишеткәч, аякларым үзеннән-үзе тыпырдый башлый», – дип сөйләде ул.

Әйтергә кирәк, «Ихлас» татар үзәге урнашкан бинада барлык мөмкинлекләр тудырылган. Монда без үзәк тарихын сөйләүче фотокүргәзмә, бай китапханә, көзгеләр белән бизәлгән бию залына… һәм инде сагындырып өлгергән баянга да юлыктык. Кичләрен Риман абый шул баянда «Зәңгәр күлмәк», «Сагыну» җырларын суза иде.

Ә яшьләр ничек тә күңелебезне юатырга, кәефебезне күтәрергә тырыштылар.

Караганда телевидениесенең «5 канал»ында Рушан Касыйм улы Бараев дигән татар егете баш мөхәррир икән. Розалия безне аның белән дә элемтәгә кертте. «Ничек инде Караганда шәһәре Тукай туганы килүе белән горурланмаска тиеш?!», – дип, ул иң элек Рушан әфәндегә «Тукай фонды» турында барып шактый мәгълүмат сөйләп кайткан. Без бу турыда фатирыбызга «5 канал» корреспонденты Вера Сидорова шалтыраткач белдек. Сәфәребез турында ике телдә (казакъ һәм рус) тапшыру эшләмәкчеләр икән. Риман абыйны киендереп, яраларын бераз төзәтеп җибәрдек тапшыруга. Бик канатланып кайтты ул аннан. Кичен хәбәрләр тапшыруыннан Риман абыйны инде телевизордан карап утырдык. Берзаман аксак-туксак йөрүебезгә карамастан, телевизордан күрепме, Риман абыйны кибетләрдә, сырхауханәдә, урамнарда таный башладылар…

Инде Роза Сәлимова турында да аерып әйтәсем килә. «Мин дә бервакыт авариягә эләгеп, җилкә сөяген сындырдым. Йөзем җәрәхәтләнеп беткән иде, дуслар чак таныды. Вакыт белән яралар төзәлә. Бер сынау инде бу. Сабыр булыгыз», – дигән иде ул һәлакәт булган урынга килгәч. Нишләтәсең, кардәшләрнең бер мөнәсәбәте дә истән чыкмый, һаман хәтердә. Ә Роза белән тиз дуслашып киттек без. Аның күңелен ярып бирергә әзер торган кыз икәнен Риман абый да тиз чамалап алды. Розаның бездән ерак яшәмәве бик зур бәхет булды. Фатирга урнашкан беренче төннән үк ул безгә ризык ташыды. Төн уртасында пылау, чәй эчәргә тәм-том күтәреп керер иде. Югыйсә, кем инде без аңа? «Кардәш, милләттәш халыклар – туганнар», – дия иде Роза бу сүзләремә. Без Казанга кайтып киткәч тә, борчылып, телефоннан смс аша хәбәргә керде ул: «Самолеттан исән-имин төштегезме?». Әле аннан соң да интернет аша сәламәтлекләрне сорап, бәйрәм саен котлау хатлары юллап торды. Бүген дә Караганда яшьләре белән телефон, интернет аша хәбәрләшеп торабыз. Аллаһка шөкер, хәлләребез дә, сәламәтлегебез дә уңай хәзер.

Карагандада без 10 көн тордык. 10 көнгә яшьләрнең хәлебезне килеп белмәгән бер көнен, Әнвәр абыйның бер тапкыр булса да шалтыратмый калуын хәтерләмим мин. Киресенчә, Әнвәр абый кайвакыт сәгать саен шалтыратып «теңкәгә тия», ә кичкә берәр йомыш табып килеп җитә иде. Көннәр тагын да салкынайткач, «Нигә безгә бу йонлач кофталар, җылы якка барабыз бит!», – дия-дия өйдә калдырган җылы киемнәребез искә төште. Фатир эчендә туңмыйбыз хәзер, теге җылыткыч бәгырьләрне дә җылыта. Әмма Рәмиләбез

туңып ятадыр дигән уйлар килә башка. Әнвәр абый шулай чираттагы килүендә: «Башка болай өшеп йөри алмыйсыз. Мин сезгә кызларымның киемнәрен алып килдем. Менә бу куртканы күптән түгел сатып алды ул, әле бер дә кимәде. Сезгә бүләк итәргә кушты. Чалбарлар, свитерлар – бөтенегезгә җитә. Риман Солтановичка үземә дип алган киемнәрне китердем», – дип сөендерде!

Укучым, милләттәшләребезнең ни дәрәҗәдә мәрхәмәтле, миһербанлы булулары турында нәтиҗәләрне үзең ясарсың. Тик кабаттан рәхмәт әйтми булдыра алмыйбыз. Һәр җылы сүзегезгә, һәр кылган гамәлегезгә зур саваплар язылсын, кадерле кардәшләребез! Без сезне беркайчан да онытмабыз!

**Гөлназ Галимҗанова**

# И, Казан, дәртле Казан!

Шатлыклы да, борчулы да булган маҗаралы сәфәребез ахырында без дә, Тукай кебек, Казанга ашкындык. Хәтирәләрне тизрәк кәгазьгә төшерәсе, китап итеп халыкка җиткерәсе килде.

Ниһаять, 10 көн дигәндә, табиблар Рәмиләне Казанга озатырга мөкин дигән куанычлы хәбәр җиткерделәр. Тик куанырга иртәрәк иде әле. Тоткарлану сәбәпле безнең акча бетте. 4 кешегә самолетка гына да 28-30 мең сум акча кирәк иде. Шуның өстенә Рәмилә яткан носилканы гадәти рейс ясаучы самолетка куярга тагын 6 урын өчен түләргә, ягъни, 3 креслоны сүттерергә туры килде. Шулай итеп кайту 70 мең сумга тартты. Баштарак Татарстанның Казакъстандагы вәкиллеге белән уртак тел таба алмадык. Тукай хәтле Тукай хакына изге сәфәргә чыксак та, без рәсми органнардан хат-рөхсәт алырга тиеш булганбыз икән. Әлбәттә, вәкиллек кешеләренең «Сезне без чакырмадык», – сыман җавап бирүләре, рәсми яктан дөрес иде, чөнки бюджет акчасының һәр тиене өчен документ кирәк. Аптырагач депутатыбыз Разил Вәлиевкә шалтыраттык. Башта ул: «Ничек ярдәм итә алмыйлар инде?», – дип аптырады, аннан соң: «Сөйләшкәч, үзем шалтыратырмын», – диде.

Минем Казакъстанда әле яшь вакытымнан ук аралашкан кешем – Илдус Тарханов бар иде үзе. Әле сәфәргә чыгар алдыннан ук телефон аша очрашасы килү теләгемне әйткәч, ул: «Мин хәзер Русия консуллыгында, милли-мәдәни мәсьәләләр белән шөгыльләнмим», – дип җавап бирде. Разил Вәлиев шалтыраткач та, үзенең Россия консуллыгында эшләвен кабатлаган. Әмма Разил Исмәгыйль улы:

«Татарстан Русия составыннан чыкканмы әллә, ничектер ишетми калдым. Үзебезнең татар егетләре-кызлары бит инде, булышырга кирәк», – дигәч, вәкиллек белән элемтәгә кереп барысын да җайлады Илдус әфәнде, рәхмәт аңа. Татарстанның Казакъстандагы вәкиле урынбасары Рафаэль Аблаков, Казакъстан Халыклары Ассамблеясы әгъзасы Тәүфыйк Кәримовка рәхмәт: «Ашыгыч ярдәм» машинасы белән самолет трапына кадәр диярлек илтеп куеп, дустанә теләкләр белән озатып калдылар.

Кызык инде бу дөнья!.. Кайчак шуны уйлап куям: Тукай кемгә кирәк соң? Сәфәр вакытында йөзләгән татар белән очраштык. Аларга безнең Казаннан, «Тукай фонды»ннан булуыбыз бик җитте. Тыйнаксызлыгым өчен гафу үтенәм: Тукайның туганы икәнемне дә белгәч, күтәреп кенә йөртмәделәр. Бер генә мисал китерим әле. Машинам бөтенләй яраксыз хәлгә әйләнгәч, аны Карагандада түләүле стоянкага куйганнар иде. Костанайда яңа танышкан кардәшләремнең берсе Ренат Биктимеров Казанга кайткач та минем белән гел хәбәрләшеп торды. Беркөнне: «Машинаңны Костанайга алып кайтабыз», – диде. Әлеге шәһәрнең татарлары махсус фонд оештырып, акча җыеп, Карагандадагы стоянкада 4 ай торган өчен акчасын түләп, эвакуатор яллап машинаны Костанайга алып кайтканнар. «Бер танышыма куйдырдым», – дип шалтыратты Ренат. Шаккатам, валлаһи, мин аларга кем инде?! «Сезгә мәшәкать өстәдем…» – дип акланып маташа башлагач, кырт итеп сүземне бүлде: «Без – татарлар бит, бер-беребезгә булышып яшәргә тиеш», – диде.

Шулай итеп, «дәртле, нурлы» Казаныбызга кайттык. Юл фаҗигасе турында ишеткәч, берәүләр: «Шундый озын юлга машина белән чыкмаска иде», – дип күңелне «юатсалар», иң якын кешеләр: «Ярый исән калгансыз, изге эш белән йөргәнгә Аллаһы Тәгалә сезне саклаган», – диделәр.

Бу китап озак язылды. Беренчедән, тән җәрәхәтләре айлар буенча сызлады һәм кайберләребез вакытлыча эшкә яраксызга әйләнде. Рәмилә белән Альбина урын өстендә ятса, Гөлназ белән минем күңелне төшенкелек биләгән чаклар ешайды. Әмма, без җиңдек! Алай гына да түгел, Тукай эзләре буйлап яңа сәфәрләргә чыгу турында хыялланып, барасы юлларыбызны тәгаенләп куйдык. Халык күңелендә Тукайны барларга алынганбыз икән – артка чигү юк, Аллаһ бирсә. Матур, изге хыяллар безгә канат куя. Ә сәяхәт – ул, чыннан да, хыялдан башлана…

**Риман Гыйлемханов**

# Эчтәлек

Сүз башы һәм юл башы . . . . . 5
Юл хәстәрләре . . . . . . . . . . . 7
Сәяхәт… акчадан башлана. . 8
Китмибез! . . . . . . . . . . . . . 9

**КАЗАКЪСТАН . . . . . . . . . . . . .14**
Исәнме, Җаек! . . . . . . . . . . .16
Әз-мәз тарих . . . . . . . . . . .16
Гугниха – Гайшә?! . . . . . . . .18
Нугай бистәсе . . . . . . . . . .20
Татар үзәге . . . . . . . . . . . .22
Безне Тукай күтәрә . . . . . . . .24
Татар яшьләре . . . . . . . . . . .26
«Империя» татарча җырлый .27
Президент килә! . . . . . . . . . .28
Тукай ни өчен ләгънәт укып киткән? . . . . . . . . . . .32
«Интеллигент татар» һәм «Шияпка». . . . . . . . . . .38
тукай рухы тагын кайларда саклана?. . . . . . . . .40
Хан урманы . . . . . . . . . . .40
Кызыл мәчет . . . . . . . . . . .41
Мотыйгыя мәдрәсәсе . . . .42
Тукай көшеси . . . . . . . . . .44
Тукай музее . . . . . . . . . . .46
Рус мәктәбе . . . . . . . . . . .51
«Иске Уральски» . . . . . . . .55
Тукай иле . . . . . . . . . . . .58
«Казан» кунакханәсе . . . . . . .60
Җаек басмаханәләре . . . . .61
Нәҗип Җиһанов . . . . . . . . . .64
«Мин Тукайны беләм!». . . . .65
Меценатлар . . . . . . . . . . . .67
Шәйхулла Шәрифулла улы Нотфуллин. . . . . . . . . .67
Ришат Увәли улы Хәйруллин.68
Без җаекка рәхмәтле. . . . . .70
Тукай һәм аның остазы . . . . .75
Остазның туган ягында. . . . . .82
«Таблетка» . . . . . . . . . . . .83
Әгәр Тукай булмаса. . . . . . .84
Туганнарны эзләп . . . . . . . . .86
Суфия апа . . . . . . . . . . . .90
Шәһәр белән танышу. . . . . . .94
Безнең дә күңел кузгалды . .95
Уртак йортта . . . . . . . . . .96
«Татар телең нәрсәгә?» – дисәләр. . . . . . . . . . . . . . .98
Астана юлында – Африка кызы?! . . . . . . . . . .102
Еракка китеп кара син, еракка китеп кара!. . . . . . . .104
Затлы татарыбыз . . . . . . . . .110
Без, без, без инде – җепкә тезелгән инде . . . . . .115
Торсынтай Габитов . . . . . .118
Әюповлар . . . . . . . . . . . .115
Сабантуйда . . . . . . . . . . .120
Габитовлар гаиләсе . . . . . . .122
Таулар моңы. . . . . . . . . . . .125
Тукай пигы. . . . . . . . . . . .126
«Күк Төбе» . . . . . . . . . . . .126
Медео. . . . . . . . . . . . . . . .130
Казыгурт . . . . . . . . . . . . .131
Хромтау . . . . . . . . . . . . .134
Нәрсә ул тау? . . . . . . . . . .135
Татар эзләре. . . . . . . . . . . .137
Латыйф Хәмиди . . . . . . . .140
Алматыдагы зыялыларыбыз . 142
Татар абруе . . . . . . . . . . .142
Кәрим бай оныклары . . . . . .144
Кәрим бай оныклары. . . . .144
Кем ул Кәрим бай? . . . . . .144

«И, Тукай!»ны көйләп… . . . . . 147
Без – Кытайдан! . . . . . . . . . . . 153
Татар китаплары . . . . . . . . . 154
«Анда Тукай дәвере, татар әдәби теленең тәэсире көчле иде» . . . . . . . . . . . . 160
Тарихчы Хәйруллин. . . . . . . 163
«Бәхтияр ул – чиксез дала» . . 167
Ак күпер серләре . . . . . . . . 171
Тукай идеясе яшәгән илләрдә . . . . . . . . . 174
Атакент . . . . . . . . . . . . . . . 184
Горур дөяләр . . . . . . . . . . .185
Туган якны ташлап китмәгез! . . . . . . .188
«Ак алтын ватаны» . . . . . .189
Зәңгәр тауларны эзләп . . . . 191
Бөек ефәк юлы . . . . . . . . . . 199
Төркиләр мәккәсе . . . . . . . . 203
Алматыга кайту . . . . . . . . . . 208

**НИ ХАО, КЫТАЙ! . . . . . . . . . . 209**
«Сират күпере». . . . . . . . . .212
Шәркый Төркестан җирендә . . . . . . . . . . . . .216
Хоргоста беренче чәчәкләр! . . . . . . . . . . . . . 218
Өремче – Гиннес китабында! . . . . . . . . . . . . . 223
Ике көнлек Хуалин . . . . . .230
Татар учагы . . . . . . . . . . .232
Мәгърифәт сагында. . . . . . . 236
«Татар теле – әнием кебек».238
Тукай белән Шаһиди таныш булганнармы? . . . . . . . . . . . 242
Малик хыялы . . . . . . . . . . 244
Шенҗан уйгырлары. . . . . . . 248
«Тукай – дөньяга күзләребезне ачкан шагыйрь» . . . . . . . . . 253
Әй, Чүгүчәк, Чүгүчәк! . . . . . . 256
Тирән тамырлар . . . . . . . . . 264
Безнең көннәр . . . . . . . . . .267
Кәримовлар. . . . . . . . . . . .272
Җырлы гаилә . . . . . . . . . . . 273
«Бөтен татарның күңелендәге адәм» . . . . . . . 276
Чанышевлар йорты . . . . . . . 278
Чүгүчәк прокуратурасы . . . . 280
Кытай безне үзгәртте – оялмаска өйрәтте . . . . . . . . 284
Татар Голҗасы . . . . . . . . . . 287
Голҗа Каберстаны . . . . . .288
Нугай каласы . . . . . . . . . .292
«Татар башың белән куркасыңмы?». . . . . . . . . . . 294
Татар мәктәбе. . . . . . . . . . . 298
Остазларга ихтирам. . . . . . . 304
Татар күгендәге сүнмәс йолдыз . . . . . . . . . . 309
Ильяр абый мәктәбе . . . . . . 313
Габитовлар эзеннән. . . . . . . 315
Милли моңнар яңгырый әле . 321
Торсынтай кәнетендә . . . . . 326
Әйдәгез, вальс биергә!. . . . . 330
Голҗа базарлары . . . . . . . . 333
Ураза гаете. . . . . . . . . . . . . 336
«Милли тәрбия бишектән башлана». . . . . . . 339
Кытайдагы иң бәхетле гаилә . 344
Габдулла Тукай Кытайда яши . 347

**ХУШ, КЫТАЙ!. . . . . . . . . . . . 350**
Алматы белән саубуллашу . 350
Фаҗига . . . . . . . . . . . . . .350
Караганда . . . . . . . . . . . .354
Әнвәр абый . . . . . . . . . . .355
Караганда яшьләре . . . . . . . 358
Дәвамы бар «И, Казан, дәртле Казан!). . . . 364




# ИСТӘ КАЛГАННАР.

Сәяхәтнамә

**Мөхәррир:**
Рөстәм Зәкуан, «Таттелеком» милли элемтә компаниясенең матбугат идарәсе җитәкчесе

**Авторлар:**
Риман Гыйлемханов,
Гөлназ Галимҗанова,
Рәмилә Газизуллина,
Альбина Газизуллина

**Фото:**
Риман Гыйлемханов,
Гөлназ Галимҗанова,
Рәмилә Газизуллина,
Альбина Газизуллина

**Предпечатная подготовка:**
Издательский дом Маковского
makovski.ru

**Дизайн, вёрстка:**
Олег Маковский,
Эдуард Ахмадеев

**Препресс:**
Сергей Рухов

Подписано в печать 5.04.2016
Формат: 60х90/16. 23 п.л.
Печать офсетная. Гарнитура Myriad.
Тираж 1000 экз. Заказ №М-872.

Отпечатано в филиале ОАО «ТАТМЕДИА»
«ПИК «Идел-Пресс»
420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2

9 785904 612412